УКУЧЫ ҺӘМ УКЫТУЧЫ

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ

Тәрҗемәи хәле • Истәлекләр
Әсәрләр • Анализ үрнәкләре
Дәрес эшкәртмәләре

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УКУЧЫ ҺӘМ УКЫТУЧЫ

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ

Тәрҗемәи хәле • Истәлекләр
Әсәрләр • Анализ үрнәкләре
Дәрес эшкәртмәләре

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2014

УДК (07)821.512.145.0:821.512.145-2
ББК 83.3(2Рос=Тат):84(2Рос=Тат)-6
Г18

«Укучы һәм укытучы» сериясе 2011 елдан нәшер ителә.

Фәнни җитәкчесе
Дания Заһидуллина, филология фәннәре докторы, профессор

Проект авторы һәм төзүчесе
Талия Шакирова

Галиәсгар Камал : тәрҗемәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре,
Г18 дәрес эшкәртмәләре / [фәнни җит. Д. Ф. Заһидуллина ; проект авт. һәм төз. Т. Р. Шакирова]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2014. – 223 б. : рәс. б-н. – («Укучы һәм укытучы» сериясе).
ISBN 978-5-298-02805-9

Китапта татар әдәбияты классигы Галиәсгар Камалның мәктәп программаларына кертелгән әсәрләре тупланды. Аерым бүлекләрдә әсәрләргә анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре, драматург иҗатының үзенчәлекләрен чагылдырган мәкаләләр, туганнары һәм замандашларының истәлекләре бирелде.

Әлеге басма мәктәп укучыларына, укытучыларга тәкъдим ителә. Гомумән, татар әдәбияты белән кызыксынган һәр кеше җыентыктан файдалы мәгълүмат алыр.

УДК (07)821.512.145.0:821.512.145-2
ББК 83.3(2Рос=Тат):84(2Рос=Тат)-6

ISBN 978-5-298-02805-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2014
© Шакирова Т. Р., төзү, 2014

Мин сөямен халыкны, халыкны,
Хезмәт итәм ялыкмый, ялыкмый.

Мин сөямен ирекне, ирекне,
Хезмәт итәм ирекми, ирекми...

Галиәсгар Камал

***Галиәсгар Камал** — татар театрының нигез ташларын салучы, классик комедияләр тудыручы. Ул артист һәм режиссёр да, декламатор һәм гримёр да, дистәләрчә профессиональ артистлар әзерләүче дә. Г. Камал каллиграфистлык һәм рәссамчылык осталыгын да шушы эштән башлады: театрның афишаларын үз кулы белән язды.*

Гази Кашшаф

ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ[1]

Галиәкбәр Камалетдинов (1849—1921) Казан губернасының Мамадыш өязендә урнашкан (хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы) Сикертән авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Гаиләдә балалар күп булганга күрә, әти-әниләренә аларны укыту түгел, туендыру да кыенга килә. 12 яшьлек Галиәкбәрне әтисе Камалетдин, Казанга килеп, Кушлавыч Мифти дигән байга (Мифтахетдин Вәлишин) асрамага бирә. Бу кешедә тамак ялына дүрт ел хезмәт иткәннән соң, Мифти бай Галиәкбәрне Фәтхулла Мамаев исемле сәүдәгәргә тапшыра. Фәтхулла бай бүрек, тун сату эшләре белән шөгыльләнә. Галиәкбәр тиз арада оста мехчы булып китә. Фәтхулла байның мондый уңган хезмәтчене ераккa җибәрәсе килми, һәм ул энесе Хәбибулла Мамаевның кызы Мәүгыйзәне Галиәкбәргә димли. 25 яшендә Галиәкбәр Мәүгыйзәгә өйләнә. Ул гомер буе, һөнәренә тугры калып, үз тырышлыгы белән көн күрә, Казанда яши.

Галиәсгар Камал 1879 елның 6 гыйнварында (иске стиль белән 1878 елның 25 декабрендә) Казан шәһәрендә тире эшкәртүче мехчы гаиләсендә туа.

Аның әтисе *Галиәкбәр Камалетдинов* аз сүзле, кырыс холыклы һәм бик тырыш кеше була. Ул иртә таңнан караңгы төнгә кадәр эшли: бүрек, яка, тун тегәр өчен, кеш, төлке,

Галиәсгарнең әтисе Галиәкбәр
(Б. Альменов рәсеме)

Галиәсгарнең әнисе Мәүгыйзә

[1]Тәрҗемәи хәле, истәлекләр, рецензияләр, аңлатмалар, искәрмәләр «Галиәсгар Камал турында истәлекләр / төз. Р. Даутов. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1979»; «Камал Г. Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. — 3 т. : хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр / текст, иск. һәм аңл. әзерл. З. Рәмиев, Н. Ханзафаров, Ф. Ибраһимова, Ә. Алиева, М. Хәбибуллин» китапларыннан алынды, берәз үзгәртеп һәм кыскартып бирелде.

Аркылы Тихвинский урамының гомуми күренеше

каракүл тиреләрен күз явын алырлык итеп эшкәртә, оста мехчы (скорняк) була.

Әнисе *Мәүгыйзә* тыныч табигатьле, сабыр, укымышлы, уңган хатын була. Өйдә йорт эшләрен алып бару белән бергә Галиәкбәрнең эшенә дә булыша: кулыннан уймак, энә, балавызлаган җеп төшми.

Галиәкбәр агай башта Галиәсгаргә атасы Камалетдин исеменә охшатып, Җамалетдин дип исем кушарга тели, аннары ул уеннан кире кайта һәм бабасы Җомагыл исемен хәтерләткән исем эзләргә керешә. Анысы да барып чыкмый. Шуннан ул үз исеменә бәйле исемнәргә туктала. *Галиәкбәр* гарәп теленнән — *олы Гали*, ә *Галиәсгар кече Гали* дип тәрҗемә ителә. Димәк, Галиәсгар «дәү Әкбәрнең нәни Әсгаре» булып чыга. Шулай итеп, Галиәкбәр агай улына Галиәсгар исемен бирә.

Бу елларда Камалетдиновлар гаиләсе *Аркылы Тихвинский урамында* урнашкан

Мәүгыйзә (1844—1936) Казан губернасы Мамадыш өязенең (хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы) Түбән Масра авылында волость старшинасы Хәбибулла Мамаев гаиләсендә туа. Кызлар арасында үсә, хезмәткә кечкенәдән өйрәнә. Китаплар укый. Камчатчы Галиәкбәргә кияүгә чыккач, Казанда әлегә юньле фатир булмаганлыктан, Мәүгыйзә дүрт ел иренең туган авылы Сикертәндә авыру каенатасын, өйдәге бала-чаганы тәрбияли. Эше күп булганга, Галиәкбәр авылга елына бер генә тапкыр кайта ала. Ниһаять, 1878 елда Галиәкбәр сөекле Мәүгыйзәсен Казанга алдыра, һәм алар бергә яши башлыйлар: икесе кара-каршы утырып, көнтөн камчат, кама бүрекләр, туннар тегәләр, балаларын үстерәләр.

Аркылы Тихвинский урамына революциядән соң — Фукс, ә 1939 елдан Галиәсгар Камал исеме бирелә.

Галиәсгар Камал туган йорт.
Сувор Хәйрулла йорты

Сувор Хәйрулла йортының өченче катында өч тәрәзәле фатирда яши. Салкын, дымлы һавалы әлеге фатирда сау-сәламәт бала үстерү мөмкин булмый. Галиәкбәр агай, «таш чарлак»тан котылырга теләп, *Мәҗар Фазлый* дигән кешенең йортына күчәргә ният итә. Фатир әзер булмаганлыктан, Фазлулла бай Галиәкбәр гаиләсен зур өйнең бер почмагындагы ян бүлмәгә урнаштырып тора. Күп тә үтми, фатир эшләнеп бетә. Буяу исе килеп торуга карамастан, алар шунда күченә. Яңа «оя» коры, иркен һәм якты була.

Галиәсгарнең әти-әнисе көн-төн эшли. Киләсе көзгә *Мәкәрҗә ярминкәсенә* алып

Мәҗар Фазлый йорты

Сувор Хәйрулла йорты – Г. Камал урамындагы 29 нчы номерлы йорт (хәзер сүтелгән). Элек бу тирәдә ун-унбиш фатирлы йортлар була, аларда кустарьлар, ямщиклар, көнлекчеләр яши. Әлеге йортлар Ташаяк Исмәгыйль, мичче Гатаулла, Сая Ибрай дворы, Шакир солдат пулаты кебек исемнәр белән атап йөртелә.

Мәҗар Фазлый йорты – Г. Тукай урамындагы 5 нче номерлы йорт (хәзер сүтелгән).

Мәкәрҗә ярминкәсе – Россиядәге иң атаклы ярминкә. Ул XVI гасыр урталарында Идел буендагы Макарьево бистәсендә барлыкка килә. 1819 елда Түбән Новгород шәһәре янындагы үзәнлеккә күчерелә. Ярминкә һәр елны июль-август айларында уздырыла торган була. Анда бөтен Россия шәһәрләреннән һәм чит илләрдән сәүдәгәрләр җыела һәм сату итә. Мәкәрҗә ярминкәсе 1929 елга кадәр эшли.

барыласы товарларны алар кыш башыннан ук әзерлиләр. Бала карарга да вакытлары булмый. Шуңа күрә нәни Галиәсгар җәй көннәрен әнисенең туган авылы Масрада әбисе янында үткәрә. Саф һавалы табигать кочагында яшәгән Галиәсгарнең сәламәтлеге ныгый.

Галиәсгаргә биш яшь тулганда, Казандагы Сәлах хәзрәт мәдрәсәсендә укыган Исмәгыйль исемле пишкадәм Масрага мулла итеп куела. Галиәкбәр агай улының Исмәгыйль муллада сабак алуын тели, һәм Галиәсгар бер кыш Масрада укый. Әмма, кыш буе укып йөреп, бер хәреф тә танымавын күргәч, Галиәкбәр агай улын, Масрадан алдырып, Казанда укытырга карар кыла.



«Госмания» мәдрәсәсе

Галиәсгар Камалның 1893 еллар тирәсендә төшерелгән фоторәсеме

Галиәкбәр агай гаиләсе белән бер фатирдан икенчесенә күчеп йөргәнгә күрә, Галиәсгаргә дә Казандагы мәдрәсәләрне еш алмаштырырга туры килә. Ул башта *«Госмания»*, *«Халидия»*, Галләм хәзрәт мәдрәсәләрендә, соңрак Әҗем мәчете мәхәлләсе мәдрәсәсендә укый. Касыйм хәзрәттә дә, Казаковлар мәчете мәдрәсәсендә дә гыйлем ала. Кайсы гына мәдрәсәдә укымасын, шәриктәшләрен бик тиз куып җитеп, узып та китә һәм һәркайчан

«Госмания» — Казандагы «Кызыл мәчет» (Солтан мәчете, Җиһанша бай мәчете, Госман мәчете, Сигезенче җамигъ мәчет) мәхәлләсенең мәдрәсәсе. Мәчет 1868 елда сәүдәгәр Җиһанша Госманов иганәсенә төзелә.

«Халидия» — Казандагы «Зәңгәр мәчет» (Дүртенче җамигъ мәчет) мәхәлләсенең мәдрәсәсе. Мәчет 1815—1819 елларда сәүдәгәр Әхмәт Аитов иганәсенә төзелә. 1825 елда дин эшлеклесе Габденнасыйр Рахманколый мәдрәсә ача.

«афәрин», «тәхсин»[1] билгеләренә генә укый. Аның кульязмалары чигелгән нәкыш шикелле нәфис һәм пөхтә була. Озак та үтми, бу «гүзәл куллы» егетнең кульязмалары, дини мәдрәсә ишекләреннән чыгып, китап бастыручы нәширләр кулына килеп керә. Алар егеткә төрле сүрәләрне матур бизәкләр белән бизәп язып бирергә кушалар. Рәсми килешүләр төзеп, шәмаилнең мөхәррире кем булуын күрсәтеп, Галиәсгарнең эшләрен бастырып чыгара башлыйлар.

1893 елда Галиәсгар *«Мөхәммәдия»* мәдрәсәсенә укырга керә. Ул монда хөр фикерле шәкертләр белән таныша, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри әсәрләрен укый, мәдрәсәдә үткәрелгән җыелышларда, фикер алышуларда актив катнаша.

Бераздан Галиәсгар күңелендә русча уку дәрте кабына. Әтисе дә «адрес язарлык» күләмдә русча укуга каршы тормый. Галиәсгар рус теле укытучысы Миргаяз Иманаевның өчьеллык башлангыч рус мәктәбенә йөри башлый.

«Мөхәммәдия» — Казанда 1882 елда Галимҗан Баруди тарафыннан ачылган мәдрәсә. «Мөхәммәдия» исеме Барудиның әтисе Мөхәммәтҗанга бәйле рәвештә куела. 1889 елдан мәдрәсәгә җәдит ысулы кертелә. 1901—1907 елларда әдәбият һәм драма түгәрәкләре эшли, кульязма газеталар чыгарыла. Ул Казанның иң алдынгы мәдрәсәсе булып санала.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе

---

[1] *«Афәрин», «тәхсин»* — шул замандагы «яхшы», «бик яхшы» билгеләре.

Өчьеллык башлангыч рус мәктәбе

Г. Камал кышын укый, язын һәм җәен, Мөхәммәтгали Кадыйров дигән кешегә ялланып, Әстерхан, Буа ярминкәләренә бара, анда эшләп алган хезмәт хакын мәдрәсәдә уку өчен тота. Әтисе белән Мәкәрҗә ярминкәсенә товар сатарга да йөри. Г. Камал бу ярминкәләрдә гади халыкның тормышын, көнкүрешен, гадәт-йолаларын аермачык күрә. Шунда ук дус малайлары белән бергә ул балаганнарга керә, өйрәтелгән маймылларны, *һиндстан факирләрен*, биюләр, фокуслар карый.

Театр, «кәмит», күңел ачу уеннары Галиәсгарне нәкъ шушы вакытларда кызыксындыра башлый. Г. Камал бөтен күңелен театр эшенә бирә: театр әдәбиятын өйрәнә, төрек телендә әсәрләр укый. Якшәмбе көннәрендә Казан шәһәр театрында уйналган көндезге спектакльләрне карый, сәхнә әсәрләрен язу хыялы белән яна.

1898 елда 19 яшьлек Галиәсгар беренче әсәрен — «Бәхетсез егет»не яза. Укытучысы Миргаяз Иманаев киңәше белән әсәрне Петербург цензорына җибәргәч, Галиәсгар төрек язучысы Нәмыйк Кемалның «Зәваллы чуҗык»[1] драмасын «Кызганыч бала» исеме

Һиндстан факирләре — Һиндстаннан килеп, фокус күрсәтеп йөргән кешеләргә европалылар биргән исем. 1930 елларда Г. Камал эстрада өчен «Һиндстан факире» дигән сатирик әсәр дә яза.

[1] Төрек телендә — Namık Kemal «Zavallı çocuk» (Намык Кемал «Заваллы чожук»). – *мөхәр. иск.*

белән тәрҗемә итә. 1899 елда Петербургтан «Бәхетсез егет»не басарга мөмкин дигән рөхсәт килә, һәм 1900 елда *«Борадәран Кәримевләр»* ширкәте әсәрне бастыра. Беренче әсәренең басылуы Г. Камалның күңелен күтәрә. Ул «Өч бәдбәхет» дип аталган әсәрен яза һәм шул ук елда аны бастырып та чыгара.

1900 елда Г. Камал, хәрби хезмәткә алу комиссиясендә каралып, солдат хезмәтеннән азат ителә. Шул көннән башлап аны мулла итү мәсьәләсе күтәрелә. Г. Камал мәдрәсәдән чыга.

Галиәкбәр агай Галиәсгарне Сикертән авылына мулла итеп куйдыртырга тели. Әмма Галиәсгар моңа каршы чыга. Галиәкбәр агай һәм мех белән сәүдә итүче Садыйк Хәйбуллин егетне, бай кызына өйләндереп, Яңа бистә белән Иске бистә арасындагы иске зират өстенә салына башлаган мәчеткә имам, мөдәррис итеп куярга уйлыйлар.

Г. Камал Садыйк бай кызы *Бибигайшә Хәйбуллина* белән хат алыша башлый. Аңа кызның аңлы, ихлас күңелле булуы бик ошый. Алар өйләнешәләр. Ләкин Галиәсгар муллалыктан баш тарта. Аның бу эшеннән аптырап калган атасы белән каенатасы гаилә киңәше уздыралар: киңәшләшәләр, сөйләшәләр. Ахырда Галиәсгаргә китап кибете ачып бирергә, аны сәүдәгәр итәргә кирәк дигән карар чыгаралар.

«Борадәран Кәримевләр» типографиясе

«Борадәран Кәримевләр» — бертуган Мөхәммәтҗан, Хәсәнҗан, Шәрифҗан Кәримевләрнең 1895 елда оештырылган китап бастыру һәм китап сату ширкәте. Алар Казан, Уфа шәһәрләрендә кибетләр һәм типографияләр тота. Революциягә кадәр Казанда чыккан татарча китапларның яртысыннан күбесе Кәримевләр матбагасында басыла. 1919 елда әлеге матбага нигезендә Камил Якуб исемендәге дәүләт типографиясе төзелә.

Бибигайшә Хәйбуллина (?—1918) — Г. Камалның беренче хатыны. Г. Камал белән унсигез ел гомер кичерә һәм алты баланың (Әхмәт, Әминә, Фәһимә, Әнәс, Мөхәммәт, Зөфәр) әнисе була.

Галиәсгар Камалның 1902 елда төшерелгән фоторәсеме

Галиәсгар Камалның беренче хатыны Бибигайшә

«Китап кибете» турындагы карарны Г. Камал шатланып каршы ала һәм 1901 елда *«Мәгариф» исемле китап кибетен* ача. Галиәкбәр агай белән Садыйк бай бу кибет дин юлында хезмәт итәр, монда «Иман шарты», «Коръән тәфсире», «Сөбател-гаҗизин» сатылыр дип өметләнәләр. Әмма «Мәгариф» бөтенләй яңача эш итә. Анда шул заманның матур әдәбият китаплары, газета-журналлар, язу-канцелярия әйберләре сатыла башлый. Г. Камал, «Мәгариф» китапханәсен яңа әсәрләр белән баету өчен, Төркиягә китә. Ул Истанбулда төрек язучылары белән таныша, аралаша. Алдынгы карашлы язучыларның әсәрләрен җыйнап, Казанга «Мәгариф» китапханәсенә кайтара, аларны халыкка һәм шәкертләргә тарата.

Шул вакытларда ул Германиядән типография эшенә өйрәнеп кайткан *Мәхмүт Алмаев* дигән егет белән тыныша, һәм алар икәүләп *гектограф* ярдәмендә «Тәрәккъый» исемле газета чыгара башлыйлар. Бу газета «Мәгариф» аркылы яшерен рәвештә шәкертләргә таратыла.

Г. Камал китап сәүдәсе белән Мәкәрҗә ярминкәсенә дә бара, халык арасына керә, хөр фикерле кешеләр белән очраша, көннән-көн белемен арттырырга тырыша.

«Мәгариф» кибете 1901 елның 1 маенда ачыла. 1904 елның 12 апрелендә шул китап кибете нигезендә «Камалетдинов вә шөрякәсе» исемендә китап бастыру һәм китап сәүдәсе ширкәте оештырыла. Ширкәтнең җитәкчесе Г. Камал үзе булып, идарә составына, пай акчасы кертү шарты белән, тагын дүрт кеше сайлана. 1907 елның 22 июнендә ширкәтнең җитәкчесе итеп Мөхәммәтәмин Мостафинны сайлыйлар, ә шул ук елның ахырында ширкәт «Мәгариф көтепханәсе» дип атала башлый. «Мәгариф көтепханәсе» Казандагы иң зур һәм иң алдынгы нәшриятларның берсе була.

Мәхмүт Алмаев (1874—1907) — типограф, журналист һәм шагыйрь. Сембер губернасының Сайман авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, аннан Истанбулда укый. 1899 елларда Германиянең Лейпциг шәһәрендә полиграфия эшенә өйрәнә. Кайткач, Казанда Кәримевләр, ә 1905 елдан Оренбургта Кәримев-Хөсәеневләр ширкәте типографияләрендә техник җитәкче булып эшли. «Урал», «Вакыт» кебек газеталарда шигырьләре дә басыла.

Гектограф (грек. *hekaton* — «йөз», *grapho* — «язам») — кульязманы күпләп бастыру җайланмасы.

Габдулла Камал (Камал I) (1893–1933) – күренекле татар артисты, режиссёр, театр эшлеклесе. Ул 1910 елдан «Сәйяр» труппасында уйный башлый һәм режиссёрлык итә. 1920–1928 елларда Үзбәк театрында режиссёр була. Аннары Ашхабадта Төрекмән дәүләт театрын оештыруда катнаша һәм 1929–1931 елларда театрның баш режиссёры була. 1931 елда, авыру сәбәпле, Казанга кайта, Казан радиосында режиссёр булып эшли.

Сәетгәрәй Алкин (1867–1919) – юрист, либераль карашлы җәмәгать эшлеклесе. Шаһиәхмәт морза гаиләсендә туа. Казанда 1 нче гимназиядә, аннары Казан университетының хокук факультетында укый. Аны беренче дәрәҗә диплом белән тәмамлап, антлы дәгъва вәкиле хокукы ала. 1905–1908 елларда «Казан мөхбире» газетасының нәшире һәм рәсми мөхәррире була. Беренче Дәүләт Думасына депутат булып сайлана.

«Казан мөхбире» – 1905 елның 29 октябреннән 1911 елга кадәр чыккан либераль юнәлештәге буржуаз газета. Казанда татарча басылган газеталарның беренчесе.

Габдулла Апанаев (1862–1919) – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, нәшир, педагог. 1880 елдан Печән базары мәчетенең имамхатыйбы була. 1892 елда Юнысовлар мәчете каршында җәдит мәктәбе ача, шунда 1918 елга кадәр укыта.

1905 елгы революция чорында «Мәгариф»нең эшчәнлеге тагын да активлаша. Социал-демократлар партиясе чыгарган брошюралар, листовкалар «Мәгариф» аркылы Казан мәдрәсәләренә, бигрәк тә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә тарала башлый. Галиәсгар бу эшкә «Мөхәммәдия»дә укучы *Габдулла* энесен тарта. Габдулла Казанның барлык мәдрәсәләрен листовкалар, брошюралар белән тәэмин итә (полиция, бу листовкаларны, брошюраларны табу өчен, «Мәгариф»тә тентүләр дә уздыра).

1905 елның октябрендә Г. Камал *Сәетгәрәй Алкинның «Казан мөхбире» газетасында* эшли башлый. Әмма мондагы мөхәррирләр белән уртак фикергә килә алмый һәм озаклամый газетадан китә.

1906 елның 1 февралендә *Габдулла Апанаев* белән Г. Камал *«Азат»* исемле газета чыгара башлыйлар. Газетаның эчтәлеге каршылыклы булып чыга. Г. Апанаев «Азат» газетасында карагруһларның мәнфәгатьләрен яклаган мәкаләләр бастырса, Г. Камал демократик фикерле мәкаләләрне алга сөрә. Шунлыктан газета озын гомерле булмый. Илле-алтмыш

«Мәгариф көтепханәсе» урнашкан бина

Габдулла Камал

№ 3

آزاد خلق

(Свободный народъ).

«Азат халык» газетасы

номер чыккач, ул ябыла. Г. Апанаев «Казан мөхбире» газетасы өчен яза башлый.

Г. Апанаев китү белән, Г. Камал газетаны *«Азат халык»* исеме белән чыгара башлый. «Азат халык» сул фикерле газета була. Ул буржуазиянең хаталарын фаш итә, халык мәнфәгатен яклый һәм гомуми халык демократиясе өчен көрәшә. Шуңа күрә цензура газетаны һәрвакыт тикшерә, аерым номерлары бер-ике көн буе язылучыларына таратылмый тора. Ә инде 15 нче номердагы баш мәкаләсе өчен газета конфискацияләнеп, Галиәсгар Камал хөкемгә тартыла. Суд аны бер айга ирегеннән мәхрүм итәргә, гражданский гауптвахтага ябарга дигән хөкем чыгара. Г. Камал карарны апелляциягә бирә, адвокат яллый. Яңадан суд була, һәм арестны 100 сум штраф белән алыштыралар. Г. Камал, бу штрафны түләп, төрмәгә ябылудан котылып кала.

1906 елның 5 маенда *«Шимбә»* түгәрәге яшьләре Казанның «Приказчиклар клубы»нда беренче ачык спектакль куялар. «Шимбәчеләр» төрек классик язучысы Нәмыйк Кемалның «Зәваллы чуҗык» исемле әсәрен (Г. Камал тәрҗемәсендә — «Кызганыч бала») һәм «Гыйшык бәласе» исемле комедияне (авторы билгесез) сайлыйлар.

«Азат» — 1906 елның 1 февраленнән 30 маена кадәр чыккан иҗтимагый-сәяси һәм икътисади газета. Барлыгы 56 саны дөнья күрә.

«Азат халык» — 1906 елның 4 июненнән 12 сентябренә кадәр чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Барлыгы 15 саны дөнья күрә.

«Шимбә» — Казанда дәүләт мәктәпләрендә, югары уку йортларында, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укучы татар яшьләрен берләштергән әдәби түгәрәк. Ул 1903—1907 елларда эшли. Утырышлары шимбә көннәрдә үткәрелгәнгә, түгәрәкнең исеме дә «Шимбә» дип йөртелгән. Түгәрәкнең җыелышлары Шаһбазгәрәй Әхмәревләр өендә, Ибраһим Терегулов, Шәрәфетдин Габитовлар кебек үз йортлары булган зыялы гаиләләрдә үткәрелә.



Һади Максуди (1868–1941) – педагог, тел галиме, нәшир. Казан өязе Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда Күл буе мәдрәсәсендә белем ала, аннары Истанбулга китеп, шунда укый. Кайтышында Кырымда тукталып, Бакчасарайдагы «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә гарәп әдәбияты укыта. 1902 елда Казанга кайта. 1906–1918 елларда «Йолдыз» газетасының нәшире һәм баш мөхәррире булып эшли. Күп санлы җәдитчә дәреслекләр, хрестоматияләр; мантыйк, тел гыйлеме, ислам диненең аерым мәсьәләләрен ачыклауга караган хезмәтләр яза.



Казанда беренче мәртәбә уйналган спектакль афишасы

Бу кичәне кабатлау теләге бик көчле була. 1906 елның декабрендә Яңа клубта татар укытучылар мәктәбе студентлары файдасына уйналачак «Кызганыч бала» һәм «Гыйшык бәласе» спектакльләрен күрсәтү өчен рөхсәт алына[1]. Г. Камал кичәне оештыру эшендә актив катнаша. Ул үзе афишалар яза (бу вакытта афишаларны татарча чыгару өчен зур шрифтлар булмый, афишалар, кулдан тушь белән языла, литографиядә басыла), «Мәгариф» аркылы билетларын сата. 1906 елның 22 декабрендә куелган бу спектакль киң яңгыраш ала, һәм бу дата татар театрының рәсми туган көненә әверелә.

---

[1] Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел : 2 томда. – Казан : Заман; Татар. кит. нәшр., 2009. – 1 т. : спектакльләр. – 30 б.

Ачык спектакльләр куела башлау Г. Камалда драма әсәрләре тудыру дәртен яңадан кузгатып җибәрә. Ул «Бәхетсез егет» исемле драмасының яңа редакциясен язып тәмамлый һәм 1907 елда аны «Мәгариф көтепханәсе»ндә бастыра. Озакламый Г. Камал үзенең беренче комедиясен — «Беренче театр»ны яза (әсәр 1908 елда басыла).

1906 елның көзендә «Азат халык» газетасы ябылгач, Г. Камал *Һади Максуди* тарафыннан чыгарыла торган *«Йолдыз»* газетасына эшкә урнаша. 1918 елга кадәр, ягъни газета ябылганчы, ул монда эшли.

1908 елда Г. Камал Г. Тукай белән берлектә *«Яшен»* исемле журнал чыгара башлый. Журналның мөхәррире дә, рәссамы да, мәкаләләр авторы да Г. Камал үзе була. Ул төннәр буе журнал өчен карикатуралар да ясый. Ләкин «Яшен» озак яши алмый, ун сан чыккач, матди кыенлыклар аркасында тукталып кала.

Г. Камал татар театр үсеше өчен күп көч куя. *Габдулла Кариев* җитәкчелегендә *«Сәйяр»* труппасы төзелгәч, Г. Камал труппага һәм матди, һәм мәгънәви яктан ярдәм итә. «Сәйяр»гә ярминкәләрдә, төрле театрларда спектакльләр куярга рөхсәт алу, билет тарату, акча табу кебек эшләрне үз өстенә ала. Костюмерлык хезмәтен дә үти. Казаки, камзул, читек-кәвеш, җилән, чапан, чалма кебек әйберләрне таныш

«Йолдыз» газетасы редакциясе урнашкан һәм Габдулла Тукай яшәгән «Болгар» номерлары

«Йолдыз» — 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр чыккан газета.

«Яшен» — 1908 елның 3 августыннан 1909 елның 24 июненә кадәр чыккан юмор-сатира журналы.

Габдулла Кариев (1886—1920) — атаклы татар артисты, режиссёры, драматургы. Казан губернасының Чистай өязе Кулбай-Мораса авылында крестьян гаиләсендә туа. Аның чын исем-фамилиясе — Миңлебай Хәйруллин. Җаекның (Уральск) «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый. Шунда Коръәнне яттан өйрәнә һәм Коръәнхафиз була. Аны «Габдулла Карый» дип йөртә башлыйлар. Беренче татар спектакльләрен күреп, театр сәнгатенә гашыйк була һәм тормышын театрга багышлый.

«Сәйяр» (гар. «күчеп йөрүче») — татар профессиональ театр сәнгатенә нигез салган театр труппасы. 1907 елда Оренбург шәһәрендә И. Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендә оеша. Беренче исеме — Россиядә беренче күчмә мөселман драма артистлары труппасы. 1908 елдан труппа Г. Кариев җитәкчелегендә «Сәйяр» исеме белән атала башлый. Труппаның даими торып эшләгән урыны Казанда булса да, җәйге айларда ул Идел буе, Урал һәм Себер ягы, Кавказ һәм Урта Азия шәһәрләрендә спектакльләр куеп йөри. Казанда булганда, спектакльләр «Шәрекъ клубы»нда, Зур театр, Яңа клуб биналарында уйнала. 1921 елда «Сәйяр» труппасы артистлары Беренче үрнәк татар театрына (1926 елдан Татар академия театры) кушыла.

«Шәрекъ клубы» — татар зыялыларының Казандагы мәдәни үзәге. 1907 елның 1 декабрендә ачыла. Башта ул «Болгар» кунакханәсенең бер бүлмәсендә урнаша, 1909 елда аерым бинага күчә. И. Терегулов, Г. Әхмәрев, Г. Камал, Г. Коләхмәтов клубның уставын төзеп, аны хөкүмәт даирәләрендә раслатып йөриләр, соңыннан клубның старшиналар советында актив эшлиләр. Клуб каршында китапханә, уку залы һәм тамаша залы була. Татарча гыйльми, иҗтимагый лекцияләр, әдәби-музыкаль кичәләр, профессиональ җырчыларның концертлары, балалар өчен чыршы бәйрәмнәре шушы клубта уздырыла. 1915 елда бина госпиталь итеп үзгәртелгәч, клуб ябыла.

«Ялт-йолт» — 1910 елның 15 мартыннан 1918 елның июненә кадәр аена ике тапкыр чыккан сатирик-юмористик рәсемле журнал. Барлыгы 123 саны дөнья күрә.

Әхмәт Урманчиев (1879–1922) — нәшир һәм журналист. Тумышы белән Касыйм төбәгеннән. 1907 елда Казанда оешкан «Юл» китап нәшриятының хуҗасы, 1910–1918 елларда «Ялт-йолт» журналының рәсми мөхәррире була.

«Сәйяр» труппасы. 1908

сәүдәгәрләре, кустарьларыннан алып тора. Алар камчатчы Галиәкбәр улы Галиәсгаргә бу әйберләрне ышанып бирәләр. Артистлар Г. Камалны «әткәй» дип йөртәләр, аның киңәшләрен тоталар, аны ихтирам итәләр.

1910 елның кышкы сезонында «Сәйяр» труппасы *«Шәрекъ клубы»*на айлыклы жалованиегә яллана. Шул беренче сезонда Г. Камал «Сәйяр» труппасында режиссёрлык итә һәм үзенең «Уйнаш» драмасын сәхнәгә куя.

Г. Камал бертуган энесе Габдулланы да сәхнәгә тарта. Галиәкбәр агайның ихтыяры белән читек-кәвеш кибетендә приказчик булып йөргән Габдулла Камал труппага шушы 1910 ел сезонында килеп керә.

1910 елда «Яшен» журналының дәвамы булган *«Ялт-йолт»* журналы чыга башлый.

«Шәрекъ клубы» урнашкан бина

Журналның рәсми мөхәррире *Әхмәт Урманчиев* булса да, ул тулысынча Г. Тукай белән Г. Камал җитәкчелегендә дөнья күрә. Журналда Г. Камалның карикатуралары да басыла.

1911 елда Балкан сугышы[1] башлана. «Йолдыз» газетасы Г. Камалны Төркиягә үз хәбәрчесе итеп җибәрә. Бу вакытта Төркиядә каты суыклар һәм көчле яңгырлар була. Салкын һава Г. Камалның сәламәтлегенә зарар китерә. Ул Төркиядән бик каты авырып, кул-аягы эшләмәгән хәлдә әйләнеп кайта. Казанда озак дәвалана: электр ванналары ала. Күп вакытлар үткәч кенә, кул-аяклары азрак языла. Ул акрынлап йөри башлый. Кулы каләм тотарлык хәлгә килү белән, Г. Камал тагын иҗат эшенә керешә. Атаклы комедиясен — «Банкрот»ны язып, аны 1912 елда бастырып та чыгара. Шул ук елда «Дәҗҗал» исемле драмасы да язылып басыла һәм «Шәрекъ клубы»нда «Сәйяр» труппасы тарафыннан уйнала.

1913 елда Г. Камал «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясен яза. Әсәр сәхнәдә уйналгач, татар буржуасы, муллалары Г. Камалга каршы ут ачалар, хәтта террор оештыралар. Караңгы, яңгырлы бер төндә извозчикта утырып кайтып килүче Г. Камалга һөҗүм ясыйлар: ике кадаклы гер белән сугалар. Гер Камалның уң як яңак сөягенә тия, шулай да язучының сәламәтлегенә зыян килми. Шул ук елда ул «Кайниш» исемле комедиясен бастырып чыгара.

1913–1917 елларда Г. Камал рус, төрек авторларының әсәрләрен тәрҗемә итә.

Бөек Октябрь революциясе башлану белән, драматург, һич икеләнеп тормастан, большевиклар юлыннан китә. *Мулланур Вахитов* җитәкчелегендә оештырылган *Казан Мөселман социалистлар комитетының «Кызыл байрак»* газетасында тәрҗемәче булып эшли; шигырь, декламация һәм ораторияләр яза.

---

[1] *Балкан сугышы* — монда Беренче Балкан сугышы күздә тотыла. Балкан дәүләтләре (Болгария, Греция, Сербия, Черногория) белән Төркия арасында башланган бу сугыш 1912 елның 8 октябреннән 1913 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

Мулланур Вахитов (1885–1918) — күренекле революционер, сәясәт эшлеклесе. Башта Казандагы реаль училищеда, аннары Петербург политехника институтының икътисад факультетында белем ала. Казанда 1905–1907 еллардагы революция вакыйгаларында катнаша. 1917 елда Мөселман социалистлар комитетын оештыра һәм җитәкли. «Кызыл байрак» газетасында мөхәррир булып эшли. 1918 елда Үзәк (Мәркәз) мөселман комиссариаты җитәкчесе, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе, РСФСРның Милләтләр эше буенча халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы була. 1918 елның августында Казанны аклар һөҗүменнән саклау көннәрендә 2 нче татар-башкорт батальоны командиры вазифаларын башкара. Ак чехлар кулына эләгә һәм атып үтерелә.

Казан Мөселман социалистлар комитеты 1917 елның апрелендә революцион-демократ татар яшьләре тарафыннан оештырыла. Максаты — татарлар арасында социалистик идеяләрне тарату; эшчеләрне, крестьяннарны берләштерү. Комитетның рәисе М. Вахитов була. Милли мәсьәлә, эшчеләр, җир, хатын-кызлар, финанс һ. б. мәсьәләләр буенча ун комиссия оештырыла.

«Кызыл байрак» — 1917 елның 15 июненнән — Казанда, 1918 елның 10 маеннан 28 июленә кадәр Мәскәүдә чыккан фәнни-сәяси һәм әдәби газета. Казан Мөселман социалистлар комитеты органы. Барлыгы 42 саны нәшер ителә.

«Эш» – 1918 елның 12 мартыннан 1920 елга кадәр эшче, солдат һәм крестьян депутатларының Казан Советы каршындагы Мөселман комиссариаты органы буларак чыккан көндәлек газета. 1920 елның 2 июленнән «Татарстан хәбәрләре», аннары «Татарстан», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан» исемнәре белән чыгарыла. «Эш» – хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасының башлангычы.

«Эшче» – татар эшчеләренең үзәк газетасы. РКП(б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы, аннары ВКП(б) каршындагы Үзәк татар-башкорт бюросы органы. 1918 елның 27 сентябреннән Казанда татар телендә, 1918 елның декабреннән Мәскәүдә, 1920 елның февраленнән 1921 елның мартына кадәр кабат Казанда, 1921 елның апреленнән 1931 елның декабренә кадәр яңадан Мәскәүдә нәшер ителә. 1932 елдан «Игенчеләр» газетасы белән берләштерелә.

«Безнең байрак» – 1922 елның 18 октябреннән 1924 елның 28 мартына кадәр чыккан иҗ-тимагый-сәяси һәм әдәби-гыйльми газета. РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты органы.



Казан Мөселман социалистлар комитеты урнашкан бина

Мөселман социалистлар комитеты янына яшьләрне җыеп, драма түгәрәге оештыра, режиссёрлык итә, түгәрәкнең җитәкчесе була.

1918 елда Казанга чехлар килгәндә, Г. Камал Казаннан тугыз километр читтә урнашкан Аракчино авылында дачада яши. Ул, чехларның Казанга һөҗүмнәре башлану белән, гаиләсен алып, Казан артындагы Караужа авылына китә. Ләкин ташкын йөрәкле Г. Камал авылда озак яши алмый, Казанга әйләнеп кайта.

Кызыл Армия Казанны чехлардан азат иткәч, Г. Камал җиң сызганып эшкә тотына. 1918 елда беренче совет татар театры барлыкка килгәч, яңа репертуар булдыру мәсьәләсе алга чыга. Галиәсгар Камал дәртләнеп эшкә керешә, һәм аның иҗаты яңадан җәелеп китә. Ул драма, комедияләр, клуб сәхнәләре өчен инсценировкалар, декламацияләр, шигырьләр, ораторияләр яза. Бик күп әсәрләр тәрҗемә итә.

1919 ел ахырында Казанда Татар запасный батальоны каршында гаскәриләр өчен татар труппасы төзелә. Г. Камал труппаның иҗади үсүенә нык ярдәм итә. Өеннән киемнәр, бу-

тафория әйберләре ташый, артистларга грим ясауда булыша. Матур, җылы йөрәкле, һәрьяктан уйлап, тырышып эшләнелгән образлар тудыра. Ул Шиллерның «Юлбасарлар» трагедиясендә – Патер, «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә – музыкант Миллер образларын, Максим Горькийның «На дне» драмасында Актёр образын тиңдәшсез осталык белән башкара.

Г. Камал журналистлык эшен дә дәвам итә. *«Эш», «Эшче», «Безнең байрак»* һ. б. газеталарга яза.

Драматург гомеренең соңгы көннәренә кадәр сәхнәдән аерылмый. Ул Наркомсобес клубына йөри, аның көндәлек эшләрендә актив катнаша, сукырлар өчен драмтүгәрәк оештыра. «Күзсез мастерлар» исемле әсәр язып, аны сәхнәгә куя. Әмма ялны белмичә эшләгән Г. Камалның сәламәтлеге нык какшый. Табиблар аңа операция ясарга киңәш итәләр. Ләкин ул матур җәй көнендә больницага кереп ятарга теләми. Операцияне көзгә калдыра һәм Татарстан Совет Язучылары берлеге тарафыннан бирелгән дачасына – Түбән Ослан авылына күчеп китә.

Г. Камал Казанга сирәк кайта. Соңгы кайтуы туберкулёз белән авырып ятучы энесе Габдулланың хәлен белер өчен була. Бу кайтуында ул әнисе Мәүгыйзә белән дә күрешә. Аңа «Боржоми» суын эчәргә кирәк» дигән киңәш бирә. Аннан Түбән Осланга кайтырга дип, пристаньга төшеп китә. Ләкин аз гына соңга кала, ул килеп җиткәндә, су трамвае кузгалып киткән була. Г. Камал берничә сәгать буе икенче трамвайны көтәргә теләми, Түбән Осланга җәяүләп юл тота. Әмма ике километр җир киткәч, Г. Камалның хәле начарланып китә, һәм ул йөрәк өянәгеннән үлә. Бу көн 1933 елның 16 июне була.

Габдрахман Камал II һәм
Әнәс Камал истәлекләре буенча

Габдрахман Камал

Габдрахман Камал II (1896–1948) – Г. Камалның энесе, күренекле артист һәм режиссёр. 1912 елда «Сәйяр» труппасында уйный башлый. Октябрьдан соң Казанда беренче татар совет театрын оештыруда катнаша. 1920 елларда Уфа, Пермь, Троицк, Ташкент театрларында эшли. 1925–1939 елларда Казанда Татар академия театры артисты була.

Әнәс Камал

Әнәс Камал (1908–1978) – Г. Камалның олы улы, күренекле татар язучысы, драматург.



***

Үзенең башка бик күп каләмдәшләреннән аермалы буларак, Г. Камал — исән чакта ук хезмәтләренең хөрмәтен күргән кеше. 1910 елның 5 ноябрендә «Шәрекъ клубы»нда татар зыялылары тарафыннан Г. Камалның иҗади эшчәнлегенә 10 ел тулу тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Кичәдә «Бәхетсез егет» һәм «Бүләк өчен» әсәрләре уйнала. Соңыннан юбилярга «Сәйяр» труппасы артистлары кул куйган адрес тапшырыла һәм бүләкләр бирелә. Кичәдән соң чиксез дулкынланган Г. Тукай, татар тормышының моңа кадәр мәгълүм булмаган якларын сәхнәдә күрсәтә алганы өчен, Г. Камалны «татар Островские» дип атый.

Совет елларында да Г. Камал иҗаты югары бәяләнә. Татарстан хөкүмәте 1924 елда иҗатының 25 еллыгы бәйрәм ителгән көндә аңа «Хезмәт батыры», ә 1926 елда татар театрының 20 еллыгы уңае белән «Татарстанның халык драматургы» исемнәрен бирә. 1939 елдан алып бүгенгәчә Татар дәүләт академия театры Галиәсгар Камал исемен йөртә. Бүгенге көндә Казандагы үзәк урамнарның берсе, элеккеге Фукс урамы, аның исеме белән аталган.

Гали Арсланов

Галиәсгар Камал.
Рада Нигъмәтуллина ясаган бюст

ШӘҖӘРӘ АГАЧЫ[1]



---

[1] Шәҗәрә агачы түбәндәге китаптан алынды:
Галиәсгар Камал : альбом / төз. Габдрахман Камал II. – Төз. һәм тулыл. 2 нче басма. – Казан : Титул, 2003. (Җәя эчендә туган еллар күрсәтелде. – *авт.-төз. искәр.*)


Галиәсгар Камал
+
I Бибигайшә (?)
Әхмәт (?)
Әминә (1902)
Фәһимә (1904)
Әнәс (1908)
+
Сәлимә Латыйпова (1914)
Мөхәммәт (1914)
+
Гайшә Вафовна (1918)
Зөфәр (1916)
Диләрә (1934)
+
Рәис Даутов (1928)
Фидакарь (1945)
+
I Рушания (1944)
II Сания (1947)
Наил Мөхәммәт улы (1940)
+
Фәридә (1939)
Айрат (1963)
Наилә Мөхәммәт кызы (1954)
+
Олег Макаров (1954)
Фәридә (1958)
+
Жәүдәт Идиятуллин (1957)
Нияз (1962)
Фаикъ (1968)
+
Гөлнара (1973)
Алсу (1979)
Аида (1973)
+
Вагыйзь
I Римма (1964)
II Люция (1968)
Артём (1980)
Айрат (1981)
Айгөл (1983)
Галиәсгар (1992)
Әдилә (2000)
Анара (1999)
Алинә (1985)
Әскәр (1993)

II Әсма *(1887)*

- Фаикъ *(1919)*
- Фәрит *(1921)* + Бәдәр Шәфигуллина *(1923)*
  - Рәфыйка *(1954)* + Владимир Шәмсетдинов *(1955)*
    - Артём *(1978)*
  - Фәридә *(1956)* + Ринат Фәхретдинов *(1956)*
    - Диләрә *(1980)*
    - Ленар *(1986)*
  - Фәрдания *(1957)* + Мансур Хафизов *(1953)*
    - Ләйсән *(1978)*
    - Гүзәл *(1984)*
  - Нажия *(1960)* + Рәшит Зарипов *(1959)*
    - Фәрит *(1983)*
    - Бәхтияр *(1984)*
- Наилә *(1924)*
- Рәфыйка *(1926)* + Рәфкать Хафизов *(1927)*
  - Гүзәл *(1955)* + Фәрит Мәгъсүмев *(1955)*
    - Айсылу *(1975)*
      - Искәндәр *(1994)*
    - Әнвәр *(1983)*
  - Алсу *(1960)* + Дамир Самитов *(1959)*
    - Искәндәр *(1985)*

Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов (Галиәсгар Камал) – драматург, тәрҗемәче, журналист, режиссёр, артист

Габдулла Галиәкбәр улы Камалетдинов (Камал I) – артист, режиссёр. Галиәсгар Камалның энесе

Габдрахман Галиәкбәр улы Камалетдинов (Камал II) – артист. Галиәсгар Камалның энесе

Зәйнәп Галиәкбәр кызы Камалова – артистка. Галиәсгар Камалның сеңлесе

Әнәс Галиәсгар улы Камалетдинов (Әнәс Камал) – артист, драматург. Галиәсгар Камалның улы

Фаикъ Галиәсгар улы Камалетдинов (Фаикъ Камал) – артист. Галиәсгар Камалның улы

Фатыйма Хәйрулла кызы Камалова – артистка. Камал I нең хатыны

Гәүһәр Габдулла кызы Камалова – артистка. Габдулла һәм Фатыйма Камалларның кызы

МИНЕМ ПЕРСОНАЛЬНЫЙ ПЕНСИОНЕР БУЛУЫМНЫҢ ТАРИХЫ[1]

(Кыскартып бирелә)

Мин яшь, үз-үземне белмәгән бала вакытымда, әти, һичбер вакытта үз-үзенә карар таба алмыйча, бер квартирдан икенчесенә күчеп йөргәнлектән, ул заманның асламчы хатыннарыннан Мәгъри астай дип йөртелә торган бер хатын минем әти белән Кариев заманында артист булып озак вакытлар уйнап йөргән кешеләрдән Ишми дигән артистның атасы Кара Савыт Шаһи дигән кеше хакында:

– Кара Савыт Шаһига хатын ярамый, камчатны Галиәкбәргә фатир ярамый, – дип шаяртып сөйли торган булган.

Шулай итеп без, бер фатирдан икенчесенә күчеп бик күп йөри торгач, элекке Тихвинский урам, хәзерге Тукай урамында Госманов мәдрәсәсе күршесендә Мажар Фазлый дигән кешенең йортына фатир күченгәнбез. Минем үз-үземне белә башлавым әнә шуннан башлана. Бу квартирга күчеп килгәндә, әле без күчәчәк квартирның таш йорты эшләнеп бетмәгән иде, шул сәбәптән безне вакытлыча гына капканың икенче ягындагы пулатның астындагы двор өенең бер почмагындагы бер бүлмәгә урнаштырып торганнар. Шунда торганда, мин мич алдында уйнап утырганда, ут кабынып китеп, күлмәгемнең алгы ягы дөрләп яна башлаган, шунда хезмәт итүче Фазыл исемле дворник, чикмәне белән каплап, утны сүндергән, мин дә, корсакларым бераз пешү белән, янып үлүдән котылып калган идем. Әнә шул вакыйга беренче һәм һич онытылмый торган бер вакыйга булып исемдә калган.

Икенче онытылмаган вакыйга дә – шул көннәрдә, шул ук йортта булган яңа квартирга күчү мәсьәләсе. Без югары каттагы шул квартирга күчкән вакытта, квартирның өй алдысы эшләнмәгән, мостиклары сүтелмәгән иде. Мине шул мостиктан житәкләп алып менгәндә, егылып төшәм, дип бик курыккан идем. Үзем белмим, ләкин шул урамда торучылар мине, шул вакытларда син жырчы идең, дип сөйлиләр. Мине жырлатып, кәләвә ашарга бер тиен, ике тиен акча бирә торган булганнар. Жырлый торган жыруым:

Алты кыек тәрәзә, куйдырмыйсың бер ишек,
Бетәр микән, бетмәс икән [сиңа төшкән] бу гыйшык, –

дигән жыр белән

Скрипка, думбыра, әти башка кундыра,
Өйгә кайтып кергәчтен, әни буран туздыра, –

дигән жыр булган.

---

[1] Истәлекләрдә сүзләрнең язылышы чыганактагыча калдырылды. – *мөхәр. искәр.*

Миңа биш яшь тулып алтыга чыккан вакытларда булырга кирәк, минем әнинең авылы булган Арча районы Казанбашы волосте Түбән Масра дигән сөннәтче бабайлар авылына Казаннан, Сәлах хәзрәт мәдрәсәсеннән Исмәгыйль дигән «бик гыйлем» бер пишкадәмне[1] мулла итеп куйганнар. Әти мине, шул «гыйлем» кешедән укырга дип, Масрага җибәргән. Анда мин укыганмындырмы, юкмы — ул кадәресен белмим, — әмма, һичбер язу танымаган көйгә, мулланың, аркага камчылар төшергәләп, «Әфтияк» сүрәләре бикләткәнен һәм кичке «сабак» кереп, шуларны тыңлатканын беләм һәм әнинең миннән бернечә яшьләр олы энесенең «Иман шарты»ндагы «Вә һүә галә көлле шәйин кадир»[2] дигән сүзне «вә һүә галә көнләшәдер Кадыйр» дип тыңлатканын беләм... Шулай иттереп, без, һич укымаган, язу танымаган көйгә, кыш буена күңел сабаклары бикләп, «бик гыйлем» хәзрәттән укып, кышны уздырып чыктык. Үземә бик күп эләкмәсә дә, шунда бергә укучы минем шикелле һәм миннән бернечә яшь зур малайларның кушка (камчы) ашаганнарын күреп, кышны уздырып чыктык, кыш буена бер мәртәбә «убыр» күрү вакыйгасеннән башка истә калырлык һичбер вакыйга дә булмады. Ул вакыйга шуннан гыйбарәт: бер төнне (чөнки Исмәгыйль хәзрәт күңел сабагына ястүдән чыгышлый гына керәдер иде, ә без мәдрәсәгә караңгы төшкәч тә барадыр идек тә, кизүнең яндырган түшәм лампасы яктысында «Сукыр тәкә», «Дерен сугыш» уйнап гөр киләдер идек) шулай, күңел сабагыннан соң өйгә кайтып барганда, мәчет елгасында җылтыр-җылтыр янган ут күренә, очкыннары да чәчрәп куя. Шуны күрүгә, арадан бер малай: «Убыр!» — дип кычкырып та җибәрде, барлык малайлар дәррәү кире мәдрәсәгә кача башладылар. Мәдрәсәгә бардык, анда хәзрәт утны сүндереп кайтып киткән. Югары оч малайлары инде алар күптән өйләренә кайтып җиткәннәр. Безгә шәфәгать сорарга урамда бер олы кеше дә юк. Малайлар шүрләделәр, белгән күңел сабакларын гына түгел, арт сабакларын да укырга тотындылар, ләкин файда юк, «убыр» һаман кышкы җилдә авызыннан утларын чәчеп ята. Кышкы төн суык, урамда төн буе торып булмый, өйләрдә дә теге «убыр»дан башка җылтыраган ут юк. Мин курыкмыйм куркуын, чөнки һәрничек дөнья күргән «шәһәр малае». Шулай да иптәшләрең барысы да курыккач, никадәр батыр булсам да, минем дә шүрләми хәлем булмады.

Өс юка, җил өрә, курку да туңдыра, ни булса да булыр, батыр булырга кирәк: «Әйдәгез, малайлар, барыгыз да белгәннәрегезне кычкырып укыгыз, «әгузе бисмилла»-дан җен-пәриләр качар, әйдә киттек!» Минем шикелле үк туңганнар булырга кирәк, малайлар да батырландылар, минем арттан курка-поса гына бара башладылар. «Догалар бәрәкәтендә» әле һаман теге «убыр» урыныннан кузгала алмый. Якынрак килгәч, кылт итеп, көндез бер әбинең елгага салам көле түккәнен күрүем хәтергә төште. Шуннан эчемә җылы кереп, батырланып йөгереп барып, утка тибеп җибәрдем дә, утлы салам көлләре тирә-якка чәчелеп китте. Инде мин герой, батырлык шәп, карга чумган, катып беткән киез итек белән калганнарын да басып, таптап сүндереп бетердем.

Бу геройлык вакыйгасе авыл малайлары арасында минем авторитетны бик күтәреп җибәрде. Көндез һәр көн безнең түбән оч малайлары белән якалашып сугыша торган югары оч малайлары каршысында да мин — «кала малае»ның дәрәҗәсе күтәрелде, мине

---

[1] *Пишкадәм* — иске мәдрәсәне тәмамлаган шәкерт.
[2] *Вә һүә галә көлле шәйин кадир* — һәм ул (Алла) бөтен нәрсәгә көчле.

дошман күрми башладылар, хәтта көндезләрдә япа-ялгыз югары очка менеп, алар белән бергәләп уйнау, алар белән бергәләп чана шуу хәленә килеп җиттем. Шуның белән бергә түбән очлар да мине дус күрәләр иде. Шулай итеп, кыш үтте. Кыш буена каладан кайтучылар артыннан берничә тапкыр әтиләрдән күчтәнәчләр, пешкән мәмиләр, каткан-туңган алмалар да килде. Алардан да авыз иттергәләгәч, минем дуслар тагы да күбәеп китте. Кыш буена күп укый торгач, минем гыйлем дә зурайды, башкалар «Әләм тәрәкәйфә» сүрәсендә тукталып калсалар да, мин «Гаммә» сүрәсенә кадәр барып җиттем. Миңа күчтәнәч җибәргәндә әтиләр, хәзрәтне дә «онытмыйча», аңар да берничә аршын ситса, сәдакалар җибәргәләгәч, әбиләр дә берничә тапкыр мунчаларга чакырып, коймаклар, кабартмалар белән чәйләр эчертеп сыйлаштыргалагач, минем дәрәҗә тагы да үсеп китеп, хәзрәт үзе белән мәчеткә алып кереп, «күрәсезме, мин ничек тырыштырам, балаларны ничек итеп кеше итәм» дигәндәй мактанып, бер җомгада «Вәлләйли иза ягъша» сүрәсен дә укытты. Авыл абыстайлары, карчык һәм киленнәре дә, минем шундый Коръән уку хәбәремне ишетеп: «Сабый баланың догасы кабул була икән аның», – дип, өйләренә алып кереп, Коръән укытып, йомыркалар, кабартмалар ашатып та чыгара башладылар...

Галиәсгар Камал

ЯЗА БАШЛАВЫМ ТАРИХЫ

(Кыскартып бирелә)

Минем язучылык, үземчә, кызык кына башланды.

Мин үземне белә башлаган вакытта атам Казанда, хәзерге Тукай урамында «Госмания мәдрәсәсе» дигән мәдрәсә күршесендә тора иде. Хәзерге көндә Колхоз базары дип аталган базар урынында элек Ашлык базары иде. Шул базарда ел саен Рождество, Масленица, Пасха бәйрәмнәре вакытларында, балаганнар корып, театр уйныйлар иде. Мин кызыгып карап тора торган театр «Курчак кәмите» иде. Анда кәмитнең бер почмагындагы тишектән карап торырга куркыныч та, күңелле дә: бик озын борынлы бер курчак чыга иде дә әллә нинди икенче бер «кыз» курчак белән бии, аның артыннан бер төрек чыга да аны кыйнап үтерә, аның артыннан яшел кәләпүшле татар чыга да аны да кыйнап үтерә иде. Бу эшкә ни өчендер минем бик ачу килә, соңыннан бутышник, чыгып, ямьсез озын борынлы курчакны акыртып-бакыртып часка[1] алып киткәч кенә, бераз кәеф килә иде. Шулай да, никадәр ачу килсә дә, көн саен ул курчакны барып карамый калмый идем. Соңыннан, Май кәмите[2] беткәч, иптәш малайлар белән ул «озын борын»нан ачуны аладыр идек. Каткан бәрәңгеләрдән юнып – курчаклар, өйгән карларны казып, «кәмит» ясап, «озын борын»ны туйганчы кыйната идек.

Бераз үсә төшкәч, кәмитнең эченә дә керә башладым. Анда эчтәге уеннарны карап кайткач, безнең кәмит тә утын келәтләренә күчте. Анда таганнарда да уйный, фокуслар да күрсәтә идек.

---

[1] *Час* – часть (полиция участогы).
[2] *Май кәмите* – русларның Масленица бәйрәме күздә тотыла булса кирәк.

Инде мин, тагы да үсә төшеп, язуны да яхшырак таный башлагач, ул заманның әдәбиятыннан *«Белек»*, *«Рисаләи Газизә»*, тагы шундый хикәяләр, К. Насыйри китапларын яратып укый башлаган вакытларда, Г. Ильясовның «Бичара кыз», Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» дигән театр китаплары чыкты. Ильясов китабын ничә кат укыганымны белмим, әмма «Рәдде бичара кыз»ны кырык-илле тапкыр укыганмындыр. Хәтта мин аны күңелдән, күрми укый да белә идем. Ул вакытларда Казанда, хәзерге көндәге Ирек мәйданында, түбәсенә таштан әллә нинди сыннар ясап куйган бик зур ташпулат бар иде[1]. Мәдрәсәдә укучы иптәшләремнең кайберләре әнә шул зур пулатта мин укыган китаплар шикелле китапларны уйнап күрсәткәнлекләрен сөйлиләр иде.

Шул елларда мин, әтигә ияреп, Мәкәрҗә ярминкәсенә бара башладым. Бер елны анда, һәр көн эштән бушагач, әтидә өйрәнчек булып хезмәт итә торган малай белән капчык күтәреп, кибет рәтләренә чыгып, ташландык кәгазьләрне җыеп, потын егерме тиеннән сатып, үзебезгә бик «зур» сума ясадык. Ул сума ярминкәдәге кәмитләргә керүдән дә артып калды. Мин шул иптәш малайга Казанда аннан да зур кәмит барлыгын, анда атнага бер көндез дә уеннар булганын сөйләп, кайткач, шунда барырга аннан сүз алдым.

Мәкәрҗәдән кайттык. Аннан кайткач, безнең бәхеткә, әти бабай белән күрешергә авылга кайтып китте.

Малайның да эше юк, якшәмбе дә туры килде, көндезге уенны да куялар (хәтеремдә калган, «Ева» дигән уен куйганнар иде). Без, җидешәр тиен түләп галёркага билет алып, уенны карап кайттык. Икебезгә бер тиенлек русча белмәсәк тә, драманың кайгылы икәнен артистларның кыланышларыннан аңладык. Ул вакытта *Мәрҗани мәдрәсәсендә* укый

---

[1] *...ташпулат бар иде.* – Казандагы рус драма театрының элекке бинасы. Бина янгын вакытында юкка чыга.

«Белек» – В. В. Радловның 1871 елда мәктәп балалары өчен басылып чыккан татарча уку китабы.

«Рисаләи Газизә» – Суфи Аллаһиярның (1624–1713) «Сөбател-гаҗизин» («Аллага ялваруда ныклык») исемле китабына шәрех (киңәйтеп бирелгән аңлатмалар) итеп 1807 елда Таҗетдин Ялчыгол (1837 елда үлгән) тарафыннан язылган әсәр. Ялчыгол бу әсәрен Газизә исемле кызына багышлап язган һәм шуңа күрә «Рисаләи Газизә» («Газизә китабы») дип исем куйган.

Мәрҗани мәдрәсәсенә («Мәрҗания» мәдрәсәсе) 1870 елда Казанда нигез салына. Мөдәррисе Ш. Мәрҗани була. 1917 елдан соң мәдрәсә ябыла. Бүгенге көндә ул бинада Казан ислам көллияте урнашкан.

Борһан Шәрәф (1883—1942) — педагог, әдип, журналист, нәшир. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. «Мөхәммәдия» (1899—1905) һәм «Хөсәения» (1909—1918) мәдрәсәләрендә укыта. 1905—1917 елларда «Казан мөхбире», «Әхбар», «Вакыт» газеталарында, «Шура» журналында эшли. 1917 елда Оренбург Мөселманнар бюросы рәисе була. 1930 елларда Урта Азиядә нәширлек системасында эшли.

Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы) (1851—1914) — җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, нәшир. Бакчасарай мәдрәсәсендә, аннары Симферополь ирләр гимназиясендә, Воронеждагы кадетлар корпусында, Мәскәүдәге 2 нче хәрби гимназиядә, Истанбулда, Парижда укый. 1968—1871 елларда Бакчасарайның «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә укыта. 1879—1883 елларда Бакчасарай шәһәренең башлыгы була. 1883 елдан «Тәрҗеман» газетасын, балалар һәм хатын-кызлар журналларын нәшер итә. Яңа ысул белән укыта торган җәдит мәдрәсәләренә нигез сала һәм алар өчен дәреслекләр чыгара; төрки халыклар мәгариф системасын үзгәртеп коруга зур өлеш кертә.

«Тәрҗеман» — 1883 елның апреленнән 1918 елга кадәр Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) төрки-татар телендә чыккан сәяси, фәнни һәм әдәби газета.

Шәехгаттар Иманаев (1875—?) — юрист. 1913—1914 елларда Казанда чыккан «Хокук вә хәят» журналының мөхәррире була. Шәһәр судьясы, коллежский асессор булып эшли.

торган Театр Шәех дигән берәү безнең белән танышты. Үзе белгән кадәр аңлатып та маташты. Тиздән бик матур, музыкаль уен башланачагын сөйләп, безне шуңа килергә димләде. Иптәшемнең күңеленә уен бер дә ошамады. Мин әле өй эче, әле бакча булып декорацияләр алмашуын яраттым һәм гаҗәпләндем. Менә бервакыт опера башланды. Югарыда әйткән Театр Шәех мине онытмаган икән: мәдрәсәгә чакыра килде. Бәясе бик кыйбат (егерме җиде тиен иде бугай) булса да, билет та алып килгән. «Фра дьявол»[1] дигән уен куелды. Шәех, үзе аңлаган кадәр, уенның мәгънәсен дә аңлатты. Уен күңелгә бик ошады. Шуннан без атна саен көндез театрга бара башладык.

Мәдрәсәдә мин *Борһан Шәрәф* белән күрше бүлмәдә торам, аның белән бергәләп *Гаспринскийның «Тәрҗеман»* гәзитәсен дә укый идек. Шуннан аның белән театрга да йөри башладык. Театр күңелле, ләкин русча белү начар, аңлап булмый. Менә бер көн «Садко»[2] куела. Б. Шәрәф, каяндыр табып, илле тиенгә «Садко» китабын алып кайта да, без икәүләп, Насыйриның русча сүзлеген[3] алга куеп, «Садко»ны моталәгә кылабыз[4]. Мин ул вакыт Миргаяз Иманаевтан русча укыйм. Белмәгән, сүзлектә булмаган сүзләрне аннан да сорыйм. Шулай итеп, ярты-йорты булса да, «Садко»ны аңлап куям. Кайткач, «Садко»ны тагы укыйбыз, тагы укыйбыз, укыган саен, аңлау арта бара. Җитмәсә, шул вакытларда М. Иманаевның энесе *Шәехгаттарның* студент вакыты. Ул «Фауст»ны[5] укый. «Фауст» китабы бик калын кәгазьгә басылып, бик

---

[1] *«Фра дьявол»* («Фра-Дьяволо, яки Террачина кунакханәсе») — француз композиторы Даниэль Оберның көлке операсы.

[2] *«Садко»* — Н. А. Римский-Корсаковның операсы.

[3] *...Насыйриның русча сүзлеген...* — 1904 елда Казанда басылып чыккан «Русча-татарча лөгать» күздә тотыла.

[4] *Моталәгә кылу* — җентекләп уку.

[5] *«Фауст»* — И. В. Гётеның трагедиясе.

матур тышланган, кызыктыра. Ш. И.[1] юк вакытта, мин, качып-качып кына, китабын укып карыйм, кайбер сүзләрен аңлап та була. Һи, шундый китапларны, шундый театр китапларын язсаң иде! Шул уй бертуктаусыз башны вата.

Нәкъ шул вакытларда Бр. Кәримевләрдә[2] приказчик булып торган И. Әхмәтҗанов дигән яшь җегет, агасымы, бабасымы бер картка иптәш булып хаҗга барып, кайтышлый, Истанбул толчогыннан берничә сандык (гәрчә ящик булса да, Истанбулдан мал китерүчеләр «сандык» дип йөриләр иде) һәртөрле тотылган төрек әдәбияты алып кайта. Без яңа әдәбиятка чумабыз. Арадан Нәмикъ Кемалның таш басмада язылып басылган «Зәваллы чуҗык»[3] дигән драмасы килеп чыга. Нинди зур байлык! Җитмәсә, мин инде төрекчәне дә бераз сукалый башладым. Аны, кат-кат укып, аңлыйм. Нәкъ шул вакытларда минем үземнең башымда да бер тема йөри. Н. Кемалның китабы мине кузгатып җибәрә дә, мин үзем уйлап йөргән «Бәхетсез җегет» дигән нәрсәмнең беренче редакциясен язып, укытучым Миргаяз Иманаевка күрсәтәм, ул бик күтәреп каршы ала да, китапның артына берничә юллык кыйссадан хыйсса[4] язып, Петербурга, цензорга да җибәрә.

Хәзер миңа җил арттан! Китапның цензордан кайтканын көтеп тә тормыйча, үземнең аңлаган кадәрем белән «Зәваллы чуҗык»ны «Кызганыч бала» дип тәрҗемә итеп, И. Әхмәтҗановның үзенә үк төшереп сатып, биш сум гонорар алып, ул гонорарга яңадан китаплар алам. Хәзер инде мин төрекчәне яхшы аңлыйм, рәхәтләнеп укыйм. Шул вакытларда «Бәхетсез җегет» тә цензордан кайта. Кәримевләр аны да бер табаклы китап итеп бастырып чыгаралар.

Җитә 1900 ел. Мин инде «Мөхәммәдия»дә укып хәтме көтеб кылган[5] бер җегет, ләкин бик тәүфыйксыз, азган-тузган бер җегет: чөнки русча укырга да йөрим, театрга да барам. Җитмәсә тагын, Борһан Шәрәф белән бергәләп, юка кәгазь астына копировка кәгазьләре куеп, мәдрәсәдәге хәлләрнең җитмәгән якларыннан көлеп, «Телескоп», «Мәнзарател-галәм»[6] дигән гәзитләр чыгарып, төнлә белән җәмәгать сәкеләренә дә ташлыйбыз. «Тәүфыйксызлык чигенә җитеп», мин тәмәке дә тарта башлыйм. Хәлфәләр бу эшләрне бик яхшы сизәләр. Мондый тәүфыйксыз, бунтарь кешедән котылу өчен, мине мулла итү ягын каералар.

Г. Баруди, хезмәте әрәмгә китмәсен өчен һәм шәһәрдә үзе яклы кеше арттыру өчен, әтине димләп, Казан байларыннан берсенең кызына өйләндереп, аннан иске зиярәт өстенә мәчет[7] салдырып, мине мулла итәргә телиләр. Мин өйләнергә риза булам, өйләнәм, ләкин... мулла булмыйм. Атам мехчы булганлыктан, мине мех сәүдәгәре ясамакчы булалар. Аңа да риза түгел. Аптырагач, китапчы ясыйлар. Мин, Истанбулга барып, җыен яңа әдәбият, шулар җөмләсеннән оригиналь, тәрҗемә, төрле театр китаплары төяп алып кайтам. Берәр ел вакыт уза. Кәримевләр үзләренә эне тиешле Мәхмүт Алмаевны

---

[1] *Ш. И.* – Шәехгаттар Иманаев.
[2] *Бр. Кәримевләр* – борадәран Кәримевләр.
[3] *«Зәваллы чуҗык»* – Н. Кемалның әлеге драмасы төрек телендә 1873 елда басылып чыга.
[4] *Кыйссадан хыйсса* – нәтиҗә, гыйбрәт сүзе.
[5] *Хәтме көтеб кылу* – мәдрәсә тәмамлау.
[6] *«Мәнзарател-галәм»* – «Дөнья күренешләре».
[7] *...иске зиярәт өстенә мәчет...* – Казанның хәзерге 5 нче номерлы шәһәр больницасы тирәсендәге урам. Әлеге мәчет 1914 елдагы янгын вакытында юкка чыга.

Германиядән типография эшләренә өйрәтеп кайтаралар. Ул *«Сарай» номерларында* тора. Аның белән бергәләп, гектографиядә басып, «Тәрәккый» исемендә газитә чыгара башлыйбыз. Ул шулвакыт «Һай Дунай, вай Дунай» дигән бер куплет яза. Мин дә, аңар ияреп, «Приказчик» дигән бер куплет язам. Шул елны, китап сәүдәсе белән Мәкәрҗәгә барып, *Т. Соловьёвның* «Двухсветный» дигән гостиницасында ачык сценада урыс артистлары белән аларны җырлыйм — шау-шу китә. Шуннан, үч иткән шикелле, миндә язу дәрте кузгала, ләкин белем сай, белгән гарәпчә, төрекчә белән эш чыгарып булмый, русчаны белмим, шулай да, тырышып-тырмашып, газитәләр укырга керешәм. «Нива» журналы алам, аңа кушымта булып килгән Чехов әсәрләрен укыйм.

Шулай маташа торгач, 1905 ел җитә. Шәһәрнең «азган-тузган» яшьләре театр артындагы урамда Приказчиклар клубында спектакль куялар. Менә шуннан соң миндә ничә ел томаланып яткан дәрт яңадан кузгала. «Беренче театр»ны язып, үз тормышымны сәхнәгә чыгарып күрсәтәм.

Театр куюлар көчәя, ләкин пьесалар юк. Шуннан электә язылган кыска «Бәхетсез җегет»не, киңәйтеп, сәхнәгә куярга яраклы хәлгә китерәм, ул гына да җитми; аннан Төркиядән алып кайткан китаплар арасыннан алып «Пенти Хәмид» дигән нәрсәне «Саран» исеме белән тәрҗемә кылып, «Гасыр» көтепханәсе аркылы бастырып чыгарам. Ул Т. Кассаб дигән бер бәндәнең, Мольердан алып, төрек тормышына күчереп, үзенеке итеп язган бернәрсә булып чыга. Аның сере ачылгач, Мольерны укырга тотынып, аннан берникадәр нәрсәләр тәрҗемә кылам.

Берзаман «Шәрекъ клубы» ачыла. Мин — клубта старшиналарның берсе. Клубны зурайтыр өчен башында Г. Кариев, М. Иманский, Сәхибҗамал Гыйззәтуллиналар тора торган «Сәйяр» труппасын яллыйбыз. Бер куйган пьесаны ике куйсаң, халык килми. Сәгыйть Рәмиевләр, Ярулла Вәлиевләр, Идрис Богда-

«Сарай» номерлары — Казанда Печән базары тирәсендәге кунакханә. Хәзерге Париж Коммунасы урамындагы 9 нчы номерлы бина.

Тимерша Соловьёв (1875—1947) — педагог, журналист, нәшир. Казанда Татар учительләр мәктәбен тәмамлый, мәдрәсәдә рус теле укыта. Аннары 1906—1917 елларда «Кәримев, Хөсәенев вә шөрәкясе» басмаханәсендә мөдир була. 1906—1910 елларда «Чүкеч» исемле көлке журналы чыгара. Мәкәрҗә ярминкәсендә «Двухсветный» дип аталган ресторан да тота.

новлар язган пьесалар гына җитми, халык һаман яңадан-яңа пьесалар сорый. «Уйнаш»ны да язып карыйм. «Дәҗҗал» да языла, башкалары да. Кариев һаман да туймый. Ул «Беренче театр»дагы Хәмзә бай[1] ролен үзенеке итеп ала да һәрбер драма артыннан шуны куя. Уенны күргән, театрга кемнәр йөргәнен тикшереп, акчасыз контроль булып йөрүчеләр театрда нинди хәлләр булганын икенче көнне түкми-чәчми Печән базары чатындагы Шкафчы Хафизга сөйли генә торалар. Ул минем каената булган Хәмзә байны (Кариев аны һәрвакыт шуның кыяфәтендә итеп уйный иде) котырта, ул, өйгә кайтып — хатынга, хатын миңа зарлана иде. Хафизның бу кыланышлары, русча әйткәндә, «наконец, мне надоело!» Шуннан соң, Хафизның бөтен кыланышларын өйрәнеп, бара торгач, ахырдан «Безнең шәһәрнең серләре» дөньяга килеп чыкты, һәм аның чыгуы минем өчен уңышлы да булды. Бердән, Хафиз миңа бәйләнүдән тукталып тынды, икенчедән, тамашачылар, типларның тормыштан алына икәнлеген аңлап алып, мещан һәм татар сәүдәгәрләре арасындагы төрле яшерен серләрне миңа ташый башладылар. Яшерә алмыйм, язган нәрсәләремнең күбесендә мин шулардан файдаландым, мещаннар һәм алардан күп аермалары булмаган купецлар тормышын, мещан табигатендәге семья аркылы аларның хатыннарының табигатьләрен шактый гына өйрәндем. Үзем мәдрәсәдә укып яткан шәкерт — пишкадәм булу аркасында, голямалар[2] да миннән серләрен яшерә алмыйлар иде. Менә минем ничек язучы — театр язучысы булып китүемнең тарихы шуннан гыйбарәт.

Галиәсгар Камал

ГАЛИӘСГАР ӘФӘНДЕ КАМАЛНЫҢ 10 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЙСЕ

Ушбу сәнә[3] 5 ноябрьдә «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәлек әдәби вә милли каләм хезмәте шәрәфенә[4] аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды.

Бу юбилейне мәхәлли[5] хөкүмәтнең әмере илә афиша вә летучкаларда[6] игълан итмәк мөмкин булмаганга, спектакльгә килгән халык бу мотантан[7] булуы матлуб[8] кичә өчен бик аз диярлек дәрәҗәдә генә иде.

Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен»дәге угылын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү аның издиваҗ[9] кеби олугъ бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне «Әлхәм» укыган кеби яңлыштырмый, гармонично санату фәкать, фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга,

---

[1] *Хәмзә бай* — «Беренче театр» комедиясенең персонажы. Аның прототибы — Г. Камалның каенатасы — Казанның зур байларыннан берсе, мех белән сәүдә итүче Садыйк хаҗи Хәйбуллин.
[2] *Голяма* — белем иясе.
[3] *Сәнә* — ел.
[4] *Шәрәф* — хөрмәт.
[5] *Мәхәлли* — җирле.
[6] *Летучка* — кечкенә прокламация.
[7] *Мотантан* — шатлыклы, тантаналы.
[8] *Матлуб* — көтелгән.
[9] *Издиваҗ* — өйләнү.

аннан соң «Сәйяр» труппа артистларының һәр җирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк ма биһил-ифтихарлары[1] шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга, шул сәбәпле алар күп уйналганга, бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассыйс[2] булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты.

«Бүләк өчен» уйналып, пәрдә төшкәч, бөтен халык күңелендә бу уеннан калган гүзәл бер хис аларны үз-үзләрен бөтенләй онытттырганга, бөтен залга тәбрик һәм кул чабу тавышлары яңгырады. «Яшә, Галиәсгар әфәнде! Яшәсен Галиәсгар әфәнде! Яшәсен татар әдәбияты! Яшәсен миллият!» тавышлары залны тетрәткәндә, бөтен яшьләр, урыннарыннан сикерешеп торып, Галиәсгар әфәндене җәбрән вә каһәрән[3] өстерәп, сәхнә эченә атып, әллә ничә кәррә[4] кулларына күтәрделәр, һәр күтәргәндә, тагы күк күкрәгән кебек кул чабулар, «Яшәсен!»нәр бөтен залны әллә ничә-ничә дәкыйкаләр[5] тотып торды.

Мөхтәрәм мөхәрриремезгә итмәсе тиешле вә лазем[6] булган бу тантаналар бераз басылгач, «Мәгариф» көтебханәсе шәрикләре[7] исеменнән ушбу нотык сөйләнде:

«Мөхтәрәм Галиәсгар әфәнде Камал!

Бүген Сезнең милли әдәбиятымызга каләм илә хезмәт итә башлавыңызга һәм дә мәктәп-мәдрәсәләремезне аяныч хәленнән чыгарып, яңа юлга салуга, яңа рухта тәрбия ителә башлавына вә милли әдәбиятымызның таралуына халкымызның иң беренче ярдәмчесе булган «Мәгариф» көтебханәсене тәэсис итүеңезгә[8] 10 ел тулды.

Сезне бу олугъ көн илән чын күңелемездән тәбрик итәмез, бу хөрмәтле көнгә ядкяран[9] бу кечек һәдиямезне[10] кабул итүеңезне үтенәмез. Вә моннан соң да күп еллар ялыкмый шул юлда дәвам итүеңезгә ышанамыз.

Ихтирам илә «Мәгариф» көтебханәсе әгъзаларыннан: Әмин Мостафин, Кәрим Хәнәфи, Гыйльметдин Шәрәф».

Аннан соң ушбу нотыкта мәзкүр[11] һәдия – гүзәл вә кыйммәтле көмешләгән альбом тәкъдим кыйлынды.

Һәдия бирелгәч, хазирун[12] янә тәбрик итеп кул чабып, «Яшәсен!»нәр белә алкышлап, аз гына тавыш басыла төшкәч, Галиәсгар әфәндегә «Сәйяр» труппа тарафыннан рәүнәкъле вә мөзәйян[13] кәгазьдә ушбу адрес тәкъдим ителде:

«Мөхтәрәм әдибемез Галиәсгар әфәнде!

Татар тарихы безнең белмәгән заманнардан бирле дәвам итә. Татарларның әүвәлге заман тарихларында төрле хасиятләр күренә иде. Соңгы гасырларда татарлар үзләренең

---

[1] *Ма биһил-ифтихар* – мактаныч.
[2] *Мөтәхассыйс* – белгеч.
[3] *Җәбрән вә каһәрән* – ирексезләп һәм көчләп.
[4] *Кәррә* – тапкыр.
[5] *Дәкыйка* – минут.
[6] *Лазем* – тиеш.
[7] *Шәрик* – компаньон.
[8] *Тәэсис итү* – оештыру, нигезләү.
[9] *Ядкяран* – истәлек итеп.
[10] *Һәдия* – бүләк.
[11] *Мәзкүр* – әйтелгән, күрсәтелгән.
[12] *Хазирун* – шундагы халык.
[13] *Рәүнәкъле вә мөзәйя* – бизәкле һәм матур.

иттифаксызлыклары[1] аркасында үзләренең парлак[2] мәукыйгларын[3] югалттылар. Шул хәл ничә еллар дәвам итте. Татарлар йокладылар. Шундый караңгылык арасында соңгы көннәрдә бер яктылык күренә башлады. Татарлар ушбу заманда үзләренең дөньяда барлыкларын дөньяга белгертә башладылар. Соңгы заманнарда Европада мөнтәшир[4] мәдәнияттән татарларның да артка калмаганлыкларын күрсәтә торган вакыйгалар дөньяга чыга башлады.

Европа мәдәниятендә мәүҗүд тәрәккъыятнең әсәрләре[5] татар галәмендә дә күренә башлады. Татарлар үзләренең әүвәлге мәукыйгларын югалтмадылар. Үзләренең хәлләрен, үзләренең дөньяда торырга мөстәгыйть[6] кавемнәр идекләрен белдерттеләр. Европалыларның асары тәрәккъыятеннән улан[7] театрларда татарлар арасында күренә башлады.

Без, берничә кешедән гыйбарәт труппа, театр хезмәтен әда кыйлу[8] өчен дөньяга чыктык. Безнең дөньяга чыгуымызга Сез, Галиәсгар әфәнде, сәбәп булдыңыз. Үзеңезнең 10 еллык хезмәтеңез аркасында безнең театрымызны юлга салырга Сез сәбәп булдыңыз. Сезнең язган әсәрләреңез шул мөддәт[9] эчендә сәхнәдән чыкмыйча дәвам итте. Сезнең әсәрләреңездән «Бәхетсез егет» бу көн утыз җиденче мәртәбә сәхнәгә куеладыр. Шул мөддәт эчендә бөтен җан вә тәнемез илә Кырым, Кавказ һәм Русиянең башка шәһәрләрендә Сезнең әсәрләреңезне без, «Сәйяр» труппа артистлары, бөтен гали[10] хисләремез илә вөҗүдкә чыгарыр[11] өчен иҗтиһад иттек. Без, «Сәйяр» труппа артист вә артисткалары, Сезнең ушбу гали хезмәтләреңезне тәкъдир итәмез. Яшә, Галиәсгар әфәнде! Яшәсен Сезнең куәи тәхририяңез[12]!

«Сәйяр» труппа артистларыннан: С. З. Гыйззәтуллина, Ф. Сәмитева, Ф. Әхмәдева, Ә. Мостафина, Г. Кариев, В. Мортазин-Иманский, Г. Мангушев, Ә. Кулалаев, Г. Болгарский, К. Шамил».

Буны сөйләгәннән соң, тагы тынычсызлык, тагы шау-шу, тагы тәбрик, тагы «Яшәсен!»нәр кычкыру башланды.

Зал бераз тынычлангач, Галиәсгар әфәнде, халыкка каршы торып, аларның тәбрик вә алкышларына каршы кыскача гына рәхмәт сүзе сөйләде. Шуннан соң халык, һич шөбһәсез, Галиәсгар әфәндегә каршы эчләрендә әллә нинди олугъ мәхәббәт уянганы хәлдә, күңелләре тулып таралыштылар. Ихтимал, шул халык арасында иң нечкәргән күңеллесе мин булганмын.

Затән, гаммәи халык[13] алдында күп сәнәләр хезмәт иткән бер кешегә кычкырып торып: «Син мөхтәрәмсең, синең эшең халык файдасына булды. Синең язганнарың

---

[1] *Иттифаксызлык* – оешмаганлык.
[2] *Парлак* – данлы.
[3] *Мәукыйг* – урын.
[4] *Мөнтәшир* – таралган.
[5] *Мәүҗүд тәрәккъыятнең әсәрләре* – алга китеш билгеләре.
[6] *Мөстәгыйть* – сәләтле.
[7] *Асары тәрәккъыятеннән улан* – алга китеш-үсеш билгеләре булган.
[8] *Әда кыйлу* – үтәү.
[9] *Мөддәт* – вакыт.
[10] *Гали* – бөек.
[11] *Вөҗүдкә чыгару* – дөньяга чыгару.
[12] *Куәи тәхририя* – язучылык көче, сәләте.
[13] *Затән, гаммәи халык* – асылда, халык массасы.

мәңге безнең күңелемездә калачак!» — дип игълан ителгән мәкаддәс бер чакта, мәгъһуд[1] кешегә үз рухының матур ягын вә идеалының изге икәнен халык күзгесеннән үз күзенә күрсәткән чакта, күңеле тулмаган кеше таш йөрәкле булырга тиештер.

Минем күңелемдә Галиәсгар әфәнде әсәрләренә моннан әллә ничә еллар элек, ярты сабый вакытымдук, мәхәббәт орлыклары чәчелгән иде. Аның әсәрләрен бу елларда сәхнәдә күрә-күрә вә муаффәкыятьле чыкканнарына тәгаҗҗеб итә-итә[2], шул мәхәббәт һаман үсә бара, тамыр җәя барадыр.

Мин, юбилей кичәсендә Галиәсгар әфәндене алгы сафтан торып, тамагым карылганча кычкырып тәбрик иткәнем кеби, хәзер дә тәбрик итәм: «Мөбарәк Сезнең 10 еллык хезмәтегез!»

Һәм дә татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә мәҗһүл[3] почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтергә каләменең көченнән килгәнлегенә хәйрат итәрәк[4], аны, Галиәсгар әфәндене, «татар Островские» наме мөкәррәм вә мөстәхәкки белән тәгъзим итеп[5], сүзне бетерәм.

Габдулла Тукай

Габдулла Тукай

Габдулла Тукай (1886–1913) — татар халкының бөек шагыйре, тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать эшлеклесе һәм тәрҗемәче.

[1] *Мәгъһуд* — шушы.
[2] *Тәгаҗҗеб итү* — гаҗәпләнү.
[3] *Мәҗһүл* — билгеле булмаган.
[4] *Хәйрат итү* — хәйран калу.
[5] *Наме мөкәррәм вә мөстәхәкки белән тәгъзим итү* — хөрмәтле вә лаеклы исеме белән олылау.

ХӘТЕР САГЫШЫ

(Кыскартып бирелә)

Аклар Казанга кергәч...

1918 елның җәе. Август аеның беренче көннәре. Без семьябыз белән Яңа Аракчино авылында дачада торабыз. Әти ул вакытта «Эш» газетасы редакциясендә хезмәт итә. Иртән эшкә китеп, Казаннан кичке поезд белән генә кайта. Мин инде ул вакытта укырга-язарга өйрәнгән, әти белән балыкка, урманга җиләккә, гөмбәгә йөри ала торган ун яшьлек бала...

Безнең үз әниебез Бибигайшә салкын тиюдән үлеп киткән иде. Яшь әни *Әсманың* әтигә кияүгә чыгып яши башлавына берничә ай гына. Безнең, өч ир баланың, үги ана кулында калуыбыз өчен әти бик борчыла булырга кирәк, ул күбесенчә безнең янда калырга тырыша, кайгырта, үткен, көлке сүзләр сөйләп, безне юатырга тырыша. Ләкин яшь әниебез бик ачык күңелле, кешелекле, бала җанлы булып чыкты, тиздән ул — безгә, без аңа ияләштек.

Көннәрнең берендә, әтинең ял көне булса кирәк, без балконда җыелышып чәй эчеп утырабыз... Әти Идел өстенә дикъкатьле караш ташлады. Без дә, аптырап, күзләребезне шунда текәдек. Берничә буксир һәм зуррак катерлар Казанга таба хәрәкәт итә иде...

Без, бер әтигә, бер Идел өстенә карап, ниндидер куркыныч барлыгын сизендек. Безнең күңелләрне шомландырган сорауга җавап буларак, Ослан тавы башыннан гөрселдәтеп туптан аттылар. Әти кесәсеннән сәгатен чыгарып карады. Куен дәфтәренә нидер язып куйды...

Әти, әрле-бирле йөренүеннән кисәк туктап, сабыр гына:

— Җыеныгыз, сугыш башланды! — дип куйды.

Берничә минуттан соң инде без калын урман эчендәге комлы юлдан барадыр идек. Әти, бер кулына зур төен күтәреп, муенына Зөфәрне атландырган. Әни дә әйберләр күтәргән һәм Мөхәммәтне җитәкләп әти артыннан чаба.

Галиәсгар Камал һәм Әсма ханым 1918

Әсма Сәгъдиева (1887—1941) — Галиәсгар Камалның икенче хатыны, дүрт бала (Фаикъ, Фәрит, Наилә, Рәфыйка) әнисе.

Мин, Зәйнәп апа белән Ситдыйка апа, алар артыннан калмаска тырышып, авыр комны ера-ера ашыгабыз. Яланаякка нарат күркәләре, ылыслары кадала, тирләгән муеннарга озынборыннар ябышып җәфалый...

Кичкә кадәр урман арасында чокырларда яшеренеп яттык. Туп тавышлары, атышлар көн буена туктамады...

Ул көнне аклар Красная Горка[1] авылыннан еракка үтә алмаганнар. Шунда бик каты сугышлар булып, аклар кызылларның кысуы нәтиҗәсендә «Иске Аракчино», «Лагерьная» станцияләренә кадәр чигенергә мәҗбүр булганнар.

Кичкырын атышлар тынды. Без урманнан дачабызга әйләнеп кайттык. Ишекләр каерылган, тәрәзәләр ватылган. Өй эчендә ак солдатлар салып ташлаган иске, пычрак күлмәкләр, каткан аяк чолгауларыннан башка берни дә юк. Самоварга кадәр калдырмаганнар. Ишек төбендә озын йонлы ак ангор куяннарымның кып-кызыл канга буялган тиреләре ята. Туздырылган мендәрләрнең йоннары очып йөри.

Без кабат, Яңа Аракчиноны бөтенләй ташлап, урман аша Карауҗа дигән авылга чыгып киттек. Ул авылда әтинең бажасы Йосыф абыйлар тора иде.

Караңгыда кара урман эченнән җәяүләп бару зур газап булды. Барыбыз да арып эштән чыктык... Өстерәлеп атлый торгач, урманны аркылы чыктык... Беренче очраган Осинское дигән авылга туктап ял итмәкче булдык.

Аннан башка да куркынып беткән крестьяннар безне бик тиз генә өйләренә кертергә теләмәделәр. Без, тәрәзә саен туктый-туктый, урам буенча йөрдек. Соңыннан берсенең мәрхәмәте килде. Ул зур гәүдәле, озын кара чәчле, көрәктәй сакаллы рус агае иде...

Чәйләр эчеп бераз тын алгач, безнең йоклыйсы, ял итәсе килә башлады. Ләкин безнең баш очына салырга да, өстебезгә ябынырга да бернәрсәбез юк иде. Үзе дә ярлы авыл агае безнең өскә карап торды-торды да әтигә сорау бирде:

— Балаларыгыз да шактый күп икән, талангансыз да... Инде дөньяда ничек яшәрбез дип уйлыйсыз? — диде.

Әти, бер дә аптырап тормыйча, мыек астыннан гына көлде дә кинәт жилет кесәсеннән никель саплы ручкасын чыгарып күрсәтте.

— Һәй, менә шушы исән булсамы!.. Бу исән булганда, без һичкайчан да, бервакытта да аптырамаячакбыз! — диде.

Әтинең кыяфәте шулкадәр җитди, торышы шулкадәр горур иде... Гаҗәпсенгән рус агае, ялтырап торган ручканың нурыннан күзләре чагылгандай булып, артка тайпылды. Аннан аның хәтәр әйбер түгел икәнлеген күргәч, бик кадерләп кенә кулына алды, бөтен ягын әйләндергәләп карарга тотынды. Алай да төшенмәгәч, каләмле башын ачып, аңа да күз салды. Аптырагач:

— Әллә бу алтыннан ясалганмы? — дип сорады.

Әти рәхәтләнеп көлде. Крестьянның җилкәсеннән кочып, өстәл янына утыртты да:

— Һәй, алтындамыни хикмәт... Хикмәт менә кайда ул! — дип, киң маңгаена бер чәпәп алды. Крестьянны янына утыртты да үзенең язучы булуын, китаплар язуын, иҗат эше белән шөгыльләнүче кеше икәнен аңлатты. Крестьяндагы гаҗәпләнү бөтенләй югалмаса да, ул әтинең бөтенләй үк пустяк кеше түгеллегенә ышанды да аны олыларга, кунак

---

[1] *Красная Горка* — хәзерге Юдино станциясе һәм посёлогы.

итәргә кереште. Сәндерәдән, мич башларыннан толыплар, мендәрләр сөйрәп төшерде, барыбызга да йомшак урыннар җәйде.

Таң атып, яктырып килә башлаган вакыт иде, ерактан тагын туп тавышлары ишетелә башлады. Әти белән теге рус агае, шуларны тыңларга дип, тау башына җыелган халык арасына чыгып киттеләр. Мин дә тәрәзәдән үрелеп карадым: тау артыннан ерактагы янгын кызыллыгы күренә иде. Безнең йокы туймаган иде әле, изрәп йокыга киттек.

Әтием портреты

Уртачарак буйлы, юантыграк гәүдәле, киң күңелле һәм шат чырайлы кеше иде ул. Ләкин аның башын түбән иеп, кулын артка куеп, моңсу йөргән чаклары да бар иде. Ни өчен дисәгез, аның гомере шул заманның авыр, алмашынучан чакларына туры килде. Аңа гомерендә ике тапкыр өйләнергә туры килеп, ун баланың атасы булды...

Әгәр дә комсыз, гел үз файдасын гына күзәтүче булса, ул шул заманның бае яки түрәсе дә була алыр иде. Чөнки андагы акыл һәм ихтыяр көче аңарга гына җитәчәк иде. Ләкин ул кирәгеннән артык гадел, гаҗәеп намуслы, олы җанлы, рәхим-шәфкатьле кеше булып яшәүне артык күрде. Шуңа да ул зур кыенлыкларга һәм кире кагуларга дучар булды. Дан артыннан кумады — ул аңа үзе килде. Кулы алтын, киләчәге якты булганлыктан, аның өчен «кара көннәр» юк иде. Ул бүген тапканына канәгать булды, һәркайчан эшлекләләргә юл куйды, мохтаҗларга булышты. Кайбер мәгънәсез, вак җанлы кешеләр моны аның йомшаклыгыннан, көчсезлегеннән килә дип уйладылар, җае чыкканда аның ярдәменнән файдаланып, җилкәсе аша югарыга үрләделәр, соңыннан ашаган табакларына төкерүчеләр дә табылды. Ул кешеләрне үтәдән-үтәли күрә алды, шуңа күрә ул бер сынаганны икенче сынамады — дусны дошманнан аера белү сәләте гаять көчле иде аңарда. Тугрылык, дөреслек аның тормышы өчен нигез ташы, көрәше өчен нык платформа иде. Ул шул нык нигез өстенә горур басты да, җил-давылларда да кымшанмыйча, нурлы киләчәкне колачын җәеп каршылады. Тик ул үзе тынычлык күрмәде — башы халык мәшәкатьләреннән чыкмады. Бу борчуларның, бу кайгыртуларның барысы да киләчәк буынның якты бәхете өчен иде.

Г. Камал гадел булмауны, сүлпәнлекне һәм тәртипсезлекне күралмады. Чатак якларны бик тиз шәйләп алды һәм аңа түземлеге җитмәде — кемнең кем, хәтта туган-тумача булуына карамастан, гаепләне аяусыз тәнкыйть уты астында калдыра торган булды. «Тугры әйткән туганына да ярамас» дигәндәй, аның мондый тугрылыгы коры куыкларга бер дә ошамады. Шуңа күрә кайберәүләр аңа, тикшеренеп, күпне күреп йөрмәслек итеп, җыен юк-бар эшләрне өя генә тордылар, аны башын да калкытмыйча эшләргә, ерып чыга алмаслык кәгазь арасында күмеп калдырырга тырыштылар.

Соңга табарак аның зур хезмәтләр өстендә утырырга вакыты да калмый — ул эштән бик арып кайта иде. Шулай да ул күп эшләде. Татар мещан тормышын нык чыбыркылаган «Көндәш» һәм «Өйләнәм!.. Ник өйләндем?» кебек комедияләреннән тыш динчеләрне, аларның төрле махинацияләрен фаш итә торган «Ахыр заман», «Суфины өйләндерделәр» кебек сатирик пьесалар да тудырды. «Җан Таһир белән Җан Зөһрә» кебек пародия-комедия һәм «Хафизәләм иркәм» кебек музыкаль комедия, «Күзсез мастерлар», «Өч тормыш» шикелле инсценировкалар да язды. Болар барысы да йокы исәбенә, ял итүдән ваз кичү исәбенә язылган әсәрләр булды.

* * *

Һәр көнне ул кичке алтылар тирәсендә эштән кайта. Әни ашны өлгертү белән, без инде, өч-дүрт бала, тәрәзәгә сарылып, аның Фукс урамы чатыннан килеп чыгуын дүрт күз белән көтәбез. Озак та үтми, өстенә соры плащ кигән, җилкәсе бераз чыга төшкән эти күренә. Без, шатланышып, кухняга, әнигә хәбәр итәргә йөгерәбез. Әни аш соса башлый, без кайсыбыз икмәк турыйбыз, кайсыбыз тәлинкәләр тезәбез. Ул, кайтып керү белән, өстен чишенеп, кулларын юганнан соң, залдагы өстәл янына куелган, инде пружиналары какшап беткән кәнәфигә барып утыра.

Күзлеген киеп, газеталар карый башлый. Әни аш сосып бетерә, ләкин эти, газетадан аерыла алмыйча, һаман укуын дәвам иттерә. Ашны ул беркайчан кайнар килеш ашамый иде.

Аш тәмам суынып бетә башлагач, әни:

— Галиәсгар, йә инде, ашны тәмле чагында аша! — димичә булдыра алмый.

Эти, йокыдан уянган кешедәй сискәнеп:

— Ә... шулаймы? — дип куя да ашык-пошык ашарга тотына...

Аның язу өстәле өстендә үз тәртибе бар. Бер кырыенда китаплар, күбесенчә төрле сүзлекләр өелеп тора...

Язу өстәле тартмаларының берсендә язылмаган кәгазьләр, икенчесендә языла башлаган әсәрләр. Һәрнәрсә үз урынында, ул аларны кайдан алса, шунда куя. Әйбер урыныннан аз гына кузгатылган булса да, ул аны шунда ук сизә һәм мондый тәртипсезлекне тудыручыга нык үпкә белдерә. Ул моны эшкә хөрмәт күрсәтмәү дип карый. Мондый мәгънәсезлек күрсәтүчене бик каты шелтәли. Шуңа күрә безнең өйдәгеләр этинең өстәле янына якын да бармыйлар, аны бер изге урынга исәпләп йөриләр иде.

Ул эш алдыннан тегене аннан, моны тегеннән эзләп вакыт үткәрми. Чиста кара савыты, яхшы каләмнәр, очланган карандашлар һәркайчан үз урынында. Иң элек ул күзлеген кия (ул аны 1922 елларда эш вакытында гына кия башлады. Югыйсә ул бик ерактан күрә алучы үткен күзле иде), бер кырыйга лупасын алып куя (монысы тагын да соңрак елларда, бигрәк тә вак хәрефле сүзлекләр караганда куллану өчен кирәк була башлады)...

Этинең эшләвендә башка язучыларда аз очрый торган бер алым бар: ул һичбер вакытта карага язмый иде (караламасы булмый иде диярgә мөмкин). Иң элек ул язачак әсәрен башында эшләп, иң нечкә детальләренә кадәр уйлап бетергән була. Аны иптәшләренә сөйләп күрсәтү гадәте дә бар иде. Ләкин ул аны төрле дустына төрлечә үзгәртеп сөйли, шушы формада, иптәшләренең әсәрне ничек кабул итү тәэсиренә карап, иҗат фантазиясен тиешле якка борып җибәрә. Соңыннан инде иптәшләренә һәм үзенә кайсы сюжет варианты ошый төшсә, ул шунысын язарга карар кыла, шуннан соң гына эшкә утыра...

Кулъязмада үзенә ошамаган урыннар — аерым битләр, хәтта сүзләр була икән, ул аны бозып куеп, шуның өстенә яки кәгазь кырыена төзәтеп кенә калмыйча, шул битне баштан ахырынача чиста итеп күчереп чыга һәм теге бозылган битне шунда ук ертып ташлый. Болай эшләү, әлбәттә, күп вакытны ала, ләкин инде кулъязма авторның үзе тарафыннан ук редакцияләнгән, кул тидермәслек төгәлләнгән булып чыга...

Әнәс Камал

«60 ЯШЕМӘ КАДӘР ДӘҮ ӘТИ ЙОРТЫННАН АЕРЫЛМАДЫМ»[1]

(Журналист Люция Хәбибуллинаның Галиәсгар Камал оныгы Фидакарь Камалетдинов белән әңгәмәсеннән өзек)

– Галиәсгар Камал турында истәлекләрне беренчеләрдән булып кемнән ишеттегез?

– Безгә еш кына язучылар килә иде. Шулай ук Салих абый Сәйдәшев килеп йөрде. Мин аларның сөйләшкәннәрен ишек артына басып тыңлап тора идем. Шунда дәү әти турында да сөйлиләр иде. Аның унике баласы дөньяга килгән. Шуларның алтысы гына исән-сау үскән. Туган берсенең исемен аерым бер затлы тышлы китапка язып барган ул. Башта минем исемне Рөстәм дип куярга ниятләгәннәр, аннары, аны сызып, Фидакарь дип язып куйган. Аның вафат булган Фаикъ исемле улы истәлегенә үзебез дә улыбызга шул исемне бирдек.



Фидакарь Камалетдинов

– Сез яшәгән Нариман урамындагы төзекләндерелгән йортыгыз бүген дә бик күп хатирәләр саклый...

– Дәү әти яшь чагында ул йортны булачак кәләшенең әтисе бүләк итеп бирә. Шуның өстенә сарае, кибете була. Ишегалдындагы йортта асраулар яши. Әти яшь чагында шул сарайга урамдагы балаларны җыеп, алар белән спектакльләр куя торган булган. Энеләре Фаикъ белән Зөфәрне дә шунда уйната. Алар да бик талантлы була. Кызганыч, икесе дә яу кырыннан кайта алмаганнар. Дәү әтиләрнең йортыннан беркайчан да кунаклар өзелми. Ул чит телләр белгән. Төннәр буе тәрҗемә эше яисә язу белән шөгыльләнгән. Үз акчасына театрга декорацияләр эшләткән, киемнәр тектергән.

– Сезнең озак еллар дәү әтиегездән калган йортта яшәвегезне беләбез.

– Әйе, 60 яшемә хәтле фатирыбызда яшәмичә, анда дәү әти өстәлендә йоклап йөрдем.

---

[1] Шәһри Казан. – 2014. – 21 август (№ 92). – 9 б.

Торбалар шартлый башлагач кына, аннан аерылырга туры килде. Хәзер ул шәһәр карамагында санала.

— Үз балаларыгызга нәсел шәҗәрәгезне сөйлисезме?

— Узган ел гына әле шул йортка җыелып, бөтен туганнарны искә алдык. Алар Камаллар нәселе турында хәбәрдар.

— Балаларыгыз сәнгатьне үз итмәдеме?

— Әти сыман, мин дә аларның сәнгать юлыннан китүен теләгән идем. Әмма алар башка һөнәр сайлады. Улыбыз төзелештә, кызыбыз Алсу шеф-повар булып эшли. Бер оныгыбызга дәү әти хөрмәтенә Галиәсгар исеме куштык. Бәлки, киләчәктә оныклар иҗат кешеләре булып китәрләр.

УЛ ШУНДЫЙ ИДЕ

(Кыскартып бирелә)

I

1918 елның көзе иде.

«Эш» редакциясе ишеге төбенә барып җиткәч, эчләре катып көлешкән тавыш ишетелде.

Берәү калын тавыш белән көйләп нәрсәдер укый, калганнары көлешәләр.

— Редакциягә әллә берәр суфи килгәнме, мөнәҗәт укый, — ди иптәшем.

Без тышкы яктан гына тыңларга тотындык. Минем колакка, пышылдап кына:

— Бу нинди көлке китап икән? — ди әлеге янымдагы кеше.

— Әйдә, керәбез. «Тәкый гаҗәп»[1] укыйлар, — дим аның сүзенә каршы.

Без икебез дә шигырьләр китергән идек. Аллы-артлы тиз генә редакция бүлмәсенә кереп киттек.

Галиәсгар абзый, тар, озынча кәгазьне кулына тотып, бүлмә уртасына чыгып баскан да «Яңа "Тәкый гаҗәп"» дигән шигырен укырга тотынган икән. Ә редакциядә эшләүчеләр, кайсы өстәлгә таянып, кайсы баскан килеш, Галиәсгар абзыйга күзләрен терәгәннәр дә көләләр дә көләләр...

Галиәсгар абзый үзе һич көлми. Төсен үзгәрткән, галим тавышын борыныннан чыгарып укый да укый. Күзен йомган, ара-тирә тамагын кырып, йөткереп тә куя. Читтән карап торганда, нәкъ сукыр суфи дип торырсың. Кыяфәте дә көлмичә чыдарлык түгел иде. Без кергәндә, ул, тыңкыш тавыш чыгарып:

> Лебедев[2]: «Казаннан һич чыкмыйбыз, — ди, —
> Большевикны Казанга кертмибез», — ди.
> Үзе тизрәк качып китәргә юл эзли,
> Мондыйн артык тәкый гаҗәп дыңларый бар, —

дип, шигырен сөйләвендә дәвам итә иде.

---

[1] *«Тәкый гаҗәп»* («Тәкый гаҗәб») — тезмә белән язылган дини китап, революциягә кадәр схоластик мәктәпләрдә дәреслек буларак кулланылган.

[2] *Лебедев* — 1918 елда Казанга кергән контрреволюцион ак чехларның гаскәр башлыгы.

Ул шушы юлларны укыган арада, редактор ак кәгазь кисәкләрен коймак зурлыгында кайчы белән түгәрәкләп кисә тора. Башта без аның сәбәбенә төшенмәгән идек.

Галиәсгар абзый үзенең шигырен укып бетергәч, әлеге редактор, көлә-көлә:

— Суфи абзый, сәдака бирергә безнең акчабыз юк инде, менә шул коймактан бераз авыз итегез, — дип, әлеге түгәрәкләп кискән кәгазьләрне өстәлнең читенә өеп салды.

Кайсыдыр аңарга урындык китереп куйды. Галиәсгар абзый, һичбер көлми-нитми генә, урындыкка утырып:

— Мәшәкатьләнү кирәкмәс иде, мелла кем, мин өченче көнне генә ашап чыккан идем. Ярый, алай булса... — дип, әлеге кәгазь кисәкләрен коймак итеп «ашарга» тотынды.

Әйтерсең аның алдында майлары агып торган коймаклар өелеп тора. Башта ике бармак очы белән генә коймакны тотып, дүрткә бөкли. Аннан соң ике иренено тидермичә генә кабып чәйнәргә тотына. Чәйнәп йотканнан соң, кәгазь кисәген салфетка иткән булып, кулларын, авызларын сөртеп куя да тагын икенчеләренә тотына. Коймакны шулкадәр оста, шулкадәр килештереп, нәкъ суфиларча ашый ки, монда инде көлә-көлә күзләрдән яшьләр тама башлый. Шунысы бик гаҗәп: кәгазьләрнең берсен-бер калдырмый йотып барган шикелле күренә. Күзеңне алмый, тырышып-тырышып карап торсаң да, кәгазьләрнең авызыннан кире чыкканы бер дә күренми.

Ашап бетерде дә, авызларын, кулларын сөртеп, дога кылырга булып, учларын күтәрде һәм:

— Аллаһеммә атыйна, мулла кызы Фатыйма, чүбек тулган башына... — дип, озын итеп кикереп куйды. Аннан, әлеге кәгазь кисәкләрен җиң эченнән чыгарып: — Мәгез коймакларыгызны, — дип, урынына барып утырды һәм үзе дә калын тавыш белән көлергә тотынды.

«Кызыл Татарстан»да эшләгән чакта да көндезге чәй вакытында: «Йә әле, Галиәсгар абзый, коймак ашап күрсәт әле», — дисәң, хәзер ашап күрсәтергә тотына иде. Аңарда ялындырып тору гадәте юк иде.

Аның әлеге шигыре өченче көнне генә «Эш» гәзитәсендә «Әүлия һәм компаниясе» дигән имза белән басылып чыккан иде. Бүгенге тамашадан соң гына без ул имзаның иясе кем икәнен белдек.

Моңа кадәрле аны бик җитди, тәкәббер, эре холыклы кеше дип уйлый идем.

Бу очрашудан соң аның гаять күңелле, уенчак кеше икәнлеге, комик вакыйгаларны чын артистларча оста гәүдәләндерүче икәнлеге беленде.

Хәтеремдә ялгыш калмаган булса, чехословак бандалары Казаннан куылганга бары ун-унбиш көн генә үткән иде булса кирәк. Бу вакытта аның каләме ыгы-зыгы килеп йөргән милләтчеләргә, байларга каршы юнәлгән, алардан ачы көлү белән көлә иде.

Редакция халкы җитди төскә кергәч, мин, «Эш» гәзитәсенең редакторы каршысына барып:

— Мин бер поэма китергән идем сезгә, — дидем.

Редактор поэманы кулына алды. Исемен һәм күләмен күз каравы белән генә чамалады да шунда бүлмәдә утырган Галиәсгар агага эндәште:

— Галиәсгар абзый, менә бу әйберне карап чык әле, — диде.

Галиәсгар абзый урыныннан торды, әкрен генә килеп, редактор кулыннан минем поэманы алды да иң элек минем имзага күз төшерде.

— Ә, синмени әле ул Кәримәм ире? Нигә алай карчыкларны кыйнап йөрисең? Менә хәзер генә бер карчык, килеп: «Кәримәм ире кыйнады», — дип, өстеңнән жалоба бирде, — диде.

Мин аптырап киттем. Уңайсызландым, ни әйтергә дә белмичә калдым. Тез буыннарым калтырап китте.

— Мин түгелдер ул, Галиәсгар абзый, минем бернинди карчыкны да кыйнаганым юк, — дигәч, ул һаман:

— Менә, булмаса, иртәгә газитәгә чыккач күрерсең, — ди, ә үзе бер дә көлми, җитди кыяфәт, җитди тавыш белән мине орыша.

Ни әйтергә дә белмәдем, җитмәсә, бөтен сотрудникларның күзе миндә генә, алар да, Галиәсгар абзыйның орышканына кушылган кебек, миңа карап торалар.

— Үзең шагыйрь кеше. Әллә мондый гадәтне аклардан өйрәнеп калдыңмы? — дигәч, бөтенләй калтырап төштем. Редакциягә ник килгәнемә үкенә башладым.

Минем кыяфәтне күреп торган редактор чыдамады, кычкырып көлеп җибәрде. Шуннан соң гына Галиәсгар абзый үзе дә көлергә тотынды.

— Әй, Галиәсгар абзый, котымны алдың! — дидем.

Галиәсгар абзыйның минем «Кәрим Әмири» дигән имзамны «Кәримәм ире» дип юри шаяртып әйтүе икән.

Минем Галиәсгар абзый белән ныклап танышуым әнә шулай башланды.

Ул, минем поэманы укып чыккач, бераз уйланып торды да сигез йөз юллык әсәрнең кайда, нинди җитешсезлекләре барлыгын күрсәтә башлады. Иң гаҗәбе шунда: укып чыкканда очраган җитешсезлекләрне ул каләм белән бер дә билгеләп бармады. Ул аларны бары күңелендә генә калдырып барган икән.

— Менә синең фәлән биттә шундый нәрсә, фәлән биттәге куплетыңны шулай итеп эшлә, — дип күрсәтә башлагач, аның шәп хәтерле икәнлегенә, нык әһәмият биреп укуына исем китте.

Галиәсгар абзыйның беренче ризасызлыгы рифмалар мәсьәләсендә иде.

— «Алдылар», «бардылар» кебек фигыльгә генә беткән рифмалар искерде инде, — диде ул. — Менә фарсы шагыйрьләреннән Фирдәүси үзенең мең юллы бер поэмасын аһәңле-гармонияле укучының күңелен дулкынландырырлык рифма белән язып чыккан. Аның бер юлындагы рифмасы исемгә бетсә, икенче юлдагы рифмадаш сүз фигыльгә яисә сыйфат, алмашлык һәм ымлыкларга беткән була. Шуның өчен дөнья әдәбиятында аның шигырьләре техник яктан иң мөкәммәл эшләнгән шигырьләрдән санала да, — дип, шунда ук миңа Фирдәүсинең кайбер шигырьләреннән үрнәкләр дә укып күрсәтте.

Бу минем «Даһи» исемле беренче поэмам иде, ул поэма, Галиәсгар абзыйның күрсәтмәләре белән төзәтелеп, «Эш»тә басылды.

III

Ул редакциядә юк иде. Вакыт соң, эш вакыты беткән. Тик секретарь гына соңгы материалларны карап, типографиягә җибәрергә ашыгып утыра иде.

— Галиәсгар абзый киттемени? — дидем.

— Әйе! — диде секретарь, башын күтәрми генә.

Аңардан адресын сорап, Галиәсгар абзыйның өенә киттем. Хәзерге Нариман урамына кергәч, чал сакаллы, нәзек кенә калдырып кырган мыеклы юан гына бер кешедән:

— Сез белмисезме, Галиәсгар Камалның өе кай тирәдә икән? — дип сорадым.

— Театрчы Камалмы? Әнә! — дип, кулындагы таягы белән Галиәсгар абзыйның өен төртеп күрсәтте.

Шул өйгә туры кереп, ишек шакып сорадым. Хуҗаның типографиягә киткәнлеге беленде.

«Театрчы Камал» дигән сүзне моңа кадәр ишеткәнем юк иде. Чыннан да, Печән базары халкы аны «театрчы Камал» дип кенә йөртә икән.

Типографиягә кергәч, аны «Эш» газитәсенең корректурасын укып утырган хәлдә таптым. Ул, мине күргәч үк:

– Ә, менә яхшы булды әле, үзең килдең. Мә, шигыреңне укып чык. Хаталарын төзәтә бар! – дип, «Ике дус» исемле поэмамның гранкаларын тоттырды.

Мин, Галиәсгар абзыйга «Бакырган» китабын биреп, гранкаларны укырга тотындым. Ул вакытта мин корректура хаталарын типография тәртибенчә күрсәтә белми идем әле. Шуңа күрә хата төшкән хәрефнең өстенә дөрес хәрефне язып кына бара башладым. Минем шулай төзәтүемне Галиәсгар абзый күзәтеп тора икән.

– Алай түгел, хата төшкән хәрефләрнең өстенә аркылыга сызып кына чык. Ә нинди хәрефкә алмаштырырга икәнен кәгазьнең читенә сызып, дөрес хәрефне шунда язып куй! – дип, мине корректура карарга өйрәтә башлады. Шул арада: – Бездә яхшы корректорлар юк. Берүземә генә авыр. Иртән редакциядә, кич редакциядә эшләгәч, иҗат эшләренә вакыт бик аз кала. Син безгә керсәң, мин сине өйрәтер идем. Бергәләп эшләр идек, – дип тә өстәде.

Галиәсгар абзыйның бу сүзен бик хуплап каршы алдым һәм аңарга эшкә керү теләгем бик зур икәнлеген аңлаттым. Шуннан соң ул:

– Иртәгә кил, мин, редактор белән сөйләшеп, эшне бетереп куярмын. Безгә кеше бик кирәк! – диде.

Иртәгәсен килдем. Чыннан да, Галиәсгар абзый «эшне бетереп» тә куйган икән.

Шул көннән башлап мин Галиәсгар абзый белән бергә эшли башладым.

Ул иртә белән редакциядә дә, типографиядә дә эшли иде. Шуның белән бергә драма әсәрләре яза, вакыт табып, үзенең шигырьләрен әдәбият кичәләренә дә барып сөйли иде.

Ул бик пөхтә яза, төзәтергә урын калдырмый. Язган нәрсәсен эшләп бетергәч, укып чыгу гадәте дә юк иде.

– Ничек шулай бик чиста, хаталар җибәрми яза аласың? – дигәч, Галиәсгар абзый:

– Миңа язудан төзәтүе авыррак. Мин аңарга гадәтләнмәгән. Шуңа күрә берьюлы эшен бетереп барырга тырышам, – ди торган иде.

Копияләрен алдырып бармаганга күрә, аның кульязмалары кеше кулында кала яисә югалып та бетә иде. Берәр инсценировка яисә шигырь язса, аны куярга һәм сөйләргә алып китәләр дә кире кайтарып бирмиләр иде. Әдәбият кичәләрендә шул көнгә бәйләнгән вакыйгаларны сәхнә артында артистларга язып бирү яисә шул язганын үзе чыгып сөйләү аның өчен һәрвакыт гадәти бер хәл иде.

VI

1920 елның башында «Эшче» газитәсе Мәскәүдән Казанга күчте. Февраль аенда чыга да башлады. «Эш» белән «Эшче» редакциясе бер йортта иде. Галиәсгар абзый «Эш»тә эшләсә дә, аңарга «Эшче» редакциясе дә тәрҗемә эшләрен биргәли иде. [...]

Ә инде шул язны «Эш» газитәсе «Эшче»гә кушылгач, Галиәсгар абзый бөтенләй «Эшче» редакциясенә тәрҗемәче булып эшкә урнашты.

«Эшче» яңадан Мәскәүгә күчерелгәч, ул байтак елларга кадәр «Татарстан хәбәрләре»ндә тәрҗемәче булып эшләде. Ул вакытта аның белгеле нормасына кадәр

төп хезмәт хакы бар иде. Нормадан артык эшләгән өчен гонорар да ала иде. Ләкин «Татарстан хәбәрләре»нә Атнагулов редактор булып килгәч, Галиәсгар абзыйны игъланнар бүлегенә күчерделәр. Бу вакытта инде ул төп хезмәт хакы белән генә калды, һәм аның ставкасы да зур семьялы кешегә җитәрлек түгел иде. Ә игъланнар бүлегенең эше бик күп һәм бик вак эш иде.

Бу бүлеккә күчерелүенә ул бер дә риза түгел иде. Ләкин Атнагулов:

— Йә ризалыгыңны бирәсең, йә чыгасың, — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйгач, ул ихтыярлы-ихтыярсыз күнәргә мәҗбүр булды.

Ул нинди генә хәлдә дә эшкә вакытында килә иде. Шулай ук аның көндәлек эшне икенче көнгә калдыру гадәте дә юк иде. Атнагулов ни өчендер Галиәсгар абзыйны кага, аңарга яхшы гонорарлы эш бирми иде. Бераздан Атнагулов аны бөтенләй редакциядән китәргә мәҗбүр итте. Шул вакытта Галиәсгар абзыйның борчылуын бергә эшләгән иптәшләр әлеге көндә дә хәтерли торганнардыр.

Бу 1925 елның җаендә булды. Шуннан соң ул театр өлкәсенә эшләргә китте. [...]

IX

Галиәсгар абзыйның хәтере бик яхшы иде. Нинди генә вак мәсьәлә булмасын, кайчан гына нинди эш эшләнмәсен — аның хәтерендә һәммәсе саклана иде. Шулай ук нинди генә китапны укып чыкмасын, аны бөтен-бөтен ваклыклары белән сөйләп чыга ала торган иде. Әгәр дә белмәгән нәрсәсе булса, ничек кенә, кемнән генә булса да белергә тырыша торган иде. Мәсәлән, ул мәдрәсәдә вакытта ук төрек әдәбияты, төрек матбугаты белән мавыгып китә. Аны ул болай дип сөйли торган иде:

— Мәдрәсәдә укыган вакытта ук театр эше белән кызыксына идем. Качып-посып булса да театрларга йөри идем. Шунда төрек телендә басылган «Зәваллы чуҗык» дигән театр әсәре кулыма төште. Шунда ук шуны татарчага тәрҗемә итү уена килдем. Ләкин төрек телен белмим. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дә сторож булып эшләүче бер төрек бар иде. Шуңардан төрек теле өйрәнергә тотындым. Аз вакыт эчендә төрекчә сөйләшергә, төрек әдәбиятын аңларга муаффәкъ булдым[1] һәм «Зәваллы чуҗык»ны «Кызганыч бала» исеме белән татарчага тәрҗемә иттем...

Шулай ук укытучылары биргән дәресне дә бер кат укып чыгу белән күңелендә калдыруын һәм шуның белән иптәшләре арасында иң яхшы укучы булып баруын сөйли торган иде.

X

Галиәсгар абзый һәрвакыт шат, һәрвакыт уенчак кеше иде. Үзенең сатирасын, юморын истә калдырырлык тирән мәгънәле итеп бирергә тырыша иде.

«Гажур»да[2] эшләгән вакыт иде, кемдер берәү билгеле бер артистның көн дә биш кадак ит, бер кәстрүл шулпа ашаганлыгын сөйләп шаккатырмакчы булды. Галиәсгар абзый аңарга каршы:

— Сәлах Атнагулов бөтен «Гажур»ны ашап бетерде, берәүнең дә исе киткәне юк әле, — дип куйды.

Икенче бер вакытны Такташның Ф. Сәйфигә нигәдер бик кәефе киткән. Аның әрсезлеген Такташ бер дә яратмый иде. Шунда Галиәсгар абзый янына килеп:

---

[1] *Муаффәкъ булу* — булдыра алу.
[2] *«Гажур»* — егерменче елларда Казандагы газета һәм журналлар нәшрияты.

— Галиәсгар абзый, Сәйфи белән кәҗә арасында нинди аерма бар? — дип сорады.

Галиәсгар абзый, бер дә уйлап тормыйча гына:

— Кәҗә — койрыгын, Сәйфи борынын күтәрә, аерма шунда гына, — дип куйды.

Шул сүздән соң Такташ мәрхүм бер рәхәтләнеп көлде дә:

— Мин «икесе дә әрсез» дип әйтмәкче идем, син ике мәгънәне аңлатып әйттең, — дип куйды.

1925 елны минем «Печән базары» дигән пьесам куелды. Шуның беренче постановкасы. Беренче пәрдәдә «Амур» ресторанны күрсәтелә. Пәрдә ачылыр алдыннан, Галиәсгар абзый:

— Мин «Амур»да һәрвакыт булам, гримсыз гына сәхнәгә чыгыймммы? — диде.

Пьесада аңарга, әлбәттә, сүз юк иде. Ул, пәрдә ачылгач, сәхнәгә чыкты. Гүяки ул «Амур»да сыра эчеп утыра...

Үзенең хәрәкәт, мимикалары белән көлдереп чыккач:

— Әсәрне тулыландырырлык берәр нәрсә эшли алдыммы? — дип сорады.

— Менә дигән булып чыкты, — дигәч, аның бик кәефе килде. Әсәрнең калган постановкаларын караучылар чыннан да аны юксыналар иде.

Үләр алдыннан, ул «Беренче театр» дигән әсәрен опера театрына либретто итеп эшли башлаган иде. Тәмам итә алмый үлеп китте. Эшләгән кадәресе кайда калгандыр, миңа билгеле түгел.

Кәрим Әмири

Кәрим Әмири

Кәрим Әмири (1893–1962) — татар язучысы, шагыйрь һәм драматург.

БЕРЕНЧЕ ТЕАТР

Комедия 1 пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Хәмзә бай – иске фикерле Казан бае; башында ак бүрек, яшел кәләпүш, өстендә намаз туны, аның эченнән бишмәт, эченнән кыска җиңле камзул кигән, чалбар балагын ак тасма белән бәйләгән.

Гафифә – Хәмзә байның кызы.

Вәли – Хәмзә байның кияве.

Хәбибрахман – Хәмзә байның улы, аңгыра.

Факиһә – Хәбибрахманның хатыны.

Биби – Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.

Фатих – Хәмзә байның кибетчесе.

Вакыйга Казанда, Хәмзә байның өендә.

Бай сымак бер өй. Ике якта икешәр ишек. Түрдә тәрәзәләр, тәрәзә арасында көзге. Стена буенда урындыклар. Сул тарафта бер диван. Аның алдында өстәл. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә Вәли күренә; өстенә пальтосын кигән, кулына таяк тоткан, күңеле бик шат, өйнең бер башыннан бер башына кызу-кызу атлап йөри.

Вәли *(кычкырып)*. Гафифә! Гафифә!

Гафифә *(булмәдән, сузыбрак)*. Әү!

Вәли. Буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам.

Вәли. Тизрәк бул! *(Халыкка таба карап.)* Гафифә дисәң Гафифә: бер җиргә бара башладың исә, кеше күрә дип коты чыга. Аның каршында ир кеше дигән сүз ерткыч җанвар дигән сүз белән икесе бертигез. Бары мин генә ул кадәр куркыныч-лы җанвар түгел. Башта миннән дә коты очты. Кияү булып кергәч, куркуыннан, куян шикелле, бер почмакка посып тик тора. Соңыннан, минем тарафтан шул яшенә җиткәнгә кадәр ата-анасыннан да ишетмәгән тәмле, татлы сүзләрне ишеткәч кенә, бераз җайланды. *(Ян ишеккә барып, ишеккә башын тыгып.)* Һи! Әле тиз генә буласың юк икән. Зинһар, тизрәк була күр! Әгәр каенатай кайтып керсә, аннан ары харап эш. Ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс. *(Башын бүлмә ишегеннән алып, халыкка таба карап, куллары белән хатын-кыз битенә пудра сөрткән төсле итеп күрсәтеп, бераз көлебрәк.)* Бизәнә: мич акшарлаган шикелле итеп, битләрен буяп маташа. Шулай да булса, үзенә килешеп тора тагын. Уйлап карагыз, әгәр мин шулай итеп битләремне буйый торган булсам, һич килешмәс иде бит! Онга төшкән таракан төсле булыр идем. Безнең бер асрау бар, йөзе менә нәкъ чуенның ундүртенче кичәсе төсле кап-кара. Беркөнне шул асрау, абыстайлары өйдә юк чагында, барган да минем Гафифәнең пу-

дырларын алып ягынган; бөтенләй менә, бигайниһи[1], бер ком гарәбенең битен акбурга буяган төсле булган. Көлешә-көлешә алҗып беттек. *(Бик җитди.)* Беләсезме? Ул бит пудыр күп кешегә килешми, хосусән[2] ирләргә бер дә килешми. Ә менә минем бер таныш егетем бар – Әхмәтҗан, ул һәр көнне өчәр мәртәбә сакалларын китәреп, пудырлар сөртеп йөри. Аңа килешә. Миңа бер дә килешми. Ул шул инде аксөяк нәселдән яратылган. Ә безнең нәрсә, без бит мужик! Безнең бабай сука сукалап үскән. Әти, чабата киеп, унике яшендә калага килгән. Безнең шикелле кара икмәк ашап үскән кешегә кая инде ул ак сөякле булу? Ак кына түгел, миңа карасы да килешми. Бервакыт хатын: «Бик матур була», – дигәч, котырынып, шушы мыегымны карага буяган идем. Ничә көннәргә кадәр кеше күзенә күренергә оялып яттым. Җитмәсә тагын, мыекка сөртәм дигәндә, битләрне буяп бетердем. Ә аның карасы тәннән һич китми икән... Тумыштан матур булып тумагач, ыспайланган булып маташу белән генә булмый инде ул. *(Ян ишеккә карый, төсләрен бозып.)* Ул нишләвең инде ул? Мин монда кайчаннан бирле, кайчан киенеп бетерә инде дип көтеп торам.

Гафифә *(бүлмәдән)*. Җә, ярар ла, хәзер булам, пудыр матур төшмәгән.

Вәли. Тизрәк бул инде, зинһар! *(Башын бүлмәдән алып, ишекне ябып, халыкка таба карап.)* Менә сиңа кирәк булса, мин инде өстемә пальтоларымны кигәнгә бер сәгать булды. Ә ул әле һаман пудыр ягынып бетерә алмый; пудыр ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята. Әле ярый, көзге ямьсез күрсәтә дип, көзгене бәреп ватмаган.

Уң як ишектән кулына поднос белән чынаяклар күтәреп чыгып, Биби узып бара.

Вәли *(Бибине күреп)*. Әй, Биби, тукта әле!

Биби *(борылып карап)*. Нәрсә дисең?

Вәли. Кара әле, ә!..

Биби. Карыйм ич инде!

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим, нинди нәрсәдер.

Вәли. Тфү, чорт! Сөйләп бетергәнне көт!

Биби. Йә, көтәм.

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим!

Вәли *(ачуланып)*. Тыңлап тор дим мин сиңа!

Биби. Тыңлыйм ич!

Вәли. Тыңласаң, шул: менә без хәзер театрга китәбез...

Биби. Кая?

Вәли. Театрга!

Биби. Нәрсә төятергә?

Вәли. Баш төятергә.

Биби. Нинди баш?!

Вәли. Атаң башы! Мин сиңа төятергә димим, театрга, дим, аңладыңмы, театрга, дим!

Биби. Йә, аңладым инде, театрга, ул нинди җир соң?

---

[1] *Бигайниһи* – нәкъ үзе.
[2] *Хосусән* – бигрәк тә.

Вәли. Анысы сиңа кирәк түгел. Без киткәч, каенатай кайтыр, ул сорар безне, «кайда киттеләр?» дип. Син аңа әйт, «кодаларга киттеләр» дип. «Театрга киттеләр» дип әйтмә!

Биби. Сорамаса нишләрмен?

Вәли. Тик торырсың!

Биби. Ярый. *(Кереп китә башлый.)*

Вәли. Тукта әле!

Биби туктый.

Син, аңгыра нәрсә, рәтләп әйтә дә белмәссең әле.

Биби. Нишләп белмәскә!

Вәли. Йә, әйтеп кара әле, ничек дип әйтерсең икән?!

Биби. «Вәли җизниләр тиатрга китмәделәр, кодаларга киттеләр» диярмен.

Вәли *(ачуланып)*. Иштең ишәк чумарын! Мин сиңа алай дип әйттеммени?

Биби. Соң ничек дидең?

Вәли. Мин сиңа «театрга киттеләр» дип әйтмә, «кодаларга киттеләр» дип әйт, дидем.

Биби. Мин дә бит «киттеләр» димәдем.

Вәли. Фу, җәфа икәнсең, кайдан башыма бәла алдым! Менә, син яхшы тыңла: әгәр дә каенатай безне «кая киттеләр?» дип сораса, «кодаларга киттеләр» диген. Башка сүз әйтмә, бар, юлыңда бул!

Биби. Ярый. *(Кереп китә.)*

Вәли *(үз-үзенә)*. Менә бәла өстенә бәла. Мин үзем дә җүләр: миңа ни эшкә кирәк иде аңар театр дип сөйләп торырга? Мин аңар дөрес әйтәмме?

Ишектән Гафифә килеп чыга.

(Аңа карап.) Нихәл, буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам инде. Нәрсәгә шаулашасыз икән дип карарга гына чыккан идем.

Вәли. Әнә шул, бар ич әле бер адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем. «Без хәзер театрга барабыз» дигән идем, «нәрсә төятергә?» дип, миннән сорап ята.

Гафифә. Ул һәрвакыт шулай, һич аңламый ул. Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем. «Абыстай «Гарифәнең алдырган кислатасы юк микән, бик күңелләрем болганып тора, үзебездә судысы бар барын да, ирләр өйдә вакытта кислата алдырырга онытылган» дип әйтте» дип сора дигән идем, барган да, «Абыстай, киез каталарын биреп торсыннар ла» дип сорап, миңа кислата урынына киез ката күтәреп кайткан. Гарифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә керерлек булдым.

Вәли. Йә, ярар, аларын башка вакытта сөйләшербез, театрга барырга соңга калабыз, бар, тизрәк бул!

Гафифә. Хәзер булам. Ә, ни, синнән шуны гына сорыйм дигән идем. Ул театрда кеше күп булыр микән?

Вәли. Һу! Күп булмыймы соң! Беләсең бит, бүген мөселманча театрның беренче башлана торган көне. Шулай булгач инде, анда бөтен шәһәр халкы агылыр.

Гафифә *(борыннарын җыерып, иркәләнгән бала кыяфәтендә)*. Әй! Әем! Алай булгач, мин бармыйм ла, анда кеше күп булгач, мин оялам.

В ә л и *(үз-үзенә)*. Менә сиңа кирәк булса! *(Алдына карап, башын бераз кашып.)* Ничек булыр икән соң? Юк, минемчә, әле бу көн кеше ул кадәр үк күп булмас. Күбесенең картлары җибәрмәс. Кайсыберсе кеше сөйләүдән куркып калыр.

Г а ф и ф ә *(янә әүвәлгечә)*. Алай булгач, без дә бармыйк: мин дә кеше сөйләүдән куркам. Әти белсә, ул да ачуланыр.

В ә л и *(бик тирән уйга калып, башын күтәреп, халыкка таба карап)*. Уттан котылдым, инде суга төштем. Моннан инде ничек котылырга? *(Гафифәгә карап.)* Мин бит инде, анда барырга дип, билет та алып кайткан идем.

Г а ф и ф ә. Кайтсаң ни! Бармый калган булгач, акчаңны кире кайтарып алырсың.

В ә л и. Бер алган булгач, кире кайтармыйлар шул инде аны.

Г а ф и ф ә. Теләсәң ни эшлә, мин барырга куркам!

В ә л и. Анда ерткыч җанварлар юк, сине ашамаслар.

Г а ф и ф ә. Ашамасалар да, мин бармыйм, кирәкми.

В ә л и. Юк инде, бармый калырга ярамый, барабыз! Ул бит бик күңелле була. Үзеңнең дә көлә-көлә эчләрең катып бетәр.

Г а ф и ф ә. Андый көлкеләрне ат кәмитендә дә бик күп күргән инде. Монда да әллә нинди артык җире булмас, кирәкми, мин бармыйм.

В ә л и. Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә, көчләмим, мин үзем генә барам.

Г а ф и ф ә. Ә, ярар менә, барыр идең бугай, кара син аны, анда ялгыз гына кызлар карарга бармакчы була. Җибәрәмме соң мин сине, Алла боерса, гомеремдә ялгыз җибәрмим!

В ә л и. Теләсәң ни эшлә, мин бармыйча калмыйм. Син бармыйсың икән, мин үзем генә тотам да барам! Хуш, сау бул, мин киттем. *(Чыга башлый.)*

Г а ф и ф ә *(тиз генә Вәлинең артыннан барып тотып)*. Җә, җә, бетте. Мин юри генә әйттем. Әйдә, мин дә барам.

В ә л и *(кире кайтып)*. Ну, әйдә, алайса, барсаң, тизрәк киен!

Г а ф и ф ә. Хәзер киенәм. *(Бүлмәгә таба бара башлый. Соңра янә борылып.)* Кара әле, анда өскә киенгән көенчә генә утыралармы?

В ә л и. Юк, салып утыралар.

Г а ф и ф ә. Әй! Алай булгач, бик читен икән. Кирәкми, бармыйбыз.

В ә л и. «Бармыйбыз» дип сөйләмә, мин барам, киттем, алайса. *(Чыга башлый.)*

Г а ф и ф ә. Барам, барам!!

В ә л и *(мыскыл итеп)*. «Барам, барам!» Ә үзе һаман терәлеп тора. *(Сәгатен чыгарып карап.)* Син, шулай итеп маташып, мине уеннан калдырмакчы була торгансыңдыр, ахры. Уен башланырга бары ярты гына сәгать калган.

Г а ф и ф ә. Мин хәзер булам. Өстемә күлмәк кенә киям.

В ә л и. Ну, бар, зинһар, тизрәк бул!

Г а ф и ф ә *(ишектән керә башлый да, янә борылып)*. Нинди күлмәгемне киим икән, асылмы, җонмы?

В ә л и *(үз-үзенә)*. Асыласың килсә, асыл инде. *(Гафифәгә.)* Зинһар, мине йөдәтмә. Эстәдең ни ки[1]: асылмы, җонмы, сатинмы, батисмы, ситсымы – минем өчен бар да бер.

---

[1] *Эстәдең ни ки* – теләсәң ни ки.

Гафифә. Ярый, алайса, мин зәңгәр асылымны киям. *(Китә башлый.)*

Вәли. Әй, юк, тукта әле, зәңгәр асылыңны кимә, нинди булса да берәр җон күлмәгеңне ки. Сезнең андый чачаклы-чуклы караватъ чаршавы шикелле асыл күлмәкләрегез белән кешегә көлкегә калыр хәлем юк. Без анда бүләк багарга[1] бармыйбыз, уен карарга барабыз.

Гафифә. Алай булгач, нинди җон күлмәгемне киим?

Вәли. Теләгәнеңне ки.

Гафифә. Теге гармун итәкле кызыл җон күлмәгем ничек булыр?

Вәли. Шәп булыр.

Гафифә. Аның шул буе озын булган. Чәнчелеп беткән җөйче, шулкадәр әйттем, «Факиһәнеке төсле матур булсын, яхшы итеп тек» дип. Бозып кына бирде. Юкка гына дүрт тәңкә акча әрәм иттем. Моннан ары, Алла боерса, гомердә ул хатынга тектермәм.

Вәли. Ярый, шулай итәрсең. Бар, тизрәк бул.

Гафифә. Соң, кайсын киим?

Вәли. Башкасын.

Гафифә. Теге, буйга буф бөргән сирый күлмәгемне киимме?

Вәли. Ки.

Гафифә. Ул да шул бик килешеп бетми, чабулары бик тар булган.

Вәли. Алайса, бүтәнне ки.

Гафифә. Ал җон күлмәгем ничек булыр?

Вәли. Бик ал булыр.

Гафифә. Кызылы?

Вәли. Бик кызыл булыр.

Гафифә. Яшеле?

Вәли. Бик яшел.

Гафифә. Соң, ниндине киим?

Вәли. Матурракны.

Гафифә. Теге шикалат төсле, тоташ буйлы, бантикле күлмәгемне кисәм ничек булыр?

Вәли *(шатланган булып)*. Һу! Менә, менә, эзли торгач таптың, ахры, бик һәйбәт булыр. Үзе шикалат төсле дә булгач, бигрәк шәп була инде ул. Чөнки шикалат бик тәмле нәрсә.

Гафифә. Мин аны кияр идем киюен дә, аның шул җиңнәре сак җиң[2]. Килешмәс. Үзең дә, ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер җүнле, матур күлмәгем юк.

Вәли. Соң бит аны хәзер генә тегеп булмый лабаса. Уф Алла! Бар икән кылану, ансы да ярамый, монсы да ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр, чәнчелеп бетегез шунда. Сезне көтеп, уеннан калыр хәлем юк. *(Чыгып китә башлый.)*

Гафифә *(артыннан барып җитеп, Вәлинең җиңеннән тотып, ялынган рәвештә)*. Җә инде! Ни эшләвең инде ул? Торасың да, чыгып китәм, дип куркыта башлыйсың. Мин сиңа бармыйм дип әйтмим ич! Әйткәч, ни була соң инде? Мин синнән

---

[1] *Бүләк багарга* – туйга әзерләнгән бүләкләрне карау өчен җыелу.
[2] *Сак җиң* – кыска җиңле хатын-кыз күлмәге.

әллә нәрсә сорамыйм бит, бары тик нинди күлмәгемне киим дип кенә сорыйм.

В ә л и. Мин сиңа әйттем бит инде: «теләсәң нәрсә ки» дип. Миңа дисәң, бөтенләй бернәрсә дә кимә.

Г а ф и ф ә. Соң, шулай диген аны. Яхшылап кына сораганда, тотасың да ачулана башлыйсың. Алай булгач, ярый торган булса, мин бернәрсә дә кимим, шушы өстемдәге күлмәгем белән генә барам.

В ә л и *(йөзләре яктырып)*. Һай, бәрәкалла! Бик яхшы булыр, бар. Зинһар, тизрәк. Өстеңә генә ки дә, хәзер китәбез.

Гафифә ашыгып кереп китә.

Уф Алла, җаным чыга язды. *(Ишеккә барып карап.)* Яңадан тагы бер-бер нәрсә тапкан булып чыга күрмәсен. Ә, юк икән. *(Ишекне яба.)* Киенә икән, ахырында мең бәла белән көчкә җиңдем. Бу үзенә күрә инде кечкенә генә, бармак башы кадәр генә булса да бер революция булды. Ярый, ни булса да булды, минем максудым[1] булды. *(Кулларын угалап.)* Их, хозур! Хәзер театрга китәбез. *(Таягын ике кулының бармак очлары белән генә тотып, сүз арасында төрле шатланган һәм мәсхәрә кылган кыяфәтләргә кереп җырлый.)*

Бүген театр була, траттата, траттата!
Шатлыктан күңлем тула, траттата, траттата!
Картның кәефе бик китә, уйуйуй, уйуйуй!
Уйнаучыларны тетә, уйуйуй, уйуйуй!
Барам мин театрга, траттата, траттата!
Хатыным белән бергә, траттата, траттата!
Каенатай кайтып кергәч, уйуйуй, уйуйуй!
Безнең киткәнне күргәч, уйуйуй, уйуйуй!
Ачуланса да курыкмыйм, траттата, траттата!
Барыбер сүзен тотмыйм, траттата, траттата!
Кайтып кергәчтен тузар, уйуйуй, уйуйуй!
Бөтен кәефне бозар, уйуйуй, уйуйуй!
Бозса бозар кәефне, траттата, траттата!
Хәзергә мин кәефле, траттата, траттата!

Г а ф и ф ә *(ишектән өстенә киенгән көенчә чыгып)*. Йа, бар икән Ходаем, тагы нәрсә җүләрләнәсең инде? Әллә син дә кәмиттә паяз[2] булмакчы буласыңмы?

В ә л и. Әһә! Булдыңмы әле син, аппагым? Әйдә, алайса, киттек инде, былбылым!

Гафифәнең култыгыннан култыклап чыгып китәләр. Сәхнә буш кала.
Бераздан, бик кызуланып, уң як ишектән Ф а к и һ ә килеп чыга.

Ф а к и һ ә *(як-ягына карап)*. Монда да юк! Болар кая киткәннәр? *(Ишекне ачып кычкыра.)* Биби! Биби!

Биби чыга.

Син беләсеңме?..

---

[1] *Максуд* – теләк.
[2] *Кәмиттә паяз* (паяц) – циркта уенчы, клоун, шамакай.

Б и б и. Беләм!

Ф а к и һ ә. Беләсең икән, әйт, алайса: кая киттеләр җизниләр?

Б и б и. Алар, син сорасаң, ничек дип әйтергә икәнен миңа әйтмәделәр.

Ф а к и һ ә. Соң, ничек дип кенә әйттеләр?

Б и б и. Абзый сораса, «кодаларга киттеләр» дип әйтерсең, диделәр.

Ф а к и һ ә. Ә башка кеше сораса?

Б и б и. Башка кеше кем сорасын? Фатих абый сораган иде дә, мин аңар әйтмәдем.

Ф а к и һ ә. Менә мин сорыйм.

Б и б и. Син башка кешемени?

Ф а к и һ ә. Йә, әйт инде, кая киттеләр?

Б и б и. Әй лә, әйтмим!

Ф а к и һ ә. Театргамы?

Б и б и. Ә! Үзе дә белә икән. Аны сиңа кем әйтте?

Ф а к и һ ә. Йә, бар. Алдыңа кара, эшеңне эшлә...

Биби кереп китә.

Шул шул, театрга киткәннәр. Мин үзем дә сизгән идем аны сизүен. Җизни ул безнеке шикелле җебегән авыз түгел. Исенә бер нәрсә төште исә, хәзер, шул минут ук эшли дә ала. Безнеке генә ул тегермән ташы шикелле, һич кузгатыр хәл юк. Тукта әле, мин дә алып бардырыйм әле. Кеше барган җирдән мин генә ни эшләп калып торырга соң? *(Бик кызуланып, сул як ишеккә кереп китә.)*

Сәхнә бераз буш тора. Бераздан, кычкырышып, Х ә б и б р а х м а н белән килеп чыгалар.

Х ә б и б р а х м а н *(кулларын селтәп)*. Бармыйм дигәч, бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның, кайда икәнен белмим.

Ф а к и һ ә *(мыскыл итеп, бармакларын бөкләп санарга керешә)*. Бу булды бер!

Х ә б и б р а х м а н. Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.

Ф а к и һ ә. Ике, өч.

Х ә б и б р а х м а н. Анда кергәч тә, нинди урынга утырырга?

Ф а к и һ ә. Шуның белән була дүрт! Зинһар, ичмаса инде, эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетереп, кешене көлдермә. Кеше ишетсә, «моның белгән нәрсәсе бар микән?» ди башларлар. Кеше җаен тапканны, без генә табарбыз әле.

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйбыз, мин куркам.

Ф а к и һ ә. Ч-чү, тагы куркуыңнан җыгылып китә күрмә! Шулкадәр зур гәүдәң белән куркам дип әйтергә сиңа кешедән оят!

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйм!

Ф а к и һ ә. Нинди бармаган да нинди нитмәгән! Кеше барган җирдән без генә калып торырга! Әйдә, әйдә, барабыз! Җизниләр әле алар үткән атнаны плашкигә дә чыктылар[1]. Без анда да авызыбызны күтәреп калдык, кияве белән кызы барган булгач, әткәй дә бер сүз дә әйтә алмас. Әйдә, тотабыз да барабыз. Нәрсәгә соң без генә ул кадәр куркып торырга!

Х ә б и б р а х м а н. Бармыйм дигәч, бармыйм инде.

---

[1] *Плашкигә чыгу* – шәһәргә күңел ачарга чыгу.

Ф а к и һ ә *(юмаларга керешеп)*. Җә инде, дим! Барыйксана инде! Харап булган икән! Гомеремә бер мәртәбә бер җиргә барыйк дигәнмен икән инде, шуны да тыңламыйсың. Әткәйдән куркып торырга син кечкенә сабый бала түгел ич инде!

Хәбибрахман эндәшми.

Җә, дим инде, нигә эндәшмисең? Орышса, кайткач бер орышыр да бетәр. Аның өчен сине ашый алмас бит ул. Әгәр дә бик каты дулый башласа, һич булмаганда, мин үзем аны көчләп алып бардым, диярмен. Орышса, мине орышыр, сине орышмас.

Х ә б и б р а х м а н *(башын кашып)*. Белмим шул, ничек булыр икән? Минем үземнең дә бер күрәсем килә килүен ул театр дигән нәрсәне. Әле мин син җөдәтерсең дип әйтмәгән идем, Гайнулла җизнинең кияве Гаптерәхимнәр дә барабыз дигәннәр иде.

Ф а к и һ ә. Соң, алай булгач, тагын ни кирәк инде? Кеше бармый торган җирмени ул? Кеше баргач, бергә-бергә күңелле дә булыр. Әйдә, өстеңә киен дә барабыз. Мин дә хәзер киенеп чыгам. *(Кызуланып, уң як ишеккә кереп китә.)*

Х ә б и б р а х м а н *(ишеккә таба карап, үз-үзенә)*. Мин әле барам дип әйтеп бетерергә дә өлгерә алмадым, ә ул киенергә дә кереп китте. Нишләргә икән инде, шулай ук барырга туры килер микәнни? Әти орышмас микән? Без чыгып киткәнче кайтып керсә генә ярар иде. Бармый калыр идек. Хатын ул әтинең гадәте начар икәнне белми. Беркөнне Гали хаҗи Гаптерахманы белән чәйгә кергән өчен дә колагымны шулай итеп борып алды. *(Борып күрсәтә.)* Күзләремнән утлар күренде. Аны кешегә сөйләп йөреп булмый. «Әти колакны борды» дип, хатынга әйтсәң, хатын хәзер ул «Һәй, нәни бәби! Шул башың белән колагыңны бордырып торасыңмы?» дип мыскыл итәргә тотына. *(Кесәсен капшап.)* Барабыз баруын да, әле кесәдә барырлык акча бар микән? *(Портмонесын алып, акчаларын өстәлгә бушатып саный.)* Унбиш тиен дә унбиш тиен – утыз тиен, тагын унбиш тиен, була кырык биш тиен. Тагын биш тиен, булды илле тиен, илле тиен дә егерме тиен, була җитмеш тиен. Тагын илле тиен. *(Бармаклары белән исәпләргә керешеп.)* Йөз, йөз ун, йөз егерме, булды бер сум да егерме тиен. Бусы өч тәңкә, барысы була... *(Янәдән исәпләп.)* Ике, өч, дүрт, дүрт сум да егерме тиен. *(Портмонесына сала.)* Өч тәңкәсенә билет алсак, каладыр бер сум егерме тиен. Анысы барырга-кайтырга булса, хәер, җитә икән җитүен, түлке бер дә барасы килми шул. Ичмаса, әти дә кайтмады. Әллә бармыйм микән? Ничек итеп бармый калырга? Ә, булды. Менә монда качып утырам да әти кайткач кына торып чыгам. *(Диван башына барып посып утыра.)*

Ф а к и һ ә килеп чыга.

Ф а к и һ ә *(үз-үзенә)*. Әле һаман теге уҗым бозавы киенеп чыга алмаган икән. Нишләп тора икән инде тагын? *(Сул як ишеккә кереп китә.)*

Х ә б и б р а х м а н *(башын бераз күтәреп карап, бик шатланып)*. Аллага шөкер, котылдым, күрмәде. Әти кайтыр инде.

Ф а к и һ ә *(ишектән чыгып)*. Анда юк, әллә кая киткән, шундый чакларда анасы кыйнамасын дип качкан балалар шикелле кача торган гадәте бар иде, бер-бер җирдә качып тормыймы?

Эзләргә тотына. Почмакта тора торган кресло артларын карый. Хәбибрахман бу вакытта, балалар шикелле, башын эчкә яшерә. Фәкиһә килеп күрә дә, акрын гына көлеп, диванның икенче башына барып, аягы белән идәнгә тибеп кычкыра.

Һәй, бәдбәхет! Күсе бар!

Хәбибрахман. Һай! *(Сискәнеп сикереп тора.)*

Факиһә *(мөстәһзианә[1] көлеп)*. Һа, һа, һа! Анда син бар идеңмени? Мин белмәдем. Ул кадәр куркытмаган булыр идем. Анда ни эшләп утырасың?

Хәбибрахман *(ни әйтергә дә аптырап торып)*. Акчам төште. Шуны аладыр идем.

Факиһә. Нинди акча?

Хәбибрахман. Менә театрга барырга акча җитә микән дип санап торадыр идем дә, берсе төшеп китте.

Факиһә. Шул гомердән бирле әле, өстеңә киенмичә, акча санап тордыңмы?

Хәбибрахман. Мин хәзер киенәм. Башыма бүрек киям дә тунымны гына киям. *(Кереп китә.)*

Факиһә *(кычкырып кала)*. Кара аны, анда да кәнәфи башына акчаңны төшермә, анда да күсе булыр. *(Көзге каршына килеп, шәлләрен, калфакларын төзәтә башлап.)* Ну ир соң! Ир димәсәң, хәтере калырлык бар. *(Ишеккә карап.)* Биби! Биби!

Биби чыга.

Әткәй безне «кая киттеләр» дип сораса, «кодаларга киттеләр» диген.

Биби. Ник, анда җизниләр киттеләр бит. Сез дә шунда барасызмыни?

Факиһә. Без театрга барабыз, әмма син шулай дип әйт.

Биби. Ярый, әйтермен. Бая җизни, син әйтә белмәссең дип, мине яңадан әйттереп карап маташа.

Факиһә. Әйтә белдеңме соң?

Биби. Ник белмәскә, белдем.

Факиһә. Йә әле, тагын әйтеп кара. Безне кая киттеләр диярсең икән?

Биби. Әллә белмәс дип беләсеңме? Мин инде аны Фатих абыйдан күптән өйрәнеп куйдым. «Театрга киттеләр» диярмен.

Факиһә. Һи, аңгыра! Җебегән авыз! Мин сиңа шулай дип әйтергә куштыммыни?

Биби. Ник, үзең әйттең ич, «җизниләр кодаларга киттеләр, сез дә шунда барасызмы?» дигәч, «юк, без театрга барабыз» дип...

Факиһә. Күп телеңә салынма. Яхшы тыңла. Әгәр дә әткәй сораса «кая киттеләр?» дип, «кодаларга киттеләр» диген.

Биби. Ярый, ярый, аңладым, «икесе дә шунда киттеләр» диярмен.

Факиһә. Кая?

Биби. Кодаларга.

Факиһә. Бар, эшеңдә бул!

Биби кереп китә. Хәбибрахман тунының югары төймәсен төймәли-төймәли чыга.

Хәбибрахман. Әйдә, булдым.

Факиһә. Әйдә, әйдә, булсаң, тизрәк атла аягыңны. *(Ишектән чыкканда, Хәбибрахманның аркасыннан этә.)*

Хәбибрахман. Тукта! Төрткәләмә инде ул кадәр! Чыгам ич.

Чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Бераздан Фатих килеп керә.

---

[1] *Мөстәһзианә* – мыскыллап.

Фатих *(як-ягына каранып)*. Абзый кая икән соң әле? Кеше бәйрәм итә дә итә, мин дә бераз бәйрәм итеп аласы иде. Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк. Бәйрәм булды исә, ишек төбе сакла. Көне буе байга килгән бер кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да кар көрә! Юк инде, булмас болай итеп. Әһем, әһем! *(Тамак кыра.)* Әллә бөтенләй өйдә дә юкмы? *(Ишекләрне карана.)*

Биби. Әһем, әһем! *(Ишектән чыга.)* Нәрсәгә тамак кырып йөргән буласың?

Фатих. Абзый өйдәме?

Биби. Өйдә.

Фатих. Ни эшли?

Биби. Тире җыеп, кұн эшли.

Фатих. Йә, шаярма әле, чынлап әйт әле, өйдәме?

Биби. Ни эшкә ул сиңа?

Фатих. Кирәк.

Биби. Әүвәле әйт ни эшкә икәнен, аннан соң әйтәм.

Фатих. Йә, әйт инде, шаярма.

Биби. Нәрсә бирәсең, әйтәм.

Фатих *(шаярып)*. Әйтсәң, сине үземә хатынлыкка алырмын.

Биби. Һи, мәхәббәтсез!

Фатих. Мәхәббәтсез?! Мин нишләп мәхәббәтсез булыйм? Кара бу мыекларны! *(Мыекларын борып күрсәтә.)* Кызларның калфак чугына ярарлык.

Биби. Йә, күп телеңә салынып торма монда, бар, чык!

Фатих. Ник, шулай ук мине яратмыйсыңмыни? Мин сине әле абзыйдан сорарга дип менгән идем, анда ялгыз гына күңелсез.

Биби *(боргаланып)*. Һай, конарсыз!

Фатих. Кызларның шул булыр инде аларның, алар һәрвакыт шулай һавалы булалар. Кызлар алар яшь чагындарак, патшага барам мин, дип торалар да, ди, аннан ары, санатка[1], дип әйтәләр, ди; ул да эләкмәгәч, актыгында, солдат булса да ярар, дип әйтәләр, ди.

Биби. Йә, йә, бар, мыскыл итмә! Бар, чык! Абзый кайтыр, абыстай да хәзер менәр.

Фатих. Күптән син шуны әйтерләр, мин синнән баядан бирле «абзый өйдәме?» дип сорыйм ич. Өйдә булмаса, хуш, сау бул! *(Чыгып китә.)*

Биби *(үз-үзенә)*. Ялганлый торгандыр ла ул, мине алдар өчен генә, юри генә әйтә. *(Кереп китә.)*

Бераздан Хәмзә бай кайтып керә. Күрмичә, ишек төбенә җәеп куйган паласка сөртенә.

Хәмзә *(кычкырып)*. Гөнаһ шомлыклары! Аяк астына әллә нәрсә җәеп куйганнар. Мал кадерен белмиләр. Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да, бернәрсә дә күреп булмый. *(Күзлеген сөртә.)* Беркөн мәдрәсәгә кергәч тә, әчелектәге[2] башмакларга сөртенеп, лаканга егылган идем. *(Ишек янындагы урындыкка утырып.)* Әй, кая, кайсыгыз бар анда? Аякны тартыгыз әле.

---

[1] *Санат* – «сенатор» сүзеннән үзгәртелеп, биредә «түрә» мәгънәсендә.
[2] *Әчелек* – мәдрәсәдәге чишенү бүлмәсе.

Биби килеп чыга.

Кая, кил, нәрсә терәлеп торасың, тарт аякны!

Биби салдыра башлый.

Чү, чү, чү, карап тарт! Мәсихемне[1] бозма! Абыстаң кая?

Биби киез итекнең берсен салдыра.

Биби. Аш өендә.
Хәмзә. Нишли анда?
Биби. Аш пешерә.
Хәмзә. Ник, килен кая?
Биби. Алар Хәбибрахман абый белән ни... ни... әй... кодаларга киттеләр.
Хәмзә. Ныграк тарт! Кулың черегән мәллә?

Биби, кинәттән тартып җибәреп, Хәмзәне егып төшерә.

Һай, бәдбәхет! Күзең чыккан нәрсә! Бар, кит, күземә күренмә!

Биби кереп китә. Хәмзә, мәшәкатьләнеп, аягын салып бетерә.

Башка кеше булса, мин аңар кирәген биргән булыр идем булуын, әллә ничек, кыз балага сугарга ул кадәр кул барып җитми. *(Тунын салып, чөйгә элеп куя.)* Бүген иртә белән чәч алучыга кергән идем, бөтенләй ишегеннән керер хәл юк. Җыен кызыл авыз кибетчеләр тулган. Байларына бөтенләй әйләнеп тә карамыйлар, чәч алучысы да һич санга санамый: «Хаҗи, син әле башка көнне дә керерсең, син бай кеше, һәрвакытта да вакытың бар; болар бит бай кешесе, җомга көннән башка вакытта вакытлары булмый», – дип, авызын җырып тик тора. *(Чалбар балагын җыеп бәйләп куйган тасмаларын чишә.)* Алары да шул кибетчеләр яклы. Аларга кибетчеләр яклы булмыйча ярыймы соң? Кибетчеләр бит аларга унар, унбишәр тиенләп яудыралар. Аларга бай акчасы кызганычмыни... Биби, Биби!

Ишектән Биби чыга.

Биби. Нәрсә дисез, абзый?

Хәмзә. Бар әле, берәрсенә әйт әле, мәдрәсәдәге Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. «Абзый чәч алырга чакыра» дисеннәр.

Биби. Нинди мәче алырга?

Хәмзә. Һай, аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа мәче алырга дидеммени? Чәч алырга, дим! Чәч! *(Үз чәчен тарткалап.)* Менә, менә шушыны алырга, дим!

Биби чыгып китә.

Бу кадәр аңгыра булырлар икән. Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга «Бар, агач базарына Хисмәткә бар да аны тизрәк монда алып кайт» дип җибәргән идем, барган да бер зур кисмәк алып кайткан. Менә бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде. Әле ярый хәзергә үзем исән әле. Үзем үлгәч, болар дөньяда ничек итеп көн күрерләр?

Биби ишектән килеп чыга да тик тора.

---

[1] *Мәсих* – дини йола буенча, читек өстеннән су йөгертү.

(Аңа карап.) Нихәл, нишләп терәлеп торасың анда?

Б и б и. Абзый, Миннебай абзыйга әйткән идем «Коръән укый торган шәкертне алып чык» дип, «нинди шәкерт ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда Әфтияк укучы юк» ди.

Х ә м з ә *(аяк тибеп)*. Һай, ахмаклар! Әрәмтамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, мәчеттә Коръән укый торган шәкертне – Гайфулланы чакырып чыксын!

Б и б и. Икесен дә чакырсынмы?

Х ә м з ә. Нинди «икесен дә»?!

Б и б и. Коръән укучыны да, Гайфулланы да?

Х ә м з ә. Үләм инде мин сезнең белән, җәфаланып үләм! Аңгыра! Соң шул Коръән укучы шәкерт белән Гайфулла икесе дә бер ләбаса инде! Бар тизрәк! Гөнаһ шомлыгы!

Биби чыгып китә.

Менә инде син сөйләш алар белән. И Алла! И Алла! Ахры инде, дөньяда акыллы кеше үк калмагандыр. Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә-чигә китерер хәл юк. Һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр. Тукта инде, әүвәл тизрәк чәчемне алдырыйм да аннан соң, тәһарәт алып, вирдләремне[1] укырмын. *(Ишеккә таба борылып.)* Әй! Кая сез? Башымны чылатырга сабын, су бирегез. *(Ишектән кереп китә.)*

Бераздан, чынаяк, поднослар күтәреп, Б и б и керә.

Б и б и. Үзләре җүнләп йомыш куша белмиләр дә кешене орышалар. *(Чәй урыны хәзерли, өстәлнең почмагына самавыр подносы, аның янына зәңгәр эмалированный пласкательный[2] куя.)* Көне-төне эшлисең дә эшлисең, аның өстенә тагын һәр көн орыш та талаш. Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга киткәннәрен әйтәм. Мине генә орышмасын әле, аларны да орышсын.

Ишектән Х ә м з ә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән.
Бер кулына яшел кәләпүшен, бер кулына күзлеген тоткан.

Х ә м з ә. Бар, миңа муенга салырга эскәтер китер!

Биби чыгып китә. Хәмзә, өстәл янына килеп, пласкательный янына кәләпүшен,
аның янына күзлеген куя. Биби бер каралган кызыл эскәтер китереп бирә.

(Бибигә карап.) Кая, миңа урындык бир әле. *(Кызыл эскәтерне муенына бәйли. Биби урындыкны китереп бирә. Янә Бибигә карап.)* Бар әле, теге якта камут тартмасында минем плитувам[3] бардыр, шуны монда китер.

Биби чыгып китә.

(Хәмзә урындыкка утыра.) Заманалар бозылды. Әле менә бүген теге урыс сымак нәрсәләр, театр уйнап, динне мәсхәрә кылмакчы булып йөриләр икән. Шуны булдырмаска йөреп, бүген ясигъка[4] бара алмый калдым. «Уйнатмагыз, рөхсәт юк!» дип,

---

[1] *Вирд* – дога.
[2] *Пласкатель* – сакал-мыек кырганда, сабын күбеге ясый торган савыт.
[3] *Плитува* (бритва) – пәке.
[4] *Ясигъ* – йокы алдыннан укыла торган соңгы (бишенче) намаз.

Җамали үндергә әйткән идек, ул: «Минем эшем түгел, пристефкә үзенә әйтегез», – диде. Пристефне өйдә туры китереп булмады, галавага менгән идек, ул да алар яклы булырга кирәк: «Минем эшем түгел, сез палисәмистергә барыгыз», – диде. Аңа барган идек, баксалга киткән. Губирнаторга да барган идек, бутишник: «Ул бу вакытта кеше кертми, иртәгә сәгать уникедә килеңез», – диде. Шулай итеп, ахрысы, бәдбәхетләрне туктатып булмады. Алла боерса, икенче вакыт уйнатмабыз әле, пристефне алдан ук күреп куярбыз.

Ишектән Б и б и килеп керә.

(Аңа карап.) Нихәл, булдымы?

Б и б и. Менә, булды. *(Бритваны өстәлгә китереп куя.)* Коръән укучы шәкерт өйдә юк, ди, иптәшләре белән театрга киткән, ди.

Х ә м з ә *(ачуланып)*. Ходай орган икән! Йөзләре генә кара булсын, бар, чакыр монда Фатихны!

Б и б и. Фатих абый ул син кайтканчы ук чыгып китте.

Х ә м з ә. Кая?

Б и б и. Шунда китте.

Х ә м з ә *(ачуы тагын да кабарып)*. Кая «шунда»?

Б и б и. Шунда инде, театрга китте.

Х ә м з ә. Ә? Театрга? Кемнән сорап китте?

Б и б и. Берәүдән дә сорамады. «Вәли кияүләр белән Хәбибрахманнар да киткәч, мин генә нишләп калыйм» диде дә китте.

Х ә м з ә *(тәмам алакаеп)*. Ә? Ни дисең? Вәли кияү дә китте дисеңме?

Б и б и. Китте.

Хәмзә урыныннан сикереп тора.

Х ә м з ә. Хәбибрахман да киттеме? *(Бибинең өстенә бара.)*

Б и б и *(кире чигенеп)*. Китте.

Х ә м з ә *(яңадан өстенә барып)*. Гафифә?! Факиһә?!

Б и б и *(яңадан кире чигенеп)*. Алар да киттеләр.

Хәмзә, кулларын йомарлап, иреннәрен тешләп, «эм-м-м-м!» дип, Бибинең өстенә килә башлый, Биби чыгып кача.

Х ә м з ә *(Биби чыгып киткәч, халыкка таба карап, кулларын сузып)*. Йә, әйтеңез инде, зинһар, нишләтим инде боларны? *(Гайрәтләнеп.)* Юк! Боларны болай гына калдырырга ярамый, йөзе караларны! Барам да якаларыннан тотып, өстерәп алып кайтам. *(Тиз генә өстәл янына килә дә пласкательныйны алып кия. Аны ыргытып бәрә дә.)* Тфү, чурт! *(Кәләпүшен алып кия. Аны да тиз генә ала да.)* Һай, йөзе каралар икән! Акылымнан шаштырасыз инде! *(Тиз генә эскәтерне муеныннан тартып алып, башын сөртә-сөртә, киемнәргә таба бара.)* Мин сезгә бирим әле кирәгегезне! *(Өстенә кия башлый, кычкыра.)* Кая киез ката? Китерегез тизрәк, ә, менә монда икән! Йөзе караларны! *(Ашыгып-ашыгып кия.)* Бәдбәхетләрне, муены астына килгәннәрне!.. *(Чыгып китә.)*

П ә р д ә т ө ш ә.

1908

«БЕРЕНЧЕ ТЕАТР» СПЕКТАКЛЕННӘН КҮРЕНЕШЛӘР

Хәмзә бай — Габдулла Кариев

«برنچی تیاتر»

«Беренче театр» комедиясенең беренче басма тышлыгы

«Беренче театр» комедиясеннән бер бит

Вәли — Хәким Сәлимҗанов

Факиһә — Гөлсем Болгарская

Биби — Мәрьям Сульва

«Беренче театр» — бер пәрдәле көлке, Казанның тәҗвидче мөтәрәкъкыйләре[1] мәгыйшәтеннән алып язылган әсәр. Галиәсгар әфәнде бу әсәрен хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган булса да, урта буржуазный классның психологиясен бик яхшы төшенгәнлегеннән, комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумиять[2] бирә вә, шулай итеп, бу кыска комедиясен гомуми, ярым «мөтәрәкъкый» купецларымызның мәгыйшәт вә дингә нәзарларының[3] бик тугры көзгесе итеп чыгарадыр. Комедиянең баш каһарманы Хәмзә бай — җәннәт ачкычын үз кулына тотып, аныңча йөрмәгән кешеләрнең берсен дә анда кертмәскә мөтәкәффил[4] булган мөттәкый[5] — үзенең бик көлке хосусыятьләре белән комедиядә бик ачык тасвир ителәдер. Моның тәрбиясе нәтиҗәсе булган балаларының хосусыятьләре дә бик көлке сурәттә күрсәтелә.

Фатих Әмирхан

---

[1] *Тәҗвидче мөтәрәкъкыйләре* — Коръәнне дөрес укырга өйрәтүче кагыйдәләрне белергә кирәк дип карау дәрәҗәсенә җиткән укымышлылары.

[2] *Гомумиять* — гомумиләштерү.

[3] *Нәзар* — караш.

[4] *Мөтәкәффил* — җаваплы.

[5] *Мөттәкый* — изге.

БҮЛӘК ӨЧЕН

Комедия 1 пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Әхмәтҗан – Казан бае, 45 яшьләрендә.
Хәмидә – Әхмәтҗанның хатыны, 45 яшьләрендә.
Габдуллаҗан – Әхмәтҗанның улы, 22 яшьләрендә.
Мәхүпҗамал – яучы хатын, 60 яшьләрендә.
Бәдриҗамал – асрау.

Казанда, Әхмәтҗан байның өендә. Өй җиһазлары иске заман нәрсәләре белән кара-катыш. Стенада рамкалы язулар. Пәрдә ачылганда, Әхмәтҗан белән Хәмидә күренә. Габдуллаҗанны өйләндерү хакында киңәш итәләр.

Беренче мәҗлес

Әхмәтҗан, Хәмидә.

Әхмәтҗан. Теләсәң нәрсә диген, хатын, мин бер дә төшенмим.

Хәмидә. Бер дә төшенәсе-нитәсе юк, кызы менә дигән кыз. Ул матур, ул сылу, күрсәң – исең китәр. *(Урта бармагын күрсәтеп.)* Урта бармак шикелле бер кыз инде.

Әхмәтҗан. Тукта әле, хатын, мин тагы да төшенмәдем; үзең әйтәсең «бик матур, бик сылу» дип, ә үзең тагы әйтәсең «урта бармагың төсле» дип. Синең урта бармагың төсле буынтыклы-буынтыклы булса, бер дә матур булмый инде ул.

Хәмидә. Җә, ярар инде. Мыскыл итеп утырган булма. Бар кеше дә синең шикелле итеп сөйләшә белми. Син генә ул бик матур итеп сөйләшәсең. Алай мыскыл итмә. «Урта бармак шикелле» дигәнне яратмасаң, шәм шикелле инде, алайса.

Әхмәтҗан. Монысы инде тагы да начар булды. Шәм шикелле иелми-бөгелми торган, үрәгә каткан нәрсә булгач, безгә бер дә мәгъкуль[1] кеше түгел икән. Ул, алай булгач, мине дә, сине дә, Габдуллаҗанны да искә-санга алмас.

Хәмидә. Бар икән, Ходаем! Мине һаман мыскыл итәсең, мин сиңа чынлап сөйлим, ә син һаман миннән көләсең.

Әхмәтҗан. Бер дә көлмим, бары тик син «шәм шикелле» дигәч, иелми-бөгелми торган бер кыздыр дип кенә әйтәм.

Хәмидә. Юк, юк, атасы, бик чибәр, бик әйбәт кыз, бөтенләй менә каймак шикелле бер кыз инде.

Әхмәтҗан. Чәйгә салып эчәргә дә яраклы икән, алайса.

Хәмидә. Тагын көләргә тотындың инде! Каймак дигәнне яратмасаң инде, алайса, кәләвә шикелле, бал шикелле, кәнфит, прәннек шикелле.

Әхмәтҗан. Хатын, инде алай булгач, мин бернәрсә дә әйтә алмыйм. Ул кадәр баллы нәрсә булгач, бик төче нәрсә булып, безне бөтенләй үтләтеп бетермәсә ярар иде дип куркам.

---

[1] *Мәгъкуль* – лаек.

Хәмидә. Бер дә хафаланма, атасы, килешерләр әле, Габдуллаҗан да бик яратыр. Менә үзебез бит әле егерме биш елдан бирле бик әйбәт, бик килешеп торабыз.

Әхмәтҗан. Торса бит, син алай кәнфит шикелле баллы гына түгел идең, синең әчкелтем-төчкелтем чакларың да бик күп буладыр иде. Син бит кайсы вакытта, керән, гәрчитсә шикелле әче булып, бөтенләй күзләремнән яшьләр китерә торган идең.

Хәмидә. Ансы өчен бер дә хафаланма, дөнья булгач, аларның да әче вакытлары булыр әле. Озак торгач, бал да чымырдап әчи, безнең Габдуллаҗан үзе дә әче суганнан бер дә ким булмас.

Әхмәтҗан. Җә, сүзем бетте инде, алайса, үзегез Габдуллаҗан белән теләсәгез ничек килешегез. Әле тик беркөннәрдә үзең, Хәйриләрдән аштан кайткач, «Хисаминың кызын күрдем, бигрәк конарсыз нәрсә икән – үзе озын, үзе чыра шикелле, шадра, авызы кыек, чепи күзле, кәкре аяклы, шулай да булса, тагын әллә кем булган булып, бүксәсен киереп утырган була» дип сөйләгән идең. Үзең шулай дип сөйләгәнгә күрә генә, безгә муафикъ[1] кеше булмас дип куркам.

Хәмидә. Юк, юк, атасы, бер дә курыкма! Бик әйбәт, бик сылу, бик уңган, җиләк шикелле бер кыз. Эшкә-кешкә дә оста, бик булган, бик чибәр, бик купшы, ди. Вәгъдә бирнәсенә дә, кәбен бирнәсенә[2] дә, актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт, калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар, ди. Безгә дигән намазлыкларын да, кияүгә дигән аякчу, намазлыклар белән бергә, моннан үрнәкләр җибәреп, иллешәр тәңкәгә Мәскәүдән эшләтеп китерткәннәр, ди. Вәгъдәгә дә өч төрле как-төш бирәчәкләр, ди. Кияүгә дигән кәләпүшне мыскалы егерме бишәр тәңкәлек кырык мыскал энҗедән эшләтәчәкләр, ди. Кияүгә булачак сәгатьне Хисами кода үзе...

Әхмәтҗан. Тукта әле, Хисами безгә әле кода булып җитмәгән.

Хәмидә. Җә, ярар ла, җураган җуш килә, диләр. Кода булачакка күрә авызыма шулай туры килеп торадыр инде. Нәрсә әйтәдер идем соң, ә, әйе, кияүгә дигән сәгатьне Хисами кода үзе...

Әхмәтҗан. Хисами кода түгел!

Хәмидә. Ярар ла инде, Хисами бай үзе, Мәскәүгә барып, ике йөз тәңкәгә алып кайткан, ди. Ул чипүшкәсен[3] күрсәң, менә бөтенләй искитәрлек, ди. Әсма кодагый...

Әхмәтҗан. Тфү! Әсма да кодагый түгел бит әле.

Хәмидә. Җә, җә, Әсмабикә...

Әхмәтҗан. Кичә генә «курнус Әсма» дип йөриләр иде әле, хәзер инде, бүген, бикә дә булып җиткән.

Хәмидә. Бикә булмый ни, бикә шул! Әсмабикә кияүгә берлиант кашлы йөзек тә алдырып бирмәкче була, ди.

Әхмәтҗан. Уф, тыңлап торып та арып беттем инде.

Хәмидә. Арырсың да шул, ул кадәр күп нәрсә биргәч. Син үзең әле, Газизәне биргән вакытта, гомердә Хисами кода...

Әхмәтҗан. Кода түгел, дим!

Хәмидә. Хисами бай шикелле итеп бирә алмассың.

Әхмәтҗан *(халыкка карап)*. Бай, имеш, Мәскәү малы белән кибетен тутыргач та, хатын аны бай дип белә тагын.

---

[1] *Муафикъ* – яраклы.
[2] *Кәбен бирнәсе* – туй булгач бирелә торган актык бүләк.
[3] *Чипүшкә* (цепочка) – сәгать чылбыры.

Х ә м и д ә *(сүзендә дәвам итеп).* Караваты чаршаулары да плүштән булачак. Караватын да Хисами кода, әй, ялгыш әйтәм, Хисами бай, Мәкәрҗәгә барганда, йөз егерме таңкәгә алып кайткан. Ул савыт-саба, урын-җир, түшәк-ястык, сөлге, эскәтер, тастымал, намазлык, чаршауларның бер дә иге-чиге юк, ди.

Ә х м ә т җ а н *(халыкка карап).* Тәмам бер талчук кибете ачарлык бар икән.

Х ә м и д ә *(сүзендә дәвам итеп).* Ун сандык нәрсә мал белән дың тулы, ди. Хисами кода… әй, тфү, Хисами бай приданны да бик яхшы итеп хәзерләтмәкче була, ди. «Кызларым байлыгым бар вакытта рәхәтләнеп калсыннар, һәммә җирләрен җитеш итеп бирәм, үз исәнлегемдә урнашып калсыннар», — дип әйтә, ди. Ун табынлык савыт-саба алган.

Ә х м ә т җ а н *(халыкка карап).* Әүвәлгеләре мануфактур кибете булган иде, инде монысы белән чынаяк кибете ачарга мөмкин булачак.

Х ә м и д ә *(сүзендә дәвам итеп).* Чәнечке, пычаклары — һәммәсе дә көмеш саплы булачак. Самавыры, чәйнекләре, куфи савытлары бары да көмештән.

Ә х м ә т җ а н *(халыкка карап).* Йа Алла, башым катты инде.

Х ә м и д ә *(сүзендә дәвам итеп).* Гуркә шкафы бик зур, бик һәйбәт, кызыл агачтан ясалган, ике дүҗинә урындыклары, көзгеләре — һәркайсы кызыл агачтан, ди. Ике өстәл, туритский диван, кәнәфи белән йомшак эскәмияләр…

Ә х м ә т җ а н *(халыкка карап).* Йа Алла, кайчан гына туктар икән!

Х ә м и д ә *(сүзендә дәвам итеп).* Гелдируплар[1], кантур өстәлләре дә бирәчәк, ди. Ул шарлы лампаларының матурлыгына бер дә чама юк, ди. Ләгән-комганнары һәммәсе никелдән булачак, ди. Тагы көмеш…

Ә х м ә т җ а н. Уф! Йә, зинһар, җитәр инде, тыңлап торып та арып беттем. Ул әйткән нәрсәләрнең бары да булса, зур кибет ачарлык мал булыр. Без аны кайда куеп бетерербез? Ул нәрсәләрне куярга аңар үзенә бер йорт салырга кирәк булыр.

Х ә м и д ә. Аның өчен бер дә кайгырма, малы булгач, куярга урыны табылыр. Хисами кода…

Ә х м ә т җ а н. Кода түгел әле!

Х ә м и д ә. Ялгыш әйтәм. Хисами бай Габдуллаҗанны бик яраткан, ди. Шуңа күрә бер сүз дә әйтмиенчә бирмәкче була, ди.

Ә х м ә т җ а н. Йә, ярар, хәерле булсын. Әнә үзең теләсәң ничек итеп Габдуллаҗанны күндер дә, ул үзе риза булса алырбыз. Габдуллаҗанны чакырт та үзең сөйләш. *(Чыгып китә.)*

Икенче мәҗлес

Х ә м и д ә ялгыз, үзалдына сөйләнә.

Х ә м и д ә. Безнең өйдә бер дә акыллы кеше юк. Шулкадәр бай кеше кызымны бирәм дип торган чакта, сакалыңны салпырайтып, мин белмим дип утыр, имеш. Кыз матур түгел диләр. Аның матурлыгы пычагымамыни? Мәхәббәт җамал[2] теләмәс, мәхәббәтләре генә булсын. Үзебез әле менә егерме биш елдан бирле торабыз. Син ямьсез дип, урамга чыгарып ташлаган кеше юк. Матур да булса, буе-сыны да кешенеке

[1] *Гелдируп* — гардероб *(Г. Камал искәр.).*
[2] *Җамал* — матурлык.

төсле булса, андый бай кешеләр, шулкадәр бүләкләр бирә-бирә, кызларын безгә этеп-төртеп бирмәсләр иде. Баланы егерме ел үстереп тә, бер җүнле, яхшы бирнә дә киеп калмагач, дөньяда торганың ни дә тормаганың ни! Әнә Гыйльми Бәдриенең кызы бик чибәр дә бит, матурлыгына карап аны алып булмый. Аларның җүнле бирнә бирәселәре дә юк, күп булса бер асыл бирнә бирерләр. Кодагый булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле. Улыңны өйләндереп тә, бер рәхәтләнеп кунакка йөреп калмагач, дөньяның ни рәхәте бар, дөнья ике килми ул.

Ишектән, кулына бер китап тотып, Габдуллаҗан килеп чыга.

Өченче мәҗлес

Хәмидә, Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Әни, аш тиз буламы? Минем учителгә барасым бар.

Хәмидә *(артына борылып карап)*. Әйдә, кил әле монда, учителгә барырга аннан ары да өлгерерсең. Урыс сабагы укып йөрергә син кечкенә бала түгел инде. Кил әле, утыр менә монда, без сине хәзер өйләндермәкче булабыз.

Габдуллаҗан. Кемне?

Хәмидә. Сине.

Габдуллаҗан. Кит аннан, мин өйләнмим! *(Чыга башлый.)*

Хәмидә. Тукта, кайда барасың? Мин бит сиңа уйнап сөйләмим, син бит инде бала түгел.

Габдуллаҗан. Әле беркөн генә үзең, Гыйльми Бәдриләреннән яучы килгәч, «әле улыбыз бик яшь, бала гына әле, өйләндермибез» дигән идең.

Хәмидә. Йә, күп телеңә салынып торма, кил, утыр! Менә хәзер яучы киләчәк, вәгъдә куеп җибәрәбез. Атаң да бик мәгъкуль күрде.

Габдуллаҗан. Кемнән киләчәк?

Хәмидә. Хисами байдан, Хисами бай сине күреп бик яраткан да сиңа бик зур придан белән кызын бирмәкче булган.

Габдуллаҗан. Мин ул кызны бер дә күргәнем юк бит.

Хәмидә. Җүләр, кызны күреп алалармыни аны? Менә мине дә атаң күреп алмады.

Габдуллаҗан. Мин беркөн «Өйләнү» дигән бер китап укыдым. Анда алачак кызның ни төстә икәнен, холкын-фигылен белеп алырга кушкан.

Хәмидә. Куй ул юк сүзләреңне, бетмәс андый сезнең такмаза китапларыгыз. Син шуны әйт: ризамы, юкмы?

Габдуллаҗан. Тукта әле, әни, ул кыз соң нинди, ни төстә, буе-сыны ничек, матурмы?

Хәмидә. Ансын бер дә тикшереп торасы юк, кыз бик һәйбәт, бик матур.

Габдуллаҗан. Буе озынмы?

Хәмидә. Озын, озын, бик озын, бик зифа!

Габдуллаҗан. Мин укыган китапта «хатынның буе ирennән бераз кыскарак булсын» дигән.

Хәмидә. Озын дигәч тә, синең шикелле үк озын түгел инде. Синнән бераз кыскарак булыр. *(Халыкка карап.)* Озын булса ни зарар? Баскыч куеп менмәс әле, торырлар шунда.

Габдуллаҗан. Кашы ни төсле, карамы?

Хәмидә. Һәммә кешенең дә кашы кара булып бетми инде. Кара булмаса да, бик матур, бик нечкә. Кара кирәк булса буярсыз. Бу чагында инде кашны гына түгел, чәчне дә буяп йөриләр.

Габдуллаҗан. Төскә ничек, түгәрәк битлеме?

Хәмидә. Җә инде, күп сөйләнеп торма, адәм фәрештә булмый. Кеше кешедән артык булмас. Мәхәббәтегез генә булсын, мәхәббәтегез булса, хур кызыннан да артык булыр. Син бигрәк менә, нәрсәләр бирәләр дип сора. Сиңа дигән чикмәнлекнең аршынын унике тәңкәдән алганнар, ди. Кәләпүшләре кырык мыскал энҗедән эшләнгән булачак, ди. Алтын сәгатьләрен ике йөз тәңкәгә алганнар, ди. Сиңа бик һәйбәт берлиант йөзек бирәчәкләр, ди. Ул башка приданнарының исәбе дә юк, ди.

Әхмәтҗан килеп керә.

Әнә атаң да кереп килә. *(Шыпырт кына.)* Күп терәлеп торма, тизрәк «риза» диген.

Дүртенче мәҗлес

Әхмәтҗан, Хәмидә, Габдуллаҗан.

Әхмәтҗан. Нихәл, килешәсезме?

Хәмидә. Килештек, килештек, Габдуллаҗан да «риза» ди.

Габдуллаҗан. Әле мин... мин «риза» дип әйтеп бетермәдем ич.

Хәмидә. Ул ни дигән сүз тагын? Риза, риза, атасы, бик риза. Ата-анасы риза булган кешегә риза булмаска, ул ни дигән сүз?

Әхмәтҗан. Тукта әле, сиңа әйтәм, ата-анасы риза дип, эшне бетереп куйма әле син. Әле бит минем дә риза булып җиткәнем юк. Бая мин әле аларның нәрсә сорыйсыларын да белеп бетерә алмадым. Алар мәһәргә нәрсә сорыйлар соң?

Габдуллаҗан. Әле мин дә сорашып бетерә алмадым, ул кыз ни төсле соң?

Хәмидә *(Габдуллаҗанга)*. Тик тор син, атаң алдында әдәпсезләнеп сорап торма! Синең шикелле җүләргә ярамаган тагын! Кыз кыз булыр инде, фәрештә булмас. *(Әхмәтҗанга.)* Инде дус-иш арасында оятка калырлык итеп биреп булмас. Үзләре шулкадәр зурлый торып та, бик кечкенә итеп җибәрергә ярамас.

Әхмәтҗан. Бик күп акча чыгып, кыйммәткә төшәрлек булса нишләрбез?

Габдуллаҗан. Бик ямьсез, бик аңгыра булып, аяклы каза булырлык булса, мин нишләрмен?

Хәмидә *(Габдуллаҗанга)*. Каза, каза! Син үзең әле аяклы каза: күп лыгырдап торма! *(Әхмәтҗанга.)* Инде, акча күп чыга дип, улыңны өйләндерми тора алмассың, хәлдән килгән кадәрле тырышырсың. Дус-иш арасында биткә оят китерерлек итмәссең. Күп дип әйтергә, алар әллә нәрсә сорамыйлар: эче-тышы, әйләнәсе белән камзуллык чатма, аннан соң, хәзерге заманча булсын дип, бер озын сак. Егерме биш мыскалдан калфак, анысын инде егерме мыскалдан эшләтсәң дә ярар. Аннан ары ике зур сандык. Аннан кала бер аксыл сирый җефәкле, чите каймасыз мамык шәл белән яхшы ише бер җефәк шәл, кырык мыскал энҗедән бер муен энҗесе. Аннан ары бер көзге сорыйлар. Көзгесе арты шкафлы булсын, хәзер инде баганалы көзгенең мудысы бетте дип әйтәләр, ди.

Әхмәтҗан *(халыкка карап).* Монысы әле аның баласы, мичтә калгандыр анасы. *(Хәмидәгә.)* Ничек тә шул дүрт-биш мең тәңкәсез котылып булмас.

Хәмидә. Нинди дүрт-биш мең тәңкә? Булса тагы, әлхәмделиллаһи, аңар гына чыдарлык хәлебез бар әле.

Әхмәтҗан *(халыкка карап).* Ул инде, мөгаен, кибеттәге малның барысы да минеке дип белә торгандыр.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Мин башка вакытта үзем дә сине борчымыйм. Вакытлы-вакытсыз әйбер сорап җөдәткәнем юк, асыл күлмәкләрем саргаеп, саташып беткән. Шулай да синнән асыл күлмәк алып бир дип сораганым юк.

Габдуллаҗан *(халыкка карап).* Алдалый, валлаһи, алдалый, ышанмагыз, сандыкта һич киелмәгән биш-алты асыл күлмәге череп ята.

Әхмәтҗан. Бөләр хәлем юк, улымны өйләндерәм дип, бар сумамнан язар хәлем юк. Дүрт-биш мең тәңкә тотып өйләндерергә минем хәлемнән килми. Безгә нигә ярамаган уртачарак кеше? Тотарбыз да Гыйльми Бәдриенең кызын алырбыз. Аның кызы укымышлы да, төскә дә матур, диләр.

Габдуллаҗан *(үзалдына).* Менә монысы өчен әтигә рәхмәт!

Хәмидә. Алды ди, алмый ни, ул хәерчеләрнең кызларын алып торырга кирәк! Аның анасы – дөньяда бер ямьсез хатын. Кияү йөртергә бер җүнле атлары да юк. Аларның бирнәгә биргән асылларының да үтәсеннән көн күренерлек булыр. Аның шикелле сидрәп беткән асыллар минем үземдә дә бетәсе юк.

Әхмәтҗан. Кызны бит синең өчен алмыйбыз. Менә Габдуллаҗан ни әйтер? *(Габдуллаҗанга карап.)* Габдуллаҗан, син кайсын алырга риза? Хисами кызынмы, Бәдри кызынмы?

Габдуллаҗан. Бәдри кызын.

Хәмидә *(йодрык күрсәтеп).* Оятсыз, атаң алдында «Бәдри кызын» дип әйтеп торырга ничек оялмыйсың? Әбәү, оятсыз!

Әхмәтҗан. Соң, ничек дип әйтсен, «Хисами кызын алам» дип әйтсенмени?

Хәмидә. Алай дип әйтсә бер хәер, аларның, ичмаса, кешеләре кеше төсле. Мин ул Бәдринең хатынын гомеремдә дә кодагый дип әйтәсем юк.

Әхмәтҗан. Кодагый дип әйтмәсәң, башкача әйтерсең, аннан безгә ни зарар?

Хәмидә. Монысы да тагы, улы белән бер яклы булган булып, миннән көлеп маташа. *(Габдуллаҗанга.)* Җә, әйт тизрәк, Хисами кызына ризамы?

Габдуллаҗан. Мин аны белмим бит.

Мәхүпҗамал керә.

Хәмидә (*тиз генә урыныннан сикереп торып, Әхмәтҗанга карап, кашларын җимереп күз кыса, аннан, Габдуллаҗанга барып, акрын гына*). Кара аны, минем сүздән чыгасы булма, «риза» диген.

Бишенче мәҗлес

Әүвәлгеләр һәм Мәхүпҗамал.

Мәхүп. Исәнмесез!

Хәмидә *(каршына барып, Мәхүпнең башыннан чапанын алып).* Мәхүпҗамал абыстай, исән-сау килдеңме? Әйдә, түргә уз! *(Ишек янына барып.)* Бәдриҗамал! Кая, самавыр куеп җибәр!

Мәхүп. Хәмидә, бер дә мәшәкатьләнмәгез, минем бер дә эчәсем килми, әле Әсмабикәләрдән килешем, аларда бик озаклап чәй эчтем. Инде, Алла боерса, алар эшне башларга торалар. Сездән вәгъдә алуга гына эшләре терәлеп тора. Мин сезнең нәрсәләр бирмәкче булганыгызны аларга барып сөйләдем, бик яраттылар. Хәмидә кодагый ул...

Әхмәтҗан. Әле Хәмидәнең кодагый булып җиткәне юк.

Хәмидә. Җә, зинһар, кешенең сүзен бүлмә әле. Кодагый булмыйча, нәрсә булсын соң? Кызын биргәч, билгеле, кодагый кодагый була инде. Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, сөйлә, аңар карама! Ул әле бүген кире ягы белән торган.

Мәхүп. Әсма кодагыең әйтә...

Әхмәтҗан. Әсма да кодагый түгел әле.

Габдуллаҗан *(үз-үзенә)*. Һәм булмас та, Алла боерса, теләсәләр нишләсеннәр, мин аны алмыйм!

Хәмидә. Җә, җитәр инде, зинһар, әллә тилердеңме инде югыйсә?

Мәхүп. Җә, аның дигәненчә булсын инде, алайса, Әсмабикә әйтә: «Хәмидә ул бик булган, бик мәнле кеше, Алла боерса, кеше арасында битебезгә оят китермәс әле», – ди. Әле соң сез инде нинди киңәштә торасыз? Кичәге вәгъдәгездән, шаять, кайтмагансыздыр бит? Мин инде, Алла боерса, иртәгә вәгъдә бүләге итәргә килермен. Бүген шуны кереп белешеп чыгыйм дидем.

Әхмәтҗан. Ул ничек «кичәге вәгъдә»? Мин бит әле бу эшне бүген генә белдем.

Габдуллаҗан. Мин дә хәзер генә ишеттем.

Мәхүп. Ничек ул алай?

Хәмидә. Җә, сөйлиләр шунда, вәгъдәбез вәгъдә инде, Мәхүпҗамал абыстай.

Әхмәтҗан. Юк әле, анасы, син алай димә! Мин ул кадәр зурдан кубып, күп акчалар чыгарырга риза түгел.

Габдуллаҗан. Мин бөтенләй кызны алырга да риза түгел.

Мәхүп. Сөбханалла, әстәгъфирулла! Бу ни дигән сүз?! Сез мине алай итеп кеше алдында көлкегә калдыра күрмәгез. Мин инде аларга тәмам вәгъдә куеп килдем.

Әхмәтҗан. Мин вәгъдә-мәгъдәне белмим. Ул кадәр күп мәһәр сорый торган булсалар, мин колак сөенчесе алышырга риза түгел.

Габдуллаҗан. Мин андый белмәгән кызны алмыйм.

Хәмидә. Мужик шикелле, тупас итеп, «колак сөенчесе» дип сөйләмә инде, «вәгъдә бүләге» диген. Алабыз, Алла боерса, алабыз. Хәерле сәгатьтә булсын. Син дә, Габдуллаҗан, олы кешеләр алдында алай әдәпсезләнеп торма. Менә кияү булып кергәч күрерсең. Ул вакытта аны, син күрмичә, әллә кем күрмәс. Кызны кияүгә күрсәтеп бирмиләр.

Мәхүп. Шулай шул, кызны инде аны кияүгә биргәндә күрсәтеп бирмиләр. *(Халыкка карап.)* Күрсәтерлек урыны булмагач, нәрсәсен күрсәтсеннәр!

Габдуллаҗан. Мәхүпҗамал абыстай, мин бит аны бер дә белмим. Чибәрме соң ул кыз?

Мәхүп. Чибәр, улым, бик чибәр. *(Халыкка карап.)* Күрсәң, гайрәтең чигәр.

Габдуллаҗан. Укыган кызмы соң ул?

Мәхүп. Укыган, улым, укыган, бик зур укыган. *(Халыкка карап.)* Әлифне таяк дип тә белми, миңа аның нигә кирәге бар? Бары тик эш кенә булсын да, үземә тиешле сәдака-хәерне генә күбрәк алыйм.

Хәмидә. Мин ул кызны кече-кечедән беләм. Бик инсафлы, бик бастырынкы, бик чибәр бала, укымышы да зур, диләр, бик озак укыды.

Мәхүп *(халыкка карап)*. Бу җүләр дә инде, минем шикелле, бүләккә кызыгып, кызның начар икәнен белә торып, бергәләшеп мактый.

Габдуллаҗан. Урысча да укыганмы?

Мәхүп. Урысча да... Әһем, әһем...

Хәмидә. Укыган, укыган, бик яхшы укыган. Атасы өйләренә марҗа китертеп укыткан. Укымаган булса тагын, алгач, менә үзең укытырсың.

Мәхүп *(халыкка карап)*. Бу миңа караганда да ялганларга остарак икән. Ул кадәресен әйтергә минем телем бармаган иде.

Хәмидә. Шул инде менә, алайса, Мәхүпҗамал абыстай, иртәгә вәгъдә бүләге алышырбыз, диген.

Габдуллаҗан. Мин әле һаман риза булып җиткәнем юк.

Әхмәтҗан. Мин дә күп акча тотарга риза түгел!

Хәмидә. Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, аларның сүзләренә карама, риза, риза, иртәгә алардан да вәгъдә бүләге китерерсең, бер-ике көннән үк иҗабе кабул итәрбез[1].

Мәхүп. Алар инде күптән хәзер, намазлык, чолгауларны күптән хәзерләп куйганнар. Ходай боерса, вәгъдә бирнәләрен дә бик һәйбәт итәчәкләр, сиңа күлмәклек җон, кияүгә...

Хәмидә *(урыныннан сикереп торып)*. Нәрсә дисең?

Мәхүп. Сиңа күлмәклек җон, кияүгә...

Хәмидә. Күлмәклек асыл диген!

Мәхүп. Ялган булмасын, миңа күлмәклек җон дип әйттеләр. Хәтта, ялгыш булмасын дип, кайтарып-кайтарып сорадым, җон диде.

Хәмидә *(авызын бүлтәйтеп, бик ачу белән, бер торып, бер утырып)*. Ишкәннәр икән, вәгъдә бүләгендә үк алай итеп мыскыл иткәч, башкаларында алар тагын да изәрләр. Җон бирнә киярлек булгач, Хисами кызын алалар иде ди. Аның карачкы шикелле кызын алмасам, дөньяда кыз беткән иде ди.

Габдуллаҗан *(үзалдына)*. Аллага шөкер, әни үзе дә кызның «күркәм» сыйфатларын саный башлады.

Әхмәтҗан *(үзалдына)*. Ходайга шөкер, кыйммәтле туйдан котылам, ахры.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп)*. Аның тилиграм баганасы шикелле озын, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы кызын алмасам да, дөньяда киленсез калмам әле.

Габдуллаҗан *(үзалдына кулларын уып, шатланып)*. Шөкер, эшләр уңайлана.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп)*. Аның селте көянтәсе шикелле сыгылып төшкән кызына җефәк шикелле улымны әрәм итәмме соң мин!

Габдуллаҗан.
Әхмәтҗан. } Һәй, бәрәкаллаһ!

Бәдриҗамал *(ишектән кереп)*. Мәхүп абыстай, сезне Хисами байларның асравы чакыра, монда гына чыгып керсен әле, ди.

Мәхүп чыгып китә.

---

[1] *Иҗабе кабул итү* – алдым-бирдем ясау (кызны вәгъдәләшеп кую).

Алтынчы мәҗлес

Әүвәлгеләр, соңра Мәхүп.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп)*. Бай дигәч тә, бик исләре киткән, аның кеше чыкмаган өрәк шикелле кызын, бүләге дә булмагач, шайтаным ала. Улым, син дә бер дә хафаланма! Алла боерса, менә дигән кыз алырбыз.

Габдуллаҗан *(Хәмидә янына килеп)*. Юк, әни, бер дә хафаланмыйм, бәлки булмый калганына шатланам гына...

Әхмәтҗан *(Хәмидәнең аркасыннан сөеп)*. Хатын, акча күп чыкмаганлыгы өчен мин дә бик шатланам.

Хәмидә. Шулай булмый ни, аларның колга шикелле озын, шадра, төссез, ямьсез, кыек авызлы, кәкре аяклы кызларына, бүләге дә булмагач, эт барсынмыни? Аңыралар, эш башламас борын ук, үзләренең мәнсезлекләрен белдерделәр, мәнсезләр, эштән чыккан шыр тилеләр!

Мәхүп *(ишектән ашыгып кереп)*. Менә син, ә, харап булдым бит, ялгышлык белән харап булдым бит! Әсмабикә, үзенең каушавыннан зиһеннәре таралып, сиңа күлмәклек җон дип сөйләп җибәргән. Җон түгел икән, чачагы-чугы белән күлмәклек ука тирәкле асыл икән. Әле асравын шуны әйтергә җибәргән. Кодагый, зинһар, гаеп итә күрмәсен, үземнең зиһенсезлегем белән бик зур оятлы булдым, кодагый, зинһар, үпкәли күрмәсен, дигән.

Әхмәтҗан *(кулларын җилпеп)*. Очты инде ул кодагый булулар. *(Көлә.)*

Габдуллаҗан *(нос ясап, мыскыл итеп)*. Үтүт инде хәзер кодагый булырга! *(Көлә.)*

Хәмидә *(уынгалап)*. Менә син, ә, мин дә ашыгычлыгым белән ачуланып ташладым, оятлы булдым, оятлы булдым. *(Ялынганрак кыяфәттә.)* Карагыз әле, атасы, улым, әле дә эш узмаган бит, мин ул сүзләрне ачуымнан гына ялгыш сөйләп җибәрдем. Кодагый — бик мәнле, бик һәйбәт кеше, эшнең җаен бик белә торган кеше, кыз да ямьсез түгел, бик сөйкемле кыз...

Габдуллаҗан. Кодагыең эшнең җаен белсә, мин дә бик яхшы белдем инде. Син, үзеңә асыл бирнәләр килсен өчен, минем башымны колга, тилиграм баганасы, белмим, тагын әллә нәрсә шикелле озын, ямьсез, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы бер кызга бәйләмәкче булган икәнсең. Юк инде, хәзер торып тор, ул эшләр бик тиз генә эләкмәс! Хуш, сау булыгыз! *(Ишекне бик каты ябып чыгып китә.)*

Әхмәтҗан. Рәхмәт, анасы, рәхмәт, мине дә күп акча тотудан коткардың. *(Чыгып китә.)*

Хәмидә *(югары карап, олылаган тавыш белән)*. Әй Раббым, нинди гөнаһ шомлыкларым булды икән? Тәмам булган эшне тараттым.

Мәхүп *(халыкка карап, җылаган тавыш белән)*. Монда иң бәхетсез кеше мин! *(Хәмидәне төртеп күрсәтеп.)* Шушы җүләрнең тиктормас теле аркасында ничә күлмәклрдән, илле-алтмыш тәңкә сәдака-хәер акчаларыннан коры калдым.

Пәрдә төшә.

1909

اثر: ع. كمال.

بولەك

* * اوچون * *

ناشری: معارف کتبخانەسی.

بهاسی: ١٠ تين.

قزانده «اورنەك» مطبعەسی

КАЗАНЬ.
ЭЛЕКТРО-ТИПОГРАФИЯ „УРНЭК"
1909

«Бүләк өчен» комедиясенең 1909 елда «Мәгариф» китапханәсе чыгарган беренче басмасы (титул бите)

Хәмидә – Нәгыймә Таҗдарова

Әхмәтҗан – Касыйм Шамил

Габдуллаҗан – Шакир Мәҗитов

Әхмәтҗан – Равил Шәрәфиев, Хәмидә – Зөлфирә Зарипова

Ошбу сәнә 5 ноябрьдә «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәлек әдәби вә милли каләм хезмәте шәрәфенә аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды. Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен»дәге угылын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү, аның издиваҗ кеби олугъ бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне «Әлхәм» укыган кеби яңлыштырмый, гармонично санату фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга, аннан соң «Сәйяр» труппа артистларының сәхнәдә һәрвакыт, һәр җирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк ма биһил-ифтихарлары шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга, шул сәбәпле алар күп уйналганга, бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассый булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты.

Габдулла Тукай

БАНКРОТ

Пьеса 3 пәрдәдә

ӘШХАС[1]:

Сиражетдин Туктагаев – заһирдә бик суфи[2] күренә торган сәүдәгәр.
Гөлҗиһан – Сиражетдинның хатыны.
Җамалетдин Туктагаев, Камалетдин Туктагаев – Сиражетдинның бертуган карендәшләре.
Хәдичә – Сиражетдиннарга белеш тол хатын.
Нәгыймә – им-том итеп йөри торган карчык.
«Туганым» – Гөлҗиһанның карендәш тиешле кешесе.
Гарифә, Мәликә – кунаклар.
Мөхәммәтҗан 1 нче, Закир – кибетчеләр.
Мөхәммәтҗан 2 нче – кибетче малай.
Гарәфи – Сиражетдинның юлдашы.
Хәмди, Мәрфуга, Гайниҗамал – асраулар.
Доктор һәм Москва доверенныйлары.

Вакыйга Казанда.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сиражетдин Туктагаевның йорты. Яхшы итеп җыештырылган, бай сымак бер өй. Сул якта контор өстәле, аның янында бер шкаф, уң тарафта диван, өстәл, креслолар. Стена буенда урындыклар, көзгеләр, ике тарафта һәм түрдә ишекләр, ике як янда тәрәзәләр. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә бер кеше дә юк.

Беренче мәҗлес

Сиражетдин ялгыз.

Сиражетдин *(ишектән бик кызуланып кереп, як-ягына каранып).* Бик яхшы булды әле, бер кеше дә юк икән. *(Өстеннән намаз туны салып ташлап.)* Бер дә шаулама, эшләрнең һәммәсе дә минем файдага баралар әле. *(Кесәсеннән бер газитә чыгарып.)* Менә бүген дә бик шәп хәбәрләр язганнар әле. *(Укый.)* «Астраханнан менеп килә торган «Кавказ – Меркурий» пароходының беренче классында килә торган юлчы – Тарабаров исемле бер бай – өстенә-башына бик яхшы киенгән бер кеше белән белешләнгән. Аның белән берничә мәртәбәләр чәйләр эчеп һәм бергә ашап килгәннәр. Кич белән чәй эчкән вакытта, теге кеше Тарабаровның стаканына йоклата торган

[1] *Әшхас* – катнашучылар.
[2] *Заһирдә бик суфи* – тыштан бик изге.

дару салып эчерткән. Тарабаровның һушы китеп егылгач, янында алып бара торган унбиш мең сум акчасын алып, өстеннән каютын бикләп, үзе бер пристаньда төшеп калган». Шәп иткән бит, ә, Тарабаров йоклаган диген, ә! Йоклаган шул, йоклаган. Бигрәк аңгыра нәрсә икән. Хәзерге заманда шулкадәр күп акчаны үзең белән бергә юлга алып чыгарга ярыймы соң! Җүләр нәрсә, аны алдан сандыкка салып, кладавайга бикләп китәргә ярамаган икән. Кладавайга бикләп киткән булса, бер дә югалмас иде. Җүләр икән шул, җүләр. Җүләрне чәчеп үстермиләр аны, ул үзе үсә. Ну ярый, бик шәп булды әле, бу да бик шәп. Ярый, үземезчә гәзитәләр чыгуның файдасын быел ук күрдем. Үземезчә гәзитәләр чыкмаса, мин әле ул фикерне кайдан уйлап чыгара алыр идем? *(Гәзитәне шкаф астына куя да, аннан бер кочак гәзитә чыгарып.)* Менә алар монда никадәр! Боларның һәммәсендә дә шундый хәбәрләр тулып ята. Мин аларның монда талаучылары бер дә тотылмаганнарын гына сайлап җыеп куйдым. Миңа аның талаучылары тотылганнарының кирәге дә юк. Мине талыйсылары да юк, һәм минем үз янымда акча йөртәсем дә юк. Янымда акча йөртергә мин җүләр түгел. *(Гәзитәләрне тыгып куеп.)* Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз әле. Сез минем өчен бик кадерле нәрсәләр. Сез миңа никадәр зур гакыл бирдегез. Сез биргән гакылны шайтан үзе дә эзләп таба алмас. Коры көе генә, турыдан-туры гына зарар иттем, кеше өстендә алачакларым бик күп китте-фәлән дип кенә шартлап[1] булмый. Алай итеп кенә мәскәүләргә сумына ун-унбиш тиен генә биреп булмый. Аның мудасы да беткән, ышанмыйлар да. Ә болай булганда, үзләренең дә күзләре алакаер. Биргәнне тизрәк алып калырга тырышырлар. Ну, болай монда вакыт уздырып, озаклап торырга ярамый, тизрәк банкыга барырга кирәк. *(Шкаф астыннан бер кечкенә саквояжны чыгарып һәм аңа берничә төргәк кәгазьләрне салып.)* Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз. Сезнең һәрберегез бишәр йөз сумнан – барысы кырык тугыз мең тәңкә акча, ди. Ну, инде вакыт җитә. *(Сәгатен чыгарып карап.)* Сәгать унбер булган, озакламый пуезга төшәргә вакыт җитә. Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм! Кая, син, бире кил әле!

Икенче мәҗлес

Сираҗетдин, Гөлҗиһан.

Гөлҗиһан *(ишектән кереп).* Ай Алла, син кайткансың да икән. Мин белми дә торам. Теге якта, сиңа юлга булыр дип, кәтлит пешереп ятадыр идем.

Сираҗетдин. Мин хәзер банкыга барам, аннан акча алып кайтам, пуезга төшәргә вакыт җитә, син нәрсәләрне тизрәк хәзерләп куй.

Гөлҗиһан. Хәзерлә дип, мин әллә нәрсәләр хәзерләмим; юлга чәй, шикәр, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем. Аннан ары – менә хәзер кәтлит пешерәм. Шулар җитәр бит?

Сираҗетдин. Ярар, җитәр. Комган белән чәйнекне онытма. Юк исә юлда бик уңайсыз була. Аннан соң теге бохар намазлыгын да куй.

Гөлҗиһан. Ә, кара әле, хәтеремдә дә юк икән, намазлык дигәч исемә төште, анда сиңа ничә пар күлмәк кирәк булыр?

Сираҗетдин. Мин анда бик озак тормыйм, куй шунда бер-икене. *(Контор өстәленең тартмасын актара.)*

---

[1] *Шартлау* – бөлү, банкротка чыгу.

Гөлҗиһан. Мин өч пар күлмәк, ике сөлге, бер пар эскәтер, ике пар аяк чолгавы, өч тастымал куйдым. Шулар җитәр бит?

Сираҗетдин. Ярар, җитәр. Ләкин тизрәк хәзерлә. Мин хәзер кайтам, мин кайтуга һәммә нәрсә дә хәзер булып торсын. *(Бер кечкенә дәфтәрне тартмадан алып, кесәсенә салып, өстенә киенә дә кечкенә саквояжны алып чыга башлый.)*

Гөлҗиһан. Берәр калай савыт белән варинья дә куйыйммы?

Сираҗетдин. Ансы булмаса да ярар. *(Чыгып китә.)*

Өченче мәҗлес

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. Әй, харап булдым, сорарга да оныттым. *(Ишеккә тиз генә барып, ишекне ачып.)* Кара әле, сиңа әйтәм, нинди көрпәне куйыйм, зурнымы, кечкенәнеме? Юрган куйыйммы, адиялмы? *(Ишекне ябып.)* Йә, ярар инде, ишетмәде. Әле онытмаска кирәк, Мәскәү өстендә[1] бер-ике табын хатыннар уздырып алырга кирәк. Инде мәҗлес уздырмаганга әллә никадәр булды. Мәкәрҗә өстеннән бирле бер табын да мәҗлес уздырганым юк. Гыймран хаҗи Газизәсе Мәскәү өстендә сигез табын хатыннар уздырды. Безнекенең һаман ужуы[2] бетми, «уздырырсың әле» ди. Мәскәүдә анда әйбер бик арзан була, ди. Беркөннәрдә Гыймран хаҗи Газизәгә ике йөз илле тәңкәгә бик киң ике алтын беләзек алып кайткан. Күрсәң, матурлыгына исең китәр. Мин дә бер брушка алып кайтырга әйтим әле.

Дүртенче мәҗлес

Гөлҗиһан, Хәдичә.

Гөлҗиһан. Әйдүк, Хәдичә абыстай, хуш киләсең!

Хәдичә. Исәнме, Гөлҗиһан, исән генә торасызмы?

Гөлҗиһан. Аллага шөкер. Әйдә, Хәдичә абыстай, түрдән уз.

Берсе диванга, берсе креслога утырып, дога кылалар.

Хәдичә. Әйтүең-нитүең юк, синең Сираҗетдинең Мәскәүгә бара икән ич.

Гөлҗиһан. Әйе шул, хәзер озакламыйча баксалга төшә.

Хәдичә. Мин дә шуны ишетеп, китеп-нитеп бармасын дип, ашыга-ашыга килдем. Аңа әйтеп җибәрәсе йомышларым бар иде.

Гөлҗиһан. Нинди йомыш?

Хәдичә. Нинди йомыш дип инде, әллә нинди зур йомыш түгел. Без Мәргубәнең кызы Фатыйманы кияүгә бирмәкче булабыз бит. Минзәлә кайткач, туйларыбыз буласы. Шуңа бер пар чиккән өстәл эскәтере, дүрт намазлык, аннан соң берничә пар аяк чолгаулары кирәк буласы иде. Шуларны барган юлы Сираҗетдин Мәскәүдән алып кайтып бирмәс микән дип килгән идем.

Гөлҗиһан. Алып кайтыр, ник алып кайтмасын? Бик авыр хезмәт түгел ич ул.

Хәдичә. Зинһар инде, алайса, бер юлга, сүз тыңлап кына, шуларны алып кайтып бирсен инде. Менә шуңа дип илле тәңкә акча да алып килгән идем. Җитмәслек булса,

---

[1] *Мәскәү өсте* – Мәскәү ярминкәсе вакыты.
[2] *Ужу* – вакыт.

тагы үз яныннан бераз кушып булса да алып кайта күрсен. Кайткач исәпләшербез. Зинһар инде, яхшыны ала күрсен, кеше арасында оятка калырлык була күрмәсен. Безнең үзебезнең барып алырга ир-атыбыз да юк. Әле инде алтын сәгатьне дә моннан гына алмакчы булдык.

Гөлҗиһан *(акчаны алып).* Ярар, әйтермен, алып кайтыр. Нәрсәләр, нәрсәләр кирәк диган идең әле?

Хәдичә. Нәрсәләр икәнен менә яздырып алып килгән идем. *(Бер кәгазь чыгарып бирә.)* Зинһар инде, тыңлый күрсен!

Гөлҗиһан. Яхшы, яхшы, алып кайтыр.

Хәдичә. Хуш, Гөлҗиһан, сәламәт булып торыгыз, Аллаһы Тәгалә хәерле сәфәрләр бирсен!

Гөлҗиһан. Хәзер китәргә ашыга, шуның өчен инде сине хәзер утыр дип тә кыстый алмыйм.

Хәдичә. Юк, юк, кирәк түгел, юк сүзне сөйли күрмә. Утырган вакыт та булыр әле. Мәскәү өстендә, Алла бирсә, үзең рәхим ит. Ярый, хуш, сау бул! *(Чыгып китә.)*

Гөлҗиһан. Хуш! *(Озатып кала.)*

Бишенче мәҗлес

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. Намазлык димәктән, үземнең дә хәтеремә килмичә тора икән әле, үзебез өчен дә чиккән постау эскәтерләр кирәк иде. Бер дә хәтерем юк шул. Ишек чаршаулык яхшы плүш тә әйтермен дигән идем. Беркөннәрне Мәңгәр Йосыфларның ишек чаршауларын күреп исем китте. Мәскәүдән алып кайтканнар. Бөтенләй менә, алтынлаган нәрсә төсле, җалык-җалык итеп ялтырап тора. Ул кәнәфиләрен, урындыкларын күрсәң исең китәр, һәммәсен берочтан хәзерләгәннәр. Беркөн үзенә әйткән идем «без дә шундыйны алыйк» дип. «Тукта, байыйк әле, баегач алып кайтырмын» ди. Без кайчан баербыз әле, баеганчы көтеп торсаң, ул вакытта тагын әллә нинди матурлары килеп чыгар.

Асрау *(ишектән кереп).* Абыстай, Нәгыймә әби килгән, монда гына чыгып керсен әле, ди.

Гөлҗиһан. Ярар, хәзер чыга, диген.

Асрау чыгып китә.

Мәскәү өстендә тамыр кайнаттырып эчә торган идем. Шуны кайнатып бирергә дип килгәндер әле. *(Чыгып китә.)*

Алтынчы мәҗлес

Сиражетдин ялгыз.

Сиражетдин *(ишектән кызуланып кайтып кереп, өстен чишенеп ташлап).* Һәммәсе дә мин теләгәнчә булды. Барысына да бишәр йөз сумлык акчалар алдым. «Андый акчалар ни эшкә кирәк соң алар?» диләр. «Акчаны үзем белән алып барам, шуның өчен кирәк» дигән булам. Фидыр Иваныч әйтә: «Ай-һай, Сиражетдин Гыйлаҗетдинович, хата кыласың икән. Хәзерге заманнарда акчаны үзең белән йөртү

апасны бит, пирават белән генә җибәрергә кирәк иде», — ди. *(Өстәл тартмасыннан әллә нәрсә эзли.)* «Ничава, — дим, — Алла кушмаган эш булмас, — дим. — Мин бит мөселман кеше, — дим. — Мөселман кеше ул андый юк-бар эштән курыкмый», — дим. Миңа нигә куркырга? Аны кладавайдагы тимер сандыктан кем килеп урлый ала? *(Өстәл тартмасыннан ачкыч алып, саквояжны шкафка куеп, кесәләрендәге акчаларны бераз чыгарып, яңадан тыгып куеп.)* Әйдәгез әле сез, акчалар, мин кайтканчы, кладавайда бик һәйбәтләп, тынычлап кына ятып торыгыз әле. Эшне төзәтергә, бәлки, сез артыгы белән житеп торырсыз. *(Чыгып китә.)*

Җиденче мәҗлес

Гөлҗиһан, Нәгыймә.

Нәгыймә. Мин Сиражетдинны киткәндер дип белгән идем, ялгыш иртәрәк килгәнмен икән.

Гөлҗиһан. Килсәң ни булган, син аннан кача торган кеше түгел бит.

Нәгыймә. Әйе шул, кызым, ә Сиражетдин бит ул минем балам шикелле кеше. Рәхмәт инде аңа, мине һичбер вакытта да хәтереннән чыгармый. Зәкятыннан[1] да, нәзер-ниязларыннан[2] да һичбер вакыт коры калдырмый. Әле узган Мәскәүгә баруында да, «мә, әби, Хуҗа Баһаветдин[3] рухына багышлап дога кылырсың» дип, илле тиен сәдака биреп киткән иде. Җылый-җылый хәер-догалар кылдым, рәхмәт яусын инде аңа. Дәүләтенең дөнья вә ахирәт игелеген күрсен. Мин һәрвакыт догада гына торам. Безнең шикелле ятим карчыкларны зурлаган өчен инде аны Алла үзе зурласын.

Гөлҗиһан. Амин!

Нәгыймә. Кызым, инде «сәдака бирде» дигәч тә, мин аны болай гына әйтәм. Син тагы, «бүген дә шулай сәдака өмет итеп килгән икән» дип уйлый күрмә. Аннан-моннан әйтүем түгел. Инде моңа кадәр биргәннәрең дә Алла үзе кабул итсен.

Асрау керә.

Асрау. Абыстай, син ул чебешләрне кайсы кәрзинкәгә салырга дип әйткән идең?

Гөлҗиһан. Кайсы кәрзинкәгә булсын, капкачлы түгәрәк кәрзинкәгә. Кеше әйткәнне яхшылап колагыгыз белән тыңламыйсыз да, аннан ары тик миегез череп йөри. Күлмәкләрне хәзерләдеңме?

Асрау. Юк әле.

Гөлҗиһан. Һи, аңгыра нәрсәләр! Хәзер бит абзаң кайтыр вакыт җиткән. Баксалга төшәргә кызуланып йөри. Үзең карамасаң, бер эшне дә җүнләп эшләүче кеше юк. Нәгыймә абыстай, син бераз утырып тор әле, мин, чыгып, шул нәрсәләрне генә рәтләп керим әле.

Нәгыймә. Ярар, кызым, бар, бар. Минем өчен эшеңнән кала күрмә.

Гөлҗиһан чыгып китә.

---

[1] *Зәкят* — дини налог; сәүдәгәрләр килеренең кырыктан бер өлеше, башкаларыннан йөздән бер өлеше алына торган мәҗбүри салым.

[2] *Нәзер-нияз* — дини йола; берәр теләккә ирешү өчен дога кылдыру.

[3] *Хуҗа Баһаветдин* — XIV гасырда Бохара шәһәре тирәсендә яшәгән суфи, динчеләр аны изге кеше дип йөрткәннәр.

Сигезенче мәҗлес

Нәгыймә ялгыз.

Нәгыймә. Биргән кешегә Алла бәхетне учлап биргән. Бирмәгәнгә бер тиен дә юк. Әле мин белгәндә генә, Сиражи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде. Аз арада гына нинди баеды да китте. Әүвәлге йорты да нинди яхшы, һәйбәт йорт иде. Базарга йөрергә ерак дип, ансын сатты. Хәзер инде Сиражи зур пулатлы бай булды. Хәзер инде Сиражиның ялтыраган көмеш көпчәкле ризиновыйларда киерелеп утырып йөргәнен күрсәң танымассың да. Ризиновыйларның көпчәкләре җылык-җылык итеп тора. Карарга күз чагыла. Ризиновыйның шиннәре бүрәнә җуанлыгы бар. Мескен Сәлимә генә бу рәхәтләрне күп күрә алмады. Үлеп китте. Берәү үлә, икенчеләре көн күрә. Ни эшләмәк кирәк соң, әҗәлдән котылып калыр хәл юк шул. Берәүнең бәхетенә икенче кеше керә алмый. Яшь хатын бәхете инде. Бичара Сәлимә бик яхшы хатын иде. Килгән саен, учлап-учлап чәй-шикәрләр биреп җибәрәдер иде. Куркулыкларны[1] да бик еш койдырадыр иде. Хәер, әле Гөлҗиһан да минем өчен файдасыз түгел. Әледән-әле тамырлар кайнаттырып ала. Тукта әле, мин тагы, бу якта утырып, авызымны ачып, юл сәдакасыннан колак кагып калмыйм. Сиражи китеп-нитеп бармасын. Чыгыйм әле. *(Чыгып китә.)*

Тугызынчы мәҗлес

Сиражетдин, Гөлҗиһан, соңра Нәгыймә.

Сиражетдин *(ишектән кереп, язу өстәле янына барып, кечкенә дәфтәрне өстәл тартмасына салып).* Инде эш тәмам булды. *(Ишек янына барып.)* Кара әле, сиңа әйтәм. Бире кара әле.

Гөлҗиһан керә.

Нихәл, нәрсәләрне хәзерләп бетердегезме? Миңа китәргә вакыт.

Гөлҗиһан. Хәзерләдем.

Сиражетдин. Бик яхшы, алай булса. Кая, миңа бик яхшы таза аякчулар китер әле.

Гөлҗиһан. Ни эшлисең ул аякчулар белән? Мин кичә генә ак аякчулар биргән идем бит.

Сиражетдин. Бар әле син, тизрәк китер. Пуезга соңга калам. Ни эшкә икәнен соңыннан күрерсең.

Гөлҗиһан чыгып китә.

Эшне шулай итеп бик ныгытып пешереп эшләргә кирәк. Бер дә кеше шикләнерлек булмасын. *(Шкафтан саквояжны алып.)* Менә болар инде акчалар ди. Аларны югалмасын өчен бик яхшылап балтырларга чорнарга кирәк. *(Аякларын чишенә башлый.)* Бераз йөрәк сикерә сикерүен дә, шулай да булса серне бирергә ярамый. Нык торырга кирәк. *(Каты гына итеп тамагын кырып, киемнәрен төзәтеп, үзенә канәгатьле бер кеше кыяфәте биреп куя.)* Менә шулай. Бер дә серне бирмә, нык тор.

---

[1] *Куркулык* – дини йола; кеше авырганда, берәр нәрсәдән курыккан дип, шул авыру янында кургашын эретеп салу.

Гөлҗиһан керә.

Гөлҗиһан. Менә аякчулар китердем. Бу аякчуларың да ак ич әле.

Сираҗетдин. Мин сиңа әйттем бит, соңыннан аңларсың дип. Менә бу кәгазьләр акча булыр. Боларда кырык тугыз мең тәңкә, аңладыңмы? Кырык тугыз мең, кырык тугыз мең тәңкә акча бар.

Гөлҗиһан. И Ходаем! Кая әле? *(Бер төргәкне алып, ачып карамакчы була.)*

Сираҗетдин. Чү-чү-чү! Тия күрмә! Мин аларны бик ыспайлап юка итеп төреп куйдым. Чуалтма. *(Төргәкле кәгазьләрне ала. Халыкка карап.)* Бөтенләй эшне боза язды. *(Гөлҗиһанга.)* Менә аларны шушылай итеп, бик һәйбәтләп читек балтырына батырабыз. *(Төргәкләрне, икешәр-икешәр итеп, балтырларының ике ягына куеп, аякчу белән чорный башлый.)* Бар, син, кара әле, ишекләр яхшы ябылганмы? Анда ишек ярыгыннан карап торучылар булмасын!

Гөлҗиһан *(ишекләрне барып карап)*. Юк, бернәрсә дә юк, һәммәсе дә бик яхшы ябылган. Кара әле, сиңа әйтәм, соң ул акчаларыңны читек балтырыннан төшереп югалтып харап булмассыңмы? Әллә ни эшләп күңелем шикләнә. Шул саквояжга гына салсаң, тагы да яхшырак булмасмы? Бу саквояжның биге дә бар.

Сираҗетдин. Һи, хатын, хатын, синең бер дә башың йөрми икән. Соң шул саквояжны урласалар? Ул вакытта ни эшләрсең? Ул бит кечкенә нәрсә, күтәрерләр дә алып чыгып китәрләр. Ә син акчадан колак кагып калырсың.

Гөлҗиһан. Хәер, инде ансын үзең беләсең. Шулай да ул кадәр күп акчаны читек балтырына гына кую, әллә ничек, бик куркынычлы шикелле тоела.

Сираҗетдин. Тәкъдирдә язылмаган булса, бернәрсә дә булмас. Бая банкыда Фидыр Иванич та шулай дип әйткән иде. Мин әйттем: «Мин мөселман кеше, тәкъдиргә ышанам, — дидем. — Ето, — дидем, — судба, — дидем. — Судбада язылмаса, бернәрсә дә булмас», — дидем. Фидыр Иванич, башын селкеп, бик гаҗәпләнеп калды. *(Киеп бетерә.)* Нихәл, бик җуан булмадымы? Тыштан бик беленеп тормыймы?

Гөлҗиһан. Юк, алай зарарлы түгел, бик беленми.

Сираҗетдин. Кая инде, алайса, әйберләрне чыгарсыннар. Пуезга төшәргә вакыт, Закирны дәшсеннәр, әйберләрне күтәреп чыгарыр. Кара әле, син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә. Бу чагында бер дә кешегә ышаныр хәл юк.

Гөлҗиһан. Алла үзе сакласын. Кешегә сөйләргә мин җүләр түгел.

Сираҗетдин. Бар, әйт, тизрәк нәрсәләрне чыгарсыннар!

Гөлҗиһан *(ишекне ачып)*. Кая, абзагызның багажларын чыгарыгыз!

Ишектән асрау белән Закир багажларны күтәреп керәләр.

Закир. Абзый, менә шулай итеп бәйләгән идем, ярармы?

Сираҗетдин *(нәрсәләрне карап)*. Ярар, яхшы бәйләгән. *(Гөлҗиһанга.)* Кирәкле нәрсәләрнең барысы да хәзерләнгәнме?

Гөлҗиһан. Хәзерләнгән, хәзерләнгән. Бер мендәр, көрпә, адиял куйдым. Комганны менә бу капчыкка тыктым. Өч пар күлмәк, ике сөлге, өч тастымал, бер пар аякчу, намазлык, кичке күлмәк — һәммәсен дә куйдым...

Сираҗетдин. Чәйнек, чынаяк?

Гөлҗиһан. Куйдым, куйдым, аларын да куйдым. Бер пычак, балкашык, тоз — һәммәсен дә куйдым. Юлга ашарга унике кәтлит, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем. Менә алары бу кәрзинкәдә булыр. Чәй-

шикәрләр дә шунда. Бер савыт белән варинья дә куйдым. Юл йөргәндә ашалыр әле, әрәм булмас.

Сираҗетдин. Ярый, бик яхшы. Закир, бар, син тизрәк әйберләрне атка чыгарып сал.

Закир күтәреп чыгып китә.

Йә, әйдә, Аллага тапшырдым инде, дога кылыйк. Өйгә яхшы күз-колак була күр. Кибетчеләр, абзый өйдә юк дип, иркенләп йөрмәсеннәр. Вакытында кайтып, вакытында кибеткә чыксыннар. Кич белән капканы бикләтеп, ачкычны үз янында ал. Кич белән чыгып йөрмәсеннәр.

Гөлҗиһан. Ярый, Алла боерса.

Сираҗетдин. Йә, ярый, башка йомыш-юл юкмы инде?

Гөлҗиһан. Ә, хәтеремдә дә юк икән, онытып кала яздым. Бая Хәдичә абыстай килгән иде. Мәргубә кызы Фатыйманы кияүгә бирмәкче булалар икән. Минзәлә кайткач, туйлары буласы, ди. Шуңа эскәтерләр, намазлыклар, тагын әллә нәрсәләр кирәк буласы икән. «Зинһар, Сираҗетдин шул йомышларны гына йомышлап кайтсын ла» дип, илле тәңкә акча калдырып киткән иде, менә акчасы, менә язуы.

Сираҗетдин *(халыкка карап)*. Ишкән икән! Мине чынлап та Мәскәүгә бара дип белә торганнардыр. *(Чырайларын сытып.)* Алар артыннан йөрергә минем эшем беткәнмени? Минем үз эшләрем дә күп. Башка кеше тапмаганнар икән.

Гөлҗиһан. Әманәт җан саклар, ди. Бер юлга гына тыңларсың инде. Мин аңа алып кайтыр дип ышандырып калдым.

Сираҗетдин. Ярар, хәерле булсын инде. Вакытым булса, алып кайтсам кайтырмын тагы.

Гөлҗиһан. Аннан соң тагы шуны да әйтермен дигән идем. Мәскәүдә анда нәрсә бик очсыз була, ди. Барган көе шуннан бер-ике генә чиккән постау эскәтер белән ишек чаршавы өчен яхшы плүш алып кайтсаң, бик һәйбәт булыр иде. Плүш чаршау бик матур була икән. Беркөн Мәңгәр Йосыфларда күргән идем, алар Мәскәүдән алып кайтканнар икән. Бик матур, кәнәфиләрен, урындыкларын да — һәммәсен берочтан шуның белән тышлатканнар.

Сираҗетдин. Яхшы, ярый, вакыт тисә алып кайтырмын.

Гөлҗиһан. Әле шуны да әйтермен дигән идем: Гыймран хаҗи Газизәгә бик һәйбәт, бик киң алтын беләзекләр алып кайткан икән. Минем беләзекләрем күп; юньле, яхшы брушкаларым гына юк. Шунда, бер барган көенчә, яхшырак бер брушка да алып кайт.

Сираҗетдин. Яхшы, ярый, вакыт тисә алып кайтырмын. Йә, дога кылыйк инде, пуезга соңга калам.

Гөлҗиһан. Йә, ярый.

Дога кылырга утыралар.

Нәгыймә *(акрынлап ишектән кереп)*. Йа Рабби Ходаем, тәүфикълы, тәлигале[1] гомерләр насыйп ит. Байлык, шатлык белән көн күрергә, шатлык, рәхәтлек белән йөреп кайтырга насыйп булсын. *(Урындыкка утыра.)*

Дога кылалар.

Сираҗетдин. Исәнме, Нәгыймә абыстай! Син монда идеңмени?

---

[1] *Тәлигале* — бәхетле.

Нәгыймә. Әйе, улым, монда. Син Мәскәүгә китә дигәч, күрешеп калыйм дидем.

Сираҗетдин *(кесәсеннән бер көмеш акча чыгарып биреп)*. Яхшы, Нәгыймә абыстай. Хәер-фатихада булыгыз инде.

Нәгыймә. Рәхмәт, улым, рәхмәт! Сәламәтлек, шатлык, куанычлык белән күрешергә насыйп булсын. Бай бул, улым! Баеп кайт. Минем шикелле ятим карчыкларны куандырган өчен, сине Алла үзе куандырсын.

Сираҗетдин. Хуш инде, әби, хуш, Гөлҗиһан. *(Гөлҗиһан белән күрешә.)*

Нәгыймә. Хуш, улым, хуш. Исән-сау йөреп кайт.

Сираҗетдин чыгып китә, Гөлҗиһан озата чыга.

Унынчы мәҗлес

Нәгыймә, соңра Гөлҗиһан, соңра асраулар.

Нәгыймә *(кесәсеннән акчасын алып карап)*. Ярый, ярый, хәерле сәфәр булсын. Бөтенне яудырган икән. Ахры, бу араларда файданы яхшы итә башлагандыр. Гөлҗиһан керсен дә инде, аннан ары акрынлап кайтырмын. Бәлки, тамыр кайнатырга акча да бирер әле.

Гөлҗиһан, кереп, тәрәзә саен карый.

Нихәл, кызым, озаттыңмы? Ярый инде, сәламәтлектә, шатлыкта йөреп кайтсын.

Гөлҗиһан *(тәрәзәдән башын алып)*. Киттеләр. Мәскәү өстендә дүрт-биш табын хатыннар уздырып алырмын дигән идем. Үзеннән сорап калырга аз гына хәтеремнән чыкмаган, озата чыккач, өйалдында гына исемә төште.

Нәгыймә. Яхшы, яхшы, кызым, бик яхшы. Шулай байлыгыгызның кадерен белеп калыгыз. Хуш, сау бул, кызым, кайтыйм инде.

Гөлҗиһан. Тукта, китми тор, чәй эчәрбез. Ашны берсекөнгә үк уздырып алам. Асрауларга өйләрне җыештырырга гына кушыйм да, аннан ары чәй эчәрбез. Гайниҗамал, Мәрфуга, Хәмди! Керегез әле монда.

Асраулар керәләр.

Асраулар. Нәрсә, абыстай, ни дисез?

Гөлҗиһан. Менә абзагыз сезгә юл сәдакасы биреп калдырды. *(Бирә.)* Хәмди, син теге бүлмәгә безгә чәй хәзерлә. Мәрфуга, син аш пешерүче хатынга бар. «Абыстай, берсекөнгә биш табын гына хатыннар уздырам, бүген үк хәзерләшергә килсен, дип әйтте» диген. Син, Гайниҗамал, кибеткә төш тә Мөхәммәтҗанга әйт: хәзер биш табынлык запискә язып менгерсен. Аннан кайтышлый Бәдри Мәфтухасына төшеп әйт: өйләр җыештырышырга килсен. Бар, тиз булыгыз! Аннан ары менә бу якларны җыештыра башларсыз. Барыгыз! Аңладыгызмы?

Асраулар. Аңладык, аңладык. *(Чыгып китәләр.)*

Гөлҗиһан. Әйдә, Нәгыймә абыстай, теге якка, чәй эчәрбез. Аннан сиңа тамыр кайнатырга акча да биреп җибәрермен. Берсекөнгә ашка син дә килерсең. Онытма, яме!

Нәгыймә. Ярар, кызым, ярар. *(Тора башлый.)* Алла! Ай! Билләрем авырта. Картлык.

Чыга башлыйлар.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге зал. Ак эскәтерләр ябылган өстәлләр хәзерләнгән. Түрдәге сәгать икенче ярты булган.

Беренче мәҗлес

Н ә г ы й м ә ялгыз.

Н ә г ы й м ә *(ишектән чирекле шешә белән саргылт төстә сыек бер нәрсә күтәреп кереп).* Уф Алла, арып беттем. *(Шешәне урындыкка куеп, башыннан шәлен сала.)* Бүгенге мәҗлескә килгәнче тизрәк өлгерсен дип алып килдем. *(Шешәне селкетеп.)* Йөзе кара, бер дә күбекләнми. Тизрәк әчесен, тизрәк төнәсен дип, трахтир сырасын ике шешә итеп салган идем, алай да әле әчеп җитмәгән. Монысы кыйммәткә төште: егерме тиенгә тамыр алдым, ике шешә трахтир сырасы, ярты кадак шикәр салдым. Мин кайнаткан тамырны бай хатыннары бик яраталар. «Синең кулың бик шифалы, әчеп җибәргәч тә, бөтен тамырларга китә, тәмам изелдереп йоклата», – диләр. Трахтир сырасын күбрәк салсаң, аның өстенә актан да бераз тамызсаң, йоклату гына түгел, җырлатыр да ул. *(Шешәне алып.)* Тукта әле, моны кая булса да бер җиргә яшереп куярга кирәк. Йә кунаклары-ниләре килеп күрерләр. Бай хатыннары алар бер дә серләрен кешегә сиздерәселәре килми. *(Шешәне диван астына яшереп.)* Аларның баш ярылса – бүрек эчендә, кул сынса, җиң эчендә була. *(Икенче ишектән чыгып китә.)*

Икенче мәҗлес

Г ө л җ и һ а н белән «Т у г а н ы м».

Г ө л җ и һ а н *(«Туганым» белән ишектән кереп).* Туганым, зинһар инде, син булыша күр. Бер дә күз-колак булырлык, булышырлык кешем юк. Син, зинһар инде, шунда рәтләп, кунакларны карап утырта күр. Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен. Бик үпкәчән, бик гаепчән кеше. Түбәнгә калдырсаң, күзенә күренгән бер кешене дә калдырмас, һәммәсенә сөйләп йөрер. Аны менә бу табынга, түргә утыртырсың.

«Т у г а н ы м». Ярар, ярар.

Г ө л җ и һ а н. Аннан ары, аның менә бу ягына Гариф хаҗи хатыны Мәликәне утыртырсың. Аларның икесенең бер-берсе белән серләре бик килешә.

«Т у г а н ы м». Һи, алар бер-берсен күрсәләр, бер дә сөйләшеп туя алмыйлар, икесе дә нәкъ тел бистәсе.

Г ө л җ и һ а н. Шулай шул, икесе бергә килсәләр, бөтен шәһәрдәге кешене элеп алалар да селкеп салалар. Шуның өчен бер дә аларның теленә керәсем килми. Алар менә шунда утырырлар.

«Т у г а н ы м». Ярар.

Г ө л җ и һ а н. Гарифә кодагыйның бу ягына Хаммат Әхмәтҗанының хатыны Хәдичә кодачаны утыртырсың. Монысына Гәчтинни Салих хатыны Рәбиганы утыртсаң да ярар. Әптери Хәйрулласының хатыны менә монда, түбән утырыр.

«Т у г а н ы м». Ярар, ярар.

Г ө л җ и һ а н. Әнимай Ибрае, Самавар Кәрим, Кылтын Гарәфи, Чатан Хафиз хатыны шикелле бертөрлерәк кешеләрне теге якка табынга утыртырсың; аларга өстәл булмаса да ярар. Үзләре дә әллә кем түгел әле. Әнимай Ибраеның хатынын бөтенләй чакырмыйм да дигән идем әле, үзенә кардәш тигәнгә күрә, чакырмый калырга

яхшысынмадым. Беркөннәрдә кызлар җыены җыйган, шунда, күршедә тора торып, мине утыртып калдырган. Бөтенләй менә җен ачуларым чыкты.

«Туганым». Тумачи җиңгине кайда утыртыйм?

Гөлҗиһан. Тумачи җиңгиләр, Апакъ абыстайлар алар – үз кеше. Алар, урын булса, теге якка утырырлар, урын булмаса, тагы калып та торырлар. Соңыннан утырырлар. Камилә туганым да теге якка табынга утырыр. И, валлаһи, бу асрауларга ышансаң, һичбер эшне юньләп эшләмиләр. Кара инде бу урындыкларны, чат тузан. Өй җыештыруларының һичбер элә-танагы юк. *(Ишекне ачып.)* Хәмди, кая, миңа бер кара сөлгеме, чүпрәкме бир!

«Туганым». Фатыйма тудыкъ кайда утырыр?

Гөлҗиһан. Фатыйма тудыкъ? Һә! Борын астыннан китеп торыр әле. Мин аны чакырмадым.

«Туганым». Ни эшләп?

Гөлҗиһан. Теле бик озын, шуның өчен.

Асрау сөлге кертеп бирә.

(Асрауга.) Сезнең, ахры, инде бөтенләй күзегез үк чыккандыр. Күзегез чыккан булмаса, менә бу тузаннарны күрер идегез. Бар, эшеңдә бул! Шәрифә остабикәгә ат җибәрсеннәр.

Хәмди. Ярый. *(Чыгып китә.)*

Гөлҗиһан *(тузаннарны сөрткәләп, сүзендә дәвам итеп)*. Беркөнне Нәгыймә абыстайга дөньяга килмәгән сүзләр сөйләп җибәргән. Мине бөтенләй эреткән дә череткән: бичара Сираҗи бик бәхетсез икән, бәхетле булса, ул бер дә Гөлҗиһанны ала торган егет түгел иде, ди икән. Мине, Сәлимә үлгәч, үзе өфү-төфүләр китереп, яучы җибәреп, Сираҗига ялынып барды, ди икән. Гөлҗиһан ул Сәлимә туганымның кисеп ташлаган тырнагына да торырлык түгел, өфү-төфүләр итеп-итеп, ярап тора инде шунда, дип әйтә, ди. Аллам сакласын, ашым-суымны аңар әрәм итәргә. Гомерем буена, Алла боерса, мин аны бусагамнан да атлатмам!

«Туганым». Аның инде бер дә теле-теше тимәгән кешесе юк. Кемне күрсә, шуңа бәйләнә. Шуңа күрә үзе дә кибеп, корып беткән инде. Им-том белән генә тора. Алар былтыр Уша Башына җыенга кайтканнар иде, шунда салып куйган җирендә бөтилеген онытып калдырган. Аны Фәхри абзыйның хатыны алып актарып караган. Эчендә бер дә юк нәрсә юк, ди: төргәк-төргәк чәчләр, җылан мүгезләре, һөдһөд тиреләре – һәммәсе дә бар, ди.

Хәмди *(ишектән кереп)*. Абыстай, Гаян остабикәнең асравы кергән, аларның ашлары бүген микән, иртәгә микән, дип әйтә, ди.

Гөлҗиһан. Син нәрсә дидең?

Хәмди. Бүген, дидем. Миңа биргән запискәләрендә иртәгә дип язылган, Гыймади муллаларга биргән запискәләрендә бүген дип язылган, дип әйтә, ди.

Гөлҗиһан. Ул ни дигән эш икән, туганым, әгәр дөрес булса, харап булдык. Әгәр бүтән кешеләргә дә шулай дип язылган булса, хур булдык! Ул нинди эш икән? Мөхәммәтҗан мондамы?

Хәмди. Монда. Әле генә өндәүдән йөреп кайтты.

Гөлҗиһан. Бар, әйт, монда керсен.

Асрау чыгып китә.

Үзең карамасаң, һичбер эшнең рәте юк. Кара инде монда, табынга тоз савыты да куймаганнар. Туганым, бар, син генә чыгып, тоз савыты гына алып керсәнә. Алакайган күзләр, шуны да күрмиләр.

«Туганым». Ярый. Тоз савытларыгыз кай төштә?

Гөлҗиһан. Шунда асраулардан сорарсың, бирерләр.

«Туганым» чыга башлый.

Ай Алла! Харап булдык! Күзләре чыккан нәрсәләр, бу табынга тишек эскәтер җәйгәннәр. Шулкадәр әйтеп, кулларына тоттырып бирдем, «бу тишек эскәтерне остабикәләр табынына җәясе» дип. Сүзне һич колаклары белән тыңламыйлар. Туганым, зинһар, тиз генә монысын да алмаштырып җәя күр! И Ходаем, кунаклар килер вакыт җиткән, безнең табыннар да хәзерләнеп җитмәгән. И Раббым! Үтте үзәгемә шул асраулар!

Тәлинкәләрне алып, эскәтерне җыялар. «Туганым» эскәтерне күтәреп чыгып китә.

Өченче мәҗлес

Гөлҗиһан, Мөхәммәтҗан, «Туганым».

Мөхәммәтҗан *(ишектән кереп)*. Нихәл, абыстай, ни йомыш?

Гөлҗиһан. Бирермен, өшегән авыз, сиңа йомышыңны! Күзең чыккан нәрсә! Ни эшләп Гаян остабикәнең запискәсенә «дүшәмбе көн» дип яздың?

Мөхәммәтҗан. Юк, абыстай, алай дип язмадым, «якшәмбе» дип яздым. Гаян остабикә ул үзе язу танымый.

Гөлҗиһан. Ялганлама миңа, остабикә кеше ни эшләп язу танымасын.

Мөхәммәтҗан. Абыстай, валлаһи, танымый менә, билләһи, танымый. Кичә мин запискәне биргәч тә: «Син теге, лимунчы Гыйлаҗиләрдән килдеңмени?» — ди. «Абыстаң исәнме? Кечкенәләре исәнме?» — ди. Мин әйтәм: «Юк, абыстай, безнең бай хатынының баласы юк, аның баласы булмый», — дидем. «Мин лимунчы Гыйлаҗи малае түгел», — дидем.

Гөлҗиһан *(ачуланып)*. Нәрсә? Кит моннан, йөзең кара, бар, тиз чык! Мин сине, абзаңа әйтеп, типкәләтеп чыгарырмын.

Мөхәммәтҗан чыгып китә.

Кара син аны?! Көчегенә кадәр: «Абыстайның баласы булмый аның», — дип, очраган бер кеше саен сөйләп йөри бит! Мин телләрегезне бик тиз кыскартырмын. Ул аны зурлары авызыннан ишетеп сөйли торгандыр әле. Мин аларны коры тотармын. Абзаларына әйтеп, һәммәсен дә кибеттән кудырып чыгарттырырмын.

«Туганым» *(ишектән кереп)*. Туганым! Монда гына чыгып кер әле, харап булдык! Оятлы булдык! Кунаклар килер вакыт җиткән, безнең аш артыннан утыртырга бламажи[1] да хәзерләнмәгән.

Гөлҗиһан. Ә, ни дисең? Ай Алла, туганым! Ул нинди сүз? Харап булдык!

Чыгып китәләр. Зал бераз буш тора.

---

[1] *Бламажи* (бланманже — фр. *blanc* — «ак», *manger* — «ашарга») — сөт, какао яки җиләк-җимеш суларына шикәр, желатин кушылып әзерләнгән һәм аш артыннан бирелә торган ашамлык.

Дүртенче мәҗлес

Хәмди ялгыз.

Хәмди *(кулына эскәтер белән тоз савыты күтәреп, көлеп)*. И билләһи, кызык соң тегендә. Абыстай тетә тегендә безне тиргәп. Мине тирги, Мәрфуганы тирги, аш пешерүчене тирги. Аш артыннан утыртырга бламажи пешерелмәгән, ди. Аның өчен без гаеплемени? Йөрмәссең түшеңне киереп, калфакларыңны кәкрәйтеп! Үзенең кулыннан бер эш килми, кешене тиргәгән була. Бая тагы «Безнең абыстайның баласы булмый» дигән өчен кибетче малайны куып, тиргәп чыгарган. Аның баласы булмаганга безнең нинди гаебебез бар? «Баласы булмый» дип әйтүче кеше без түгел. Абзый үзе беркөннәрдә кибеттә, кантур бүлмәсендә, Сафа абзыйга сөйләп утырган: «Минем хатынның баласы булмый, шуның өчен бер дә мәхәббәтем юк, әгәр эшләрем яхшы барса, Мәскәү кайткач монысын аерып, аның урынына икенче бер, бала китерә торган кыз алам, өйләнәм», – дигән. Закир аны ишек артыннан тыңлап торган да Мөхәммәтҗанга әйткән. Мөхәммәтҗан миңа әйтте: «Безнең абыстай бала китерми икән, абзый аны яратмый икән, аны аерып икенче бер яшь хатын алмакчы була икән», – диде. Ә абыстай монда беркөннәрне, Мәкәрҗә өстендә, абзый өйдә юк вакытта, Нәгыймә әби чүлмәк салырга килгән чакта, абзыйны гаепләп утырды: «Аның баласы булмый», – диде. Аларның берсенә дә ышаныр хәл юк. *(Чыгып китә.)*

Бишенче мәҗлес

Гарифә белән Мәликә.

Гарифә *(Мәликә белән ишектән кереп, түргә утырып)*. Син ишеттеңме? Алар анда нәрсә пыш-пыш сөйләшәләр?

Мәликә. Юк, мин ишетмәдем. Мин кергәч, шып туктадылар.

Гарифә. Мин кергәч тә шулай иттеләр. Әллә нәрсә «бламажи» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Йә бламажилары оемагандыр әле. Йә җилемен аз салганнардыр.

Мәликә. Бламажилары оемаган дигәннән исемә төште, беркөннәрне мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лычкылдап тора.

Гарифә. Андый була ул, әнә беркөнне мин читекче Таҗиларга чәйгә барган идем. Кабарткан паштитлары менә нәкъ такта шикелле булган. Бөтенләй менә үзе такта шикелле, үзе ике куллап сындырып булмаслык каты булган иде.

Мәликә. Читекче Таҗи дигәннән исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде. Ончы Шакир улына кияүгә биргәннәр иде, ишеткәнең бармы, чибәр торалар микән?

Гарифә. Белмим, чибәрдер, сорашканым юк, каенанасының сүзен бер дә тыңламый, диләр иде.

Мәликә. Каенанасының сүзен бер дә тыңламый дигәннән исемә төште әле, син ишетмәдеңме, тегүче Әхмәдулла хатынын аерган дигәннәр иде, чын сүз микән?

Гарифә. Чын булырга кирәк, беркөнне югары урамга кибеткә чыкканда күргән идем, кулына кәрзинкә күтәреп, бәрәңге алып йөридер иде.

Мәликә. Бәрәңге димәктән, безнең дә кәбестә тозлыйсы бар иде әле, алдырырга һич җитешә алганым юк. Сез тозладыгызмы әле?

Г а р и ф ә. Тозладык, алма белән карбыз да тозладык. Кәбестәләр бик һәйбәт туры килде.

М ә л и к ә. Кавын тозламадыгызмыни?

Г а р и ф ә. Пудвалчы Әхмәтләр кавынны үзебез җибәрттерербез дигәннәр иде дә, ужулары җитмәде. Карбызлар көпшәкләнеп бетәр дип көтмәдек.

М ә л и к ә. Ул пудвалчы Әхмәтнең улы аталарын ташлап чыгып киткән дигәннәр иде, дөрес булды микән?

Г а р и ф ә. Дөрес. Аларның астында фатирда торган ямшекнең бер кызы бар икән. Шул кызны алам, дип әйткән, ди. Аталары алырга риза булмагач, ташлап чыгып киткән, ди.

М ә л и к ә. Ул башы белән чыгып кая бара инде ул? Алар инде бөтен нәселләре белән шулай булып чыктылар. Әхмәтнең энесе дә аның җүнле җирдән өйләнмәде. Нигъмәтҗан кучернең кызын ябыштырып чыгарды.

Г а р и ф ә. Хәзер инде кыз ябыштырып чыгару бер җола булып китте. Әле менә шул көннәрдә генә итче Вәлинең кызы тулчукчы Сабир улына ябышып чыккан, ди.

М ә л и к ә. Ай Алла, ул шулаймыни? Миңа тагы аны беркөнне Хәмидә «үзләре алдылар» дип сөйләгән булды.

Г а р и ф ә. Алдылар, алмый ни! Кызлары ябышып чыкмаса, Вәлиләр кызларын үзләре риза булып тулчукчыга бирерләр идеме соң? Вәлиләр алар бай кешеләр бит.

М ә л и к ә. И-и, бай булсалар да инде, бер дә затлы кешеләр түгел. Хатыны бөтенләй чирмеш әкәе төсле нәрсә.

Г а р и ф ә. Чирмеш әкәе дигәннән, шуны әйтим әле, теге бүрекче Гобәйдулладан калган Мәфтуха үзләрендә торган Хәйретдингә кече хатынлыкка бара, ди.

М ә л и к ә. Чынлапмы? И адәм көлкесе, адәм көлкесе! Мөгаен, араларында элек тә берәр эш булгандыр. Юк исә аның хатынын, балаларын кан-яшь җылатып барып йөрмәс иде.

Г а р и ф ә. Йөрмәс дип, Әхмәтҗан бай хатыны карт башы белән үзләрендә торган япь-яшь егеткә бармадымыни?

М ә л и к ә. Барса да инде, аның эше икенче, аның акчасы да күп, аннан соң ул Әхмәтҗан байны яратып та тормады.

Г а р и ф ә. Ә соң Фазлый хатыны?

М ә л и к ә. Шәмсенисаны әйтәсеңме?

Г а р и ф ә. Әйе.

М ә л и к ә. Ә, ул чибәр, бик матур бит! Аның әле бер дә яшь кызлардан аермасы юк. Аннан соң бит ул хатын өстеннән дә бармады.

Г а р и ф ә. Бармаса да инде, мыек чыкмаган япь-яшь егеткә баруы оят.

М ә л и к ә. Оят димәктән, кара әле, син ишеттеңме, теге Галләм, кызын марҗага җибәреп, кул эше өйрәттергән була, ди. Ничек кешедән оялмый икән?

Г а р и ф ә. Алар марҗадан гына өйрәттерәләр әле, ул хатын кеше. Әле менә Миңнебай Фатихы өйләренә бер шәкерт китертә, ди. Кызын шул шәкерт көн саен килеп укытып йөри, ди. Фатих үзе, сакалын салпайтып, шуның укытканын карап утыра, ди. Остабикәләр бик надан, бер дә укыта белмиләр, дип әйтә, ди. Алладан курыкмасалар да, бераз бәндәдән оялырга кирәк иде.

Алтынчы мәҗлес

Җамали, Гөлҗиһан, Камали.

Мөхәммәтҗан *(ишектән сулуы кабып йөгереп керәп)*. Абыстай! Абыстай! Әй, монда юк икән. Җамали абзый керәп килә. «Бик кирәкле йомышым бар, хатын-кызлар бер читкә китеп торсыннар», — ди.

Гарифә. Һи, мәхәббәтсез, тапкан икән йомыш йомышларга вакыт!

Чыгып китәләр.

Җамали *(ишектән кереп, әрле-бирле йөгергәләп, ишекләр саен барып)*. Килен! Килен!

Гөлҗиһан *(ишектән кереп)*. Нәрсә, абзый, ни бар?

Җамали *(сулуы кабып)*. Килен!.. Мин... мин... Сезгә... Уф!..

Гөлҗиһан *(каушап)*. Нәрсә бар? Нәрсә?

Җамали. Сиражетдин... Сиражетдинны... Талаганнар!

Гөлҗиһан *(урындыкка егылып)*. Аһ! Харап булдык! Читек балтыры!

Җамали. Әйе, әйе, читек балтыры... Менә тилиграм... Сиражетдинның читек балтырыннан акчасын алганнар!

Гөлҗиһан. Аһ!.. Кырык тугыз мең!

Җамали. Ни дисең? Кырык тугыз мең? Кырык тугыз мең, дисеңме?

Гөлҗиһан *(авыр сулап)*. Әйе... Кырык... тугыз... мең!

Җамали. Читек балтырында кырык тугыз меңме?

Гөлҗиһан. Әйе!

Җамали. Булмас!

Гөлҗиһан. Үзем, үзем күрдем.

Җамали. Алай булса, харап булдык! Малайның башы бетте! Читек балтырында кырык тугыз мең диген, ә! Әйтеп адәм ышанмаслык сүз! Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең! *(Урындыкка утыра, бераз аптырап тора.)*

Гөлҗиһан. Үзем күрдем, бишәр йөзлек иде.

Җамали. Ах, җүләр, җүләр, соң, читек балтырында кырык тугыз мең тәңкә акча йөртергә ярыймы?! Ах, җүләр, җүләр, шыр тиле икән!

Камали *(ишектән кереп)*. Абый, абый!

Җамали. Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең!

Камали. Нәрсә дисең?

Җамали. Кырык тугыз мең!

Гөлҗиһан. Ах! Читек балтыры!

Камали. Нинди читек балтыры? Нинди кырык тугыз мең?

Җамали. Сираҗиның читек балтыры!.. Сираҗиның кырык тугыз мең сумы!..

Камали. Читек балтыры ни эшләгән?

Җамали. Талаганнар.

Камали. Читек балтырынмы?

Җамали. Кырык тугыз мең сумын!

Камали. Ни дисең?

Җамали. Менә тилиграм...

Камали. Мин укый белмим.

Җ а м а л и. Мин дә белмим, Вәли укыды.

К а м а л и. Нәрсә ди, ни эшләгән ди?

Җ а м а л и. Ни эшләсен, Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын талап алганнар, ди.

К а м а л и. Кайда?

Җ а м а л и. Пуезда.

К а м а л и. Ә үзе?

Җ а м а л и. Үзе... үзе... килен, акылдан шашкан, ди!

Г ө л җ и һ а н. Аһ!

К а м а л и. Ә?

Җ а м а л и. Акылдан шашкан, ди. Бүлнискә җибәргәннәр, ди.

Г ө л җ и һ а н. Аһ!

К а м а л и. Соң, соң, ни эшлимез?

Г ө л җ и һ а н. Аһ!

Җ а м а л и. Белмим!

К а м а л и. Үзе кайда ди?

Җ а м а л и. Бүлнистә, ди.

К а м а л и. Анысын беләм. Үзе кайда ди, кайсы шәһәрдә ди?

Җ а м а л и. Анысын белмим, менә монда язган, мә, кара.

К а м а л и. Мин дә белмим. Анысын да Вәли белер.

Җ а м а л и. Ие, ул белер шул.

К а м а л и. Алай булгач, аны аннан алып кайтырга кирәк.

Җ а м а л и. Ие шул.

К а м а л и. Бүген үк китәргә кирәк.

Җ а м а л и. Бүген үк.

К а м а л и. Ие, бүген үк. Бүген, пуез белән. Әйдә, тизрәк китик. Тилиграмны Вәлигә укытыйк та бүген үк китик.

Җ а м а л и. Шулай дисеңме, бүген үк дисеңме? Башым әйләнә, бернәрсә дә белмим. Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең сум! Әйтергә генә ансат, кырык тугыз мең сум!

К а м а л и. Әйдә, абый, әйдә, кичекмик, китик. *(Җамалины җитәкли.)*

Җ а м а л и. Шулай дисеңме? Минем башым бер дә йөрми.

К а м а л и. Шулай дим. Әйдә, китик. Килен, хуш, сау бул. Без Сираҗины алып кайтабыз.

Чыгалар.

Г ө л җ и һ а н. Хуш!

Җиденче мәҗлес

Г ө л җ и һ а н, «Т у г а н ы м», Х ә м д и, Н ә г ы й м ә, Г а р и ф ә һ ә м М ә л и к ә.

Г ө л җ и һ а н. Аһ, харап булдык! Читек балтыры! Кырык тугыз мең сум! Туганым! Туганым! Ни эшлик? Кырык тугыз мең сум! Бөлдек, беттек! Инде ни эшлим? Мәҗлес! Бламажи! Кунаклар! Хәмди! Мәрфуга! Гайниҗамал! Мөхәммәтҗан! Барыгыз, бар!

«Туганым», Хәмди, Нәгыймә, Гарифә һәм Мәликә керәләр.

Һәммәсе бердән. Нихәл, ни булды? Нәрсә бар?

Гөлҗиһан. Барыгыз, бар! Йөгерегез! Кунакларга әйтегез! Килмәсеннәр. Мәҗлес бетте! Бөлдек, харап булдык! Һай, читек балтыры! Һай, кырык тугыз мең сум! Барыгыз, бар! Бламажи да кирәк түгел, бернәрсә дә кирәк түгел, мәҗлес тә юк! Ах, харап булдык, Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын урлаганнар. Ух! Үләм! Бетәм! *(Егыла.)*

Нәгыймәдән башкасы Гөлҗиһан янына җыелалар.

Нәгыймә *(бер читкә тайпылып)*. Ай Алла, харап булдым! Бәхетсезлек! Дүртбиш тәңкә чиертә дип торганда гына харап булдым! Ичмаса, ясаган тамыр әрәмгә китмәсен, кемгә булса да икенче бер кешегә бирермен. *(Диван артыннан чирекле шешәне алып, шәле астына кыстырып, аяк очлары белән генә басып, артына борылып карый-карый чыгып китә.)*

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зал. Залда күп үзгәреш юк. Өстәлләр җыелган.

Беренче мәҗлес

Җамали, Камали, Сираҗетдин һәм Гөлҗиһан.
Җамали белән Камали Сираҗетдинны җитәкләп килеп керәләр.

Җамали. Килен, килен!.. Әйдә, Камали, булыш әле, менә шунда гына утыртыйк!

Сираҗетдинны бер эскәмиягә утырталар. Сираҗетдин, дивана кеше төсле, тирә-ягына ялт-йолт карап утыра. Ишектән Гөлҗиһан килеп керә.

Килен, мин сезгә ничә мәртәбә әйттем, Сираҗетдинны яхшы саклагыз, өйдән чыгып китмәсен, дип. Ул бит үзен бер дә белешми. Әле менә хәзер, трамвай дип белеп, утын төягән вагуннар өстенә менеп утырган да киткән. Хәмидуллалар җитәкләп китерделәр. Ул бит бернәрсә дә белми.

Гөлҗиһан. Абзый, мин ни эшләтим соң инде аны, аны бит бер дә җиңеп булмый. Бәреп җибәрә дә чыга да китә.

Сираҗетдин *(урыныннан сикереп тора да почмакта, өстәл өстендә тора торган граммофон янына барып бора башлый. Бер колагына кулын куеп)*. Палисә, палисиски! Палисиски!

Җамали, Камали *(урыннарыннан сикереп торып, Сираҗетдинның ике кулыннан тотып)*. Чү, чү, ни эшлисең?

Сираҗетдин. Палисиски! Каравыл! Талыйлар!

Җамали. Һай, бичара!

Камали. Чү, энем, чү, монда бер кеше дә юк, бер кеше дә!

Сиражетдин *(читек балтырларын тотып карап).* Таладылар! Таладылар! *(Ике кулы белән чигәләрен тотып, икенче якка таба китә. Аннан тагы җәһәтләп китеп, ишектән чыга башлый.)*

Җамали, Камали *(Сиражетдинны барып тотып).* Чү, Сиражетдин, чү, бернәрсә дә юк, бернәрсә дә! Кил, урыныңа утыр! *(Урындыкка утырталар.)*

Җамали. Менә, агай, эш! Моны ни эшләтергә инде?

Камали. Сумашушныйга менгерсәк, ничек булыр икән? Ул монда килеңнәрне дә борчып бетерер. Төнлә белән ялангач күенчә чыгып китеп, белешмичә, әллә кайларга китеп, суга барып төшүе ихтимал.

Сиражетдин *(халыкка таба карап, үзалдына).* Төшәр, төшәр, суга төшәргә мин җүләрмени? Болар инде мине чын-чыннан җүләр дип беләләр.

Гөлҗиһан. Абзый, шул, мин дә шунсыннан куркам. Бөтенләй төн йокыларым качып бетте инде. Аз гына бер нәрсә кыштырдый башлады исә, ул чыгып китә торгандыр дип котым оча.

Җамали. Менә инде Мәскәү давиринныйлары гына килеп килешеп китсеннәр, аннан соң сумашушныйга менгерсәк менгерербез.

Сиражетдин *(үзалдына).* Тотарсыз капчыгыгызны! Алар килеп киткәч, ничек йөрергә икәнлеген мин үзем дә бик яхшы белермен.

Камали. Алар соң әле ни диләр?

Җамали. Бернәрсә дә әйтмиләр, кибеттәге кенәгәләрне карадылар. «Сезнең бу кенәгәләрегезне чурт үзе килсә дә аңлый алмас», — диләр.

Сиражетдин *(үзалдына).* Аны шул алар төшенсен дип язмыйлар.

Камали. Соң син нәрсә диден?

Җамали. Нәрсә дип әйтим, мин дә шул бернәрсә дә аңлый алмыйм, үзе булса, бик яхшы аңлар иде дә бит, хәзер исән түгел, гакылдан шашкан, дидем.

Сиражетдин *(үзалдына).* Шашкан гакылдан, шашмый ни! Мин сезнең үзегезне гакылдан шаштырырмын әле.

Камали. Соң, тагы нәрсә диделәр?

Җамали. Бүген без аны барып карыйк әле, үзебез белән бер доктор да алып барырбыз, ул аның гакылдан шашканмы, юкмы икәнлеген карар, диделәр.

Сиражетдин *(үзалдына).* Ә менә монысы гына бераз күңелгә ятып бетмәде. Әгәр ул минем җүләр түгел икәнлекне белсә, эш харап. Тукта әле. Алар килгәнче, җүләрлекне ныклап күрсәтергә өйрәнә торырга кирәк. *(Аякларын бөкләп, өстәл өстенә менеп утыра.)*

Камали. Чү, чү, Сиражетдин, ни эшлисең?

Җамали. Тимә, тимә, утырсын. Тик утырсын.

Камали. Ярый, алайса. Хуш, тагы нәрсәләр дип әйтәләр диден, докторга күрсәтербез, дип әйтәләр дисеңме?

Җамали. Әйе, докторга күрсәтербез, ди. Әгәр дә доктор авыру дип әйтсә, бераз скитке ясап булса да килешербез, диләр. Кибеттәге малларны да бер кат карап чыктылар. Малы бик аз калган икән, диләр.

Камали. Соң син нәрсә диден?

Җамали. Нәрсә дип әйтим, бары шунда инде, дидем. Менә бит сезгә бирергә дип малны акчага алмаштырып бетергән иде дә, хәзер инде акчасыз да, малсыз да калган, дидем.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Бер дә хафаланмагыз, акча ерак түгел, кладавайда гына. Ачкычы менә монда, кесәдә генә.

Гөлҗиһан. Соң инде, абзый, без шулай бер тиенсез бөлеп калырбыз микәнни? И Ходаем! Бар икән күрәселәребез! *(Жылый.)*

Камали. Хафаланма, килен, хафаланма, Алла язмаган эш булмас, Сиражетдинның болай булуы безнең өчен дә бер дә күңелле түгел.

Гөлҗиһан. И Ходаем, күңелле генә итеп аш уздырам дип йөргәндә генә, бөтен эшләр чуалды да китте.

Камали. Килен, анысы бик зур эш түгел, Сиражетдин терелсә, бар да булыр әле.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Эшне бетергәч, ничек фарсит итәргә кирәклеген Сиражетдинның үзе дә бик яхшы белер әле. *(Өстәл өстеннән сикереп төшеп, кулына лампа алып, ишеккә таба бара башлый.)* Ахмак нәрсәләр, йөзе каралар, кладавай ишеген ачык калдырганнар.

Камали. Чү, зинһар, чү, һәммәсен бикләгәннәр!

Сиражетдин һаман чыгарга маташа.

Җамали. И бичара, бөтенләй коты очып, куркып беткән.

Камали белән Җамали Сиражетдинның кулыннан тотып чыгармаска тырышалар.

Сиражетдин. Талыйлар, талыйлар! Тотыгыз!

Җамали *(һаман да кулыннан җибәрмичә)*. Юк, Сиражетдин, юк! Бернәрсә дә юк!

Сиражетдин. Талыйлар! Әнә йозагын ваталар! *(Ишектән чыгып китә.)*

Аның белән бергә Җамали белән Камали да чыгып китәләр.

Икенче мәҗлес

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. И Раббым, и Раббым, тәмам харап булдык! Эштән чыктык! Фатыйма тудыкъ инде миннән авызын җырып көләр. Нинди генә матур иттереп аш уздырам дип торганда гына харап булдык. Әле менә кибетне дә пичәтләгәннәр, ди. Урам кибетеннән акча сорыйлар. Акча чыгармасагыз, бер тиенлек тә әйбер бирмибез, дип әйтәләр, ди. Итче дә бүген ит бирмичә керткән. Аласыз да аласыз, акча бирүне белмисез, сез җүләрне туйдырырга мин ялланып керешмәгән, дип әйтә, ди. Асрауларның да берсенә дә бер сүз әйтер хәл юк, хәзер үзеңнән битәр биш өлеш артык итеп кычкырырга торалар. Кечәгенәк Гайнижамал: «Торасың да кычкырасың, торасың да кычкырасың, мин җүләр кешенең хатыны түгел, мин кычкырмасаң да аңлыйм. Кычкырырга беләсез, ә өскә-башка ясарга белмисез, менә алъяпкычларым тузып беткән, кычкырганчы бер алъяпкычлык алып бир», — ди. Хәзер инде күчерләренә кадәр мыскыл итә башладылар. Кичә тудыкъларга барырга ат җигәргә кушкан идем. «Әллә, абыстай, син дә инде акылга җиңеләя башладыңмы? Чыгасыз да утырасыз, бер эшсезгә чабасыз, ул атларның аяклары тимер түгел бит көне буена чабып йөрергә», — ди. Белмим инде мин, ни эшләргә дә аптырадым. Сиражины җүләр дип әйтер идем, кеше юк чагында

үзалдына әллә нәрсәләр хисаплый, әллә нәрсәләрне шутка сала[1]. Мин килә башладым исә, «таларга киләсең» дип кычкырынырга тотына. И Аллам, харап булдык шул, харап булдык. Бламажи пешерелми онытылып калган дигәч тә, әллә нәрсәгә эчләрем жу итеп киткән иде. Күрәчәгебезгә каршы булган икән шул.

Ишектән Нәгыймә карчык килеп керә.

Өченче мәҗлес

Гөлҗиһан, Нәгыймә.

Гөлҗиһан. Әйдә, хуш киләсең, Нәгыймә абыстай, килүең-китүең юк.

Нәгыймә. Исәнме, кызым Гөлҗиһан, исәнме! Кешенең борчулы вакытында һаман-һаман килеп кешене борчып йөреп булмый шул. Нихәл әле, кызым, ниләр эшләп торасыз? Исән-сау гына торасыңмы? Хафалана торгансыңдыр, ахры, ябыгып киткәнсең.

Гөлҗиһан. И Нәгыймә абыстай! Ничек итеп хафаланмаска кирәк? Инде Мәскәү бүләкләре кайта дип көтеп торганда гына, ирең шулай җүләрләнеп кайткач, ничек итеп хафаланмассың! Ичмасам, акчасын алдырмый гына кайткан булса, тагын да бер хәл иде. Әле ярый көн күреп торырга сумабыз бар дип торыр идең. Әле әнә мәскәүләр килеп кибетне дә пичәтләгәннәр, ди. Сиражины докторга күрсәтәбез. Әгәр чын-чыннан җүләр булса, аз белән дә килешермез, дип әйтәләр, ди. Ул инде соң, җүләр булмаса, урамда утын төягән вагуннарга утырып йөрер идеме?

Нәгыймә. Әйе шул, әйе шул, кызым, бер дә акыллы кешенең эше түгел инде. Әле менә беркөн, теге, беләсең ич Хәмди Мәфтухасын, шуның Әсма атлы бер кызы бар. Шул кыз урамнан узып бара икән. Сираҗетдин шуның каршысына барган да: «Син кем кызы, бик матур кыз икәнсең, мин сине үземә кече хатынлыкка алам», — дип юлыннан туктаткан. Ул аны анасына кайтып сөйләгән. Анасы тагын, җүләр нәрсә, шул сүзгә ышана калган. «Бай кеше бит, сораса, ни эшләп бирмәскә, бирәм, һәйбәт, яхшы атларга утырып, рәхәтләнеп йөрер», — ди. Мин әйтәм: «И җүләр, җүләр, шул сүзгә ышандыңмы? Ул бит хәзер акылдан шашкан, белешеп әйтми ул, аның хатыны Гөлҗиһан синең Әсмаңнан мең өлеш артык, синең йөз Әсмаңны бәреп егар», — дим.

Гөлҗиһан. Кайсы Хәмди Мәфтухасы инде ул?

Нәгыймә. Ай Алла, син Хәмди Мәфтухасын белмәскә, менә тагы, алар бит синең әтиләрең күршесендә, Чүпрә Йосыф йортында, түбән өйдә фатир торганнар иде.

Гөлҗиһан. Ай, әҗәткана, шулмыни? Сираҗины башларына чәйнәп яксыннар, җүләр белән тормасам, миңа ир бетмәгән! Ачуымны китерсәләр, иртәгә үк аерылып китәрмен. Тәмам туеп беттем инде. Беркөнне карап утырды-утырды да: «Әйдә, гармун алып уйнап җибәр әле», — ди. Мин тагы, җүләр, аның сүзенә ышанып, чынлап әйтә дип белеп, уйнарга гына тотынган идем. «Әйдәле, җырлап та җибәр», — ди. Мин җырламагач, тотынды биергә, тотынды биергә, мин, куркып, гармунны ташладым, ул һаман бии дә бии. Тәмам арып, башлары-күзләре әйләнеп бетте. Чәнчелеп китсен Сиражилары, башларына чәйнәп яксыннар! Шул җүләргә бирмәсәләр, кызларына урын таба алмаганнар икән.

---

[1] *Шутка салу* (счётка салу) — исәпләү.

Нагыймә. Мин шуны әйтәм: «Юкка җүләрләнеп, үзегездән кеше көлдереп, алай итеп йөри күрмәгез», — дим.

Гөлҗиһан. Бирсеннәр, минем бер сүзем дә юк. Гомеремдә мин аннан нинди рәхәт күрдем?

Нагыймә. Анысы шулайдыр да инде, шулай да булса, иргә бер баргач, шунда торган яхшы. Әле соң ни эшләп торасыз? Бераз өшкертеп-төкертеп караганыгыз юкмы? Бәлки, Алла кушса, сәламәтләнеп тә китәр иде. Әле менә сезгә шуны әйтим дип килгән идем. Нурый хаҗиларга читтән бер ишан килгән, ди. Сулышы бик шифалы, өшкерткән кеше бер дә сәламәтләнми калмый, ди. Әле менә әллә кемнең хатыны шуңа өшкерткән генә икән, бик зур файда күргән, ди.

Гөлҗиһан. Мин бер дә хәзер ни эшләргә дә белмим инде. Әле менә бүген мәскәүләр белән килешмәкче булып йөриләр. Шулар белән килешеп, эшләр уңайга китсә, тагы ни булса да, ул булыр иде.

Ишектән Җамали, Камали, Сиражетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан килеп керәләр. Сиражетдинны урындыкка утырталар.

Дүртенче мәҗлес

Гөлҗиһан, Нагыймә, Җамали, Камали, Сиражетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан.

Җамали. Закир, Мөхәммәтҗан, сез шунда Сиражетдинны яхшы гына каравыллап утырыгыз, бер җиргә дә чыгып китмәсен. Килен, сез дә бераз күз-колак булыгыз. Әйдә, Камали, без кибеткә төшик. Анда теге давиринныйлар безне көтеп тора торганнардыр. Аларны монда алып килербез. Гарәфигә дә әйттерергә кирәк, ул да килсен, ул аның юлда ничек таланганын күргән кеше, бәлки, файдасы тияр.

Чыгып китәләр.

Гөлҗиһан *(урындыкта башын артка таба салып, йоклаган төсле утырган Сиражетдинны күрсәтеп)*. Әнә инде, Нәгыймә абыстай, аның хәле шул инде. Йә ул шулай башын артка сала да изелеп йоклый, йә тора да пыр тузып өй эчендә йөгергәләп йөри, йә булмаса, өстәл өстенә менеп утыра да әллә ниләр мыгырдап укырга тотына. Менә инде көне буе шуны саклап утыр, әгәр гомер буена шул җүләрлегендә булса, аның белән ничек торырсың?

Сиражетдин *(үзалдына)*. Тормассың, тормассың бер дә. Тизрәк эшем генә бетсен, мин аннан ары сине типкәләп ишегемнән чыгарып җибәрермен.

Нагыймә. Шулайдыр шул, Гөлҗиһан, шулайдыр. Бу килешкә булганда, хәлең бик яхшы түгел; ичмасам, байлыгы бар вакытта шулай булган булса бер хәл иде. Байлыгы бар дип чыдап торыр идең; син яшь кеше, балаң-чагаң юк, бер дә хафаланмас идең. Әле менә теге җүләр Йосыф хатыны акча белән калды да нинди чибәр яшь кешегә барды.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Күрәсезме, карчык нинди яхшы киңәшләр бирә! Калдырдылар ди сезгә акча, капчыгыгызны тотмыйсызмы?!

Закир *(үзалдына)*. Итәрсең аны җүләр, үз файдасына килгәндә ул бер дә җүләр түгел! Беркөнне миңа алмаштырырга дип егерме биш таңкәлек акча биргән иде, шул вакытта мин, бераз батырып калыйм әле дип, бер өчлекне кесәгә яшергән идем, хәзер сизде. «Кая акча? Талыйлар!» — дип, каравыл кычкыра башлады.

Мөхәммәтҗан *(үзалдына)*. Акчасы булгач, баргандыр шул, акчасы булса, абыстайны алудан мин дә качмас идем. Мин дә бит бик чибәр егет. *(Мыекларын боргалап-төзәтенеп куя.)* Абыстай карт кеше түгел, акчасы булгач, аның белән торырга мөмкин. Матур булмаса да, акчасы булгач, ярап торыр иде.

Гөлҗиһан. Нәгыймә абыстай, зинһар, акрынрак сөйли күр. Йә үзе ишетер, тегендә тегеләр дә тыңлап торалар, үзе ул, дивана булса да, сөйләгән сүзне бик тиз ишетә. Әйдә, без теге якка чыгып, бераз сөйләшеп утырыйк. *(Закир белән Мөхәммәтҗанга карап.)* Сез монда абзагызны саклап утырыгыз.

Закир *(Мөхәммәтҗан янына барып утырып)*. Нихәл, Мөхәммәтҗан? Кичә бит минем ай тулды. Беләсеңме, миңа акча кирәк. Жалунияне аласы иде. Бу җүләрне көтеп торсаң, монда жалуния алганчы сакалың агарыр.

Мөхәммәтҗан. Минем үземнең дә жалуния алганым юк. Кичә Җамали абзыйдан сораган идем, сезнең ябык кибетегез өчен мин нишләп сезгә жалуния түләп торыйм, абзагыздан сорагыз, ди.

Закир. Ә соң мин кайдан алыйм?

Мөхәммәтҗан. Белмим.

Закир. Җамали абзыйдан сорыйм да, әгәр ул бирмәсә, ташлыйм да чыгып китәм.

Мөхәммәтҗан. Теләсәң ни эшлә, мин сине тотып тора алмыйм.

Тик утыралар.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Тимә әле, минем бу җүләр булып кыйлануның бик күп файдасы булды, мине җүләр дип фараз кылып, һәммәсе дә үзләренең серләрен яшермичә сөйлиләр. Хатынның да, кибетчеләрнең дә, күчерләрнең дә — һәммәсенең серләре мәгълүм булды. Тизрәк эшләрем генә бетсен, аннан ары мин сезнең барыгызны да ничек итеп өреп чыгарырга белермен. Инде теге мәскәүләр тиз килеп җитәрләр. Алар күзенә җүләррәк булып күренү өчен алданрак юллар эзләп куярга кирәк. Әгәр доктор чын-чыннан да җүләр дип шаһитлык бирсә, эшне озакка сузмаслар, тиз килешерләр. Аны ничек тә булса кулга алырга кирәк, докторлары нинди кеше икән? Аңа бер биш йөзлекне сузмый туры килмәс. Эшнең башы шунда. Аннан гына эшне бозарга ярамый. Әгәр биш йөздән дә ким бирсәң, бәлки, ул риза булмас. Абыйлар бик йомшак маташмасалар ярар иде. Сумына ун тиеннән артык бер дә бирергә ярамый. Кибеттә малы бик аз икән, дип әйтәләр, ди. Аз булмый, анда икенче кеше исемендәге вывиска астындагы кибеткә мал төямичә, пила чүбе тутырмаган. Алар барысы да мал.

Ишектән Мәскәү доверенныйлары керә башлыйлар.

Уф! Килеп тә җиттеләр. Ничек тә булса серне сиздермәскә кирәк.

Җамали. Әйдә, Васили Димитрич, әйдә, пожалысты, пожалысты.

Доверенныйлардан дүрт кеше, доктор, Җамали, Камали һәм Гарәфи килеп керәләр.

Бишенче мәҗлес

Әүвәлгеләр, дүрт доверенный, доктор, Җамали,
Камали, Гарәфи һәм Сиражетдин.

Җамали *(доверенныйларга)*. Пажалти, пажалти, менә моннан утырыгыз. *(Урын күрсәтә.)*

Василий Дмитриевич. Тукта әле, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, әүвәле Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович белән күрешергә кирәк. *(Сираҗетдин янына килә.)* Здраствуйте, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович!

Сираҗетдин *(алдына гына карап утырган урыныннан сискәнеп сикереп торып)*. Каравыл! Талыйлар! *(Ишеккә таба бара башлый.)*

Закир.
Мөхәммәтҗан. } Тукта, абзый, тукта! *(Урынына китереп утырталар.)*

Василий Дмитриевич *(куркып, артка чигенеп утырып)*. Кызганыч, бичара, куркыныч.

Икенче доверенный. Бөтенләй төсләре дә үзгәргән.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Үзгәрерсең, уен түгел ул, кырык тугыз мең тәңкә диләр аны!

Җамали. Бар, Мөхәммәтҗан, әйт әле, чәй китерсеннәр.

Бер доверенный. Юк-юк, кирәк түгел. Без эшебезне генә эшлик тә китәрбез.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Шаулама, бу беренчесе яхшы чыкты әле, малайларыңның куркудан котлары чыкты. *(Сикереп өстәл өстенә менеп утыра.)*

Бер доверенный. Карагыз әле, тагы әллә ни эшли.

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Доверенный. Ах, бичара!

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Күрсәтермен әле мин сезгә бичараларыгызны!

Василий Дмитриевич. Ну, менә без хәзер барыбыз да җыелган чак. Сез тагын бер сөйләгез әле, вакыйга ничек-ничек булган?

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Беләләр алар вакыйганы! Аны сез миннән сорасагыз, мин әйтер идем ничек булганын. *(Урыныннан сикереп торып, ишеккә таба бара башлый. Утырган кешеләргә күзләрен зурайтып ачып карый.)*

Закир белән Мөхәммәтҗан, барып тотып, яңадан урынына китереп утырталар.

Бер доверенный. Нишләп ул һаман тынычсызлана?

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Василий Дмитриевич. Ну, ярый, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сез сөйләгез әле, эш ничек булган?

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Берничек тә булмаган.

Җамали. Менә ничек булган. Ул безгә сөйләнеп йөргән иде: «Мин фәләнчә көн Мәскәүгә барам», – дип. Мин аңа әйттем: «Тукта, бераз сабыр ит, бергә барырбыз», – дип. Ул әйтте: «Юк, мин хәзер барам, кибеттә мал бик аз калды. Күп нәрсәләрнең төрләре беткән», – дип. Шуннан соң мин дә бер сүз әйтмәдем, ул да китеп барды. Ул акчасын үз янында алып киткән икән, минем аннан да хәбәрем булмады.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Китәр, китәр, үз янында алып китәр! Үз янымда алып китәргә мин дурак түгел!

Җамали. Хәтта мин аның күпме акча алып киткәнен дә белмәдем. Соңыннан, «Сираҗетдин таланды» дип, менә Гарәфидән тилиграм килгәч, киленнән ишеттем, «кырык тугыз мең» диде.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Бик дөрес, шулай, кырык тугыз мең.

Василий Дмитриевич. Киленегез аны кайдан белгән? Үзе әйткәнме?

Җамали. Юк, үзе әйтмәгән. Ул чыгар алдыннан аягын чишенеп, кәгазь акчаларны балтырына чорнап, аягын киенгән.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Анысы дөрес, кәгазьләрне балтырына чорнап киенгән.

Василий Дмитриевич. Киленегез мондамы? Аннан да сорап карасак, ничек булыр?

Камали. Юк, ярамый, хатын кешегә ирләргә күренергә шәригать ни вилит!

Җамали. Сорасыннар, сорасыннар, безгә кеше хакы бер тиен дә кирәкми, сорасыннар.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Дөрес, дөрес, бер тиеннәре дә кирәкми!

Җамали. Бар әле, Мөхәммәтҗан, абыстаңны монда чакыр, хәзер генә чыгып керсен әле.

Гөлҗиһан керә.

Алтынчы мәҗлес

Башкалар һәм Гөлҗиһан.

Җамали *(Гөлҗиһанга)*. Менә, килен, болар Мәскәүдән килгән давиринныйлар, синнән сорамакчы булалар.

Гөлҗиһан. Нәрсәне?

Камали. Сираҗетдинның акчасын.

Гөлҗиһан. Нинди акчасын?

Җамали. Югалткан акчасын.

Гөлҗиһан. Аны ничек миннән сорыйлар, мин аны кайдан алып бирим?

Василий Дмитриевич. Туктагыз әле сез, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сез сорый белмисез. Менә нәрсә, абыстай, сез Сираҗетдин Гыйлаҗетдиновичның үзе белән акча алып киткәнен белдегезме?

Гөлҗиһан. Белдем.

Василий Дмитриевич. Ул аны кайсы кесәсенә салып алып китте?

Гөлҗиһан. Бер кесәсенә дә салмады. Иң әүвәл менә шушы төшкә утырды да аякларын чишенде. Аннан соң кырык тугыз мең тәңкә акчасын дүрткә бүлде дә аякларының як-якларына, балтырларына куйды да киенде.

Василий Дмитриевич. Сез ул акчаларның нинди икәнлекләрен күрдегезме?

Гөлҗиһан. Күрдем.

Василий Дмитриевич. Нинди акчалар иде?

Гөлҗиһан. Бишәр йөзлек.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Күрдең, пычак, ул вакытта инде ул акчалар күптән кладавайда яталар иде.

Василий Дмитриевич. Ул акчаларны ул кайдан алып чолгады?

Гөлҗиһан. Сумкадан алып чорнады. Банкыдан алып кайтты да аягын чишенеп чорнады.

Василий Дмитриевич. Аягын киенгәч, өйдә озак тордымы?

Гөлҗиһан. Юк, озак тормады. Аягын киенде дә, атка утырып, вакзалга төшеп китте.

Василий Дмитриевич *(башка доверенныйларга карап)*. Әфәнделәр, сез дә берәр нәрсә сорап карамыйсызмы?

Доверенныйлар. Юк.

Василий Дмитриевич. Ярый, абыстай, рәхмәт. Башка сорый торган сүз юк.

Гөлҗиһан чыгып китә.

Җиденче мәҗлес

Гөлҗиһаннан башкалар.

Василий Дмитриевич *(башка доверенныйларны бер читкә тартып)*. Ну, әфәнделәр, сез ни дисез? Минемчә, боларның әйткән сүзләре дөрес шикелле күренә. Банкның кассиры да һәммәсе бишәр йөз тәңкәлек акчалар бирдем дигән иде.

Бер доверенный. Минемчә дә дөрес.

Икенче доверенный. Мин дә бер дә шикләнергә урын күрмим.

Һәммәсе дә килеп утыралар.

Василий Дмитриевич. Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сүзегезне сөйләп бетерегез, аннан соң ни булган?

Җамали. Аннан соң ни булганын мин бик яхшы белмим. Менә бу Гарәфи аның белән бер пуезда барган кеше, эшне ул бик яхшы белә. Безгә тилиграмны да ул бирде.

Василий Дмитриевич. Алай икән, бик яхшы. Алай булса, сез, Гарәфи әфәнде, эшнең ничек булганын безгә сөйләп бирегез әле...

Гарәфи. Без аның белән вакзалдан кузгалып киттек. Юлда бик яхшы бардык.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Бик дөрес, хәтта пирасаткага төшкәндә бергә пирәшләдек[1] тә.

Гарәфи. Соңыннан Мәскәүгә барып җитәргә берничә станса калгач...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Әйе, берничә станса калгач.

Гарәфи. Сиражетдин: «Мин тышка чыгып керим әле», — дип, тышка чыгып китте. Төн караңгы иде...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Дөрес, караңгы иде.

Гарәфи. Пуез да бик шәп барадыр иде. Ул чыгып бераз торгач, пуез бер стансага туктады, аннан да кузгалып китте...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Анысы да дөрес.

Гарәфи. Шуннан соң мин, тынычсызланып, Сиражетдинны эзләргә чыктым. Бәдрәфне барып төртеп карадым, бәдрәф бикле иде...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Монысы да дөрес.

Гарәфи. Бәдрәф янында бер-ике кеше көтеп торалар, бәдрәфтәге кешене «озак торды» дип сүгәләр иде.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Анысы да дөрес. Хәтта ишекне дөбердәтеп аптыратып бетерделәр.

---

[1] *Пирәшләү* — пәрәмәч белән чәй эчү.

Гарәфи. Шул вакытта бер кандуктыр узып барадыр иде, аңа жалуба бирделәр...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Анысын да ишеттем.

Гарәфи. Кандуктыр: «Стансада торганда, икенче кандуктыр бикләп куйгандыр аны», – дип ачып керде.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Уф! Иң читен җиренә килеп җиттеләр.

Гарәфи. Бервакытны ачып керсәк... ни күзебез белән күрик, Сиражетдинның башыннан бүрекләре, кәләпүшләре төшкән...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Дөрес.

Гарәфи. Аякларын салдырганнар...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Анысын үзем салдым.

Гарәфи. Казакиларын, камзулларын чишкәннәр...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Аларын да үзем чиштем.

Гарәфи. Бернәрсә белмичә һушы китеп ята...

Сиражетдин *(үзалдына)*. Әйе, белмәмешкә салынып яттым.

Гарәфи. Моны күргәч тә, минем йөрәкләрем гөп итеп китте, кандуктыр да: «Кенәзне талаганнар!..» – диде.

Сиражетдин *(сикереп торып)*. Каравыл! Тотыгыз! Тот! *(Ишеккә таба йөгерә.)*

Һәммәсе урыныннан сикереп торалар. Сиражетдинны барып тоталар.

Каравыл! Талыйлар!

Җамали }
Камали } *(беравыздан)*. Җибәрмәгез, җибәрмә! Сиражи, Сиражи, бернәрсә юк,
Гарәфи } утыр! Утыртыгыз! *(Урындыкка китереп утырталар.)*

Сиражетдин. Каравыл! Талыйлар! *(Урындыкка егылып, изелеп төшә.)*

Доверенныйлар. Доктор, доктор әфәнде, ярдәм итегез, карагыз.

Доктор килә.

Доктор. Рәхим итеп, бер чүпрәкне салкын суга манып китерегез әле. Бераз хәл алдырырга кирәк булыр. Аннан соң тамырларын карарбыз.

Сулы чүпрәкне китерәләр.

(Сулы чүпрәкне маңгаена куеп.) Шул килешкә бераз гына торып хәл алсын әле, сез, зинһар, бераз читкәрәк китеп торыгыз, яңадан күзен ачып җибәреп, сездән курыкмасын.

Читкә китәләр.

(Бераз торып.) Менә инде хәзер тамырларын карап карыйк. *(Сиражетдинның асылынып торган кулын кулына ала.)*

Шул арада Сиражетдин бик кечкенә итеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра.

(Ул, биш йөзлеккә күзен төшереп, үзалдына.) Һа, алай икән, эш сизелде, бик шәп акылдан шашкан икән. Ярый, миңа барыбер. *(Кесәсеннән сәгать алган булып, биш йөзлекне кесәсенә тыга. Тамырын тотып бераз караганнан соң.)* Эш бу яктан бик өмитле түгел, тамыр бик еш тибә. *(Күкрәкләрен тыңлый.)* Монда да хәл бик яхшы түгел. Йә әле, башкача тәҗрибә кыйлып карыйк. *(Кесәсеннән бер нәрсә алып,*

кулларына, битләренә төртеп карый.) Дөрес. *(Доверенныйларга әйләнеп карый.)* Әфәнделәр, эш бик өмитле түгел, гакылына бик зур хәләл[1] килгән. Әгәр дә бик зур, хәтта харикыльгадә[2] бер вакыйга булып, шул вакыйганы күргәндә кинәттән гакылына килмәсә, дәва белән генә терелтергә зур өмит күренми. Менә бу чүпрәкне алып куегыз әле. Хәзер күзен бераз ача башлады. Инде миңа тагын бер стакан салкын су китереп бирегез, шуны эчерткәч, бераз хәл алыр. Аннан соң мин сезгә бер дару язып бирермен. Шул даруны эчерткәч, ул тынычсызлануыннан бераз тукталыр. Шулай да булса, әфәнделәр, бөтенләй терелүенә өмит бик аз.

Сигезенче мәҗлес

Гөлҗиһан һәм башкалар.

Гөлҗиһан *(ишектән җылап кереп)*. Доктор әфәнде, мин нихәл итәрмен, кая барырмын?

Доктор. Тс, тс! Тавышыгызны чыгармагыз! Авыру янында җылаган тавыш чыгарырга ярамый, ул аның кәефен генә боза.

Гөлҗиһан, күзен яулык берлә каплап, акрын гына җылый.

Белмәссең, бәлки, Ходадан вәгъдә җитсә, терелеп тә китәр. Дөньяда төрле вакыйгалар була. Менә бервакыт шундый бер кеше акылыннан шашкан, ничә еллар үзен-үзе белмичә йөргән. Бервакыт шуларның йортлары яна башлаган. Ул кешенең алты-җиде яшендә кечкенә кыз баласына ут кабынырга якынлашкач, бала бик каты, ачы аваз белән кычкырып җибәргән дә, шул тавышка теге кеше йокысыннан уянып китеп, коточкыч пожарны күреп, кыз баланы кочагына алган да, ут эченнән йөгереп чыгып, баланы янудан коткарган һәм үзе дә яңадан акылына килгән.

Җамали. Хода безгә дә шулай ярдәм бирсә иде.

Камали. Илаһым, үзең ярдәм бир!

Гөлҗиһан. И Раббым, Ходаем!

Тынычлык.

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде, алайса, сез Сиражетдин әфәнденең акылына зарар килү хак дисез?

Доктор. Анда һичбер шик-шөбһә юк.

Василий Дмитриевич *(доверенныйларга карап)*. Алай булгач, әфәнделәр, безгә эшкә керешергә вакыт. Сез ни дисез?

Сиражетдин *(күзләрен бераз ачып, үзалдына)*. Йа Алла, эшләр бераз җиңеләя, иң авырлары узды. Акча төрткәч, докторың эреде. Шайтан да эзләп таба алмаслык ялганнарны ялганлый!

Доверенныйлар. Без дә шуны уйлап торадыр идек, без дә шул фаразда.

Гөлҗиһан чыгып китә.

---

[1] *Хәләл* – зарар.
[2] *Харикыльгадә* – гадәттән тыш.

Тугызынчы мәҗлес

Гөлҗиһаннан башкалар.

Василий Дмитриевич. Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, соң сез нинди фаразда?

Җамали. Без нинди фаразда булыйк?

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде әйтә, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович акылга килерлек түгел, ди. Шулай булгач, инде ул моннан соң сату итә алмас. Кибеттәге бар малын, йортларын сатарга кирәк тә, шуның белән бурычларын түләргә кирәк.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Ай-яй, начар сүз әйтте.

Җамали *(аптырап китеп)*. Ул ни дигән сүз? Ничә еллардан бирле бер тиен калдырмый түләп килгән фирманы шулай итеп тар-мар итмәкче буласызмы?

Василий Дмитриевич. Ә соң сез ни эшләмәкче буласыз?

Җамали. Менә сезнең белән килешсәк, агай-эне икебездән беребезне апикун итеп куярбыз да әүвәлгечә сату итә бирербез.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Менә монысы яхшы сүз.

Василий Дмитриевич. Соң сез ничек итеп килешмәкче буласыз?

Җамали. Белмим, ничек килешергә?

Василий Дмитриевич. Соң сез күпме бирмәкче буласыз?

Җамали. Белмим.

Василий Дмитриевич. Илле процент бирәсезме?

Җамали. Ул ни дигән сүз? Аның йорты залук, кибетендә малы юк, акчасы урланган.

Василий Дмитриевич. Анысын һәммәсен дә беләбез.

Җамали. Шулай булгач, ни өчен илле прасинт сорыйсыз? Аның кибетендәге бар малын сатып бетерсәгез дә ун прасинттан артык җыя алмассыз.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Монысы өчен абыйга рәхмәт.

Василий Дмитриевич. Соң күпме бирмәкче буласыз?

Җамали. Күпме дип, ун прасинт бирербез. Аны да инде тик, барган көенә фирманың эше туктамасын дип кенә бирәбез.

Василий Дмитриевич. Алай бик аз. *(Доверенныйларга карап.)* Әйдәгез әле, монда килегез.

Бер читкә китәләр.

Ну, сез ни дисез?

Үзара шыпыртлап бераз киңәшәләр. Янәдән килеп утыралар.

Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, менә нәрсә, унбиш процент бирерсез. Аннан да ким булганда, иптәшләр риза булмыйлар.

Җамали. Ихтыярыгыз, без артык бирә алмыйбыз. Ничә еллардан бирле килгән фирманы бетерәсез икән, хәерле булсын.

Василий Дмитриевич. Алай булса, менә нәрсә: ун процентның һәммәсен дә иртәгә биреп бетерергә кулыгыздан подписка бирәсезме?

Җамали *(Камалига карап)*. Камали, синдә иртәгә алты мең тәңкәләп акча булырмы? Калган яртысын мин табам.

Камали. Яхшы, ярар, булыр.

Василий Дмитриевич. Димәк, алай булгач, риза буласыз?

Җамали. Риза.

Сиражетдин *(узалдына)*. Эш пешә.

Василий Дмитриевич. Ну, доверенныйлар, сез дә ризамы?

Доверенныйлар. Риза, риза!

Василий Дмитриевич. Алай булса, мин актны язам. ***(Яза.)*** Менә сезгә үзебезнең йөз егерме мең сум алачагыбыз бәрабәренә уникe мең сум алырга риза булганлыгыбызга распискалар. Рәхим итеп, һәммәгез дә шуңа кул куегыз!

Куялар.

Яхшы, инде алай булса, менә, менә монысы сезгә. Ә менә монысы безгә. ***(Кесәсенә тыга.)*** Яхшы, хәерле сәгатьтә булсын!

Кул бирешәләр.

Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, инде эш бетергәнлекнең сые сездән.

Җамали. Әйдәгез, рәхим итегез, барабыз.

Бер доверенный. Ә Сиражетдин Гыйлаҗетдиновичны тәбрик итәргә кирәк.

Василий Дмитриевич. Юк, ярамый.

Җамали. Әйдәгез.

Чыга башлыйлар.

Сиражетдин *(узалдына)*. Ух, эш пеште! Бер көн эчендә йөз дә сигез мең тәңкә файда!

Доктор. Әфәнделәр, сезгә бер сүзем бар. Әгәр дә минем сүземне тотсагыз, хәзерге көндә ике кешегә сез бик зур файда китерә аласыз. Бердән, сез авыруны терелтә аласыз, икенчедән, миңа бик зур шөһрәт була.

Доверенныйлар. Ничек итеп?

Доктор. Менә ничек итеп: бая мин сезгә сөйләгән идем бит, харикыльгадә бер эш булса, диваналарның терелүе ихтимал дип.

Доверенныйлар. Ие.

Доктор. Менә хәзер минем башыма бер фикер килде. Сезнең кайсыгызда булса да дүрт данә бишәр йөз сумлык акчалар бардыр бит?

Доверенныйлар. Бар, миндә дә бар.

Җамали.
Камали. } Миндә дә бар.

Сиражетдин *(узалдына, шатланып)*. Аңладым, аңладым, бу доктор түгел икән, шайтан икән! Яңадан бер биш йөзлекне тамызмый туры килмәс. Дәртен белгән – дәрманын белер, диләр, бик дөрес сүз.

Доктор. Булса, китерегез монда акчаларыгызны.

Бирәләр.

Хәзер миңа калын-калын итеп дүрткә бүлеп төргән чуар кәгазьләр бирегез.

Җамали. Хәзер китерәм. ***(Чыгып китә.)***

Камали да өстәл асларыннан кәгазьләр эзли башлый.

Василий Дмитриевич. Сез ни эшләмәкче буласыз? Мин аңламыйм.
Доктор. Бераз гына сабыр итегез, хәзер күрерсез.

Кәгазьләрне китереп бирәләр.

Менә аларны шушылай итеп төрик.

Төрәләр.

Хуш, сез, әфәнделәр, менә бу почмакка килеп, бер дә дәшми-тынмый гына тик торыгыз.

Тегеләр почмакка китәләр. Доктор, тышкы ягыннан бишәр йөзлек акча белән төргән кәгазьләрне икешәр-икешәр ике кулына тотып, аларны югары күтәреп, акрынлап, аяк очлары белән генә басып, Сиражетдинның артына килә. Соңра кинәттән, аяк тибеп, бик каты аваз белән: «Сиражетдин!» – дип кычкыра. Сиражетдин, сискәнеп, аяк өстенә баса. Акчаларны карап тора. Соңра көлеп җибәреп: «Акчам! Акчам!» – дип, кулларын суза.

Доктор *(акчаны биреп)*. Мә, ал акчаларыңны! Монда кырык тугыз мең тәңкә! Акчаң табылды!

Сиражетдин, акчаларны алып, контор өстәленә йөгерә. Өстәл эченә салып бикләп, ачкычны ала.

Доктор *(халыкка карап)*. Ну, каналия, нинди оста эшли, артист кына буласы бар! *(Сиражетдин янына бара. Бер кулы белән Җамалига ишарә кыла.)*

Җамали килә.

Сиражетдин әфәнде, бу кем? Бу абзаң, күрешегез.
Сиражетдин *(Җамалига карап)*. Абый!
Җамали. Исәнме, энем! Исән кайттыңмы?
Камали. Исәнме, энем!
Сиражетдин. Исәнме!
Доктор. Хатынын чакырыгыз!
Җамали. Исән-сау кайттыңмы, энем?
Сиражетдин. Ә?
Җамали. Исәнме, дим!
Доктор. Менә болар агаларың, таныйсыңмы?
Сиражетдин. Таныйм.
Доктор. Танысаң, күреш.

Сиражетдин күрешә. Гөлҗиһан керә.

Унынчы мәҗлес

Гөлҗиһан һәм башкалар.

Доктор. Менә монысы кем?
Сиражетдин. Гөлҗиһан?
Доктор. Күрешегез.

Күрешәләр.

Йә, инде утырыгыз.

Дүртесе дә утыралар.

Йә, менә инде тыңлап торыгыз, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович! Әнә сезнең кырык тугыз мең тәңкә акчагыз, сез ул акчаны Мәскәү юлында югалттыгыз.

Сираҗетдин *(сикереп торып)*. Ә?

Доктор. Утыр, утыр, менә инде хәзер ул акчалар табылды.

Сираҗетдин. Сез кем?

Доктор. Мин – доктор.

Сираҗетдин. Хуш?!

Доктор. Хәзер инде син терелдең.

Сираҗетдин. Мин авырмадым!

Доктор. Ярый авырмасаң. *(Халыкка карап.)* Авырмаганлыгың бик мәгълүм. *(Сираҗетдинга.)* Ярый, хуш инде! Мин китәм.

Сираҗетдин *(урыныннан торып)*. Ярый, хуш! Ә болар кемнәр? Ә, Василий Дмитриевич, уһу-у, исәнме! Миңа ник әйтмисез, исәнме! Һа, сез дә исәнме! Акчага дип килдегезме? Менә хәзер сезгә акча бирәм. *(Өстәл астын барып ача башлый.)*

Доверенныйлар шаркылдап көлеп җибәрәләр.

Василий Дмитриевич. Юк, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович, кирәк түгел. Бирерсез әле. Әйдә, без сине сыйланырга алып барабыз. Шунда сөйләшербез.

Сираҗетдин. Ярар, барам, бар, чыга торыгыз. Кая, Гөлҗиһан, бүрек белән яңа киемнәрне китер.

Һәммәсе дә чыгып китәләр. Доктор кала.

(Докторга.) Аңладым, аңладым. Сезгә тагын биш йөз. Мин хәзер чыгам.

Доктор чыга.

Ә менә монда икән җилән. *(Киенә.)* Эш пеште! Бер минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында! *(Чыгып китә.)*

Гөлҗиһан *(ишектән сөйләнеп кереп)*. Бүрекләрең бу яктадыр, ахры. Ай Алла, чыгып та киткән, күрми дә калдым. Үзе дә терелде! Байлыгыбыз да үзебезгә калды. Кунакка барам, кунакка чакырам, мәҗлес уздырам! Янсын дошманнарның йөрәге!

Пәрдә.

1911

«Банкрот» пьесасының 1912 елда чыккан беренче басмасы (тышлыгы)

«Банкрот» спектакленең сәхнә бизәлеше

Сиражетдин – Хәлил Әбҗәлилов

Спектакльдан күренеш

Сиражетдин – Рәфкать Бикчәнтәев, Гөлҗиһан – Рәшидә Җиһаншина

Галиәсгар әфәнде бу әсәрендә вакыйганы бик оста тасвир итә белмеш вә моның илә бәрабәр пьесаның әшхасын бик табигый вә көлкеле итеп күрсәтмештер. Мөхәррир әфәнде үзенең мәһарәте каләмиясе[1] вә истигъдаде табигыясе сәясендә[2] боларның берберенә аерым бер хосусият[3], башка бер әһәмият бирә. Шул сәбәптән булырга кирәк, Камал әфәнденең әсәрләре кальбебезгә[4] бик якын хис ителә, аның кешеләрен һәммәбез бертигез аңлыйбыз, бер дәрәҗәдә ләззәт алабыз.

Габдрахман Кәрам

---

[1] *Мәһарәте каләмия* – язу осталыгы.
[2] *Истигъдаде табигыясе сәясендә* – табигый таланты аркасында.
[3] *Хосусият* – үзенчәлек.
[4] *Калеб* – күңел.

БЕЗНЕҢ ШӘҺӘРНЕҢ СЕРЛӘРЕ

Мәнзарә[1] *5 пәрдәдә*

ӘШХАС:

Себер бае – шәһәргә өйләнергә килгән, 35 яшьләр чамасында, мәгърифәтле бер кеше.
Яучы – аңа кыз димләргә йөрүче, маклер сымак бер ысул кадимче[2].
Сәркәтиб[3] – уртача яшьләрдә, русчадан яхшы мәгълүматлы кеше.
Фатих, Насыйр, Касыйм, Садрый – җәмгыяте хәйрия[4] идарәсендә әгъзалар.
Дежурный – клуб старшиналарыннан берәү.
Сакчы, Кара казакилы, Серый киемле, Гариф, Кәрим – клуб әгъзалары.
Шкафчы – ысул кадимчеләр башлыгы.
Дирижёр, рассказчы, карт, халык, членнар вә башкалар.

БЕРЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

ҖӘМГЫЯТЕ ХӘЙРИЯДӘ

Җәмгыяте хәйриянең залы. Урталыкта өстәл. Өстәл өстенә кәгазьләр, кара савыты, звонок һәм башка язу әсбаблары куелган. Пәрдә ачылганда, өстәл янында җәмгыятьнең Сәркәтибе бер дәфтәрне карап утыра.

Беренче мәҗлес

Сәркәтиб, соңра җәмгыятьнең Сакчысы.

Сәркәтиб *(үзалдына)*. Устав, устав, диләр. Уставның һичбер җитешмәгән җире юк. Бу устав буенча әллә нинди зур эшләр кылырга мөмкин. Бары тик тырышырга гына кирәк. Дарелгаҗизин[5], дареләйтам[6], вәладәтханә[7], кыйраәтханә[8], көтебханә, шифаханә, ашханә, тагын белмим әллә нинди ханәләр ачарга мөмкин. Эш бары әгъзаларның

---

[1] *Мәнзарә* – күренеш.
[2] *Ысул кадимче* – иске карашлы кеше.
[3] *Сәркәтиб* – секретарь.
[4] *Җәмгыяте хәйрия* – ярдәм җәмгыяте.
[5] *Дарелгаҗизин* – картлар йорты.
[6] *Дареләйтам* – ятим балалар йорты.
[7] *Вәладәтханә* – бала тудыру йорты.
[8] *Кыйраәтханә* – уку өе.

тырышлыгында гына. Әгъзалар чынлап тырышсалар, акча да булыр, эш тә чыгарып булыр иде. Әгъзалар тырышмыйлар. Әле менә инде минем килгәнгә ике сәгатьләп була, ә алар әле һаман килмиләр. Тагы бер ярты сәгать кенә көтәм дә кайтам да китәм. Аларның аена 15–20 тәңкә вазифалары[1] өчен баш ватып, көн уздырып, монда көн буе утырыр хәлем юк... *(Звонок шалтырата.)*

Сакчы керә.

Кара әле, Хафиз, бар әле, капка төбенә чыгып кара әле, килмиләр микән?

Сакчы. Мин баядан бирле капка төбендә торам инде, як-якка карый-карый муеннарым каерылып бетте. Берсе дә килми.

Сәркәтиб. Син соң дәгъватнамәләрне[2] һәммәсенә дә бирдеңме?

Сакчы. Бирдем.

Сәркәтиб. Нәрсә диделәр?

Сакчы. Садрый абзыйның үзен күрмәдем. Асрауларына бирдем. Садрый абзыйның җәмәгате баскыч башыннан карап торадыр иде.

Сәркәтиб. Хуш!

Сакчы. «Ул нәрсә ул тагы?» – ди. Идарә мәҗлесенә запискә, дигән идем, ачуланырга тотынды. «Бетмәде инде мәҗлесегез», – ди. «Көн дә, көн дә ул нинди мәҗлес булсын, бүген бармас, бүген безнең парлы кунакка барасыбыз бар. Һәр көн кич анда барып, төн уздырып кайтырга булмас», – ди.

Сәркәтиб. Башкалары нәрсә диделәр?

Сакчы. Касыйм абзыйны күргән идем: «Ярар, бушый алсам, барырмын. Минем, ясигъдан чыккач, бер җиргә туйга барасым бар. Миңа карамасыннар, мәҗлесне ачып, эшкә башлый торсыннар. Мин пртакулга кул куярга барып җитәрмен. Бара алмасам, иртәгә пртакул дәфтәрен кибеткә төшерерсең, кул куеп бирермен», – ди.

Сәркәтиб. Ә Рәхим абзый нәрсә диде?

Сакчы. Ул да: «Мин бу көн бара алмам, вакзалга кунаклар озатырга төшәсем бар. Иртәгә пртакул дәфтәрен кертерсең, кул куеп бирермен», – диде.

Сәркәтиб. Алай икән! Ә Фатих?

Сакчы. Фатих абзый бернәрсә дә әйтмәде. «Барыбер, барсаң да аяк туздырып йөрүе генә калыр, җыелмаслар», – диде.

Сәркәтиб. Соң син әйттеңме, бүген бер дә җыелмый калырга ярамый, дип.

Сакчы. Әйттем.

Сәркәтиб. Башкалары нәрсә диделәр?

Сакчы. Ярар, барырга тырышырбыз, диделәр.

Сәркәтиб. Алай икән. Ярый, башка йомыш юк.

Сакчы чыга башлый.

Ә, кара әле, кем, Хафиз, сәгать ничә булган?

Сакчы. Унынчы ярты. *(Чыгып китә.)*

---

[1] *Вазифа* – хезмәт хакы.

[2] *Дәгъватнамә* – чакыру кәгазе.

Икенче мәҗлес

Сәркәтиб ялгыз.

Сәркәтиб *(үзалдына сөйли)*. Унынчы ярты. Сәгать сигездә дип чакырган мәҗлескә әле һаман килгәннәре юк. Бүген инде өченче мәртәбә чакыру, алай да килмиләр. Монда карасы эшнең очы-кырые юк. *(Кәгазьләрне актарып карый.)* Менә монда бер бичарасы, юлга китәргә акчам юк, дип, ярдәм сорый. Гаризасы язылганга нәкъ бер ай да ун көн булган. Әгәр бүген дә җыелмасалар, ул бичарага тагы ун көн көтәргә кирәк булыр. Әгәр дә ул кеше җәмгыятьнең ярдәменә ышанып ятса, язган булса, яз көне, шаять, китәр. Менә монысында, бер бик фәкыйрь хатын урын өстендә үләргә ята, табиб китертергә ярдәм сорый, дигәннәр. Аның гаризасының язылганына да бүген нәкъ бер ай булган. Кем белә, мескен, көткән-көткәндер дә, ярдәм килмәгәч, «ахры, булмас инде» дип, бәлки, күптән теге дөньяга киткәндер! Монда көтеп утырудан бер тиенлек тә мәгънә чыкмас. Кайтырга кирәк. Садрый байның хатыны: «Ул нинди көн саен мәҗлес», — дип әйтә, ди. Кем белә, бәлки, ул шулай көн саен, мәҗлескә барам дип, өеннән чыгып китә торгандыр. Бервакытны бер гласный[1] шулай һәр көн өеннән: «Мин управага менәм», — дип чыгып китә икән. Бервакыт, кыш узгач, кыш буена кемнең ничә мәртәбә Дума мәҗлесләренә барганлыгын мөселман гәзитләренә язып чыгардылар. Хатыннары гәзитне укып карасалар, теге гласный кыш буе бары ике генә мәртәбә мәҗлескә барган булып чыккан. Шуның шикелле, Садрый абзый да һаман «мәҗлескә барам» дип чыгып китә торгандыр әле. *(Халыкка карап.)* Хуш, сау булыгыз, мин өйгә йокларга кайтам инде. *(Чыгып китә.)*

Өченче мәҗлес

Сәркәтиб белән бер идарә әгъзасы.

Тыштан тавыш. Юк-юк, китмә, китмә! Хәзер килерләр. Әйдә, әйдә.

Керәләр.

Сәркәтиб. Соң инде, Насыйр абзый, минем килгәнгә бит ике сәгать булды. Сездән 15–20 тәңкә вазифа алам дип, монда төн буена утырыйммыни?

Әгъза. Хафаланма, хафаланма, хәзер килерләр. Мин, кибет япкач, хатын белән киниматуграфка барган идем, шуңа бераз соңга калдым. Фатих та шунда иде, ул да, хәзер киләм, диде.

Сәркәтиб. Анда башка көнне барсагыз да яраган булыр иде. Сәгать сигездә дип чакырган мәҗлескә унда килгәч, эш ничек барсын?

Әгъза. Бармаса, мин ни эшлим инде? Һаман җәмәгать эше артыннан гына йөреп булмый. Башкалар тырышмагач, мин берүзем генә ни эшлим? Кая, бүген каралырга нинди эшләр бар?

Сәркәтиб. Бүген каралырга тиешле булган эшнең очы-кырые юк. Утызлап гариза бар.

Әгъза. Һу, бигрәк күп икән. Кая соң, башкалар тизрәк килсәләр ярар иде. Бар әле син, тизрәк кайсына-берсенә тилифун белән хәбәр ит әле. Тизрәк килсеннәр.

---

[1] *Гласный* — шәһәр Думасына сайланган кеше.

С ә р к ә т и б. Ай-һай, килерләр микән? *(Телефон янына бара. Телефонны бора.)* Синтральный? Синтральный? *(Яңадан бора.)* Синтральный? Синтральный? Фу, чурт! Хафиз, Хафиз!

С а к ч ы керә.

Әллә бу безнең телефон бозылганмы?

С а к ч ы. Юк, бозылмаган. Кичә генә Кәрим абзый банкы белән сөйләште.

С ә р к ә т и б. Нишләп соң, алай булгач, бер дә хәбәр бирмиләр? *(Яңадан бора.)* Синтральный? Йа Алла! Көчкә килделәр. Зинһар, миңа Садрый Атабаевның кантурын тоташтырыгыз әле? Нәрсә, мәшгуль дисезме? *(Халыкка карап.)* Бу вакытта ул кем белән сөйләшер икән? Алай булса, Хәким Ямашевка тоташтырыгыз. Рәхмәт! *(Шалтырата. Каршыга җавап бирәләр.)* Кайдан бу? Нәрсә? Яким Дадашев? Зинһар, кирәк түгел! Өзегез әле. *(Шалтырата.)* Мин аларга, Хәким Ямашев, дим, ә алар Яким Дадашевка тоташтырганнар! *(Шалтырата.)* Синтральный? *(Шалтырата.)* Синтральный? *(Шалтырата.)* Синтральный? Уф Алла! Хафиз, сәгатьне кара әле, күпме булган?

С а к ч ы. Ун тулып чирек.

С ә р к ә т и б. Уф! *(Шалтырата.)* Синтральный? Синтральный? Ярабби, шөкер, килделәр! Зинһар, дип әйтәм, Хәким Ямашевка тоташтырыгыз әле. Мин сезгә, Хәким Ямашев, дим, ә сез Яким Дадашевка тоташтырасыз. Болай гына аңламасагыз, номерын әйтим: 666 нчы. Рәхмәт! *(Шалтырата. Каршыга җавап бирәләр.)* Кайдан бу? Нәрсә? Өченче часть. Кирәк түгел. Зинһар, өзегез! *(Телефонның трубкасын элә.)* Менә бәла, 666 нчы урынына 676 нчыны, өченче частьны биргәннәр! Булмас, ахры. *(Маңгаендагы тирләрен сөртеп.)* Моңарчы инде һәммәсенә җәяүләп барып әйтсәң дә булыр иде.

Тыштан аяк тавышлары ишетелә.

Әнә киләләр бугай.

Ф а т и х килеп керә.

Дүртенче мәҗлес

Ф а т и х һәм ә ү в ә л г е л ә р.

Ф а т и х. Әссәламегаләйкем!

Б а ш к а л а р. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдәгез, хуш киләсез.

Ф а т и х. Нихәл, мәҗлес таралдымы әллә?

С ә р к ә т и б. Җыелса, таралыр.

Фатих. Мин бер килмәскә дә уйлаган идем дә, ут яктысы күргәч, тукта, кереп чыгыйм, дип кердем, нихәл, ниләргә карар бирдегез? Кая, мин дәфтәргә кул гына куеп китим, эшем ашыгыч.

Ә г ъ з а. Әле мәҗлес булганы юк.

Ф а т и х. Алай булгач, бүген булмас та инде.

С ә р к ә т и б. Килмәгәч, әлбәттә, булмас.

Ф а т и х. Килмәгәч дип, мин берүзем килеп кенә ни эшлим, башкалар берсе дә килмиләр ич?

С ә р к ә т и б. Җәмгыятьне тотарга да ябарга. Бүтән бер эш тә юк.

Ә г ъ з а. Әнә тагы киләләр бугай.

С е б е р б а е белән Я у ч ы керә.

Бишенче мәҗлес

Шулар ук һәм Себер бае белән Яучы.

Себер бае. Әссәламегаләйкем!

Башкалар. Вәгаләйкемәссәлам!

Себер бае. Мин бүген монда мәҗлес була дип ишеткән идем. Шуңа күрә бер кереп чыгыйм дигән идем. Өлгерә алмадым, мәҗлесегез таралган икән.

Сәркәтиб *(халыкка карап)*. Таралыр өчен, әүвәл оешырга кирәк әле.

Әгъза. Рәхим итегез, таралмаган әле, хәзер яңа җыелабыз.

Фатих. Рәхим итегез, әфәндем, рәхим итегез! Сез кем буласыз? Кайдан киләсез? Кайда барасыз? Ни белән сәүдә кыласыз? Кем номерына төштегез? Озак торасызмы? Чугунка[1] белән килдегезме?

Себер бае. Ие, чугунка белән килдем. Мин үзем Себер ягында сәүдә кылучы бер кеше булам, хатыным үлгән иде дә, монда өйләнергә дип килгән идем.

Әгъза. Рәхим итегез, рәхим итегез! Ни белән сәүдә кыласыз?

Фатих. Нинди җирдән өйләнмәкче буласыз? Бай кеше кызын алырга ният кыласызмы? Әллә уртача булса да ярыймы?

Себер бае. Минем сәүдәм төрле нәрсә белән. Нинди җирдән өйләнергә туры килер әле, ул кадәресен белә алмыйм. Минем монда бер дә белеш кешем юк.

Әгъза. Читек-кәвеш белән сәүдә кыласызмы? Монда мал аласызмы? Бездә читек-кәвешнең төрлесе бар. Бәһасен дә арзан гына бирербез.

Фатих. Кәләпүш, калфак, бүрек шикелле нәрсәләр аласызмы? Безнең нәрсәләр бик яхшы була.

Сәркәтиб. Менә сезгә кирәк булса — базар! *(Кулын җәеп күрсәтеп.)* Менә инде син эшлә болар белән эшне!

Әгъза. Сезнең якка, бәлки, намазлык, комган, сөлге, эскәтер, чалма, чалма бүрек шикелле нәрсәләр дә китә торгандыр?

Фатих. Алары инде аның һәммә кешедә дә табыла; намазлык, комган шикелле нәрсәләр бездә дә бар. Без дә кыйммәт бәһа алмабыз.

Сәркәтиб *(халыкка карап)*. Хәзер инде конкуренсия дә башланды!

Себер бае. Әфәнделәр, мин андый нәрсәләр белән сату итмим. Мин урыс арасында сату итәм. Минем төрле нәрсә дигәнем икенче нәрсә. Мин кызыл мал, галантерейный, бакалейный нәрсәләр белән сәүдә кылам.

Әгъза. Алай булгач, бик яхшы. Менә Зарифка әйтергә кирәк. Ул сезгә гилтаринный малларның һәртөрлесен дә табып бирер.

Фатих. Кызыл малны Вафа хаҗидан алырсыз, ул сезгә очсыз сатар. Акчага алсагыз, ул сезгә скиткәне дә күп ясар.

Сәркәтиб *(халыкка карап)*. Инде хәзер маклерлыкка да керешә башладылар!

Себер бае. Юк, әфәнделәр, мин монда мал алырга килмәдем. Мин малны туптуры Мәскәүдән фабрикантлардан алам, мин монда бары өйләнер өчен дип кенә килдем.

Әгъза. Алай икән, соң сез нинди җирдән өйләнмәкче буласыз? Бай җирдәнме, уртача җирдәнме?

Фатих. Кыз булсын дисезме, тол булса да ярыймы?

---

[1] *Чугунка* — тимер юл, поезд.

Сәркәтиб *(халыкка карап)*. Инде хәзер яучылыкка да керештеләр.

Яучы. Байлар, мин сезгә бер сүз әйтим әле, бу безнең якташ кеше; безнең белән бер өяздән. Аңа кызны мин үзем димлим.

Әгъза. Кемне димлисең? Әнә Җамали хаҗиның кызын димлә, аны бик матур диләр.

Сәркәтиб *(халыкка карап)*. Чеп-чи ялган!

Фатих. Безнең Әхмәтнең кияүдән кайткан кызы ничек булыр? Әгәр тол дип әйтмәсә, аны димләргә ярый. Бик чибәр кыз.

Сәркәтиб *(сәгатькә карап)*. Әфәнделәр, мин кайтам. Инде сәгать 11 тулган. Бүген мәҗлес булмас, ахры.

Фатих. Тукта, бераз сабыр ит әле, ул кадәр ашыгып кая барасың?

Сәркәтиб. Килмиләр ич.

Әгъза. Ник, килмәсәләр, без үзебез генә эшне карый алмыйбызмыни? Кая, китер эшләреңне, нәрсәләр бар?

Сәркәтиб *(халыкка карап)*. Кырырсыз инде сез эшне! *(Әгъзаларга.)* Менә өстәл өстендә һәммәсе дә хәзер.

Әгъза. Кая, укып күрсәт, нәрсәләр бар?

Сәркәтиб. Укудан эш калмас, укырмын. Ләкин әле бит монда устав буенча җитәрлек әгъзалар җыелмаган.

Фатих. Җыелмаса, ни булган? Иртәгә Хафиз кул куйдырыр. Йә, укы. *(Себер баена.)* Без, менә шулай, кеше җыелмаган дип тормыйбыз. Эшне тиздән йөртә бирәбез.

Себер бае. Бик яхшы, бик яхшы.

Сәркәтиб *(кәгазьләрне карап)*. Менә монда бер шәкерт укырга дип иганә[1] сорый.

Әгъза. Ул ни эшләп бездән сорый, ата-анасы укытсын, безнең балаларны бер кеше дә акча биреп укытмый.

Сәркәтиб. Фәкыйрь, ди, ятим, ди.

Фатих. Ятим булса, приютка кереп укыр. Бездә артык акчалар юк әле. Йә, икенчесен укы!

Сәркәтиб. Алай булса, инде моңа бирмибезмени?

Фатих. Юк, юк, атказ!

Әгъза. Атказ, атказ!

Сәркәтиб *(икенче кәгазьне алып)*. Менә монысы, бик фәкыйрь идем, җәмгыятьтән миңа берәр киемлек бирмәсләр микән, ди.

Әгъза. Ул нинди аңгыра нәрсә ул тагы? Әле күптән түгел генә ураза узды. Шунда байлардан зәкят сорарга ярамаганмыни? Юк, булмас.

Фатих. Йә, башкасын укы!

Сәркәтиб *(янә бер кәгазьне алып)*. Монысы, юлга акчам юк иде, бераз рәхим итмәсләр микән, ди.

Фатих. Ул ни дигән сүз тагы? Аны монда кем чакырып китергән, килмәсен иде. Андый урыннарга тарата башласаң, монда җәмгать акчасы түгел, башыңдагы чәчең дә төтмәс. Йә, башкасын укы!

---

[1] *Иганә* – ярдәм.

Сәркәтиб. Моңа да атказмыни?

Фатих.
Әгъза. } Атказ, атказ!

Сәркәтиб *(янә бер кәгазь алып).* Менә монысында шәһәрнең яшьләре игълан кылалар: «Без җәмгыяте хәйрия файдасына театрлар куеп, әдәбият кичәләре ясар идек, мәсарифыннан[1] артып калган акчасын җәмгыяте хәйриягә бирер идек», — диләр.

Себер бае. Афәрин, афәрин, сездә дә шундый һиммәтле[2] яшьләр бар икән. Бик файдалы эш.

Әгъза белән Фатих һәр икесе тынычсызланалар.

Безнең сәүдә кыла торган җиребездә дә яшьләр ураза бәйрәмендә кыйраәтханә файдасына дип театр уйнаганнар иде. Җиде йөз сум файда иттеләр.

Фатих *(халыкка карап).* Алай икән, бозылган кеше икән! *(Себер баена.)* Җиде йөз тәңкә файда иттеләр дисезме?

Себер бае. Әйе.

Сәркәтиб. Афәрин һиммәтләренә, бик шәп булган икән.

Фатих. Тик тор, син сүзгә катышма! Син ни беләсең, син бит идарә әгъзасы түгел.

Әгъза. Әйе шул, сиңа катышырга тиеш түгел. Шәпме, түгелме икәнен без үзебез дә бик яхшы беләбез.

Фатих. Һә, җиде йөз тәңкә файда иттеләр диген, ә? Бер көндә җиде йөз тәңкә! Соң, ул акчаны ни эшләттеләр?

Себер бае. Һәммәсен дә кыйраәтханәгә бирделәр.

Әгъза. Хәзрәтегез ни әйтте?

Себер бае. Бернәрсә дә әйтмәде, бик яхшы, диде.

Фатих. Хәрам дип әйтмәдемени?

Себер бае. Юк, бик яхшы эш, диде.

Фатих *(халыкка карап).* Муллагыз да үзегез шикелле бер азган-тузган нәрсәдер шунда?!

Әгъза. Муллагыз кайда укыган?

Себер бае. Элек Казанда укып, хәтме көтеб кылгач, хаҗга барып, Мисыр, Истанбулларда йөреп кайткан.

Фатих *(халыкка карап).* Чеп-чи җәдит икән!

Әгъза. Алай булгач, әйтмәс шул. Мисырда укыганнар алар эшләпә киюне дә дөрес, диләр. Урыс суйган итне ашаудан да тартынмыйлар.

Сәркәтиб. Хуш, әфәнделәр, бу гаризага ни дип әйтәбез?

Тын.

Фатих. Насыйр, син ни дисең?

Әгъза. Белмим, ә син ни дисең?

Фатих. Мин бер сүз дә әйтә алмыйм, киләсе мәҗлескә калсын, дим.

---

[1] *Мәсариф* — чыгым.
[2] *Һиммәтле* — ярдәмле.

Әгъза. Ярый шул.

Сәркәтиб. Әфәнделәр, яшьләр алар бүген үк җавап сорыйлар. Без берсекөнгә әдәбият кичәсе ясыйбыз, әгәр җәмгыяте хәйрия риза булмаса, икенче бер җәмгыять файдасына ясыйбыз, диләр, көтмиләр.

Фатих. Көтмәсәләр, алабия кичәләре белән чәнчелеп китсеннәр! Без аларның хәрам акчаларына калмаган!

Әгъза. Әлбәттә, әлбәттә, хәрам акчаны алырга ярамый.

Фатих. Сафа хәзрәт Бохарада укып, мөдәррис булып кайткан кеше, белми әйтмәс, мин беркөнне сораган идем: «Һич ярый торган эш түгел, чеп-чи хәрам», — диде. «Дуңгыз ите ни, ул ни — икесе дә барыбер», — диде.

Сәркәтиб. Соң бит, безнең җәмгыятьнең сумасы бик аз. Бирәчәкләребез дә бик күп, ә кассада акчабыз бик аз.

Әгъза. Син белмәгән эшкә катышма. Акчаң аз булса, юрганыңа карап аягыңны сузарсың.

Сәркәтиб. Алай булгач, кабул итмибез дип әйтәсезмени?

Фатих.
Әгъза. } Атказ, атказ!

Фатих *(сәгатен чыгарып карап)*. Һу, сәгать 12 булган! Соңга калына, иртәгә иртәрәк торасы бар. Мин кайтам.

Әгъза. Мин дә кайтам, әйдә, бергә кайтабыз.

Торалар.

Сәркәтиб. Монда тагы 26 гариза бар, аларын ни эшлибез?

Фатих. Атказ! Әй, юк, аларын икенче мәҗлестә карарбыз.

Әгъза белән чыга башлыйлар.

(Әгъзага, бөгелеп, колагына.) Нихәл, ни эшләттек теге җәдитне?! Авызына бармагын кабып шаккатып карап калдымы? Әйдә, минем белән барасыңмы?

Әгъза. Кайда?

Фатих. Беләсең инде.

Әгъза. Әйдә. *(Сәркәтибкә карап.)* Пртакулны яз, иртәгә Хафиз кул куйдырыр. Хуш!

Чыгып китәләр.

Себер бае. Сезнең мәҗлес дигәнегез шушымы инде?

Сәркәтиб. Бу гына түгел әле, моннан биш өлеш битәрләре дә була.

Себер бае. Мин бу көн җәмгыять була дигәч, күреп калыйм дип, бу кешене көчләп алып килгән идем. Мин аны бик шәп була торгандыр дип фараз кыладыр идем.

Яучы. Әфәндем, ул яхшы була торган иде дә, әле бу көн карт байларның берсе дә килмәгән.

Сәркәтиб. Алар килсә, монда бөтенләй сафура бураннары куба!

Себер бае. Сезнең бу җәмгыятькә яшьләр бер дә катышмыйлармыни?

Сәркәтиб. Катышырлар иде дә, аларга бер дә юл бирмиләр. «Сез — җәдит», — диләр.

Себер бае. Соң, бу эш үзе дә җәдитләр эше бит.

Сәркәтиб. Дөрес, җәдитләр эше. Ул эшне әүвәл җәдитләр башлаган иде дә, соңыннан картлар: «Җәдитләр динне бозып бетерәләр», — дип килеп катыштылар. Яшьләрне төрлечә куркытып, качырып бетерделәр.

Себер бае. Ярый, хәерле булсын, мин дә әгъза булып язылырмын дигән идем дә, хәзер инде, әгъзаларыгызның «атказ, атказ, атказ»ларын ишетеп, күңелем кайтты. *(Яучыга.)* Шушы икән инде сезнең җәмгыятегез! Әйдә, тизрәк китик. Йә тагы берәрсе, килеп, безгә дә «атказ» ди башлар. Әле мин ашамаган, безнең номерда кухнялар ябылгандыр. Әйдә берәр ресторанга барып ашап кайтыйк. Атказ! Атказ! Атказ! Миңа синә кирәк булса җәмгыяте хәйрия! Хуш, сау булыгыз!

Чыгып китәләр.

Сәркәтиб. Хуш! *(Кәгазьләрен җыештыра.)* Хафиз! Хафиз!

Сакчы керә.

Менә бу кәгазьләрне шкафка бикләп. Мин киттем. Иртәгә мин килгәнче кем килсә дә, әйт: «Атказ!» — диген. Хуш, сау бул! Ишеттеңме? Һәммәсенә: «Атказ, атказ, атказ!» *(Чыгып китә.)*

Сакчы *(кәгазьләрне алып)*. Атказ, атказ! Нәрсәгә җыелган булалар? Мин монда тора башлаганнан бирле һаман бер сүз инде ул: «Атказ, атказ!» *(Чыгып китә.)*

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

РЕСТОРАНДА

Зур зал, стена буйларына өстәлләр тезелгән. Берничә өстәлдә ашау-эчү белән мәшгуль берничә рус утырган.

Беренче мәҗлес

Садри, официант, руслар вә дамалар.

Садри *(залга кереп, сул тарафтагы өстәлгә утырып)*. Әле иртә икән, берсе дә килмәгән. Бәлки, алар җәмгыять мәҗлесенә барганнардыр? Алар килгәнче берәрне эчә торырга кирәк. *(Звонок бирә.)*

Официант килә.

Бер бутылка сыра бир!

Официант. Яхшы. *(Китә.)*

Садри. Җәмгыять бик яхшы сылтау булды әле, анда-монда барасы булса, «җәмгыятькә барам» дип чыгып китү бик ансат. Хатын: «Бүген бармасаң да ярар инде. Бик соңга калдың», — ди. Мин: «Юк, бер дә бармый калырга ярамый, карала торган бик кирәкле эшләр бар, мәҗлеснең ахырына барып җитсәм дә, барып калырга кирәк, анда миннән башка бер эш тә булмый», — дип чыгып киттем. Мин инде аларны күптән монда килеп җиткәннәрдер дип торадыр идем, әле килмәгәннәр икән. Узган

ел гласныйлыкка сайланырга да йөреп караган идем, булдырып булмады. Әгәр анда сайланган булсам, эш тагы да яхшырак буладыр иде.

Официант бер шешәне китереп куя.

(Шешәне карап.) Нигә мондыйны, кыйммәтлене китердең? Миңа сталавай кирәк түгел, бабарскийны[1] китер!

Официант. Хәзер ярамый, князь, сәгать унике тулды. Сәгать уникедән соң бездә андый бирелми.

Садри. Ни эшләп тулсын! *(Сәгатен чыгарып.)* Менә бит әле, сәгать уникедән чирек ким.

Официант. Юк, князь, безнең сәгать унике тулды инде. *(Китә.)*

Садри. Каһәр сукканнар, сәгатьләрен юри алга җибәреп куйганнар. Биш тиен көмеш әрәм китте. Алай буласын белгән булсам, мин җәмгыятькә дә кереп чыккан булыр идем. Унике тулганчы, арзан вакытта, бер-икене бушатып калырмын дип ашыга-ашыга килгән идем, булдырып булмады. Көн саен ун тиеннән ул бит елына утыз алты тәңкә була. Утыз алты тәңкә ул нинди булса да бер эшкә ярап куя.

Икенче мәҗлес

Шулар ук һәм яшь егет.

Яшь егет *(залга кереп, өстәлләрне күздән кичереп, Садри янына килеп).* Исәнме, Садри абзый!

Садри. Исәнме!

Яшь егет *(урындыкны тартып).* Сезнең янга утырырга мөмкинме? *(Урындыкка утыра.)* Монда бер студент килергә вәгъдә кылган иде, килеп җитмәгән икән.

Садри *(халыкка карап).* Менә тагы икенче бәла, бу инде кусаң да китмәс! *(Яшь егеткә.)* Утырыгыз, утыр!

Яшь егет. Студент килгәч тә, мин хәзер китәм. Ялгыз утыруы күңелсез. *(Звонок бирә.)*

Официант килә.

Кая, монда бер стакан китер әле. *(Садрига.)* Бүген бер җирдән ике йөз тәңкә акча аласы бар иде, мин кайтканчы, кибетләр ябылып калган, өлгереп булмады. Садри абзый, миңа иртәгә кадәр ун тәңкә акча биреп торыгыз әле, мин сезгә иртәгә иртә үк, шул ала торган җирдән алгач та, кертеп бирермен.

Официант стакан китерә. Яшь егет бер стакан тутырып эчә дә икенчене салып куя.

Садри *(халыкка карап).* Менә бәла, чистый бүз көясе булды бу! Мин әле монда биш тиен артык китте дип кызганып утырам, ә ул сала да эчә, сала да эчә.

Яшь егет. Минем иртәгә ала торган урыным бар. Ләкин миңа бүген бик кирәк иде. Монда бер кешегә бирәсе бар, бирми калсаң, вәгъдәсезлек була, яхшы түгел.

---

[1] *Бабарский* (баварский) – сыра төре. Германиядәге Бавария дигән төбәк исеме белән бәйләнгән.

(Сыраны эчә. Шешәдән яңадан салмакчы була. Шешәнең эчендә беткәнлекне күреп.) Монда беткән икән. *(Звонок бирә.)* Официант, кая, тагын монда берне китер әле. Садри абзый, зинһар, бүгенгә тыңлап торыгыз әле, мин сезгә иртәгә иртә үк кертеп бирермен.

Садри. Минем янымда ул кадәр үк акча юк.

Яшь егет. Алай икән, миңа бик кирәк иде шул. Булмаса, биш тәңкә генә биреп торыгыз, мин сезгә иртәгә иртә үк бирермен.

Садри. Алай да юк.

Яшь егет. Соң, күпме генә бар?

Официант бер шешә китерә. Яшь егет стаканга салып берне эчә.

Садри *(халыкка карап)*. Бер дә бирмичә котылып булмас инде, берәрне бирергә кирәк. *(Яшь егеткә.)* Барлы-юклы ике тәңкә акчам бар, мә, менә берсен бирим.

Яшь егет. Хәерле булсын, ичмаса, өч тәңкә дә юкмы?

Садри. Юк шул!

Яшь егет. Хәерле булсын! *(Бер сумны алып, жилетка кесәсенә кыстыра.)* Иртәгә мин сезгә кибет ачкач та кертеп бирермен. Әле минем сезгә әүвәлге бирәчәкләрем дә бардыр. Аларын да кертеп бирермен. *(Яңадан шешәдән эчеп.)* Мин, теге яктан чыгып, студентны гына карап керим әле. *(Чыгып китә.)*

Садри. Кара син аны, ә! Бер тәңкәлекне чәлде бит! Мин инде аның күзенә кырып салырга сукыр бер тиен дә бирмәгән булыр идем, ярамый. Беркөннәрне тегендә күргән иде. «Бәладән башаяк» ди. Йә, бирмәсәң, өйдәгеләргә белдереп харап итәр. *(Шешәдән салмакчы була.)* Әле моны да бетергән икән! *(Звонок бирә.)*

Официант килә.

Кая, тагы берне китер! *(Халыкка карап.)* Әүвәлгеләрен дә бирермен дигән була, алырсың инде шайтаннан иман! Әле ярый кесәдә бер тәңкәлек акча бар икән, юк исә өч тәңкәлегә дә эрегән булыр иде.

Официант *(шешәне китереп куеп)*. Бу стакан артыкмы?

Садри. Артык, артык, алып китә күр. *(Халыкка карап.)* Йә тагын килеп эчә башлар!

Официант алып китә.

Ул шайтаннан, кая барсаң да, качып котылып булмый. Кайсы ристаранга гына кермә, ул анда була. Өстәл саен килеп эчә дә йөри. Хәерле булсын! Биш тиен урынына егерме мәртәбә биш тиен китте.

Яшь егет *(килеп утырып)*. Минем стаканны алып киттемени әле?

Садри. Алып китте. Мин сине чыгып киткән дип торам.

Яшь егет. Ул ни эшләп алай алып китә аны, сорарга кирәк. *(Звонок бирә.)*

Садри *(халыкка карап)*. Менә бәла! *(Яшь егеткә.)* Юк, кирәкми, мин хәзер китәм.

Яшь егет. Палужым, минем дә эчәсем килми. Теге студентны гына көтеп утырадыр идем. Хушыгыз әле хәзергә! *(Тора, кесәсеннән бер сумлыкны чыгарып күрсәтеп.)* Китсәң китәрсең, миңа монда бүгенгә җитәрлек булды инде. *(Чыгып китә.)*

Өченче мәҗлес

Садри һәм Касыйм.

Касыйм *(залга кереп, Садри янына килеп утырып).* Исәнме, Садри!

Садри. Исәнме!

Касыйм. Әле члиннар җыелмадымыни?

Садри. Юк әле.

Касыйм. Син җәмгыятькә бардыңмы?

Садри. Юк. Ә син бардыңмы?

Касыйм. Юк. Минем бүген эшем бар иде. Вакзалга төштем. Син ник бармадың?

Садри. Безнең бүген парлы кунакка барасы булды.

Касыйм. Кая, миңа да берне әйтергә кирәк. *(Звонок бирә.)* Вакзалда тегене күрдем. Мәскәүгә китеп бара. Бик матурланган икән ул.

Садри. Мин әле аны өченчекөн генә күргән идем, бер дә үзгәргән урынын тапмадым.

Официант килә.

Кая, тагын берне китер.

Официант китә.

Син, бәлки, бераз җибәргән булгансыңдыр, шуңар күрә чибәр күренгәндер.

Касыйм. Булса бераз булгандыр инде. Кунак озатканда була торган эш.

Официант китерә, эчә башлыйлар.

Йә, тагы сезнең тирәдә нинди хәбәрләр бар?

Садри. Ул – бу хәбәр юк. Әле ярый син килеп җиттең. Теге, сиңа каршы очраган нәрсә, сыраны эчеп җанымны чыгара язды.

Касыйм. Аңа ни эшкә эчертәсең соң?

Садри. Эчертми булмый, беркөн ул мине тегендә күргән иде, эчертмәсәң, ул аннары бөтен дөньяга исемемне чәчеп йөри башлый.

Касыйм. Һу, әнә члиннар киләләр.

Дүртенче мәҗлес

Шулар ук һәм Насыйр белән Фатих.
Насыйр белән Фатих, кереп, килеп утыралар.

Фатих.
Насыйр. } Исәнмесез, исәнме!

Фатих. Ник сез җәмгыятькә бармадыгыз?

Садри. Барыбер җыелмагандыр бит?

Фатих. Җыелмаса, без үзебез генә эшли белмибезмени? Кая, әйтергә кирәк әле. *(Насыйрга.)* Нәрсә әйтәбез?

Насыйр. Әйтергә кирәк, икене китерсен.

Фатих. Юк ла, ул ярамый, иң әүвәл бик ныгытып нигез салырга кирәк. Аннан соң өстеннән сипләргә ул да ярый. *(Звонок бирә.)* Иң әүвәл бик яхшылап бер графинчыкны сындырыйк та, аннан соң аны әйтербез. Садри, ярый бит шулай, ә?

Садри. Ярый шул.

Насыйр. Ярый, китерсен инде, алайса.

Официант килә.

Фатих. Кая, син безгә бик шәп итеп закуска белән берне китер әле. Түлке кара аны, закускасы бик шәп булсын.

Официант китә.

Ник монда кеше күз алдына, залга утырдыгыз? Монда бит теләгәнчә җәелеп утырып булмый. Кабинетка кереп утырырга кирәк иде.

Шул арада бер рус белән бер маржа, икенче өстәлгә килеп утырып, ашарга сорыйлар.

Садри. Мин килгәндә, бер кеше дә юк иде, кабинетта ялгыз утыру күңелсез булыр дип монда кердем.

Фатих. Кара әле, Касыйм, тегенең янындагы мәткәне, шәп бит?

Касыйм. Нәгыз[1] икән шул.

Фатих. Без бит әле җәмгыятьтән киләбез.

Садри. Ниләр булды?

Фатих. Анда без берничә төрле эшне карадык. Иртәгә сезгә пртакул кенәгәсен китерерләр, кул куярсыз. Анда теге тар балаклы яшьләр, алабия кичәсе ясыйбыз, файдасын җәмгыятькә бирәбез, дип, прашиния биргәннәр иде, без риза булмадык. Акчаларын башларына чәйнәп яксыннар, аларның хәрам акчаларының бер тиене дә кирәк түгел, дидек.

Касыйм. Шулай шул, бик яхшы иткәнсез.

Насыйр. Анда бер Себер сәүдәгәре килгән иде, ул да алар яклы бернәрсә икән: «Яшьләрегез бик яхшы эш эшләмәкче булалар икән», — ди.

Фатих. Бездәге яшьләр дә бәйрәмдә әллә нәрсәханә файдасына театр куйдылар, ди.

Насыйр. Бер кичтә җиде йөз тәңкә файда иттеләр, ди.

Фатих. Аның авызын бик яхшы гына итеп томаладык.

Насыйр. «Аның акчасы хәрам бит», — дидек.

Фатих. «Сезнең хәзрәтегез андый эшкә ничек риза була?» — дигән идек: «Безнең хәзрәт ул акчаны хәрам дип әйтми, бик яхшы эш дип әйтә», — ди. Аларның муллалары үзләре шикелле, Мисырда укып бозылып кайткан кеше икән.

Насыйр. Мин әйттем: «Мисырда укыган кешеләр алар эшләпә киюне, урысча киенүне дә дөрес дип әйтәләр, урыс суйган итне ашаудан да тартынмыйлар», — дидем.

Фатих. Малаеңның авызы шап итеп капланды!

Көлешәләр.

---

[1] *Нәгыз* — шәп, гүзәл, әйбәт.

Садри. Нинди нәрсә соң ул, кайдан килгән?

Фатих. Бер малакасус, кызыл авызлы нәрсә шунда, өйләнергә килгән. Кайдагы икәнлеген сорамадык.

Себер бае Яучы белән, кереп, икенче яктагы өстәлгә утыралар.

Әнә, әнә шул нәрсә. Әле монда да килеп җиткән икән!

Садри. Болай үзенең кыяфәте байга охшый.

Насыйр. Өйләнәсе булгач, бай булып күренергә тырышмыйча ярамый бит!

Фатих. Бай булып күренмәсә, аннан ары кыз бирмиләр бит!

Бишенче мәҗлес

Шулар ук һәм Себер бае белән Яучы.
Себер бае звонок бирә. Официант килә.

Себер бае. Кая, безгә ашарга бернәрсә китерегез әле?

Официант. Рәхим итегез, нәрсә китерик? Менә прейскурант. Рәхим итеп, шуннан карап әйтегез.

Себер бае *(Яучыга)*. Сез нинди нәрсә телисез, беренчегә суп әйтикме, борщмы?

Яучы. Алар нинди нәрсәләр?

Себер бае. Икесе дә шулпалы нәрсәләр.

Яучы. Анысын беләм, нинди иттән пешергән, балыктанмы?

Себер бае. Юк, балыктан түгел, иттән.

Яучы. Юк, алай иттән булса, кирәк түгел. Мин урыс ите ашамыйм.

Себер бае. Ул бит урыс ите түгел, сыер ите. Адәм ите булса, мин дә ашамыйм.

Яучы. Юк-юк, мин ашамыйм. Син үзең аша. Мин берәр нәрсә эчеп кенә утырам. *(Официантка.)* Миңа бер шешә сыра китер.

Себер бае. Хәерле булсын, алайса, мин ашыйм әле. Минем ашыйсым килә. *(Официантка.)* Миңа бер порция суп китер, тавыктан булсын, икенчегә бер порция ростбиф китер.

Официант. Яхшы, ярар. *(Китә.)*

Икенче официант тегеләр өстәленә бер графин һәм закускалар китереп куя.

Фатих *(закускаларны карап, официантка)*. Бу ни?

Официант. Гөмбә.

Фатих. Ә монысы?

Официант. Севрюга.

Фатих. Балыкмы?

Официант. Әйе.

Фатих. Ә монысы?

Официант. Бозау ите.

Фатих. Бозау ите?

Официант. Әйе.

Фатих. Анысын сезгә кем китерергә кушты?

Официант. Аның порциясе шулай инде.

Фатих. Без мөселман бит, ник син безгә андый нәрсә китерәсең? Бар, тиз алып кит. Аның урынына башка нәрсә китер.

Официант. Башка төрле нәрсә бирелми.

Фатих. Бирелмәсә, кирәк түгел, алып кит. Үзең аша.

Официант алып китә.

Фатих. Урыс суйган ит ашарга без җәдит түгел, анысын әнә теге җәдиткә бирер. Ул ашар, чиркәнмәс. *(Төкерә.)* Тфү, җирәнгеч, әле ярый башка киткән вакыт булмады. Мин аның бозау итен башына каплаган булыр идем.

Садри. Безнең өчен Максим трактиры яхшы, аның хәҗәене бик яхшы кеше. Мин, кенәз, мөселманнарга ярамый торган бернәрсәне дә тотмыйм, ди. Анда һәрвакытта закускага тозлы кәбестә, тозлы кыяр, торма, балык – шундый нәрсәләр генә китерәләр. Шуның өчен анда агай-эне тулып ята.

Фатих. Моның әле кешесенә очраганы юктыр. Өйрәтерләр иде аны.

Эчәләр. Официант тегеләр өстәленә аш китереп куя.

Яучы. Ничек җирәнмичә ашыйсыз? Мин урыс ашының исен дә яратмыйм.

Себер бае. Без өйрәнгән инде. Безнең тора торган якларда ат итеннән башка мөселман суйган ит тә табып булмый.

Яучы. Ат ите бик шәп була ул. Без аны бик яратып ашыйбыз. Урыс ите ашау гадәте бездә юк. Агай-энедән бер кеше дә ашамый. Әнә күрдең бит, тегеләр закускага китергән итне дә кире җибәрделәр. Ул турыда безнең агай-эне динне бик яхшы тота.

Себер бае. Алар ни дип ашамадылар?

Яучы. Әйтәм ич, бездә ашамыйлар дип. Хәрам.

Себер бае. Ә теге графиндагы нәрсә хәрам түгелме?

Яучы. Хәрамын хәрам да инде, әллә ничек урыс ите шикелле түгел. Бәндәчелек инде, андый эшләр генә була ул. Тәүбә кылгач бетәр.

Себер бае. Шәп икән!

Фатих. Мәҗлес бик шәп булып китте әле. Тагы берне алдырырга кирәк. Булган-булган берәгәйле булсын. *(Звонок бирә.)*

Официант килә.

Кая, тагын берне китер.

Себер бае. Тегеләр баягы җәмгыять членнары түгелме соң?

Яучы. Шулар, теге икесе баягы кешеләр. Болары да члиннар, бая мәҗлескә килмәделәр.

Себер бае. Мәҗлескә килмәсәләр дә, монда киләләр икән.

Официант тегеләр өстәленә тагын берне китерә. Эчәләр.

Яучы. Киләләр дип, һәрвакыт та килмиләр инде, бүген шулай туры килгән.

Себер бае. Бая, әдәбият кичәсеннән килгән акчаны хәрам дигәч, мин аларны бик тәкъва[1] кешеләрдер дип белгән идем. Үз турыларына килгәч, тәкъвалык бер якта торып тора икән. Суфи суган сөймәс, күрсә, кабыгын да куймас, ди.

Официант ростбифны китереп куя.

---

[1] *Тәкъва* – диндар.

Ф а т и х *(бераз кызган, боларга таба борылып).* Ни ди җәдитең? Ни сөйли? Бездә алабия кичәсе ясыйлар, диме?

С е б е р б а е. Ясаганны, әлбәттә, ясыйлар, дибез шул.

Ф а т и х. Ә без ясамыйбыз, хәрам, дибез!

Н а с ы й р. Без эшләпә дә кимибез, хәрам, дибез!

Ф а т и х. Сезнең шикелле урыс ите дә ашамыйбыз, хәрам, дибез!

С е б е р б а е. Бик яхшы итәсез. Алай булгач, эчмәскә дә кирәк иде. Ул да хәрамдыр бит?

Ф а т и х. Анысы, анысы ничава, аның юлын без үзебез дә беләбез. Дөньяны менә сезнең шикелле җәдитләр харап итеп бетерәләр. Урысча киенеп, яланбаш йөреп, мөселманны мыскыл иттерәләр.

Дама янындагы рус чыгып китә.

К а с ы й м. Фатих, Фатих, тукта әле, бәйләнүеңне куй әле.

Фатих борыла.

Әнә теге мәткә бушады, син шуны кара. Шәп бит, ә?

Ф а т и х. Ә, бушадымыни? Әйдәгез әле, эчик әле. Мин аны хәзер кулга төшерәм.

С е б е р б а е *(ашап бетереп).* Берәр стакан чәй дә эчәргә кирәк. *(Официантка чәй китерергә куша.)*

Ф а т и х. Мин аны хәзер кулга төшерәм. Кабинетка кереп утырырбыз. *(Дама янына барып утыра.)* Нихәл, баришна, ни эшләп утырасың? Әйдә безнең янга. Нинди матур, ә? *(Битеннән тотмакчы була.)*

Д а м а *(урыныннан сикереп торып).* Бу нинди безобразие?! Официант!

О ф и ц и а н т *(йөгереп килеп).* Нельзя, князь, нельзя! Бар үз урыныңа!

Себер бае елмаеп-көлеп тора.

Ф а т и х. Төртмә, ник мине төртәсең?

Даманың и р е керә, икенче яктан да б е р н и ч ә к е ш е керәләр. Араларында Я ш ь е г е т тә күренә.

Д а м а *(җылаган тавыш белән).* Володя, менә бу татар мине оскорбить итте. Монда килеп утырды да, әйдә безнең янга, ди.

Р у с. Как ул алай сметь итеп монда кеше хатыны янына килә? Официант, бар, чакыр хозяинны, полиция китерсен!

Официант чыгып китә.

С а д р и. Ну, Фатих, бәйләнмәгез, әйдә китик.

Урыннарыннан торалар. Касыйм акча чыгарып өстәлгә куя, чыга башлыйлар.

Ф а т и х. Нигә куркасыз аннан ул кадәр, ул кем булган? Сүз әйттерәсе килмәсә, хатынын монда ир-ат арасына алып килмәсен. Аның монда хатынын алып килгәне өчен кем винаават? Мин бер дә курыкмыйм!

Н а с ы й р. Зинһар, юкны сөйләмә. Әйдә, әйдә кайтабыз.

Чыга башлыйлар.

Рус. Официант! Чыгарма боларны, хозяин килсен!

Фатих. Бер дә синнән куркып чыкмыйбыз, үзебез чыгабыз.

Хозяин килә, артыннан Околодочный илә Городовой күренә.

Алтынчы мәҗлес

Шулар ук һәм Околодочный илә Городовой.

Рус. Вот менә бу татар минем хатынга начар предложение ясаган. Менә болар – шаһитлар. *(Кешеләрне күрсәтә.)*

Фатих. Кем белә аны: әллә хатыны, әллә түгел?! Хатыны булса, монда ирләр янына алып килмәсен. Без алып килмибез бит!

Околодочный *(Городовойга)*. Әйдә, алып кит!

Фатих. Как ул алып китә мине, мин бит думавладилис, мин бит купис. Ни имиет права ул мине алып китәргә!

Околодочный. Ну, ну, күп сөйләнмә, әйдә, анда баргач сөйләрсең!

Алып чыгалар. Аның артыннан Касыйм, Насыйр һәм Садри да бик юашланып кына чыгып китәләр.

Җиденче мәҗлес

Яшь егет, Себер бае, Ямчы һәм Официант.

Яшь егет *(халыкка карап)*. Шауламагыз, хәзер миңа тагы бераз имәрлек урын чыкты. Әгәр бераз бөдәмәсә, мин аны бөтен шәһәргә фаш итәрмен. *(Чыгып китә.)*

Себер бае. Шәп икән эшләрегез, членнарыгыз мәсьәләне бик яхшы хәл кылдылар! Әйдә, без дә кайтыйк инде.

Торалар.

Кадимнәрегез бик шәпләр икән! И бичаралар, инәдән куркып лом йоткан халыклар!

Чыгып китәләр.

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

КЛУБТА

Клубның бер бүлмәсе. Өстәлләр, урындыклар тезелгән. Бер почмакта лото барабаны куелган. Биш кеше домино уйный. Ике кеше алар янында аяк өстендә басып карап тора.

Беренче мәҗлес

Домино уйнаучылар, Дежурный.

Уйнаучыларның берсе. Йә, чык. Әйдә. Мин сиңа бик яхшы мач бирдем. Яса алты да алты.

Икенчесе. Юк әле, алты да алтылар алар өшкергән әле. Менә мин болай итеп бер дә бер генә ясап торыйм әле. *(Бер шакмак куя.)* Нихәл, шәп булдымы? Шулай итәләр аны. Бик тәмле булыр әле ул.

Өченчесе. Кайдан килеп утырдым синең кул астыңа, әйдә, Әптерәй, куй!

Дүртенчесе. Әйдә, шул көенчә генә, мин дублитын гына куям.

Бишенчесе. Капламадыгыз шул берлене, менә хәзер ала инде ул, син бер дә йөри белмисең!

Беренчесе. Юк әле, алмый торсын, аның җиденчесе менә монда әле. *(Куя.)* Кая, китерегез әле акчаларыгызны! Ха-ха-ха! Ни эшләтте? Сигезенчесен кулыңа тотып калдыңмы? Шулай иттерәләр аны! Кая, китерегез акчаларыгызны, китер, китер!

Икенчесе. Өлгерерсең әле, ул кадәр ашыгып кая барасың? *(Шакмаклар ала.)*

Дүртенчесе. Сайлама, сайлама, алай иттереп сайлагач, һәркем дә отар.

Өченчесе. Монда миңа дүрт дублит килгән. Алай итеп уйнагач, уен буламыни инде ул, китер монда шакмакларыңны! *(Шакмакларны тартып ала.)*

Икенчесе. Кит аннан, кеше алдыннан ни эшкә шакмакларын тартып аласың?

Дүртенчесе. Китер, китер, өләшеп бирәбез.

Читтән карап торучының берсе. Шулай кирәк, шулай, правила буенча өләшергә тиеш!

Икенчесе. Монда правила көтеп торсаң, авызыңны ачып калырсың!

Дүртенчесе. Кара әле, хәерсезне, җыен алтылыкны бер кулга җыеп бетергән!

Икенчесе. Кулыңнан килсә, син дә җый, мин сиңа бер сүз дә әйтмим.

Дүртенчесе. Мин синең шикелле шулер түгел. Син генә ул һәммә шакмакларны билгеләп бетергән.

Өченчесе. Йә, өләшсәң өләш инде, нәрсәгә вакыт әрәм итеп утырасың?

Беренчесе. Кая, син миңа акчаны бирмәдең ич! Әле монда акчагыз ким, кайсыларыгыз бирмәгән?

Өченчесе. Мин башта ук бирдем, әнә ул ун тиенлек мин биргән акча.

Дүртенчесе *(өләшә-өләшә)*. Мин дә башта ук бирдем, унбиш тиен биреп, биш тиен кайтарып алдым.

Беренчесе *(Икенчегә)*. Алай булгач, син әле монда бирмәгән.

Икенчесе. Нәрсә? Мин сиңа бая ук әйттем ич, ун тиенең миндә булыр, дип.

Беренчесе. Юк, ул алай ярамый. «Динги на кон». Монда һәркем дә синең шикелле акча оттырып утыра.

Бишенчесе. Ул һәрвакытта шулай. Вакытында алып калмасаң, эченнән тына да кала.

Өченчесе. Ягез инде, зинһар, тизрәк булыгыз, нәрсә вакытны уздырасыз, кемгә чыгарга?

Беренчесе. Хут менә моңа, иң әүвәл акчасын түләсен дә, аннан ары чыгар!

Ишектән Дежурный кереп, карап тора.

Икенчесе. Исең киткән икән шул ун тиен акчаңа, мә ал, бу кадәр җылак булырсыз икән!

Дежурный. Әфәнделәр, зинһар, бераз кеше төслерәк кылансагыз ла. Бер-берегез белән кычкырышып, клубта тавыш чыгармагыз.

Дүртенчесе. Син – дижурный кеше, син карарга кирәк. Сезне бит шуның өчен старшина итеп монда сайлап куйган.

Беренчесе. Бу да бит старшина. Старшина була торып, үзе правиланы бозып утыра.

Өченчесе. Иштегез, бу юлы өләшкән булып җыен дублитны миңа тутыргансыз!

Икенчесе. Бер дә шаулама, менә хәзер мин синең бер дублитыңа бирәм. Миндә менә монда чыгарга бер дублит та юк, мәгез сезгә алты да өч!

Өченчесе. Менә, менә анысына рәхмәт, чуен юлы китте! Йә, яса син өч тә өч!

Беренчесе. Өч тә өч ясарга аңа ерак әле.

Дүртенчесе. Кара әле, валлаһи, бер рәтле нәрсә килмәгән. Әйдә куегыз, мин – пас!

Себер бае белән Яучы кереп, карап торалар.

Икенче мәҗлес

Шулар ук һәм Себер бае белән Яучы.

Бишенчесе. Тукта әле, алай булса, мин бик кызык итим әле, өч тә өчне куйыйм! Йә, капла!

Беренчесе. Бик шәп иттең, миндә алтыдан күп нәрсә юк иде. Мә, рәхәтләнегез, алты да буш!

Икенчесе. Сиздек эшеңне, син бушлайга уйныйсың икән! Тора тор әле! Менә ул өч тә өч булып торсын әле. Куй әйдә!

Өченчесе. Юк миндә, әйдә куй!

Дүртенчесе. Чын хәерсезләр икән, кара әле, валлаһи, биш шакмактан берне дә куя алмыйча утырам. Каплагыз, зинһар, шуның өчлесен, ул өчлегә уйный.

Икенчесе. Шулаймы, уйныйм шул, сайлап ала дигән идең, ник куймадың?

Дүртенчесе. Куярмын әле, бер дә кәпрәймә, өчлеләрең белән әллә кая бара алмассың!

Икенчесе. Барганны карап торырсың. Ничек итеп кенә барырмын!

Бишенчесе. Мәгез, бер башын мин әчтем. Мәгез өч тә дүрт!

Беренчесе. Маладис ул эшеңә! Минем дүртле дублит китте.

Дүртенчесе *(Икенчегә)*. Нихәл, ни эшләттеләр? Ачасыңмы өчлекне?

Икенчесе. Бер дә ачмый торсын әле! Миндә аннан башкалары да җитәрлек әле! Мәгез дүрт тә алты!

Дүртенчесе. Чын хәерсез икәнсең! Ябыгыз тизрәк шуның өчлесен!

Өченчесе. Шулай итикмени? Мәгез, алайса, алты да биш булсын.

Дүртенчесе. Менә монысы ярады, ягез әле, менә сезгә мин биш тә бишле дублитны куеп җибәрим әле!

Бишенчесе. Шулай иттегезмени, тукта әле, алай булса, мин тагы алты да алты ясап җибәрим әле. Йә, каплагыз!

Беренчесе. Мин – пас! Алтылы тәмле булыр әле ул.

Икенчесе. Юк. Мин дә – пас!

Дүртенчесе. Ә, шулаймы, нихәл, пас булдыңмы? Синең шикеллеләрне шулай итәләр аны. Өч тә өч ясап бик кабарынып утырган идең!

Өченчесе. Мин дә – пас!

Дүртенчесе. Икесе дә моның үзендәдер лә инде ул!

Беренчесе. Булса, нәрсә карап утырасың инде? Йә, ал инде!

Бишенчесе. Уйнамагыз, егетләр. Ике башы да миндә, кая, китерегез акчаларыгызны!

Икенчесе урыныннан торып китә.

Бишенчесе. Кая барасың, акчаңны түләп кит!

Икенчесе. Мин уйнамыйм.

Бишенчесе. Уйнамасаң уйнамассың. Монда акчаңны түләп кит әле!

Дежурный. Әфәндем, алай ярамый, акчагызны түләп китегез!

Икенчесе. Кит аннан, акчам юк! *(Чыгып китә.)*

Дүртенчесе. Уенга кертергә кирәк түгел аны, һәр көнне ул шулай, оттырды исә, акчасын түләмичә чыга да китә!

Өченчесе. Бер дә килешә торган эш түгел инде.

Дүртенчесе. Җитмәсә тагы, үзе старшина! Старшиналарыбыз әүвәле үзләре тәртип белмиләр!

Өченчесе. Тәртип белмәгән кешене сезгә сайларга да тиеш түгел.

Беренчесе. Сайламыйча, кемне сайлыйсың? Бер кеше дә сайланмый. Акчасызга кемнең хезмәт итәсе килә?

Себер бае *(Яучыга)*. Сезнең бар нәрсәгез дә кызык икән. Җәмгыятегезгә барсаң, анда талаш, клубыгызга килсәң, анда кычкырыш, ресторанnarга керсәк, анда җәнҗал! Әллә сез шәһәрегездә талаш, кычкырыш, җәнҗал белән генә тамак туйдырасызмы?

Яучы. Юк ла, алай ук түгел лә, сез генә әле, әллә ничек, шундый вакытларга туры киләсез.

Дүртенчесе. Әйдә өләшегез, дүртәү генә уйныйбыз.

Дежурный. Юк, әфәнделәр, сәгатегез тулды инде, уйнарга вакыт бетте!

Дүртенчесе. Тулса, икенче сәгатькә алабыз.

Дежурный. Юк, хәзер лото башлана.

Беренчесе. Кая, кем белән башлыйсыз? Лотога монда кеше юк ич әле.

Дежурный. Теге якта кеше күп, хәзер керәләр. *(Икенче бүлмәгә чыгып.)* Кая, кем, звонок бирегез, лото сата башлагыз.

Икенче якта звонок тавышы ишетелә. Бүлмәгә **халык** керә башлый. Кайсы кайда, кайсы кайда урыннар алып утыра башлыйлар.

Өченче мәҗлес

Шулар ук һәм лото уйнаучы халык.

Лото әйләндерүче *(кычкыра)*. Әфәнделәр, лату башлана!

Себер бае *(Яучыга)*. Нәрсә ату башлана инде?

Яучы. Юк, бернәрсә дә ату башланмый, лата диган уен башлана.

Залда тавыш күтәрелә, һәркайсы, бер-берсе белән сөйләшеп, шаулаша башлыйлар. Карта сатып алалар.

Күзлекле бер кеше. Гариф, Гариф, кара әле, син миңа икесе дә бертөслене биргәнсең, кая, берсен алмаштырып бир!

Читтән тавышлар. Юк, юк, алмаштырыш юк, бирмәгез, бирмә!

Себер бае. Сезнең монда тавыш бер дә артильный мунчадан ким түгел икән!

Дежурный *(Себер бае янына килеп)*. Әфәндем, сез, ахры, мондагы кеше түгелсездер?

Себер бае. Юк, әфәндем, мондагы түгел, читнеке. Шәһәрегезгә бер эш белән генә килгән идем дә клубыгызны да карап чыгыйм дип кердем. Әле шуны әйтеп торадыр идем, монда сезнең һич кирәкмәгәнгә бик шаулашалар икән.

Тавыш һаман дәвам итә.

Дежурный. Шулайрак шул, нихәл итмәк кирәк. Әле клублар безнең арада яңарак бер эш. Халык ияләнеп җитмәгән, тавышланудан тыйсаң, аннан ары клубны бөтенләй ташлап, килмәс булалар. Шуңа күрә ихтыярлы-ихтыярсыз түзелә инде. Рәхим итегез, утырып карап торыгыз, әле музыка башланырга шактый вакыт бар.

Себер бае, Яучы урындыкларга утыралар.

Серый киемле *(бүлмәнең икенче башында утырган бер кешегә картасын күрсәтеп)*. Кәрим, Кәрим, миңа теге кичәге бальшуйны алган карта чыккан.

Почмакта утырган кеше. Шаулама инде. Алайса, алабыз, билләһи, алабыз!

Кара киемле берсе. Гариф, синдә 17 ле бармы?

Гариф. Юк.

Кара киемле. Миндә 17 ле икәү. Миндә ике 5 ле, ике 17 ле, ике 36 лы, ике 49 лы бар.

Гариф. Зарар юк. Алар чыга торган сифрлар.

Лото әйләндерүче *(звонок шалтыратып)*. Сатылган — 28 карта, 7 сум. 70 тиене клубка. Малый — 60, бальшуй — 1 сум 25 тиен.

Халыктан берәү. Ни эшләп алай?

Лото әйләндерүче. Бальшуйга 5 тиен артык.

Халыктан берәү. Ярый, болгат!

Лото әйләндерүче. Беренче уен. Первый — 49.

Серый киемле. Миндә юк.

Гариф. Шауламагыз! Ничек дисең?

Халыктан берәү. 61!

Кара киемле. Шауламагыз әле!

Почмактагы кеше. Тише!

Лото әйләндерүче *(звонок бирә)*. 49, 36!

Гариф. Капла, Җәләли, 36 ны, әйттем бит ул чыга дип!

Халыктан берәү. Шауламагыз инде!

Лоточы. 3!

Кара киемле. Гариф, тирный булды!

Лоточы. 23, 14, 59!
Кара киемле. 49 диген!
Лоточы. 16!
Кара киемле. Ах!
Лоточы. 42, 43!
Халыктан берәү. Сана шулай, 44 диген!
Лоточы. 39!
Кара киемле. Гариф, миндә фатир булды.
Лоточы. 34!
Кара киемле. 5 диген, 5!
Лоточы. 12!
Кара киемле. 5!
Лоточы. 4!
Кара киемле. 5!
Гариф. Миндә дә фатир бар!
Кара киемле. Бальшуйдамы?
Халыктан берәү. Болгат!
Лоточы. 6!
Берәү. Готова!
Почмакта утыручы. Нәрсә?
Кара киемле. Каһәр суккан икән! *(Картасын күтәреп бәрә.)* 5 ле фатир ни гомердән бирле торды бит!
Халыктан берәү. Минем дә 60 лы фатир янды.
Икенче берсе. Страхавайт итәрләр аны, ул вакытта янмас иде.
Лоточы *(тулган картаны килеп алып)*. Малый. *(Барабан янына барып.)* 6, 14, 23, 36, 42 – дөрес.
Гариф. Шаулама, малый гына китте әле, бальшуйны без алабыз!

Почмакта утырган кеше, урыныннан торып, икенче почмакка барып, идәнгә утыра.

Серый киемле. Кәрим, ни эшлисең анда?
Кәрим. Теге урын бик бәхетсез икән. Бары икене генә ябып калдым.
Гариф. Анда барып утырганчы, син минә монда, өстәл астына кереп утыр!
Кәрим. Утырырмын шул, анда синең эшең булмасын!
Лоточы *(звонок биреп)*. Икенче уен, малый – 60 тиен, бальшуй – 1 сум 90 тиен.
Халыктан берәү. Тыңлагыз, җәмәгать, яңа көйне әйтә.
Лоточы. 60!
Серый киемле. Әйт шуны!
Гариф. Бая миңа кирәк иде ул. Бая 60 лы фатирым янды!
Лоточы. 51!
Берәү. Үзеңә булсын!
Лоточы. 17!
Кәрим. Үктәбрис!
Гариф. Болгат!
Кәрим. Болгатма, болгатма, харап итәсең, хәзер миндә фатир була!

Лоточы. 9!

Кәрим. Менә, менә монысы ярый.

Халыктан берәү. Нәрсә син анда лыгырдап ятасың?

Лоточы. 13!

Берәү. Яхшылап болгат әле, гел баягыларны әйтәсең.

Лоточы. 29!

Берәү. Менә шулай. Тагы 32 не әйт!

Лоточы. 40!

Берәү. Ә менә монысы ярамады!

Гариф. Шауламагыз инде, зинһар, әллә монда базар дип белдегезме?

Лоточы. 48!

Кәрим. Була, була!

Лоточы. 33!

Кәрим. Айт! 32 дисә...

Лоточы. 32!

Кәрим. Һап! Фатир булды!

Лоточы. 12!

Кәрим. Эһем! *(Урыныннан сикереп торып, барабан янына бара.)*

Лоточы. 11!

Кәрим. Һай!

Лоточы. 4!

Ике җирдән тавыш. «Булды, готова!»

Халык шауларга тотына.

Гариф. Әйттем бит, алабыз, дип!

Кара киемле. Бальшуймы?

Гариф. Юк, малый. Әй, малай!

Кәрим. Каһәр икән, шунда 3 дип әйтмәде бит, бальшуй буладыр иде!

Халыктан берәү. Ничәле дисең?

Кәрим. 3 ле лә!

Берәү. 3 ле булса, икәү уртаклыйдыр идек.

Гариф. Әйттем бит мин сиңа, өстәл астына кереп утыр, дип, чыгар иде. Малай! Кая, миңа бер стакан чәй, ике сумса китер әле.

Кәрим. Тыгыныгыз инде безнең акчага!

Лоточы. Ике малый – 4, 12, 29, 33, 40, 4, 13, 29, 33, 48 – дөрес. *(Акчаларны китереп бирә.)* Өченче уен, малый – 60, бальшуй – 2 сум 55 тиен.

Гариф. Менә бу юлы бальшуйны алырга расчёт бар.

Лоточы. 52!

Берәү. Тукта әле, мин карталарны рәтләмәгән, ничә?

Лоточы. 52, 45, 15!

Кәрим. Болгат!

Лоточы. 53, 34, 20!

Кәрим. Болгат!

Лоточы. 10, 8, 6, 1!

Кәрим. Болгат, дим!

Лоточы. 31!

Берәү. Стоп!

Кәрим. Әбәү!

Гариф. Нихәл, болгаттымы?

Кәрим. Бигрәк тиз. Бары 12 генә шакмак чыккан.

Гариф. Беркөнне теге клубта бары 6 гына шакмак чыкты. Берәү бальшуйны алды.

Кәрим. Анда чыга. Мин дә әле бүген, моннан чыккач, анда барам. Ичмасам, анда барып оттырсаң да стует. Мин беркөн анда 24 тәңкә бальшуй алдым.

Лоточы. Бальшуй! 1, 15, 20, 31, 45, 52! Рәхим итегез!

Берәү. Мә сиңа 5 тиен чәйлек!

Лоточы. Кит аннан, бальшуй алып та 5 тиен генә бирергә!

Кәрим. Син миңа бальшуйны чыгар, билләһи, мин 10 тиен бирәм!

Гариф. Мин 15 тиен!

Серый киемле. Мин 20 тиен!

Халыктан берәү. Кем арттыра, юкмы тагын арттыручы?

Лоточы. Дүртенче уен, малый — 60, бальшуй — 1 сум 25 тиен.

Кара киемле. Хәзер уенның тәме китте инде.

Лоточы. 6, 12, 9, 7, 3, 2!

Кәрим. Бигрәк вактан турый башладың!

Лоточы. 1!

Кара киемле. Менә тагы сиңа, башкаларын яратмасаң!

Серый киемле. Берлеләрнең барын да әйтеп бетерә инде!

Лоточы. 60!

Кәрим. Уһу! Сразы югары менеп китте!

Халыктан берәү. Тише!

Лоточы. 30, 43, 14, 21, 31, 40!

Кәрим. Бол... Болгат!

Кара киемле. Нәрсә кешене куркытып утырасың?

Лоточы. 39!

Хатын-кыз тавышы белән берәү. Давольне!

Гариф. Яна 50 тиен!

Халык шаулый.

Лоточы. 2, 14, 21, 39, 43! Малый. *(Акчаны бирә.)* Актык уен, азы саналмый. 28, 3, 16, 5, 9, 29, 39, 43, 4, 12!

Кара киемле. Шул 12 һаман чыга!

Лоточы. 50, 45, 54, 17, 6, 11!

Берәү. Стоп!

Кәрим. Каһәр икән, тагы шул алды!

Халык шауларга тотына.

Серый киемле. Нигә ул кадәр каты кычкырасың, әллә ишетмәсләр дип беләсеңме? Бигрәк бизабрази кыланасыз!

Берәү. Үзеңә чыкмаганга ачуың киләмени, үзеңә чыкса, үзең дә кычкырыр идең әле!

Ишектән бер дама килеп керә. Халык һәммәсе кинәттән туктап, һәммәсе дә шып булалар, һәркайсы даманы карарга башлыйлар.

Себер бае *(Дежурный янына барып)*. Серләрегез мәгълүм булды. Сезнең тавышыгызны туктатырга бер хатын кеше булса җитә икән.

Дама чыгып китә. Халык янә шауларга тотына.

Монда тагы моннан башка берәр эш буламы?

Дежурный. Рәхим итегез! Менә хәзер музыка башлана.

Икенче якта звонок була. Халык чыгып китә.

Себер бае. Аннан соң?
Дежурный. Аннан соң тагы лото уйнала.
Себер бае. Аннан соң?
Дежурный. Аннан соң, аннан соң янә музыка, янә лото.
Себер бае. Башка юк?
Дежурный. Домино уйнала.
Себер бае. Башка юк?
Дежурный. Юк.

Икенче якта музыка уйный.

Себер бае. Әйдә, алайса, киттек музыка тыңларга! Лото, домино, музыка! Лото, домино, музыка! Шул өч нәрсәне бергә кушкач, була, ди, клуб!

Чыгып китәләр.

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

БАЗАР ЧАТЫНДА

Базар чаты. Халыктан караганда уң һәм сул якта шкафлар, каршыда кибетләр. Шкаф алларында эшсез халыклар җыелып торалар. Базардан халыклар узгалап йөриләр. Уң яктагы шкафта берничә кәләпүшләр, шешәләр, тасмалар вә башка вак-төяк галантерея тартмалары күренә.

Беренче мәҗлес

Шкафчы, мөритләр, халык, соңра кәләпүче кыз.

Шкафчы *(үзенең алдына җыелган мөритләргә)*. Бик яхшы иткәннәр, бик яхшы. Мин аларга рәхмәт әйттем. Бу эшегезнең әҗерен, Алла боерса, кыяматтә күрерсез, дидем. Аларның хәрам акчаларын алып, җәмгыятьне мордар[1] ясарга ярамый, дидем. Әдәбият кичәсе, имеш! Анда авыз күтәреп җырлыйлар, ди, сөйлиләр, ди. Җыен кызыл авызлар, чыгып, скрипкә, гармун уйныйлар, ди, кочаклашып биешәләр, ди. Ул нинди әдәбият кичәсе булсын?! Анда нинди әдәп булсын? Ул әдәпсезлек кичәсе ул! Кем дә кем мөселманча итеп, менә шуның шикелле кызыл төймәле казакилар кисә, башына ак бүрек

[1] *Мордар* – шакшы.

кисә, мыегын сөннәтчә итеп кырып йөртсә, чалбар балагын озын итеп йөртмәсә, чәчен алдырса, өендә идәнгә тезләнеп, кыйблага каршы утырып ашаса, хәзрәтләр алдында тез чүгеп кенә утырса, йөргән чагында да алдына гына карап йөрсә, муллалардан алга чыгып сүз сөйләмәсә, менә шул кеше чын әдәпле кеше булыр.

Халык. Дөрес әйтәсең, мулла Әхмәтҗан, дөрес!

Шкафчы. Ул җәдитләр барысы да кяферләр алар, барысы да җәһәннәмлекләр алар!

Халык. Рәхмәт, рәхмәт!

Шкафчы. Аларның каннары – хәләл, маллары – ганимәт[1], хатыннары – талак!

Берәү. Шулай укмыни, мулла Әхмәтҗан? Анысын сез белми әйтми торгансыздыр.

Шкафчы *(прилавкага аякларын бөкләп менеп утырып)*. Аларның һичберсенең никахлары дөрес түгел. Алар динне мыскыл итеп, кыска киемнәр киеп, аякларына шиблит, башларына картуз киеп, чәчләрен-мыекларын җиткереп, кулларына әллә нинди шәйтан мөгезе шикелле таяклар тотып, ак якалар куеп, корсакларын киереп йөриләр.

Мөритләрдән берсе. Аларның муеннарына кигәннәре нәгъләт камыты инде ул, нәгъләт камыты!

Бер сала кешесе тәмәке тартып узып бара.

Шкафчы *(акырып)*. Һай, нәгъләт, ташла тәмәкеңне, ташла!

Сала кешесе илтифат итмичә узып бара.

(Урыныннан сикереп төшеп.) Ташла, дим, нәгъләт, ташла! Һи, оятсыз! *(Йөгереп барып, авызыннан тәмәкесен тартып алып, аяк астына салып таптап.)* Ничек итеп шулкадәр мөселманнар алдында, базар уртасында тәмәке тартып барасың?! *(Урынына килеп, яңадан аягын бөкләп утыра.)*

Сала кешесе аптырап карап тора да кулын селтәп китә.

Мөритләр. Менә монысы өчен рәхмәт, яхшы иттең.

Шкафчы. Шәригать әмере мәгъруф, нәһи мөнкәр кылырга[2] боерган. Әле ярый ташлады. Ташламаса, мин аның яңагына да менеп төшкән булыр идем.

Бер мөрит. Шулай шул, ник монда мөселманнарны мәсхәрә кылып бара! Әйдә, Ибраһим, чәйгә керәбез, син дә керәсеңме?

Шкафчы. Барыгыз, бар, ике дә өчне[3] әйтә торыгыз, мин хәзер кереп җитәм.

Бер кеше *(шкаф янына килеп)*. Әфәнде, миңа бер ярты дюжина гына ак яка кирәк иде.

Шкафчы *(бик коры гына)*. Юк!

Бер кеше. Мин мондагы түгел идем, кайдан табарга мөмкин булыр икән?

Шкафчы. Кит аннан, кит, кит, кит! Мин нәгъләт камыты белән сату итмим!

---

[1] *Ганимәт* – трофей.
[2] *Әмере мәгъруф, нәһи мөнкәр кылырга* – яхшы эшкә кушарга, яманны тыярга.
[3] *Ике дә өч* – сәүдәгәрләр жаргоны, «ике чәй, өч пәрәмәч» дигән сүз.

Кеше. Ник, ул нәгъләт камытымыни?

Шкафчы. Кит, дим, кит, кит! Кәсафәтең[1] йогар, кит! Сезнең шикелле динсезләр белән сөйләшәсем дә килми!

Кеше. Сез мине ни өчен мәсхәрә кыласыз? Мин ничек динсез?

Шкафчы. Җәдит син, җәдит! Аягыңа кара! Хи-хи-хи!

Кеше. Синең бар эшең, ахры, шул: кешегә көфер пичәте басып утыру гына булырга кирәк. Әйтәләр иде аны, сезнең базар чатында «Көфер почмагы» дигән җир бар, дип. Шушы икән инде, ярый, күрдек. *(Китә.)*

Шкафчы. Авызы тыгылдымы малаеңның! Хи-хи-хи-хи!

Мөритләр. Рәхмәт, мулла Әхмәтҗан, рәхмәт, шулай кирәк.

Шкафчы. Каһәр төшкән җәдит! Ак яка дип сорап ята бит! Бирермен мин ак якаларыгызны! Үзегез белән бергә ак якаларыгызны җәһәннәмгә салып яндырырмын!

Кыз *(бер төргәк кәләпүш китереп).* Абзый, кәләпүш алмыйсыңмы?

Шкафчы. Кызый үзе бик чибәр икән! Кая, китер әле, карап карыйк. *(Кәләпүшләрне карап.)* Моны үзегез эшләдегезме?

Кыз. Әйе.

Шкафчы. Апаң бармы?

Кыз. Йә, аласыңмы?

Шкафчы. Апаң бармы? Апаң булса, алам. Апаң матурмы?

Кыз. Йә инде, шаярма, алсаң ал, алмасаң бир кәләпүшләрне.

Бер мөрит. Апасы да, моңа охшаса, чибәр булыр!

Шкафчы. Апаң булса, апаңа әйт, кәләпүшләрен алмыйм, үзен, матур булса, кече хатынлыкка алам, дип әйтте диген!

Кыз. Китер инде! *(Кәләпүшләрне тартып ала.)* Лыгырдап утырасыз шунда, чүбек чәйнәп! Кәләпүш алырга әле синең акчаң юк! *(Китә.)*

Мөритләр. Ха-ха-ха-ха! Ни эшләтте кызый?

Бер мөрит. Үсеп җиткәч, бу әле әллә нинди атчайный кыз булыр!

Шкафчы. Безнең урамдагы Галим кызы ул, аталары үлгәч, кәләпүш эшли башладылар. Тутасы бик нәгыз нәрсә аның. Күкрәкләре менә болай!

Бер мөрит. Монысы да яман булмас. Бер-ике елдан таза гына хайван булыр. Хәзердән үк күкрәкләре калка башлаган!

Ике шәкерт, кыска киемнәрдән, узып баралар.

Шкафчы. Шифырт, шифырт! Итәкләрегезгә абынып егылмагыз! Һи, күмер каралары!

Шәкертләр. Лыгырдама, чухур[2]! *(Китәләр.)*

Мөритләр. Ха-ха-ха! Алай да үзең бер дә тешләми уздырмыйсың!

Бер мөрит. Мулла Әхмәтҗан ул барысын да булдыра.

Халык бар тарафтан йөгерә башлый.

---

[1] *Кәсафәт* – каралык, динсезлек.

[2] *Чухур* – сатучыларны мыскыллау сүзе.

Ш к а ф ч ы. Нәрсә бар анда? Нәрсәгә йөгерәләр?

Мөритләр ашыгып китәләр. Шкафчы да шкафына аркылы бер таяк куеп китә. Бераздан икенче шкаф янына кешеләр җыела.

Икенче мәҗлес

Юан кеше, Нечкә кеше, Сары сакал.

Ю а н к е ш е *(шкаф янына сөялеп)*. Ишеттегезме яңа хәбәр, әле менә чәй янында укыдылар.

Н е ч к ә к е ш е. Нинди хәбәр?

Ю а н. Чалма[1] Афстралияне Макидуниядән куып чыгарган икән.

С а р ы с а к а л. Аны инде беркөннәрдә үк укыдылар. Афстралия дисезме, нәрсә дисез әле, бер көн эчендә шуның җитмеш мең солдатын кырганнар, ди.

Н е ч к ә. Дөрест сүз булды микән, чалмага әгелчән пумукка бик күп солдат җибәргән икән, дигәннәр иде.

Ю а н. Юк сүз. Әгелчән нишләп солдат бирсен? Чалманың аның үз солдатлары да ничә милиунлап бар бит.

С а р ы с а к а л. Чалманың аның кораллары да бик шәп, ди. Аларда менә шушылай беләккә кия торган бертөрле мылтык бар, ди, бер минут эчендә ике йөз тапкыр ата, ди. Һичкем каршы килә алмый, ди.

Ю а н. Аларга сугышта каршы тора ала торган кеше бу заманда бер дә юк инде. Аларның туплары да бик ерактан ала, ди.

С а р ы с а к а л. Алар бит бер елны грикләрне дә ни эшләттеләр! Грикләрнең Фисалия дигән зур бер крипечләре бар икән. Ничә милиуннарга төшереп салганнар икән. Ягрупа шул вакытта әйткән иде: «Бу крипечне алты ел сугышсалар да ала алмаслар», – дип. Чалмалар шуны бер көн эчендә алдылар.

Ю а н. Чалмага каршы аңа кеше чыдый алмый инде. Бисмарк әйткән, ди: «Әгәр дә ун ел эчендә Туртсияне бүлеп алмасагыз, аннан соң пузны булыр», – дип әйткән, ди.

Н е ч к ә. Әле беркөн әгелчәннәргә каршы афганнар сугыш ачканнар, имеш, дигәннәр иде. Бу арада бер дә ул турыда хәбәрләр күренми.

Ю а н. Юк сүздер ул. Афган хәзер үк сугышмас әле, ул берничә ел хәзерләнер дә аннан соң әгелчәннәргә каршы чыгар. Афган ханы инде ул бик күптәннән бирле Һиндне алырга кыҗрый. «Ни эшләсәм дә эшлим, Һиндне алмыйча туктамыйм», – дип әйтә, ди. Афганнар да алар бик сугышчы халык. Бер тотынсалар, әгелчәннең эшен китермичә бер дә туктамаслар.

Н е ч к ә. Әле соң япун ни эшли, япун?

Ю а н. Япунның эше шәп аның. Япунның патшасы Микаду мөселманлыкка чыгарга юл эзли икән, ди. «Әгәр дә Чалма риза булса, мин бөтен гасударствам белән мөселманлыкка чыгар идем», – дип әйтә икән, ди.

С а р ы с а к а л. Япун патшасы инде ул үзе күптән мөселманлыкка чыккан, ди. Бары тик әле халкын мөселман итә алмаганга гына аптырый, ди.

---

[1] *Чалма* – Төркия күздә тотыла.

Н е ч к ә. Юк сүзләр. Патшасы үзе мөселман булгач, аның халкын мөселман итәргә көче җитмәс идемени?

Ю а н. Юк, тора тор әле, алай бик тиз генә булмый ул. Халык ул приказчик түгел. Бу заманда инде прикащиккә дә тиз генә сүз тыңлатып булмый. Әле менә прикащикләр: «Кибетләр иртә белән сәгать сигездә ачылсын да, кич белән сәгать җидедә ябылсын», — дип йөриләр. Атнасына бер көн кибет ябылу гына җитмәгән, аның өстенә син тагы кибетне дә иртә яп. Хәзер инде байлар хуҗа түгел, прикащикләр хуҗа. Әүвәлге заманнарда без салкын кибеттә иртә белән сәгать биштән башлап кара төнгә кадәр сату итәдер идек, алай да байга тиз генә ярап булмыйдыр иде.

С а р ы с а к а л. Алар шул хәзер клубка барып гуләйт итәргә өйрәнделәр инде. Төне буена клубта утыралар да аннан ары көн буена аңгы-миңге килеп йөриләр.

Н е ч к ә. Губернаторга әйтеп, аларның клубларын яптырырга кирәк иде.

Ю а н. Бик күп йөреп карадык инде. Булмый, ди. Әле менә бу көн әллә нинди кәмит ясыйлар икән. Аны ясатмаска кирәк дип, пристефкә барган идек, анда закунга каршы килә торган бернәрсә дә булмагач, без тыя алмыйбыз, диде. Ул бит безнең шәригатьтә дөрес түгел, дигән идек, дөрес булмаса, бармассыз, ди.

С а р ы с а к а л. Карга карганың күзен чыгармас, ди. Алар инде аңа шатланалар гына.

Өченче мәҗлес

Ш у л а р у к һәм Ш к а ф ч ы, м ө р и т л ә р, соңра Ш к о л ь н и к[1], М у ж и к, С е б е р б а е, Я у ч ы, к е ш е в ә х а л ы к.

Шкафчы, килеп, аягын бөкләп утыра. Аның артыннан мөритләр дә киләләр.

Ш к а ф ч ы. Бик яхшы иттеләр. Этнең бәддогасы төшсә, бөтен кеше һәлак булып бетәр иде.

Б е р м ө р и т. Бервакытны шулай Истанбулда бер солтан урамдагы этләрне җыярга кушкан. Шәһәрдәге бар этләрне җыеп, бер атауга илтеп ташлаганнар. Шуннан соң, этләрнең күз яшьләре тотып, шәһәрдә халык кырыла башлаган. Бик каты ачлык булган. Шуннан соң солтан, тәүбә итеп, этләрне кире кайтарткан. Авыру да беткән.

Ш к а ф ч ы. Этләрне бер дә бирергә ярамый. Мин һәрвакытта, эт тотучылар килсә, этләрне качырам. Эт үтерсәң, аның афәте бик зур була.

Теге шкаф алдындагы кешеләр дә җыелалар.

Ю а н. Нихәл, анда нәрсә бар иде? Халык ни эшкә җыелган?

Ш к а ф ч ы. Эт үтерүчеләр килгәннәр. Күмәчче Галәвинең этен тотып алып китәләр дигәндә генә, көчкә генә сызгырып котылдырып калдык. Эт үтерүчеләрнең бөтенләй ачулары кабарды.

Б е р м ө р и т. Кабармый ни, алар бит акчаны эт башыннан алалар. Мулла Әхмәтҗан, син сызгырып бик яхшы иттең. Ахирәттә аның өчен сиңа зур әҗер булыр.

И к е ш к о л ь н и к узып бара.

---

[1] *Школьник* — махсус киемнән йөрүче Татар укытучылар мәктәбе (Татарская учительская школа) укучысы.

Шкафчы *(испәштергәләп)*. Фу, колак исе чыга. Мәскәү яна!

Юан. Нихәл, егетләр, җилән кысмыймы?

Школьник. Не лай, собака!

Керер китәләр.

Шкафчы. Менә шулар инде бөтен дөньяны каралтып бетерүчеләр, динсезләр. Боларның кырыгына бер иман да юк инде!

Бер яктан бер Мужик бер тире күтәреп килә. Аның каршысына икенче яктан биш-алты кеше, йөгереп килеп, һәммәсе дә тирегә ябышалар.

Берсе. Ничә тиен?

Мужик. 1 сум 30 тиен.

Берсе. Башыңа капла, әйдәгез, әйдә, сатарга китермәгән ул!

Китә башлыйлар. Бер читтә Себер бае белән Яучы килеп чыгып карап торалар.

Мужик. Соң, күпме бирәсез?

Берсе. 70 тиен!

Мужик. Юк, алай ярамый.

Берсе. Ну, 75 тиен.

Мужик. 1 сум 10 тиен.

Икенчесе. Әйдәгез, әйдә!

Берсе. Ну, 80 тиен.

Мужик китә.

Ну, 90 тиен.

Мужик. Бирегез акчагызны.

Берсе акча чыгарып бирә. Тирене алалар да керер китәләр.

Себер бае. Алар ни эшлиләр?

Яучы. Тире алалар.

Себер бае. Ничә мең тире?

Яучы. Юк, бер генә.

Себер бае. Нигә соң бер тирегә ул кадәр җыелганнар?

Яучы. Бездә шулай инде: берсе ала да, калганнары файданы бүлешәләр.

Себер бае. Шәп икән! *(Шкафны күрсәтеп.)* Ә монда халык ни эшкә җыелган? Әллә бу сезнең биржагызмы?

Яучы. Юк, биржа түгел, бу – безнең шәһәрнең могтәбәр кешеләре җыела торган җир.

Себер бае. Анда соң алар ни эшлиләр?

Яучы. Анда төрле сүзләр була.

Себер бае. Әйдә, алайса, без дә барып тыңлап торыйк әле. Берәр файдалы сүз ишетербез.

Киләләр.

Әссәламегаләйкем!

Шкафчы. Вәгаләйкемәссәлам сәламен дә, сезгә ни кирәк? Әгәр ак яка кирәк булса, миндә юк, йөрмәгез!

Мөритләр. Ха-ха-ха-ха!

Себер бае. Ник алай дисез?

Шкафчы. Чүлмәкнең тышыннан билгеле. Җәдит икәнлеге әллә кайдан күренеп тора!

Себер бае. Җәдит булгач ярамыймыни? Сез җәдитләргә әйбер сатмыйсызмыни?

Шкафчы. Кит аннан! Кит, кит, кит! Без андый паганый маллар белән сату итмибез.

Себер бае. Хәерле булсын! *(Китә. Яучыга.)* Сезнең могтәбәр кешеләрегез шулармыни инде?

Яучы. Шулармыни дип, болар гына түгел инде, әле монда барысы да җыелып җитмәгән.

Себер бае. Сезнең монда бөтен дөньяга исеме җәелгән «Көфер почмагы» дигән чатыгыз кайда? Килгән көе ул чатыгызны да күреп китик инде.

Яучы. «Көфер почмагы»?

Себер бае. Әйе, узган-барганга эт шикелле өреп кала торган бер почмак бар, диләр иде.

Яучы. Белмим, ул кайсы булыр икән тагы? Аны инде җәдитләр әйтә торганнардыр.

Себер бае. Дөрес, укыганрак яшьләр авызыннан ишеткән идем.

Яучы. Алай булса, шул чатны әйтә торганнардыр инде, монда башка андый чат юк.

Себер бае. Алай булса, бераз сабыр ит әле, шунда кайда булса да сүзләре ишетелә торган бер урынга барып тыңлап утырыйк әле.

Яучы. Ярар.

Бер җиргә утыралар.

Шкафчы. Каһәр суккан нәрсә! Бүген икенче җәдит инде ак яка сорап мыскыл итеп килде.

Сары сакал. Ул ак яка сорамады ич!

Шкафчы. Сорамаса да билгеле инде. Аның башка нәрсә сорау ихтималы юк.

Бер мөрит. Кем соң ул?

Шкафчы. Чурт белә аны! Әфтәх каян килеп ияргән тагы ул җәдиткә?

Бер мөрит. Ә, беркөнне сөйләгәннәр иде, Себердән бер бай өйләнергә килгән, Әфтәх яучы булырга йөри икән дип. Шул нәрсәдер инде, алайса.

Шкафчы. Ә, шул нәгъләт икән инде, алайса, шул! Бая Фатих әйткән иде, бик кызык иттек, дип. Өченчекөн шул динсез җәмгыятькә кергән, анда теге тар балаклар, әдәбият кичәсе ясыйбыз, файдасын җәмгыятькә бирәбез, дип, прашиния биргәннәр икән, бу динсез шунда яшьләрне яклап утырган була, ди. Фатихлар бик яхшы иткәннәр, моның авызын каплаганнар.

Бер мөрит. Рәхмәт аларга, бик яхшы иткәннәр.

Европача киенгән бер кеше таяк тотып узып бара.

Шкафчы. Менә тагы бер җәдит! Шайтан чакырып, таягыңны селкеп йөрмә монда!

Җ а д и т *(туктап)*. Нәрсә дисең?

Ш к а ф ч ы. Исәнме, дим, исән торасыңмы, дим!

М ө р и т л ә р. Ха-ха-ха-ха! *(Көләләр.)*

Җ а д и т. Авызыңа телең сыймыймы әллә? Нәрсә лыгырдаган буласың? *(Килә башлый.)*

Ш к а ф ч ы *(урыныннан сикереп төшеп)*. Кит аннан, кит! Кит, кит! Кәсафәтең йогар, кит! Син кяфер, мордар!

Җ а д и т *(китә-китә)*. Һи, хәбис[1], зверь!

Ш к а ф ч ы *(артыннан бара-бара)*. Кяфер сез, кяфер! Хи-хи-хи!.. *(Туктый.)*

Җ а д и т. Синең шикелле урам этләре бөтен урам буена өреп бара торганнар иде, әле син ул кадәр үк булдыра алмыйсың икән! Һи, падлис! *(Китә.)*

С е б е р б а е. Утыру бушка китмәде. Бер картинаны күрдек.

Ш к а ф ч ы *(урынына килеп, аягын бөкләп утыра)*. Ул җәдитләрнең бар эшләгән эшләре хәрам, ашаганнары хәрам, эчкәннәре хәрам, йөргәннәре хәрам, торганнары хәрам, өсләренә кигәннәре хәрам!

С е б е р б а е *(халыкка карап)*. Ә адәм ите чәйнәү, көн буе гайбәт сатып утыру анысы хәрам түгел!

Бер кеше шкаф янына килә.

К е ш е. Кая, миңа бер мыскал гына дару бир әле.

Ш к а ф ч ы. Ниндине бирим, укмаштырганы булсынмы, бармаклысымы?

К е ш е. Бармаклысын бир.

Шкафчы чыгарып бирә, акчаны алып сала.

С е б е р б а е. Ул кеше дару белән сату итәмени?

Я у ч ы. Итә.

С е б е р б а е. Кара син аны, үзе кадим булса да, аптик тота икән. Мин мөселманнан аптикче юктыр дип беләдер идем.

Я у ч ы. Юк, ул аптикче түгел.

С е б е р б а е. Соң ул нинди дару сата?

Я у ч ы. Дару дип инде, дару түгел. Кеше белмәсен өчен аны шулай дип әйтәләр.

С е б е р б а е. Нинди нәрсә соң ул?

Я у ч ы *(Себер баеның колагына гына)*. Әфиун ул, әфиун. Палитсә белмәсен өчен, аны шулай дару дип әйтәләр.

С е б е р б а е *(халыкка карап)*. Шәп икән! *(Яучыга.)* Соң ул хәрам түгелмени?

Я у ч ы. Ул ни эшләп хәрам булсын! Ул бит аракы түгел, хәрам булса, аны ишан хәзрәт тыяр иде. Ишан хәзрәт аны бик шифалы нәрсә ди. Әледән-әлегә мулла Әхмәтҗаннан берәр кадаклап алдырта. Бу кеше ишан хәзрәтнең бик якын кешеләреннән.

С е б е р б а е. Соң ул исертмиме?

Я у ч ы. Юк, аның һич тә исе сизелми, аны борчак кадәрле генә кабып, артыннан чәй эчеп җибәрсәң, бөтенләй күз аллары яктырып китә. Әле аның тагы икенче бертөрлесе, мәгъҗүн[2] дигәне бар. Анысын ишан хәзрәт үзе җитмеш җиде төрле ши-

---

[1] *Хәбис* – пычрак, шакшы.
[2] *Мәгъҗүн* – наркотик.

фалы нәрсәләрдән ясата. Әгәр инде анысын бер балкашык кабып, чәй эчеп җибәрсәң, бөтенләй бу дөньядан кичәсең. Ахирәт күз алдына килә.

Себер бае. Хур кызлары да күзгә күренәләрме?

Язучы. Әй, син бигрәк инде, арттырып җибәрә башладың.

Шкафчы. Син теге җәдитне монда өйләнергә килгән дисеңме?

Бер мөрит. Әйе, өйләнергә килгән, ди. Укымышлы, урысча да, мөселманча да яза белә торган кыз булсын дип әйтә, ди.

Юан. Андый кыз кирәк булса, мәткә алыр!

Шкафчы. Үзе шикелле татар марҗалары бетмәс әле!

Мөрит. Кызны күреп алам, үзе күренмәсә, патритен күрсәм дә ярый, дип әйтә, ди.

Шкафчы. Сурәтне төшерүче дә, төшертүче дә — икесе дә кяфер!

Сары сакал. Сурәт төшерткән кызны алучы? Монысының да аннан артык җире юк!

Ул арада урамның бер башыннан халык йөгерешеп чыгалар. Кибетләрдән дә ак алъяпкыч япкан кибетчеләр, кайсы себерке, кайсы щётка күтәреп, йөгерешеп чыгалар.

Шкафчы. Күсе тотканнар, күсе!

Сикереп төшеп, себерке күтәреп йөгерә, аның артыннан мөритләр дә йөгерәләр.

Тавыш. Ычкындырма, нык тот! Бәр себерке белән! Өстенә бас! Башына бәр, башына!

Үтерәләр. Берсе койрыгыннан җеп белән өстерәп китә. Көлешәләр.

Шкафчы *(килеп, себеркесен куя)*. Әйдәгез, инде чәйгә керик.

Китәләр.

Себер бае. Ярый, моны да күрдек. Шәһәрегезнең шәп кешеләре эт булып өреп калу белән генә канәгатьләнмиләр, мәче булып күсе дә тоталар икән! Әйдә, киттек.

Китәләр.

Читтән тавыш. Кайда куясы бу шәп гарчицаларны?

Икенче бер тавыш. Үзең аша!

Пәрдә.

БИШЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

ӘДӘБИЯТ КИЧӘСЕНДӘ ҖӘНҖАЛ

Бакча сценасы ясалган.

1 нче номер

Мәшһүр скрипач сәхнәгә чыгып башын ия. Скрипкада «Ашказар» көен берничә мәртәбә уйный. Халык кул чаба. Скрипач чыгып башын ия. Яңадан «Тәфтиләү» көен уйный. Халык янә кул чаба. Скрипач, яңадан чыгып, җиңел бер көй уйный. Халык кул чаба.

2 нче номер

Рассказчы Фәләнев уйнаячак. Халык көтә. Ул арада партерда тавыш күтәрелә. Уртачарак киенгән киң сакаллы берәү европача киенгән яшь бер адәмгә бәйләнә.

Киң сакал. Урын беткәнмени сиңа, нәрсәгә монда кеше хатыны янына килеп утырасың?

Яшь егет. Әфәндем, бит минем урыным шушы. Менә билетым!

Киң сакал. Менә билетым, менә билетым! Чурт кушканмы сиңа монда кеше хатыны янына билет алырга?

Яшь егет. Әфәндем, мин бит белеп алмадым. Минем янымда кем утырасын мин кайдан белим?

Киң сакал. Әфәндем, әфәндем дигән булып, тагын монда кеше мыскыл иткән була! Син үзең дә әле күптән түгел генә әфәндем идең әле!

Яшь егет. Ай Алла, абзыкаем, мин бит бу турыда бер дә гаепле түгел. Минем урыным шулай туры килгәч, мин ни эшлим?

Киң сакал. Килгән, килми ни!

Билет караучы *(болар янына килеп)*. Әфәнделәр, ни бар? Акрын гына утырсагыз ла, тавышланмасагыз ла!

Киң сакал. Тавышланмагыз дигән була тагы! Нигә монда кеше хатыны янына ир кеше китереп утыртасыз?

Билетчы. Аны бит без утыртмаган, үзе утырган.

Киң сакал. Әнә әйттем бит син үзең утырган, дип!

Билетчы. Ялгыш әйттем, аның билеты шулай инде, сезнең яныгызга туры килгән.

Яшь егет. Бу турыда мин гаепле түгел, әфәндем.

Киң сакал. Тик тор, синнән сорамыйлар! *(Хатынына.)* Әйдә, утыр менә бу якка! *(Хатынын үз урынына утыртып, үзе яшь егет янына утыра.)* Син шул, әйдә алып бар, анда бик күңелле була икән дип алып килдең! Булды менә монда күңелле! Булмый ни! Сиңа монда, яныңда яшь егетләр утыргач, күңелледер шул! *(Билетчыга.)* Нәрсә монда тагы кеше хатыны каршысына килеп калкынып торасың? Әллә хатын күргәнең юкмы? *(Хатынына.)* Капла битеңне! Син монда егетләргә күренер өчен дип килгән икәнсең!

Хатын. Әй, сиңа әйтәм, кеше алдында, алай бөһтаннар[1] ягып, мине харап итмә инде! Кеше арасында көлке булабыз ич!

Киң сакал. Көлке, көлке, син үзең көлке! Мине монда кеше арасында көлкегә калдырдың! Әнә һәммә кеше безгә карап көлеп тора!

Билетчы. Әфәнделәр, зинһар, тавышланмыйча гына утырсагыз ла. Хәзер икенче номер башлана.

Киң сакал. Башлансын, пычагыма да хаҗәте юк! Әйдә, тор, хатын! Минем монда җыен ир-ат арасында сине утыртыр хәлем юк! Һәммәсенең күзләре тоз булган, безгә карап утыралар. *(Тора.)* Әйдә, әйдә, капла битеңне! Сөртенеп егылма!

Чыгып китәләр. Рассказчы чыга. Урта бер җиргә туктый, сөйли.

---

[1] *Бөһтан* – яла.

Хатыннар хөррияте[1]

Рассказчы.

— Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатыннарга,
Бөтен фикрем, уем шулдыр, карамый көн вә төннәргә.
Бу уйдан кайтасым юктыр, әгәр канлы сугыш булса,
Хатыннар ирке угърында[2] үләрмен мин, үлеш булса.
Хатыннар! Атлагыз алга! Бу юлда шаула, матбугат!
Хатыннарны кысучыларга каршы ач сугыш, ук ат!
Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга!
Яшә, и галәме өнса[3]! Вакыт хакларны аңларга!
Таралырга вакыт инде чапан атлы болытларга;
Чапаны да, Бохары да ашарга калсын этләргә!
Алар да, ир кеби, шаһлык, хәкимлек[4] намнарын[5] таксын!
Хатыннан көч тәрәкъкый бәхренә[6] күл-күл булып аксын!
Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкаддәс яртыбыз безнең!
Кеше булмак өчен иң-иң беренче шартыбыз безнең!

*

— Эшем бар бит, хатын, тиз булсана, бирсәңче чалбарны!
Бу тапланган икән; бир, яхшысы һәм тапсызы бармы?
Кара, монсы да тапланган, дидем бит, таплары бетсен!
Шуны чистартмагансың: җә, хатынмы син? Сыер бит син!

Халык кул чаба. Рассказчы кереп китә. Дирижёр сәхнәгә чыга.

Дирижёр. Әфәнделәр, программада «Мәшһүр җырчы Адамантов җырлаячак» дип язылган булса да, ул, авыру булган сәбәпле, килә алмады. Шул сәбәптән без аның урынына шәһәребезнең мәшһүр музыка һәвәскәрләрен чакырдык. Хәзер 3 нче номер — җырчы Адамантов урынына милли музыка һәвәскәрләреннән ясалган оркестр уйнаячак.

Сәхнәгә урындыклар тезә башлыйлар.

Партердан берәү. Далуй, далуй, кирәк түгел безгә аркистр, далуй! Безгә Адамантов җырласын!

Дирижёр. Әфәнделәр, шауламый гына утырсагыз ла, әдәбият кичәләре яңа бер эш булганга күрә, безнең халкыбыз, ахры, төшенеп җитә алмый торгандыр.

Партердан икенче берәү. Дөрес! Афәрин!

Партердан берәү. Далуй! Далуй! Кирәк түгел безгә аркистр! Далуй! Безгә Адамантов җырласын! Без башканы тыңламыйбыз! Кирәк түгел!

---

[1] Шагыйрь Габдулла Тукаев әдәбиятыннан. *(Г. Камал искәр.)*
[2] *Угърында* — юлында.
[3] *Галәме өнса* — хатын-кыз дөньясы.
[4] *Хәкимлек* — философлык.
[5] *Нам* — исем.
[6] *Тәрәкъкый бәхренә* — прогресс диңгезенә.

Партердан икенче берәү. Кирәк булмаса, бар, чык та кит! Нәрсә монда кычкырып утырасың?

Партердан берәү. Чыкмыйм мин. Миңа Адамантов кирәк! Адамантов җырласын! Аркистр кирәкми!

Дирижёр. Әфәндем, әйттек бит инде мөмкин түгел дип. Адамантов авырый. Шул сәбәптән аның чыгуы мөмкин түгел.

Партердан берәү. Ул булмаса кирәкми! Башка кеше җырламасын!

Партердан икенче берәү. Дирижёр әфәнде, нәрсәгә ул кешене сөйләтеп торасыз? Аның өчен монда никадәр кеше тәшвишкә төшә. Чыгарыгыз да җибәрегез үзен!

Партердан берәү. Мин ни эшләп чыгыйм? Мин дә монда синең шикелле тыңларга килгән!

Партердан икенче берәү. Чыкмаса, полиция белән чыгарыгыз! Нәрсәгә монда тавыш ясап утыра?

Дирижёр. Әфәндем, монда алай тавыш чыгарып, халыкның кәефен җибәреп утырмагыз! Тыңлыйсыгыз килми икән, билет акчагызны кире кайтарып алыгыз да яхшылык белән чыгып китегез!

Партердан берәү. Билет акчасын?!

Дирижёр. Әйе, билет акчасын кире кайтарып алыгыз да чыгыгыз!

Партердан берәү. Һә, алай икән! Мин аны сездән бигрәк яхшы беләм.

Дирижёр. Соң ник чыкмыйсыз, ник кешене көттерәсез?

Партердан берәү. Соң, соң! Минеке бит билет түгел, кантрамарка!

Дирижёр *(көлеп)*. Алай икән! Аны каян алдыгыз?

Партердан берәү. Адамантов бирде. Мин җырлагач, бик каты кул чабарсың, диде. Ә үзе монда килмәгән!

Дирижёр. Алай булгач инде, сез акча алмыйча гына чыгып китегез!

Партердан берәү. Юк инде, туганкаем, мин чыкмыйм! Ярый инде, аркистр булса да ярый, тыңлыйм!

Дирижёр китеп китә.

3 нче номер

Оркестр бер-бер артлы берничә мәртәбә уйный. Халык кул чаба. Кереп китәләр. Алар кереп китүгә, ишектән картрак бер кеше керә дә әрле-бирле йөри башлый, урындыклар арасыннан бер алга, бер артка таба бара.

Карт. И Ходаем, и Ходаем! Бар икән күрәселәрем! Шәһәрдә бер дә акыллы кеше калмаган икән инде! Кара инде боларны?! Бары да ахырзаман галәмәтләре! Әхмәди, Әхмәди, кая син? Тиз чык, йөзең кара булган нәрсә! Кая минем углым, кая качырдыгыз? И оятсыз, оятсыз, оялмыйча мәзингә кадәр килгән бит! Кая куйдыгыз минем углымны? Ник берегез дә эндәшмисез? Һәммәсе бергәләшеп минем углымны качырганнар! Җитмәсә тагы, авызларын җырып көлеп торалар!

Яшь егет, урыныннан торып, кача башлый.

Ә, әнә, әнә, кая качасың? Әллә артыңнан җитмәс дип беләсеңме? Мин синең якаңнан өстерәп алып кайтырмын! *(Артыннан бара башлый.)*

Б и л е т ч ы. Әфәндем, сезгә ни кирәк?

К а р т. Кит аннан, Ходай органнар, кит! Минем улгымны аздырырга керешкән икәнсез! Мин аңа, өйгә кайткач, күрмәгәннәрен күрсәтермен әле.

Б и л е т ч ы. Абзый, монда андый тәртипсезлекләр ясап йөрмәгез!

К а р т. Кит аннан, кызыл авыз, кит! Мин сезнең барыгызны да аталарыгызга әйтеп кирәгегезне бирдерермен әле!

Яшь егет кулиса[1] артына кача. Карт та артыннан кереп китә.

Качма, качма, миннән качып котыла алмассың, мин сине алып кайтмыйча калмыйм.

Я ш ь е г е т сценага килеп чыга. Аның артыннан к а р т та сценага килеп чыга, яшь егетнең колагыннан тота.

Һи, оятсыз, оятсыз! Оялмыйча, миннән рөхсәтсез-нисез син монда килеп йөрергә! Әйдә өйгә!

Яшь егетне өстери. Д и р и ж ё р вә б а ш к а б е р н и ч ә к е ш е, сценага кереп, картның кулыннан егетне коткарырга тырышалар.

С ц е н а д а г ы к е ш е л ә р. Бабай, бабай, бу ни эшегез бу? Монда андый тәртипсезлек чыгарырга ярамый. Әйдә, чык моннан! Үзе дә кайтыр. Барыбер инде уен бетте. *(Картның кулыннан егетне коткаралар.)*

К а р т *(халыкка карап, җылаган тавыш белән)*. Ягез инде, җәмәгать, әйтегез инде, мин ни хәл итим инде? Ни эшлим инде бу бала белән?! Шулай ук инде, актык улгымны да кулымнан алып, мине мәхрүм итеп калдырасызмыни? *(Җыламсырый.)* Тычканга үлем, мәчегә көлке, ди. Җитмәсә тагы, сез авызыгызны җырып көлеп торасыз! *(Чыгып китә.)*

С е б е р б а е *(ложадан)*. Җәмгыятегездә — җәнҗал, ресторанда — җәнҗал, клубыгызда — җәнҗал, базарыгызда — җәнҗал, әдәбият кичәгездә дә җәнҗал! Булмас, ахры, өйләнмим мин! Хуш, сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*

Музыка марш уйный.

П ә р д ә.

1911

---

[1] *Кулиса* — сәхнә арты.



«Безнең шәһәрнең серләре» пьесасының 1913 елда Казанда чыккан беренче басмасы (тышлыгы)

Җәмгыяте хәйриядә җәмгыять файдасына театр уйнату хакында мәҗлес. «Яшен» журналы карикатурасы

Шкафчы Әхмәтҗан – Касыйм Шамил

«Шәрекъ клубы»нда лото-котель уеннары. «Ялт-йолт» журналы карикатурасы

Галиәсгар Камал әфәнде татар тормышының начар җирләреннән көлүендә дәвам итә. Ул бу елларда мөтәхассыйс драматург кыяфәтенә кереп бара. Бер-бер артлы әсәрләре агыла. Сәхнәдә һәрбере кулъязмадан ук куела башлый, туктаусыз бара бирә. Ул быел үзенең «Безнең шәһәрнең серләре» белән бөтен дөньяны көлдерде.

Галимҗан Ибраһимов

Күрең кызыл кодрәтен,
Белсен, диеп, куәтен,
Совет җөмһүриятен
Нинди күрекле кыйлдыя.

Байлыкларның ни барын —
Урман, кыр һәм суларын,
Йорт-җирләрнең зурларын
Халык милке кыйлдыя.

Халыкларны кыйлды азат,
Буржуйлар китте назад,
Алпавыттан һичбер зат
Калдырмады, тидия.

Байга юк һичбер кадер,
Алдында аның — кабер,
Эшче дөньясы хәзер —
Хуҗа шулар, тидия.

Бай, алпавыт яки поп,
Аксөякләр хәзер юк;
Һәммә кеше бертигез —
Серый шинель кидия.

Солдатка элек ярлы
Кешеләр генә барды,
Байлар котылып калды
Оборонда, тидия.

Хәзер котыла азы.
Буржуй да окоп казый
(Ягъни сугышлар базы)
Тирән итеп, тидия.

Байлар бик күп йөрделәр,
Төрле рәхәт сөрделәр,
Бу көннән соң эшче йөрер
Дышлаларда[1], тидия.

Бай бик тәкәббер иде,
Карамады мужикка,
Инде ул килә ишеккә
Икмәк сорап, тидия.

Байның эше күңелсез:
Байлык булган гомерсез;
Бу көннән соң күрерсез
Нужаларны, тидия.

Ята алмассыз эшсезгә,
Без табарбыз эш сезгә,
Булмас җәбер көчсезгә
Бу көннән соң, тидия.

Ярлы — эшнең башында,
Буржуй аның кашында[2]
Күтәрә алмый башын да —
Җиңелде шул, тидия.

1918

---

[1] *Дышла* (дышло) — бер тәртәле арба, фаэтон.
[2] *Кашында* — «каршында» сүзенең революциягәчә шундый язылышы да булган.

Беленеҙ Совет берлеген,
Күңелләрнең көрлеген,
Нык иттереп өрлеген,
Нигез кордык, бәдәвам.

Хәзер кадер малга юк,
Буржуага сан да юк,
Суга сусаган да юк,
Һәркем тигез, бәдәвам.

Буржуй Бәдигъ Җәмалы,
Эшченең Гөлҗәмалы, –
Барсының да чамалы
Өст-башлары, бәдәвам.

Түш киермәк байга юк,
Шикәр дә юк, май да юк;
Кара икмәккә һәркем тук
Бер чамада, бәдәвам.

Бездә түгел[1], һәр җирдә
Эшче халыклар бергә
Тырыша көн күрергә
Рәхәтлектә, бәдәвам.

Рус, татары, болгары,
Немец, французлары –
Ярлы халыкның бары
Берләшүдә, бәдәвам.

Берләшә ярлы халык,
Бай бара астка калып,
Җыгылыр беркөн арып,
Бара торгач, бәдәвам.

Эш кемнәрнең кулында
Булса – барыр юлында
Булыр беренче урында.
Бара торгач, бәдәвам.

Менәр эшнең башына,
Ходка китәр машина,
Карамый тау-ташына,
Алга китәр, бәдәвам.

Бу көн «бай» дип мактанган,
Акча өстенә атланган.
Байыйм диеп шатланган
Хур булачак, бәдәвам.

Байлар кerә гүренә,
Эшче утыра түренә, –
Һаман шулай күренә
Һәрбер эшләр, бәдәвам.

Бай акча өчен жылый,
Чөнки ул – акча колы:
«Калам бит инде коры
Кул белән», – ди, бәдәвам.

Көн-төн ул дога кыла,
Төрле планнар кора,
«Яхшы» булмакчы була.
Байлык торса, бәдәвам.

Ләкин аның догасы
Һич юк кабул буласы.
Гомер буе ул гасый[2]
Булып килде, бәдәвам.

Җәберләнде күп кеше,
Талау иде бар эше,
Жылаганда ач кеше,
Көлеп торды, бәдәвам.

Эшче алдында торса,
«Ачмын!» – диеп аһ орса,
Кылды аны мәсхәрә:
«Ялкау син!» – дип, бәдәвам.

[1] «Бездә генә түгел» мәгънәсендә.
[2] *Гасый* – гөнаһлы.

Ярлыларга төкерде,
Белмәстәй булып йөрде,
Көне-төне йөгерде
Мал артыннан, бәдәвам.

Шампан шәрабын эчеп,
Аулакта кызлар кочып,
Яхшатлар белән очып,
Типтереп йөрде, бәдәвам.

Бирми бер тиен фәкыйрьгә,
Кермиләр трактирга,
Китәләр ерак җиргә
Шыпырт кына, бәдәвам.

Кеше алдында бик суфи,
Көн дә биш намаз укый;
«Бары тик тәмле йокы
Кыз катында», бәдәвам.

Хатыны булса да өч,
Җитә иде асрарга көч
Берничәне «болай гына»
Чит фатирда, бәдәвам.

Рәхәт гомер сөргәндә,
Җәннәтләрдә йөргәндә,
Мал файдасын күргәндә,
Эш таралды, бәдәвам.

Большевик килде чыгып,
Алды бар малны сыгып,
Үзен дә куйды тыгып
Чыкмас җиргә, бәдәвам.

Килеп җитте кыямәт,
Сизелде һәр хыянәт,
Инде ялган дианәт[1]
Файда бирми, бәдәвам.

«Мин бай» диеп йөргәне,
Ярлылардан көлгәне
Үз башына булганы
Күрнә инде, бәдәвам.

Шәп сарайлар гүр булды,
Ишек каты түр булды,
Бай абзыйлар хур булды,
Ахры, бер көн, бәдәвам.

Байга үләргә генә,
Безгә көләргә генә,
Малын бүләргә генә
Калды инде, бәдәвам.

1918

[1] *Дианәт* – динлелек.

ТАТАРГА

Юкка уздырма көнеңне юк кына гайбәт белән.
Кулда бар көч, эшлә дә тап, эшлә зур гайрәт белән.

Ташла кеше җилкәсе өстеннән ашауларыңы.
Бергәләп бар, калма артка, син дә алгы рәт белән.

Ташла ансат юл белән күп мал җыю уйларыңы.
Аша эшләп, юкка йөрмә, селкетеп буйларыңы.

Ал кулыңа эш коралын да тырыш хезмәтеңә,
Ик иген, күрсәт һөнәр яки көт куйларыңы.

Уйлама, күп акча җыеп, салырым дип ташпулат,
Яки, бикә берлә утырып, җигеп йөрергә туры ат.

Тук булып, иркен тору һәм шулай авылдадыр:
Шунда тырыш, шунда эшләсәң, салырсың син зурат[1].

Тынма, эшлә, тынма, тырыш, булма, туган, аксөяк,
Эшләмиче тик ятучы селкетә алмасияк.

1919

---

[1] *Зурат* – озынча кибән.

ЯҢА «БАШМАК» КӨЕ

Башмагымның башы башка,
Аерылды эләгеп ташка,
Киярлек түгел — чыгарып ташла,
Бирче яңа башмагымны.

Башмак башы тишек була,
Тишегеннән тузан тула,
Күн табылса, җамап була,
Төзәтеп бирче башмагымны.

Башмак башы каерылган,
Олтаны да аерылган,
Нишлим икән, Ходай орган!
Биреп торчы башмагыңны.

Үкчәсе дә булган агач,
Ике кидем микән алгач,
Тагы алсам, калам бит ач,
Нишләтим бу башмагымны?

Башмак башы чиккән була,
Тегелүе читтән була,
Шуңар күрә тиз җыртыла,
Бирче таза башмагыңны.

Бу эшкә хәйран калырлык,
Олтаны кәгазь калынлык,
Акча юк бит тагы алырлык.
Юкка кидем башмагымны.

Башмак башы күтәрелгән,
Ахрысы, нык бәрелгән,
Тишелеп чыккан төпләреннән,
Кызганам шул башмагымны.

Җыртыгыннан җилләр уйный,
Җыртылган бит буйдан-буйлый,
Дивана булам уйлый-уйлый,
Нишләргә бу башмагымны?

Башмак башы бик зур тишек,
Әйтерсең лә ачык ишек,
Киярга инде буны ничек,
Мә, ал кире башмагыңны!

1921

ЯҢА ӘСӘРЛӘР

(«Мирза кызы»)

Әдибе мөхтәрәм Фатих әфәнде Кәримевнең беренче язылган әсәрләреннән улан бу хикәя буннан берничә еллар мөкаддәмдә[1] оренбурглы Шәрәфетдин Шәһидуллин тарафыннан нәшер ителгән әһали исламия[2] календарена дәреҗ ителмеш[3] иде. Ләкин ул календарь халык арасына күп таралмадыкыннан, бу гүзәл әсәрне күрү күп кенә кешегә мөяссәр[4] булмагандыр. Ушбу көннәрдә бу әсәр, яңадан китап шәкелендә табгы ителеп, Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан нәшер ителде.

Бер бакчачы егет илә мирза кызының мөнәсәбәте гыйшкыяларыны тасвирдан гыйбарәт булган бу хикәя, Кырым мирзаларындагы дворян булмаган кешеләргә тәхкыйрь нәзары илә[5] карау кеби начар гадәтләрне тәмамилә бәян итәрәк, бу гадәтнең файдасызлыгыны җанлы уларак әнзаре галәмгә[6] күрсәтәдер. Бу хикәядә, гәрчә Кырым мирзаларыннан бер генә кешене тасвир ителгән булса да, бундый гадәтләр һәр җирдәге мирзаларда бер төрледер. Шул сәбәптән һәркем өчен дә моталәгә[7] итеп чыгу истифадәле[8] вә гыйбрәтледер. Лисан җәһәтенә[9] канча[10] Фатих әфәнденең лисаныны тәгъриф итәргә[11] хаҗәт юкдыр. Гүзәлдер.

Фәкать шул кадәресенә тәәссеф ителәдер ки, Фатих әфәнде гүзәл бер каләмгә малик[12] улдыгы хәлдә бундый әсәрләр язудан бу елларда бөтенләй тукталып китте.

Рисаләнең[13] яхшы җәһәтләрендә узып, кимчелекләренә килсәк, мәтбагачы казанлы Кәримевләрнең гаепләрене әйтергә тугъры киләдер. Бу әфәнделәр мәтбагаларыны башка кешеләрнең матбагалары рәтенә кертергә аз гына булса да ни өчен бер дә иҗтиһад кыйлмыйлар икән?

---

[1] *Мөкаддәм* – элек.
[2] *Әһали исламия* – мөселманнар.
[3] *Дәреҗ ителү* – басылып чыгу.
[4] *Мөяссәр* – җиңел, җайлы.
[5] *Тәхкыйрь нәзары илә* – мыскыллы караш белән.
[6] *Әнзаре галәм* – дөнья (дөнья игътибары).
[7] *Моталәгә* – уку, өйрәнү.
[8] *Истифадәле* – файдалы.
[9] *Лисан җәһәтенә* – тел ягыннан.
[10] *Канча* – ул кадәр.
[11] *Тәгъриф итү* – аңлату, таныштыру.
[12] *Малик* – ия.
[13] *Рисалә* – китап, әсәр.

Китапның нәширләре никадәр гүзәл кәгазьгә китапларыны табгы кыйлдырсалар да, Кәримевләр, буяуның потына берәр сум артык бирүне кызганып, китапны бозып чыгаралар. Заманга бераз гына булса да илтифат кыйлсалар, Кәримевләргә дә шаять гөнаһ булмас иде.

*

Бу көннәрдә китап базарына чыккан әсәрләрнең икенчесе янә шул ук «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан нәшер ителгән «Хат болгатты»[1] нам бер пәрдәлек көлкеле театру рисаләседер. Югарыда зикер ителгән[2] «Мирза кызы»ның мөндәрижат[3] җәһәте макталырга тиеш булса, бу соңгысының табгысының[4] гүзәллеге макталырга лаектыр. Табгысы вә кәгазе хәкыйкатән фәүкыльгадә[5] диярлек дәрәҗәдә гүзәлдер. Мөндәрижат җәһәтенә кәленчә, максат, театрудагы сәерчеләрне көлдерү улганлыктан, матлубка муафикъ улу[6] мөмкин исә дә (ул да уйнаучыларының кәефенә табигъ[7]), ләкин мәгънәле көлү дәгелдер. Көлгән тәкъдирдә үз арамызда булган килешмәгән гадәтләрдән көлү артыграк булса кирәк. Көләргә мөстәхикъ[8] булган гадәтләрне, Петербургтагы бер уч мөселманнар арасыннан барып эзләгәнче, үземезнең Казаннан гына яхуд мөселманнарның күбрәк җирләре булган Оренбург, Уфа, Әстерхан мөселманнарының тормышлары арасыннан эзләнсә, дәхи[9] дә яхшырак булыр иде.

Язган сүзләремез хәтергә килгән фикерләремезне генә бәяндан гыйбарәттер. Юкса бундан бу рисалә укырга да яраРлык бер нәрсә түгел икән дигән сүз акланмасын.

1907

«ПОМАДА МӘСЬӘЛӘСЕ»

(Харитонов мәтбагасы, «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» нәшриятыннан)

Язылганына ничә вә ничә еллар узып киткән булса да, Гогольнең язган комедияләреннән «Ревизор» илә «Женитьба» нам комедияләре әдәбият вә театр галәмендә һәмишә онытылмыйдыр. Заныма күрә[10], бунларның онытылмавы тасвир вә лисанында гадәттән тыш ихтирагъларның[11] барлыгыннан түгел, бәлки заманындагы интикад[12] итәргә лазем булган кыяфәтләрне бер арага кямил мәһарәт[13] илә җыеп

---

[1] *«Хат болгатты»* – Г. Ильяснең («Аң» журналы мөхәррире Әхмәдгәрәй Хәсәни) сәхнә әсәре, комедия бер пәрдәдә.
[2] *Зикер ителү* – телгә алыну.
[3] *Мөндәрижат* – эчтәлек.
[4] *Табгысы* – басылышы.
[5] *Фәүкыльгадә* – гадәттән тыш.
[6] *Матлубка муафикъ улу* – таләп ителгәнгә туры килү.
[7] *Табигъ* – ярашлы, табигый.
[8] *Мөстәхикъ* – хаклы, лаеклы.
[9] *Дәхи* – янә, тагын.
[10] *Заныма күрә* – уйлавымча.
[11] *Ихтирагъ* – яңалык, ачыш.
[12] *Интикад* – тәнкыйть.
[13] *Кямил мәһарәт* – камил осталык.

кертеп, һәрбер кыяфәт иясенең килешмәгән җирләреннән көлә белеп көлгәнлеге өчендер.

Яңа мөхәррирләремездән Идрис әфәнде Богдановның язган «Помада мәсьәләсе» исемендәге комедиясе дә минем каршымда шуңар мөшабиһдер[1]. Бу комедиядә, кеше көлдерү өчен диеп, һичбер урынсыз көлке сүзләр язылмаган. Ләкин комедиядә тасвир ителгән кыяфәтләрнең һәрберсенең табигать вә кыйланышлары һәм, шул кыйланышлары өстенә үзләренең үзләренә бик зур хөсне заннары[2] илә сөйләгән сүзләре һәм гарыз кыйлган[3] фикерләре хәкыйкатән[4] көленечтер. Комедиядә тасвир җәһәтеннән һичбер хәкыйкать хариҗенә[5] чыккан урын күренмидер. Тасвир ителгән кыяфәтләр һәркаюсы урынлы, һәрбересе заманыбызда мәүҗүд[6] каһарманнарныкыдыр. Мәсәлән, комедиядә тасвир ителгән Сәлим байдан алып муллалар, бәдәлчеләр[7], шәкертләр һәм Касыйм кеби маклерларга кадәр һәрбересе ушбу көндә мәүҗүд кыяфәтләрдер. Заманнар узган саен, халыкның табигате, әлбәттә, башкачарак. Бу көндәге кыяфәтләр бетеп, аның урынына икенчеләр киләчәктер. Узган заманда халыкның ни табигатьтә булганлыгыны белү өчен бундый әсәрләр бик зур хезмәтләр күрсәтәчәкләрдер. Шул сәбәптән Идрис әфәнденең бу рәвешчә тугъры вә җанлы итеп тасвир кыйлган әсәре көннән-көн игътибарга керә барачактыр. Әсәрнең җитешмәгән җире фәкать бу көндә татар әдәбиятында мәкъбуль[8] булып бара торган әдәби төрки телендә булмавыдыр. Сүзләрнең тәртибе афакый мишәр лисаны тарзында[9] булуы күркәмлегене бераз югалтадыр.

1908

«ХӘКЫЙКАТЬМЕ, ХЫЯЛМЫ?»

(Ф. Кәримев әсәре, Әхмәд әл-Исхакый нәшере)

Галәмдә хыял диңгезе кадәр һичбер диңгез юктыр. Никадәр тирән диңгез булса да, төпсез түгел.

Әмма хыялның һич ниһаяте[10] юк.

Хыялларның арасында бик ләззәтсезләре, ачылары да буладыр. Ачы хыялны тасвир кыйлган чакта рух бик мөгаззәб[11] була, димаг[12] арып хәлдән тая, өмидсезләнә, хәтта һәлак булыр мәртәбәгә килеп җитәдер. Татлы хыял каршысында рух үзенең асылына кайта, бетмәс-төгәнмәс ләззәтләр илә ләззәтләнәдер.

---

[1] *Мөшабиһ* – охшый.
[2] *Хөсне зан* – яхшы уй, фикер.
[3] *Гарыз кыйлу* – әйтү, белдерү.
[4] *Хәкыйкатән* – чын-чыннан.
[5] *Хәкыйкать хариҗенә* – дөреслектән читкә.
[6] *Мәүҗүд* – реаль.
[7] *Бәдәлче* – кеше өчен ялланып хаҗга баручы.
[8] *Мәкъбуль* – кабул ителгән.
[9] *Афакый мишәр лисаны тарзында* – бозык мишәр теле рәвешендә.
[10] *Ниһаяте* – чиге.
[11] *Мөгаззәб* – газапланган, азап чиккән.
[12] *Димаг* – ми (акыл, аң).

һәркем үз хыялы илә хыялланып яткан вакытта, нәфес өчен бик зур тәэсире булмый.

Чөнки үз хыялының хәкыйкать түгел икәнлеге бик мәгълүм. Икенче бер кешенең димагыннан чыккан хыялый хикәяләрне укыган вакыттагы ләззәтләр бөтенләй башка була. Әгәр дә бер хыял гүзәл каләм иясе булган кеше тарафыннан язылган булса, рухлы, нечкә вә нәфис каләмнәр илә хыялый бер тасвирны тамаша кыйлган вакыттагы зәвекъ вә ләззәтләр бөтенләй башка буладыр.

Фатих әфәнденең язган «Хәкыйкатьме, хыялмы?» исемендәге хыялый хикәясе ушбу соңгы җөмләдәндер. Фатих әфәнденең язган хыялый Дума әгъзасы, депутат әфәнденең хәрәкәт вә кыйланышлары вә аның фикерләре бик тугърылык һәм осталык илә тасвир ителмештер. Хыял уларак тасвир ителгән ханым әфәнде дә милләтне үз гыйндендә[1] кыйммәт күргән һәрбер кешеләрнең җан вә дил[2] илә арзу кыйла[3] торган ханымнарыдыр.

Бундый ханымнар бу көндә, табигый, хыялдан гына гыйбарәттер. Киләчәктә шул дәрәҗәдә ханымнарның булуы арзу ителәдер. Ләкин бу тиздән хәкыйкатькә әвереләчәк түгел. Икенче Дума вәкиле каршысында хыял булган бу галәм, бәлки дә, егерменче Дума әгъзасы каршысында да һаман да хыялдан гыйбарәт кенә булып калыр. Татар галәмендә бу көндә бундый хыялларны хәкыйкатькә алмаштыруга тырыша торган хәрәкәтләр һич күренми. Тиздән шундый хәрәкәтләрнең булуыны өмид итәргә дә урын юк.

«Хәкыйкатьме, хыялмы?» хикәясе туя алмаслык ләззәт илә укылачак әсәрдер. Ләкин һәркем өчен түгел, бәлки миллият сәүдаәсендә[4] булган кешеләр өчен.

Бу әсәр хакында кыска гына ушбу сүзне әйтәсем килә: Фатих әфәнде аз яза, ләкин матур яза.

1908

«ҮГИ БАЛАЛАР»

Бу көннәрдә кулыма төшкән яңа әсәрләрдән берсе — Габделмәҗит Гафури тарафыннан язылган мәзкүр исемдәге бер хикәядер.

Габделмәҗид әфәнденең әүвәлдәрәк язган әсәрләре ни өчендер миңа яхшырак күренә иде. Ләкин бу әсәрендә, никадәр тырышып укысам да, ул кадәр ләззәт таба алмадым. Габделмәҗит әфәнде бу әсәрендә, хикәясенең вакыйгъга татбигы[5] мөмкин булып-булмаячагын һич фараз кыйлмыйча, тасвир кыйлган вакыйгаләренең һәммәсен үзенең фаразына ияртәдер. Габделмәҗит әфәнде, хикәяне тизрәк тәмам кыйлу кирәк булганлыгы өчен булырга кирәк, һичбер катил[6] дә җөрьәт итә алмаслык өч җинаятьне

[1] *Гыйндендә* — каршында.
[2] *Дил* — күңел, йөрәк.
[3] *Арзу кыйла* — тели.
[4] *Миллият сәүдаәсе* — милләтне шашып сөю хисе.
[5] *Вакыйгъга татбигы* — чынбарлыкка нисбәте, охшашлыгы.
[6] *Катил* — үтерүче.

бер-бер артлы бер хатын кулыннан кыйлдыра ала. Шушындый ашыгычлык аркасында хикәянең ләззәте тәмам югала да кала.

Аның өстенә Габделмәҗит әфәнде үзе дә һәм наширләре дә хикәяне, бер мәртәбә булсын, табгыга биргәнче укып чыкмаганнар булырга кирәк. Чөнки хикәянең әүвәлендә балаларын дөньяда калдырып, никадәр хәсрәтләр чигеп үлгән Зөһрә хикәянең ахырында, янәдән кайтып булса кирәк, балаларын үги ана булып җәберли. Латыйфа исемле үги ана хикәянең ахырында Зөһрә исемендә була. Җәбер күргән Фатыйма исемле кыз Латыйфа була.

Игътибарсызлыклар хикәянең ләззәтен янәдән бер кат югалтадыр. Хикәя, хикәялектән бигрәк, «Милли шигырьләр»[1] шикелле подряд эшләнгән нәрсәгә бик охшыйдыр.

1908

«ЯШЬ ГОМЕР»

(Драма биш пәрдәдә, мөхәррире — Габделгафур Коләхмәтев. Наширләре «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе»)

Ушбу соңгы ай эчендә китап базарында берникадәр яңа әсәрләр күзгә күренде. Яңа туган ушбу балаларның һәммәсен дә әдәбиятка нисбәт бирергә яраса, бер ай эчендә әдәбиятымыз хили[2] баеды. Ләкин арада бәгъзеләре тик сикыт[3] көенчә туган булганга күрә, чын балага хисап итү мөшкилрәктер.

Арада иң сәламәт туганнарыннан берсе — «Яшь гомер» исемендәге драма рисаләседер. Драманың тасвир җәһәтләре хили гүзәлдер. Икенче, өченче вә бишенче пәрдәләре бик маһиранә тасвир ителгән. Хосусән икенче пәрдәнең, гәрчә уенга тәгаллекы[4] бик аз исә дә, хикәядәге каһарманнарның хәрәкәтләренә даир[5] бу пәрдәдә һичбер нәрсә булмаса да, тасвиры бик табигый һәм вакыйгъга мотабикъ[6] рәвештәдер. Беренче вә дүртенче пәрдәләрнең бәгъзе урыннары вакыйгъдән хили озактыр[7]. Бишенче пәрдәдә хәкыйкатьтән бик бәгыйд[8] эшләр юк түгелдер. Мәсәлән, үзен һәлакәттән коткарырга йөргән егеттән Зөләйханың алты-җиде айлар кадәре һичбер хәбәрсез ятуы гакылга сыя торган нәрсәләрдән түгелдер. Хосусән Зөләйханың Мостафадан күргән җәфалары моны хәтердән чыгармаска тиеш иде. Беренче пәрдәдәге Мостафа иптәшләренең дә кыйланышлары һәм алар илә Мостафаның мөгамәләсе дә гайре табигый чыгалар.

Кыяфәтләрне сайлап алуга килсәк, хикәядә икенче дәрәҗәдәге кешеләр һәммәсе бик яхшы табигый кыяфәтләрдә алынган булса да, хикәянең ике каһарманы — Гали илә

---

[1] *«Милли шигырьләр»* — бу исем белән М. Гафуриның алты шигырь җыентыгы чыккан. Биредә сүз шуларның беренчесе — 1907 елда басылганы турында бара.
[2] *Хили* — шактый, байтак.
[3] *Сикыт* — җитлекмәгән.
[4] *Тәгаллекъ* — бәйләнеш.
[5] *Даир* — бәйле, кагылышлы.
[6] *Вакыйгъга мотабикъ* — чынбарлыкка охшаган, туры килгән.
[7] *Вакыйгъдән хили озактыр* — тормыштан шактый еРактыр.
[8] *Бәгыйд* — ерак.

Зөләйха кыяфәтләренең дә дөньяда булуы бик бәгыйд күренәдер. Чөнки егет бер интеллигент, бер сыйныф халкының хадиме[1] һәм хамие[2]. Кыз исә, хикәядә күрсәтелгәнчә, үз файдасын үзе аңламас дәрәҗәдә аңгыра, һәртөрле хорафатларга ышана торган яхшы гына җитәрлек надан бер кыздыр. Бундый ике кыяфәтнең дөньяда аерым-аерым ике җирдә табылуларын мин һич инкяр итмим. Әмма бундый гакыл, фикер, гыйлем вә мәсләк җәһәтеннән бер-берсенә тәмам зыйд[3] булган аерым ике табигатьтәге кешеләрнең, арасында бер галяканең хосулына[4] һәм егетнең шул рәвештәге фикер җәһәтеннән үзеннән бик ерак булган бер кызны тәхлисъ[5] итәргә йөрүенә һичбер төрле гакылым ирешмидер. Егет нидән буңа мәҗбүр булды икән? Заныма күрә, хикәя йә бер Мәкъсудка мәбни уларак[6] язылырга, яхуд хикәядә хәзерге көндә мәкъбуль күрелмәктә улан тугърыдан-тугъры мәгыйшәтнең[7] копиясе кеби вакыйгa тасвир ителергә кирәк иде. Китапны кулга алып укыганнан соң, бәнем белүемчә, яшь гомер тасвир ителгән китаптан яшь гомер, фотограф рәсеме кеби, күз алдында күренеп тора торган булырга тиеш иде.

Икенче дәрәҗәдәге кыяфәтләрдән Вәли илә Йосыфның кыяфәтләренең яхшылыгына һич сүз юк. Бунлар тәмам-тәмамына бер сыйныф халыкка хезмәт итүчеләрнең кыяфәтләренең җанлы сурәтләредер. Йосыфның бакчадагы, участкадагы кыйланышлары, Гали өендә вакытта урамда үзләренә дошман берәүнең кыйналуын күргән вакытта шатланулары, вакыйган, бик урынлы, бик табигыйдер.

Әгәр дә мөхәррир әфәнде кыз кыяфәтенең дәрәҗәсен интеллигент бер ир илә араларында галяка хасил булырлык итеп югарырак күтәргән булса, яхшырак булган булыр иде. Ләкин, нишләмәк кирәк, бик югарыдан егылдырып төшерү дә бик ансат эш түгел шул. Ул вакытта, бәлки, драманың бөтен планын үзгәртергә кирәк булган булыр иде.

Мин бу язган сүзләрем илә әсәрнең кадерен киметүне уйламыйм, бары тик үземнең ушбу хакта мәгъкуль күргән фикерләремне генә әйтәм. Шул җәһәтләре игътибар кыйлынган булса, мөкәммәллеге дәхи дә арткан булыр иде дип уйлыйм. Ялгыш исә, гафу ителсен.

1908

«АЧЛЫК КУШТЫ»

(Ярулла әл-Вәли әсәре, «Шәрекъ көтебханәсе» нәшере)

Эстәрсә, драма булсын, эстәрсә, комедия, язган вакытта әсәрнең сәхнәгә куелачагыны фараз итеп язган нәрсәсе сәхнәгә кую шартларына муафикъ булып-булмаячагыны игътибар итү — мөхәррирнең вазифасыдыр. Фараз итик, бер әсәр тамашага куелса

---

[1] *Хадим* — хезмәтче.
[2] *Хами* — яклаучы.
[3] *Зыйд* — дошман.
[4] *Галяканең хосулына* — бәйләнешнең барлыкка килүенә.
[5] *Тәхлисъ* — коткару, котылдыру.
[6] *Мәбни улу* — корылу.
[7] *Мәгыйшәт* — тормыш, тереклек.

да, куелып пәрдә күтәрелсә, сәерчеләр[1] урыннарына килеп җирләшкәнче, тамашага куелган әсәрдәге хәрәкәтләр илә танышып җиткәнче пәрдә төшсә, икенче пәрдәләре дә кәзалик[2] бере-береннән кыска булып, һәр пәрдәсе биш дәкыйка зарфында[3] тәмам була торган булса, тамашага килгән кешеләр моннан нинди ләззәт ала белерләр! Зан идәрсәм[4], мөхәррир әфәнде үзе шундый бер уенда хазир булса[5], тамашаханәдән, әлбәттә, мәэюс[6] булып кайтачактыр. Шуның өчен тамашага куелачак әсәрләрнең пәрдәләренең күплегеннән бигрәк, эчендәге хәрәкәтләренең канәгать хасыйль итәр дәрәҗәдә күбрәк булуына иҗтиһад итәргә тиеш.

Мәсәлән, Ярулла әфәнде ушбу әсәрендә һич кирәкмәгән урында ике пәрдә ясаганчы, беренче вә икенче пәрдәләрне берләштереп, икесеннән бер пәрдә ясаган булса, мөкәммәл булачагы бик әшкярәдер[7]. Бу ике пәрдәне берләштерү мөхәррир өчен бик асат бер эштер. Өченче пәрдәдә кәзалик хикәянең каһарманы санарга ярый торган Маһсылуның хәрәкәтләре, аның мәзлумлекләре[8] һичбер төрле тасвир иделмәдекеннән, Маһсылу үзенең тәэссоратларыны һичбер төрле кирәгенчә изһар[9] кыйлмадыгыннан, үзенә бер пәрдә итеп тасвир кыйлуның лөзүме[10] һич күренмидер. Дүртенче пәрдәсе янә, заныма күрә, артыктыр. Чөнки нинди дә булса бер мөнәсәбәт илә Идрисне Морат аганың куышында күрештерү мөмкиндер. Иштә[11] бу җәһәтләреме караган вакытта бу хикәя өч пәрдә эчендә хәзергегә караганда да мөкәммәлрәк итеп тасвир ителә алачактыр.

Соңра, әсәрнең уйналачак сәхнәләрене дә бераз игътибар итәргә тиешледер. Татарча язылган театр рисаләләре, әлбәттә, Париж, Лондон вә гайре пайтәхет[12] шәһәрләрендә куелачак түгелләрдер. Буларның куела торган җирләре кечкенә генә клублар илә, бик уза китсә, шәһәр театрларыдыр. Хикәядәге көтүләрне тасвир итү өчен, зур шәһәр театрларында булганда да, яңадан-яңа декорацияләр ясарга лязем булачактыр ки, бу эш бик күп мәсарифка мохтаҗдыр.

Шул сәбәптән китапта күрсәтелгән бу нәрсәләр вөҗүдкә китерелмәдектән соңра, аннан башка да кыска булган хикәя яңадан да рухсыз булып чыгачактыр.

Ярулла әфәнденең бер әсәре Казанда тамашага куелган иде[13]. Ушбу вакытта да әсәрнең техника җәһәтеннән җитешмәгән җирләре бик күп булганга күрә, уйнаучылар үз тарафларыннан әллә никадәр сүзләр арттырырга мәҗбүр булганнар иде. Мәзкүр рисалә Ярулла әфәнденең беренче әсәре булдыкыннан, бераз мәгъфу[14] иде. Бу икенче әсәрендә янә шундый җитешмәгән урыннар күренәдер. Ярулла әфәнде икенче әсәрене язган вакытта, әүвәлгегә караганда тәҗрибәсен арттыру урынына, яңадан бераз кимета

---

[1] *Сәерче* – караучы, тамашачы.
[2] *Кәзалик* – шулай ук.
[3] *Дәкыйка зарфында* – минут эчендә.
[4] *Зан идәрсәм* – уйлыйм ки.
[5] *Хазир булу* – монда: «тамашачы булса» мәгънәсендә.
[6] *Мәэюс* – өметсез.
[7] *Әшкярә* – ачыктан-ачык.
[8] *Мәзлумлек* – җәбер, изелү.
[9] *Изһар* – белгертүеннән.
[10] *Лөзүм* – кирәклек.
[11] *Иштә* – менә.
[12] *Пайтәхет* – башкала.
[13] *...тамашага куелган иде* – Я. Вәлинең «Оят, яки Күз яше» исемле пьесасы Казанда 1907 елның 24 августында һәм 1908 елның 25 апрелендә уйнала.
[14] *Мәгъфу* – гафу ителгән.

төшкән икән. Бунлар фәкать әсәрнең техника җәһәтеннән килеп җитешмәгән җирләре.

Хикәянең рухи җәһәтенә килсәк, анда да ноксаннар[1] җитәрлектер. Әүвәле драманың каһарманы булырга тиешле Маһсылу бик җамид[2] күренә. Мәзлумә бер хатынның буңа караганда күп хәрарәтле[3] булуы ляземдер. Хосусән, үзләренең мәзлумиятләрене, тәэсирләрене кешегә аңлатуда ирләргә караганда күп дәрәҗә өстен булган хатын-кыз таифәсенең[4] бу кадәр суык тасвир ителүе урынсыздыр. Сөйләгән урыннарның да күбесендә Маһсылу тәэссоратыны карьяле[5] бер кыз кеби дәгел, мәктәп күргән тәрбияле бер кызның хиссият изһар кыйлганы шикелле сөйлидер. Бу да, табигый, урынсыздыр. Соңра аңлашылдыгына күрә, кызның анасы Рәхимә үги ана түгел. Үги ана булмаганнан соң, һич кирәкмәгән урында аны үги ана кеби рәхимсез итеп тасвир кыйлу тиешсездер. Рәхимле, шәфкатьле итеп тасвир ителсә дә, хикәянең асылы бозылмас иде. Бәлки, кызыны төрекмәнгә сатып җибәргән вакытта егълый-егълый озатып калса, ачлыкка тәхәммел кыйла[6] аямаганлыктан биреп җибәрергә мәҗбүр булганлыгы яхшырак аңлатылса, хикәя, бозылу урынына, бәлки, берничә кат төзәлгән булыр иде һәм ахыргы пәрдәләрдәге шәфкатьле Рәхимә илә беренче пәрдәдәге Рәхимә арасында мөнәсәбәт тә камилләнгән булыр иде. Рәхимәнең дә мөхавәрәләрендә[7] табигый булмаган җирләр бар. Мәсәлән, Хәйдәр аганың каршысында сүз сөйләгән вакытта: «Мин — арыслан, татар баласы», — дигән кеби мактанулары сала карчыгының агызына бер дә килешми. «Карчык бигрәк сознательный националистка икән!» — диясе киләдер. «Милләтче» сала карчыклары илә философ дворниклар дөньяда күренгәне юк. Булмагач, язмаска да кирәк.

Мәзкүр әсәрне театр рисаләсе түгел, бәлки бер хикәя китабы дип игътибар иткән вакытта хили гүзәл бер хикәядер дияргә мөмкин. Шул җәһәтне мөляхазә кыйлып[8] укып чыкканда, мәзкүр китап хили гыйбрәтле бер әсәрдер.

1908

ЯҢА ӘСӘРЛӘР

(«Яшьләр», «Кыямәт»)

Көннән-көн артып бармакта улан яңа әдәбият китаплары арасында ушбу көннәрдә «Яшьләр» исемле китап дөньяга килде.

«Яшьләр» Фатих әфәнде Әмирхан тарафыннан язылмыштыр. «Яшьләр» — 3 пәрдәлек бер театр мәҗмугасыдыр. Бунда тормышыбызның алмашыну көннәрендә яшьләрдә булган тәбәдделат[9] күз алдына китереп күрсәтеләдер. Хикәянең каһарманы

---

[1] *Ноксан* — кимчелек.
[2] *Җамид* — коры, салкын.
[3] *Хәрарәт* — җылылык.
[4] *Таифә* — төркем, җәмәгать.
[5] *Карьяле* — авыл кешесе.
[6] *Тәхәммел кыйлу* — чыдау, түзү.
[7] *Мөхавәрә* — сөйләшү, әңгәмә.
[8] *Мөляхазә кыйлып* — дикъкать белән.
[9] *Тәбәдделат* — үзгәреш.

уларак бер байның ике улы илә бер кызы тасвир ителмештер. Байның угыллары әүвәлдәрәк адрес яза белерлек дәрәҗәдә русча белү өчен укырга бирелгәннәр. Заманның икътизасы[1] буенча бунлар уйганын, русчаны ныклап укуның кирәклегене аңлап, ибтидаи тәгълим[2] илә генә калмаенча, гимназия вә университетларга кереп уку һәвәсенә төшкәннәр һәм шуңар тырышалар. Һәмширәләрене[3] дә үз араларына алып, үзләренә иш ясаганнар, аны да укыталар. Башта балаларының аз гына укуларына разый булган ата, балаларының еракларга кадәр китәргә ниятләре барлыгыны күреп, курка башлый, базар халкының котыртуларына ияреп, балаларны укудан мәнгъ кыйла[4]. Укытучы мөгаллимәләренә акча түләүдән туктый. Яшьләр аның ул эшене игътибарга алмыйлар, укыр өчен үзләреннән акча табарга тырышалар. Акчаны тыю илә генә балаларыны укытудан тыю мөмкин булмаслыкны күргәч, аталарына карышырга ярамаганлыкны, аның җәзасы бик зур идекене күрсәтү һәм калган ике баласыны «гыйбрәт»ләндерү өчен бай олугъ улыны йортыннан куып чыгара. Хикәя шуның илә тәмам була.

Хикәянең тасвиры хили гүзәл һәм анда тасвир ителгән яшьләрнең типлары бүген дә Казанда мәүҗүд типлардыр. Хәтта һәрбер язылган әсәрләрне «бу фәлән кеше хакында язылган икән» дип тәэвил кыйлырга[5] яраткан кешеләргә «бу да фәлән бай балалары хакында язылган икән» дип әйтерлек дәрәҗәдә якын тормыштан алынган типлардыр. «Яшьләр» Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе тарафыннан нәшер ителеп, Казанда «Үрнәк» матбагасында басылмыштыр. Бәһасе – 25 тиен.

1910

МӘРХҮМ ӘХМӘД МИДХӘД ӘФӘНДЕ

Төркиянең, бәлки дә, бөтен ислам галәменең иң зур мөхәррир вә әдипләреннән һәм дә философларыннан Әхмәд Мидхәд әфәнде шимбә көн – 15 декабрь кич, ахшамга бер сәгать калганда, вафат итте. Якшәнбә көн, 16 декабрьдә, өйләдән соң Солтан Фатих җамигъсендәге төрбәләрнең[6] берсе янына дәфен иттеләр[7].

Әхмәд Мидхәд әфәнде шул көн дарелшәфәка[8] мәктәбендә булган бер мәҗлестә рәис булып, мәҗлесне дәвам иттергән. Мәҗлес тәмам булып, халык таралгач, үзендә бер кәефсезлек хис кыйлган. Доктор чакырып китергәннәр. Доктор, никадәр иҗтиһад кыйлса да, бичараны әҗәлдән коткара алмаган.

Әхмәд Мидхәд әфәнде 18 яшендә мөхәррирлеккә башлаган. Җитмеш еллык гомере эчендә һәртөрле фәннәр вә фәлсәфәләргә даир ничә вә ничә җилдләр[9] илә китаплар язган. Бик күп мәэмүриятләрдә[10] булган. Ахыр гомерендә дарелфөнүндә иң яхшы

---

[1] *Икътиза* – таләп итү.
[2] *Ибтидаи тәгълим* – башлангыч уку.
[3] *Һәмширә* – кыз туган.
[4] *Мәнгъ кыйлу* – тыю.
[5] *Тәэвил кыйлу* – аңлату, юрау.
[6] *Төрбә* – мавзолей.
[7] *Дәфен итү* – җирләү, күмү.
[8] *Дарелшәфәка* – интернат-мәктәп.
[9] *Җилд* – том.
[10] *Мәэмүрият* – дәүләт эше.

мөдәррис иде. Бик күп кешеләр аңа шәкерт иделәр. Ләкин, мәгаттәәссеф[1], җеназасында кеше бик аз иде. Хәтта, ике йөздән зиядә[2] дарелшәфәка таләбәләрен[3] хисапка алмасак, бик күп булса бөтенләе егерме-егерме биш кадәр адәм вар иде, диләр. Әгәр Мидхәд әфәнде шикелле бөек бер зат вафат итсә, башка милләтләр дөньяны кубарырлар, җеназасына ничә вә ничә мең халык җыелыр иде. Төрекләрнең үзләренең бундый иң газизә бер кешеләренә бу рәвешчә илтифатсыз кыйлanулары шаян тәәссефтер[4]. Хәтта мөшар иләйһинең[5] кайда дәфен иделәчәгеннән түгел, вафатыннан хәбәр алган кешеләргә дә аз очрадым. Кайда дәфен иделәчәген белү вә җеназасында хазир булу өчен мөшар иләйһинең мәхәле икамәте[6] улган Бәккүзгә киттем. Мин шул тирәдә дәфен ителә торгандыр дип фараз кыйлган идем. Фатихта дәфен ителәчәк, диделәр. Бәккүзгә, аннан пароход илә күпергә, аннан да Фатих җамигъсенә барганчы, ике ярым сәгатьтән артык вакыт узды. Мин Фатихка барып җиткәнче, дәфен кыйлып, халык таралган иде.

Зур кешеләргә илтифатсызлык бер Мидхәд әфәнде хакында гына түгел, башкалар хакында да шулай ук. Мәсәлән, моннан ике ай әүвәл монастырлы Исмәгыйль Хаккый җәнабләре вафат иткән. Бу зате гали бөтен ислам галәменә исеме танылган мөхтәрәм бер зат иде, аның кеби гүзәл бер вагыйз[7] бөтен Төркия мәмләкәтендә юк иде. Галәмдә яд тулы сахибе[8] иде. Язган тәфсире һәркем гыйндендә мәкъбуль иде. Көнһтә[9] Истанбул -ның иң зур мәктәпләрендә мөгаллим иде. Сөйләүләренә караганда, аның да җеназасында әкърабларыннан[10] башка һичкем булмаган.

1912

---

[1] *Мәгаттәәссеф* – үкенечкә каршы.
[2] *Зиядә* – артык.
[3] *Таләбә* – укучылар, студентлар.
[4] *Шаян тәәссефтер* – кызгануга (үкенечкә) лаек.
[5] *Мөшар иләйһи* – югарыда күрсәтелгән (зат).
[6] *Мәхәле икамәте* – тору урыны.
[7] *Вагыйз* – сүз остасы.
[8] *Яд тулы сахибе* – киң мәгълүматка ия кеше.
[9] *Көнһтә* – иң югары дәрәҗәле чагында.
[10] *Әкъраб* – якын туганнар.

«Казанда Печән базары чатында политика мәҗлесләре». «Яшен» журналы

«Егерменче гасырда, тән җәзасы нәсех кылынган заманнарда, ысул кадим хәлфәсенең мәктәптә шәкерт тәрбия кылуы». «Ялт-йолт» журналы

«И Ходаем, тагын бер йөзек киярлек тә урын калмады. Ни өчен бу кул бармаклары егерме булмады икән?» «Ялт-йолт» журналы

«Бала. Әти, теге бара торган нәрсәләр ниләр алар?
Атасы. Углым алар печән чүмәләләре.
Бала. Соң, алай булгач, ник аларның аяклары бар?
Атасы. Углым, алар әүвәлдәрәк кеше булганнар».
«Ялт-йолт» журналы



«Иң арзанлы, ләкин бик таза фундамент өстенә салынган 50 мең сумлык йорт». (Бу рәсемдә Уфадагы Диния идарәсе күрсәтелә.) «Ялт-Йолт» журналы

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ИҖАТЫНА ГОМУМИ КҮЗӘТҮ

Г. Камал – реалистик татар драматургиясенә нигез салучы, хикәяче һәм шигырьләр авторы, тәнкыйтьче, журналист, тәрҗемәче, рәссам, театр эшлеклесе.

Галиәсгар Галиәкбар улы Камалетдиновның үсеп-формалашу чоры аны татар драматургиясенең әйдаманы булырга әзерли дисәк, һич тә ялгыш булмас. Казанда туып, башлангыч белемне әнисенең туган авылы Масра (хәзер Арча районына керә) мәктәбендә алган Галиәсгарга кадими «Госмания» һәм «Халидия» мәдрәсәләрендә, 1893–1900 елларны яңа ысулдагы, җәдит «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырга, бер үк вакытта өч сыйныфлы рус мәктәбенә йөрергә насыйп була. Шулай итеп, яшүсмер вакытында ук ул бер-берсенә капма-каршы юнәлешле белем бирү системаларына эләгә, бер-берсеннән тирән упкын белән аерылган дөньяларны чагыштыра ала. Әдәбият һәм театр сәнгате белән кызыксына башлагач та, бер яктан, рус театрында барган спектакльләрне яратып карый, икенче яктан, һәм рус, һәм шәрык (төрек) авторларының сәхнә өчен язылган китапларын мавыгып укый.

Рус-европа көнитешен һәм мәдәниятен белеп, читтәге казанышларны үз милләтен үстерү өчен файдалану омтылышы Г. Камалның бөтен эшчәнлеген һәм иҗатын бербөтен итеп карарга мөмкинлек бирә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, халык арасында аң-белем таратуга үз өлешен кертү максаты белән, яшь Галиәсгар 1901 елда «Мәгариф көтебханәсе» исемендә китап бастыру һәм сату ширкәте оештыра һәм 1905 елгы революция көннәренә кадәр аның белән җитәкчелек итә. 1905 елның октябреннән ул Казанда чыга башлаган беренче татарча газета «Казан мөхбире»ндә эшли башлый, 1906 елның февралендә демократик юнәлештәге «Азат» газетасына күчә, аның мөхәррире була. Шул ук елның июнендә бу газетаның исеме «Азат халык» дип үзгәртелә. Ләкин «Азат халык»ның гомере озын булмый. Г. Камалның шуннан соңгы журналистлык хезмәте башлыча «Йолдыз» газетасы белән бәйле: ул анда 1917 елның октябренә кадәр эшли. 1908–1909 елларда ул Г. Тукай белән бергә революцион-демократик эчтәлекле «Яшен» исемле көлке журналы чыгара. Г. Камал, бу журналның нәшире, рәсми мөхәррире була, анда күп санлы мәкалә, шигырьләре белән дә актив катнаша, карикатуралар ясый. Ул татар укучысына дөньяда барган хәлләрне, башка милләтләрнең тормышын сөйләүне үзенең бурычы дип саный. Татар җәмгыятендәге теләсә нинди яңалык аның игътибарыннан читтә калмый. Әйтик, татарның булачак зур галиме Гали Рәхим 17 яшендә 240 битле «Җир йөзе» (1909) дип аталган география дәреслеге бастырып чыгаргач, Г. Камал аны хуплап һәм мактап «Йолдыз» газетасында мәкалә бастыра, бу китапта моңа кадәр басылган дәреслекләрдәге кимчелекләрнең бетерелгәнлеген билгеләп, «Китапның язылуына, гыйбарәләренең гүзәллегенә, ифадәсенең садәлегенә караган кешенең Мөхәммәдгали әфәнденең кабилиятенә тәхсин итәчәген һәм киләчәктә

Мөхәммәдгали әфәндедән әдәбиятымызга зур хезмәтләрене өмид итәчәгендә шөбһә кылмыймыз»[1] дип яза. Аның әлеге олы бәясен Г. Рәхим алдагы хезмәтләре белән дә раслый.

Г. Камал 1905–1907 елларда шигърияттә каләмен сыный. Милли яңарыш, гыйлемле, һөнәрле, мәгърифәтле булырга өндәү, җәмгыятьне камилләштерү мәсьәләләрен үзәккә куеп язылган **«Азатлык»** (1905), **«Өндәү»** (1905), **«Безнең кирәк»** (1906), **«Әй, мөселман, йокламагыл»** (1906) кебек шигырьләре шул чор матбугатында дөнья күрә.

Г. Камал татар әдәби тәнкыйтен формалаштыруда, аны аякка бастыруда үзеннән лаеклы өлеш кертә. «Йолдыз» газетасы битләрендә 1907 елдан башлап даими рәвештә рецензияләр сәхифәсен алып бара: яңа китаплар, татар театрының репертуары, яшь талантлар – Г. Камал каләменең сурәтләү объектлары[2]. Аерым алганда, Г. Камалның татар әдәбиятын, театр сәнгате үсешен күзәтүләре аның үз иҗатына мөнәсәбәтен дә күрсәтеп тора. Әйтик, И. Богдановның шул исемдәге комедиясенә нисбәтле язылган «Помада мәсьәләсе» («Йолдыз», 1908, 19 март) язмасы әсәрнең үз заманы татар җәмгыятендә киң таралган типларны күрсәтү, аларны киләчәк буыннар өчен «саклап калу» җәһәтеннән әһәмиятенә игътибар итә. Яки Ф. Кәриминең «Хыялмы, хакыйкатьме?» хикәясенә кагылышлы «Хәкыйкатьме, хыялмы?» тәнкыйть мәкаләсе әсәрнең милләтне күтәрүгә хезмәт итәргә тиешле кешеләр өчен, аларга юл күрсәтеп язылганлыгына басым ясый: «миллият сәүдаэсендә булган кешеләр өчен»[3]. Шуның белән әдәбиятның вазифасына карашын беркетеп куя.

1914–1917 еллар арасында Г. Камал рус һәм дөнья әдәбиятыннан шактый гына сәхнә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Алар арасында А. Н. Островскийның «Күк күкрәү» (1914), француз драматургы Мольерның «Саран» (1914) һәм «Ирексездән табиб» (1916), Н. В. Гогольнең «Ревизор» (1916), төрек драматургы Г. Хәмиднең «Һинд кызы» (1917) әсәрләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Бу тәрҗемә пьесалар шул еллардагы театр сәхнәләрендә кат-кат уйналып, татар милли театр сәнгатенең үсешенә, формалашуына уңай йогынты ясыйлар. Аның тәрҗемә эшчәнлеге рус-европа һәм төрек драматургиясен татар сәнгатен үстерү өчен өлге дип санавы турында да сөйли. Шунысын да искәртергә кирәк: төрек драматургиясе үз чиратында француз сәхнә әдәбиятының көчле йогынтысында формалаша.

Г. Камал, күп кенә әсәрләрне сәхнәләштергәндә, бизәүче вазифасын үти. И. Н. Харитонов типографиясе өчен татар шрифтларын эшләүче, сатирик журналларда рәсемнәрен бастыручы рәссам булып та таныла. Сызыклар һәм төсләр гармониясенә сизгер, зәвыклы Г. Камал бу сәләтләрен татар драматургиясен үстерү өчен файдалана.

Татар театр сәнгате барлыкка килү, шиксез, Г. Камал исеме белән бәйле. Бу хакта иң беренчеләрдән булып язган Г. Рәхим фикеренчә, татар мәгърифәтчеләренең беренче пьесалары, сәхнә өчен булудан бигрәк, әлеге өлкәдә каләм сынау булса, тормыштан алынган һәм халык телендә иҗат ителгән әсәрләре белән Г. Камал драматургияне татар халкының сәнгате буларак мәйданга чыгарды[4].

---

[1] *Камал Г.* Яңа әсәрләр. «Җир йөзе» – Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдшакир Габдерәхими әсәре // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан : Җыен, 2008. – 359 б.

[2] *Мәһдиев М.* Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1987. – 68–80 б.

[3] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. – 3 т. – 161 б.

[4] Галиәсгар Камал турында берничә сүз // Галиәсгар Камал әсәрләре. – Казан : Татарстан матбугат-нәшрият комбинаты, 1925. – 6–22 б.

1898 елда ул **«Бәхетсез егет»** (беренче варианты) драмасын иҗат итә. Аның артыннан **«Өч бәдбәхет»** һәм тәрҗемә ителгән **«Кызганыч бала»** драмасы (төрек язучысы Н. Кемал әсәре) язылып, 1900 елда Казанда аерым китаплар булып басылып чыга, **«Сабир хәзрәт»** (1903) хикәясе пәйда була. 1906 елның 22 декабрендә «Гыйшык бәласе» һәм «Кызганыч бала» пьесалары буенча Казанда беренче мәртәбә ачык спектакль уйнала. Г. Камал профессиональ театр сәнгатен башлап җибәргән «Сәйяр» труппасы эшенә турыдан-туры булышлык итә[1].

Әдәбиятта беренче адымнарын Г. Камал мәгърифәтчелек әдәбияты традицияләре мәйданында ясый. Ләкин беренче драмаларында, башлап Й. Г. Нигъмәтуллина игътибар иткәнчә, үзәк персонаж драма герое дәрәҗәсенә күтәрелми, тормыш исә татар җәмгыятендәге искелек калдыклары булган комик типлар ярдәмендә мәгънәсезлек кебек бәяләнә. Моннан тыш, наданлык проблемасы үзәккә куелса да, мәгърифәтчеләр Г. Ильяси, Ф. Халиди әсәрләреннән аермалы буларак, Г. Камал әсәрләрендә гыйлемлеләр һәм наданнар конфликты түгел, бәлки «иҗтимагый бәла буларак наданлык кешенең табигатенә, табигыйлегенә» каршы куела, нәтиҗәдә шушы бәла корбаны Закирның кичерешләрен, күңел хәрәкәтен тирән яктырту күзәтелә — әсәрләргә сентиментальлек хас[2].

Г. Камалның беренче әсәрләрендә жанрлык чикләре билгеләнеп бетмәгән, ләкин аларда татар мәгърифәтчелек әдәбиятының үзгәреше, сентиментальлек сукмагында эзләнүләре чагыла. Шушы эзләнүләр аңа геройлар бирелешендәге схемачылыктан котылырга ярдәм итә. Һәр сурәтләнгән персонажны характер буларак тулы ачу һәм тормыш ситуацияләрен холык-фигыль үзенчәлекләренә, бигрәк тә хисләрнең акылдан өстен чыгуына бәйләп кую — Г. Камал драматургиясенә хас сыйфатлар.

Г. Камалның беренче әсәрләрендә үк иҗатының лейтмотивы тоемлана: татар җәмгыятенең иске тормыштан яңа тормышка күчү котылгысызлыгын ассызыклау. Моның өчен драматург иске тормыштагы төрле катлау вәкилләренең көнкүрешен сәхнә әдәбиятында булган мул мөмкинлекләрдән файдаланып тергезә, үзгәрергә тиешле кимчелекләрне характерлар буларак тулы ачылган типик образларда күрсәтә. Татар тормышындагы искелекне детальләрдә тасвирлау, патриархаль гадәтләрне сурәтләү белән янәшә, драмаларда җәмгыятьнең үзгә үсү юлы күзаллана. «Бәхетсез егет»тә яңа фикерле Әхмәт, «Өч бәдбәхет»тә укымышлы, гыйлемнең тормыштагы файдасы турында уйланган Гомәр образлары — яңа тормыш кешеләре, алар — автор фикере, үгетнәсыйхәтен җиткерүчеләр. «Сабир хәзрәт» хикәясендә дә шулай: бозык, азгын, аталык хисләреннән мәхрүм Сабир хәзрәтнең тормышы укучыларга гыйбрәт итеп сөйләнә, аңа керсез күңелле, яхшыны яманнан аера белүче, сабыр холыклы, гыйлемле, әхлаклы Габдулла мулла каршы куела. Бу яктан Г. Камал әсәрләре татар мәгърифәтчелеге традицияләрен үстерә. Гадәти булмаган сюжет — өйләнеп, хатын аеруны гадәткә әйләндергән Сабирның, үзе дә белмичә, кайчандыр аерган хатыны тапкан кызына яучы җибәрүе — авторга әхлак мәсьәләсен үзәккә куярга ярдәм итә. Шул ук вакытта хикәядә милләтне үстерү мотивы да әһәмиятле урын ала. Автор Сабир мисалында әхлаксызлык, хатыннар алмаштырып тору кебек сыйфатлар халыкны надан калдыра

---

[1] *Рәми И. Г., Даутов Р. Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). — Казан : Татар. кит. нәшр., 2001. — 126 б.

[2] *Нигматуллина Ю. Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. — Казань : Изд-во КГУ, 1970. — С. 88.

дип ассызыклый. Хикәя ахырында тәүбәгә килгән Сабир: «Мөселман кардәшләремә гыйбрәт булсын, анлар милләтләрен онытып, тиешсез эш берлә вакыт качырмасыннар»[1] дигән сүзләр әйтә. «Белем бирү — милләтне кайгырту, ә әхлаксызлык — милли мәсьәләләрдән читләшү» дигән фикерләр уздырыла.

Милли тормышның бер баскычтан икенчесенә күчү халәтен тасвирларга алыну үзе үк ике төрле яшәү рәвешен бер ноктада очраштыруны таләп итә. Г. Камал шушы күренешне тулырак гәүдәләндерү юлларын эзли. Төрек әдибе Н. Кемалдан тәрҗемә булган «Кызганыч бала» (1898) драмасында тормышны идеал һәм көнкүреш яссылыкларына кискен аеру күзгә ташлана. Әсәр төрек кызы Шәфыйканың ярлы студент Ата бәйгә көчле мәхәббәтен, бергә була алмау кайгысыннан икесенең һәлакәтен сурәтли. Әтисенең бурычларын түләү өчен, кыз үзен карт байга корбан итә. Драма сентименталь пафослы. Ләкин гашыйкларның үлемендә драматург патриархаль тәртипләрне гаепли. Й. Нигъмәтуллина фикеренчә, Г. Камал төрек әдәбияты сюжетын үзгә иҗтимагый-тарихи нигезгә куя, шуңа да әсәр идеяләр белдерелеше ягыннан демократик төс ала[2]. Гашыйклар иске тормыш корбаннары буларак бәяләнә башлый.

Беренче рус инкыйлабы Г. Камал эшчәнлеген тагын да активлаштыра. Ул татар җәмгыятенә, андагы төрле катлау вәкилләренә үтемле тәэсир итүнең иң туры юлы итеп журналистлык эшчәнлеген саный, шуңа да, дөньядагы һәм татар җәмгыятендәге хәлләрне күзәтеп, күп санлы мәкаләләр яза, үз укучысын булдыра. Театр сәнгатенә дә Г. Камал зур өметләр баглый. Сәхнә уенының язма сүздән дә көчлерәк тәэсир иткәнен исәпкә алып, ул үз чорының бай һәм урта хәлле кешеләре тормышын сәхнәгә менгерә. Театрны оештыру, аның эшен җайга салуда артист, режиссёр, сәхнә бизәүче, драматург буларак башлап йөрүче, рус, Көнбатыш Европа драматурглары иҗатын җентекләп өйрәнеп, аларны үз җирлегенә күчерүче Г. Камал татар драматургиясенең әйдаманына әйләнә.

Үзенең башлангыч чор әсәрләренә тәнкыйть күзе белән карап, драматург аларның икенче вариантларын яза. Әйтик, **«Бәхетсез егет»** (1907) драмасының яңа вариантында мәгърифәтчелек карашлары белән янәшә иҗтимагый тәнкыйть көчле яңгыраш ала. Бер яктан, Закирның фаҗигасенә ата-анасы, аларның баланы тәрбия итә белмәве төп сәбәп дигән фикер үткәрелә. Драма Сәгыйтьнең «Дөньяда баланы бигрәк ата-ананың тәрбия кыла белмәве харап итә»[3] дигән сүзләре белән төгәлләнә. Кәрим, Җәмилә образларына, аларның бала тәрбиясе, татар тормышындагы яңалыкларга карата булган карашларына идеаль гаилә — Сәгыйть Сабитовлар тормышы каршы куела. Аларның уллары — идеаль герой — Әхмәт: «Җәмилә абыстай Закирны үзенең белгәне рәвешчә тәрбия иткән. Закирның бу әхлаксызлыклары, бу тәрбиясезлекләре, бу фасикълыклары — бар да Җәмилә абыстайдан, бар да аның тәрбия кыла алмавыннан»[4], — дип белдерә. Шул рәвешле, автор фикере мәгърифәтчеләрчә яңгыраш ала.

Икенче яктан, җәмгыятьтәге әхлаксызлык, наданлык, караклык, бозыклык кебек сыйфатлар калкытыла. Болар иске тормыш билгеләре, символлары дәрәҗәсендә гомумиләштерелә. Аерым алганда, Әхмәт һәм Гайшә сөйләшүләрендә татар җәмгыятендә

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. — 3 т. — 25 б.
[2] *Нигматуллина Ю. Г.* Творческий метод Г. Камала // Галиәсгар Камал : язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1981. — 7 б.
[3] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. — 1 т. — 58 б.
[4] Шунда ук. — 30 б.

хатыннарның хокуксызлыгы («Никадәр тырышса да, залим, ерткыч иренең тырнакларыннан котылырга, аның кармакларыннан ычкынырга чарасы юк. Залим ире хатынының актык тамчы канын эчеп бетереп, гүргә кергәнчегә кадәр бара»[1]), ирләрнең эшлексезлеге («Бар эшләре — узган-барганнан көлеп, гаеп итеп калу. Үзләренең һичбер вакытта бер тиенлек эшләгәннәре юк, бер тиенлек сату иткәннәре юк, һичбер җирдән бер тиен көмеш килерлек доходлары юк. Шулай да дөньяда торалар. Кайсының хатыны җөйче, кайсыныкы калпакчы»[2]), бай хатыннарының әхлаксызлыгы («Ирләренең бар тапкан малларын һич кирәкмәскә җилгә сарыф кылдырып бетерәләр»[3]) һ.б. ассызыклана. Иске татар җәмгыятенең яшьләрне тормышка әзерләмәве хакында фикер уздырыла. Драматург тормыштагы очраклылыкларның, мәхәббәт хисенең, ирекка омтылышның кеше язмышына тәэсире турында сүз алып бара. Яшь буынга европача тәрбия бирү, европача укыту, җәмгыятьтә үз урыныңны табуның әһәмияте һәм моны аңлауның котылгысызлыгы билгеләнә. Шушы яктан әсәр җәмгыятьтә бәхәсләр уяткан җәдитчелек карашларына аваздаш була. Театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрам әсәрне «Кирәк фикер, кирәк зәмин җәһәтеннән бу көнгә кадәр нәшер ителгән театр китапларының иң гүзәле вә мөкаммәледер»[4] дип бәяли. Әсәр сәхнәдә дә уңыш казана.

«Уйнаш» (1910) драмасы — шулай ук «Өч бәдбәхет» пьесасының кабат эшкәртелгән варианты, ул иске тормышның тагын бер ягын — әхлаксызлыкны, бозыклыкны сурәтләү объекты ясый. Бер якта мәхәббәткә, гаилә бәхетенә омтылган Сәрбиҗамал, ә икенче якта аны үзләре корган тозакка төшерү өчен акчаны эшкә җиккән бозык Әнвәр, явыз Мәгълифә карчык, мәкерле Фәтхерахман образлары тормышны, урта гасыр татар әдәбиятындагыча, яхшылык һәм явызлык каршылыгы кебек сурәтләргә ярдәм итәләр. Мәхәббәт, матур хис-омтылышлар җәмгыятьтә хөкем сөргән әхлаксызлыкка тап була. Әхлаксызлык теләсә нинди кыйммәтләрне, матурлыкны, якты хисләрне җимерерлек дәрәҗәдә гомумиләштерелә. Г. Камал аны кешедәге байлыкка омтылыш белән дә, үз рәхәте өчен генә яшәү, үз мәнфәгатьләре хакына бар нәрсәне корбан итәргә әзер булу белән дә бәйлелектә күрсәтә. Мондый әхлаксызлыкка каршы кешенең аң-белемгә омтылышы, башкалар мәнфәгате белән исәпләшүе куела. Автор фикеренчә, кешенең камилләшүе хәтта тормышны үзгәртә ала.

Әхлак мәсьәләләрен төрле ситуацияләрдә, төрле сыйфатларда сурәтләргә омтылу **«Каениш»** (1912) драмасында (усал каенана Бәдигыльҗамалның уйлап тормыйча сүз сөйләве, эш-гамәлләр кылуы, көнчелеге), **«Дәҗҗал»**да (1912) (көнчелек, икейөзлелек, ихтыярсызлык, эчкечелек) дәвам итә. Г. Камал шул рәвешле татар җәмгыятен камилләштерергә, тискәре сыйфатларны, вакыйгаларны, хәлләрне, аларның нәтиҗәләрен күрсәтеп, шулардан арындырырга омтыла. Мондый әсәрләрдә драматург кешеләр арасындагы каршылыкны җәмгыятьтә күзәтелә торган уңай һәм тискәре сыйфатлар каршылыгы дәрәҗәсендә гомумиләштерә. Әйтик, «Каениш»тә улы белән киленнен аерыр өчен кызыннан ялган хат яздырган Бәдигыльҗамалның начарлыгын аның ире — акыллы, сабыр Габделкәрим фаш итә, яшьләрне килештерә. «Дәҗҗал»да исә Әхмәтнең эчкечегә әйләнүендә, тормыш төбенә тәгәрәвендә Шөҗагның көнчелеге, явызлыгы сәбәп итеп күрсәтелә. Шул ук вакытта Әхмәтнең ихтыярсызлыгы игътибарга алы-

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. — 1 т. — 27 б.
[2] Шунда ук. — 28 б.
[3] Шунда ук. — 29 б.
[4] *Кәрам Г.* Яңа китаплар // Йолдыз. — 1907. — 24 июнь.

на. Бу әсәрләр Г. Камалның сентименталь тасвирлау рәвешеннән баш тартуы хакында сөйли. Ул тормышны үзенә якын итеп сурәтләргә омтыла башлый, яңа алымнарга актив мөрәҗәгать итә. Н. Г. Ханзафаров, «Дәҗҗал» исеменә бәйле, әсәрдә дини-мифологик метафора кулланылуга игътибар юнәлтә. Дини риваять буенча, дөнья беткәндә, мөселманнарга җибәреләчәк Дәҗҗалга ияргәннәрнең маңгаена мөгез чыгачак, имеш. Мифологик материал авторга татар тормышындагы хәлләрне «милләтнең «маңгаена мөгез чыга башлау» галәмәтләре»[1] кебек гомумиләштереп бәяләргә мөмкинлек бирә.

Драматург каләме өчен милли тирәлектә отышлы тормыш материалы җитәрлек була. Аның иҗади фикерләү ягыннан шушы амплуада икәнлеген әле 1908 елны Борһан Шәрәф күрсәтеп үтә: «Г. Камал – иске тормышның инсанны кыса вә изә торган икәнен татып белгән вә шуны сизә башлаганнан бирле шуңа каршы җиһад илә мәшгуль булган заттыр. Ул үзен газаплаган иске тормыштан үч алырга вә аның әшәкелеген башкаларга да ачык күрсәтеп, аннан яшьләрне биздерергә керешкән...»[2]. Шуңа күрә реалистик пландагы комедияләрендә кешеләр арасындагы, кешенең үз эчендәге каршылык һәрчак иске тормыш – яңа тормыш каршылыгы кебек гомумиләштерелә ала.

Г. Камалның XX гасыр буе сәхнәдән төшмәгән иң күренекле комедиясе – **«Беренче театр»** (1908) – нәкъ менә иске-яңа көрәшенә корылган. Бер пәрдәдән, өч күренештән торган комедиядә татарча беренче театр куелу вакыйгасын автор төп каршылыкның сәбәбе итеп сайлый. Бер яктан, гаиләдә дә, хәтта шәһәрдә дә үзен иң акыллы, бөтен кешеләр аныңча яшәргә тиешләр дип санаучы Хәмзә бай театрны куйдырмаска йөри. Икенче яктан, аның үзенең балалары һәм якыннары театрга китеп бетәләр, театр куюга каршы көрәшкә чыккан Хәмзә бай берни эшли алмый, көлкегә кала. Хәмзә бай белән балалары һәм якыннары арасындагы каршылык – яңалык белән искелек арасындагы мәңгелек тартышның бер чагылышы. Ләкин яңалык, нинди генә киртәләргә очрамасын, барыбер җиңеп чыга, тормыш шулай алга бара, ди драматург.

Әсәрдә яшьләр лагерена карый торган берничә кызыклы тип тудырыла. Гади гаиләдән чыккан, укымышлы, Хәмзә бай кызына өйләнеп, аларда яшәп торучы Вәли – заманча уйлый, барлык хәлләр-вакыйгалардан хәбәрдар кеше. Хатыны Гафифә – иркә генә бай кызы, өйдә утырырга күнеккән, шуңа күрә кеше арасына чыгарга ояла, курка. Театрга баруны да яңалык тарафдары, үзен бу вакыйгада һичшиксез катнашырга тиеш дип санаучы Вәли оештыра. Бай улы, әтисе куркытып бетергән Хәбибрахман белән батыр килен Факиһә гаиләсендә исә театрга килүнең сәбәбе Факиһәнең кешедән калышасы килмәүдә булып чыга. Приказчик Фатих, нигездә, Хәмзә байга үч итеп, театрга китә. Шулай Камал татар тормышында яңалык яклыларның да төрле катламнарга аерылуын ассызыклый.

Камал тулы бер катлам-сыйныфка хас кимчелекләрне сурәтләү объекты ясый. Байлык, мал-мөлкәт, кием-салым колы булуга каршы юнәлдергән сатирик юнәлешле **«Бүләк өчен»** (1909) комедиясендә сәүдәгәр-мещаннар катлавыннан булган аерым кешеләрнең байлыкны бар нәрсәдән, хәтта улының бәхетеннән дә өстен куюы сурәтләнә. Улы шәкерт Габдуллаҗанны өйләндерү уңае белән баеп калырга ниятләгән Хәмидәнең икейөзлелеге, ата-аналык хисләреннән мәхрүм булуы, намуссызлыгы,

---

[1] *Ханзафаров Н. Г.* Г. Камал драматургиясендә татар сәүдәгәрләре // Галиәсгар Камал : әдип һәм заман (язучының 125 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы). – Казан, 2005. – 24 б.
[2] *Шәрәф Б.* Театр // Әл-Ислах. – 1908. – 14 август.

искергән гореф-гадәтләрне үз максатларына буйсындырырга омтылуы фаш ителә. Ләкин Хәмидәнең комедия ахырында яңгыраган соңгы репликасы («Әй раббем, нинди гөнаһ шомлыкларым булды икән? Тәмам булган эшне тараттым»[1]) сәхнәдә күрсәтелгән вакыйгаларны аның характеры, уйламыйча эшләп куюы, хисләрнең акылны томалавы нәтиҗәсе итеп карарга мөмкинлек бирә.

«Банкрот» (1911) комедиясе иске тип сәүдәгәрләрнең яшәү рәвешенә, түбән әхлагына каршы юнәлдерелгән. Каршылык сәүдәгәр Сираҗетдин Туктагаевның ялган банкротлыкка чыгып, хәйлә юлы белән зур табыш алу вакыйгасында чагыла. Диндар һәм изге булып кыланучы бу сәүдәгәр үзенең эшлекле танышларын гына түгел, туганнарын-якыннарын да алдарга уйлый, моның өчен акылдан язган кеше ролен уйнаудан да баш тартмый. Җәмгыятьтәге намуссызлык, комсызлык, икейөзлелек, алдакчылык кебек сыйфатларны фаш итү өчен, драматург ярдәмче персонажларга зур мәгънәви йөкләмә сала. Акча өчен «юләрлеген таныган» доктор акча өчен Сираҗетдинне «терелтә» дә: драматург сәүдәгәрнең «игезәкләрен» тормышның башка катламнарында да таба. Комедиядәге хатын-кыз образлары, алар арасындагы икейөзлелек, мәгънәсезлек, гайбәт, нахак сөйләү гаиләдә туганлык, дуслык, ир-хатын мөнәсәбәтләренең дә ялганга корылуын фаш итү өчен кирәк.

Беренче карашка, «Банкрот»та үзәккә куелган сәүдә-акча проблемасы драматургны милли мәсьәләләрдән читкәрәк алып китә кебек тоела. Ләкин, Н. Г. Ханзафаров бик дөрес билгеләгәнчә, әсәрнең эчке конфликты — «киң мәгънәдәге җәдит-кадим көрәше»[2] ул. Сираҗетдин Туктагаев — «туктаган заман» кешесе, автор «аныңча яшәргә омтылу перспективасыз һәм көлке»[3] икәнне ассызыклый.

Татар җәмгыятендәге милләтне кайгыртабыз дип кыланучы байлар яшәешен көлү объекты ясаган **«Безнең шәһәрнең серләре»** (1911) комедиясе тормышның төрле катламнарын чолгап алган наданлык, кирелек, бозыклык, икейөзлелек, яңалыкка дошман булу, усаллык кебек сыйфатларны ача. Казанга өйләнергә килгән Себер бае һәм аңа ияреп йөри торган яучы артыннан укучы һәм тамашачы «Җәмгыяте хәйриядә», «Ресторанда», «Клубта», «Базар чатында», «Әдәбият кичәсендә» була, аларның һәркайсында ачы сатира утына алырлык күренешләр табыла. Бу әсәрдә инде автор үзләрен яңа тормыш күренешләре буларак тәкъдим итә торган иҗтимагый оешмалар, яңа тормыш яклы, хәтта аны төзүчеләр итеп күрсәтергә омтылган кешеләр турында сөйли. Аларның тышкы яктан заман куйган таләпләргә җавап биреп тә, асылда, искелек билгеләре булып калуына игътибар итә. Бу хакта әсәрнең беренче репликасында ук искәртелә: «Уставның һичбер җитешмәгән җире юк. Бу устав буенча әллә нинди зур эшләр кылырга мөмкин. Бары тик тырышырга гына кирәк»[4]. Алга таба автор күп санлы мисалларда, чынлап та, больницалар, китапханәләр, ятим балалар йортлары, картлар йортлары һ. б. ачу, җәмгыять өчен кирәкле башка хезмәтләр башкару өчен мөмкинлекләр булып та, моны башкарырга алынган кешеләрнең үз мәнфәгатьләре белән, табыш алу артыннан йөрүләрен күрсәтә. Җәдит караштагы Себер баеның әсәрне тәгалләүче сүзләре («Җәмгыятегездә — җәнҗал, ресторанда —

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 94 б.
[2] *Ханзафаров Н. Г.* Г. Камал драматургиясендә татар сәүдәгәрләре // Галиәсгар Камал : әдип һәм заман (язучының 125 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы). – Казан, 2005. – 21 б.
[3] Шунда ук. – 22 б.
[4] *Камал Г.* Күрсәтелгән хезмәт. – 173 б.

җәнҗал, клубыгызда – җәнҗал, базарыгызда – җәнҗал, әдәбият кичәгездә дә – җәнҗал»[1]) язучының тормышны үзгәртү өчен татар җәмгыяте үзара килешергә, уртак фикергә килергә, бер максат белән яшәргә тиеш дигән идеяне белдерүгә хезмәт итә. А. Әхмәдуллин бик дөрес билгеләгәнчә, әсәрдә сатира фаҗигагә әйләнеп китә[2], татар җәмгыятендәге яңарыш хәрәкәтенең, асылда, буш эшләр белән капланувы, буш кешеләр тарафыннан юкка чыгарылуына ачыну тудыра.

Г. Камал комедияләре тулаем көлке дөнья тудыруы белән үзенчәлекле. Бу дөньяда барлык геройлар да тискәре булып, аларга авторның идеалы каршы куела. Герой холык-фигыльләрендәге җитешсезлекләр, көлке исә җәмгыять тормышындагы тискәре күренешләр дәрәҗәсендә гомумиләштерелә. Көлү ярдәмендә драматург җәмгыятьне әлеге сыйфатлардан арындырырга тели. Шуңа күрә, проблемалар ягыннан караганда, Г. Камал комедияләре әхлакый мәсьәләләр куя, аларны иҗтимагый чынбарлык белән бәйли, шуларны чишү юлларын мәгърифәтчеләрчә эзли. Укучыны һәм тамашачыны кызыксындыру максатыннан, драматург халык көлүе-шаяруы традицияләрен, «төркем» сөйләмен, кабатлауларны актив файдалана.

«Өйләнәм!.. Ник өйләндем?» (1915) трагикомедиясе Г. Камал драматургиясен жанр ягыннан төрләндереп җибәрә. Аның үзендә көлке элементларын да, фаҗига элементларын да берләштерүе авторга психологизм алымнарын, ирония, сарказмны уңышлы кулланырга мөмкинлек бирә.

Г. Камал иҗатына югары бәя биргән, аның әсәрләрен драма өлкәсендә беренче карлыгачлардан дип атаган Г. Сәгъди үзенең фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы»нда (1926) драматургка махсус бүлек багышлый һәм әлеге иҗатның иң әһәмиятле билгеләрен аерып чыгару омтылышы ясый. Аның фикеренчә, иң беренче үзенчәлек – сюжетка «татар байлары тормышының аянычлы, көлкеле, серле якларын ачык, тулы иттереп ала белү булса, икенчесе – типларны сәнгатьчә зур осталык белән эшләп чыгара» алуда: «Ул каһарманнарын нәкъ үз тормышлары белән яшәтеп, аларга тәмам үз табигатьләренә яраклы сүзләр, хәрәкәтләр бирә. Сүз, табигать, эш, хәрәкәт, итенешкыланыш, болар – аның каһарманнарында бер-берсе белән тәмам берләшә ала торган нәрсәләр»[3]. Өченче әһәмиятле як дип галим автор фикере-позициясе түгел, ә геройлар фикеренең алга чыгуын атый. Дүртенче үзенчәлек «матур әдәби татар телендә» язылу дип билгеләнә. Бу фикерләр Г. Камал иҗатының үзе исән вакытта ук гаять югары һәм тулы анализлануы турында сөйли.

Октябрь революциясеннән соң Г. Камал татар совет көндәлек матбугатында хезмәт итә башлый һәм «Эш», «Эшче», «Кызыл көрәшче» газеталары битләрендә Гражданнар сугышы чорының төрле актуаль темаларына багышланган күп санлы сәяси, сатирик шигырьләрен – атаклы декламацияләрен бастыра. Бу чорда аның сәхнә иҗаты да үзгәреш кичерә. Егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында иҗат иткән «Тәкый гаҗәб, яки ахыры заман», «Могҗиза», «Ысул кадимче», «Җантаһир белән Җанзөһрә» кебек сатирик комедияләренең һәм «Хафизәләм иркәм» (1921–1922), «Күзсез мастерлар» (1930), «Өч тормыш» (1930) кебек пьесаларының темасы искелеккә

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 220 б.
[2] *Ахмадуллин А. Г.* Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма. – М.: Наука, 1983. – С. 43.
[3] *Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы // Габдрахман Сәгъди : фәнни-биографик җыентык / төз. Д. Заһидуллина,Ч. Гыйлаҗева. – Казан : Җыен, 2008. – 72 б.

каршы көрәш, яңалыкны раслау булып төгәлләшә. Искелек исә – инкыйлабка кадәрге яшәү рәвеше, яңалык – иҗтимагый көрәш ярдәмендә төзелә торган тормыш кебек аңлатыла. Аларда социалистик үзгәртеп корулар барышы, шушы юлдагы көнкүреш каршылыклары, кешеләрнең дөньяга карашы үзгәрүе чагылыш таба («Хафизәләм иркәм» комедиясе, 1922; «Өч тормыш» драмасы, 1930).

Татар мәдәниятендә Г. Камал татар театрына нигез салучы, аның киләчәккә үсеш юлларын билгеләүче буларак билгеле. Г. Тукайның аны «татарның Островские» дип зурлавында хаклык бар: Г. Камал милли театрга хезмәт итүне яшәвенең максаты дәрәҗәсенә куя. «Аң» журналы 1913 елны татар язучыларына һәм журналистларына «Яңа елда ни телисез?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Г. Камал аңа мондый җавап бирә: «Милли театрымызның мәдәни бер шәкелгә керүен, халкымызның театрга җитди күз белән карый башлавын, театр сәнгате гражданлык алып, уйнаучыларның да, театр язучыларның да күбәюен һәм камилләнүен телим»[1]. Үзенең көчен, талантын, егәрен исә ул, чыннан да, шушы теләкне тормышка ашыруга юнәлтә.

Дания Заһидуллина,
филология фәннәре докторы, профессор

---

[1] *Аңчы.* Яңа елда ни телисез? // Аң. – 1913. – № 22. – 377 б.

МӘКТӘПТӘ ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ (ГАЛИӘСГАР КАМАЛ КОМЕДИЯЛӘРЕ МИСАЛЫНДА)

Драма – матур әдәбиятның мөстәкыйль бер төре; тормышчан конфликтка, вакыйгаларны геройларның эш һәм хәрәкәтләре аша ачуга корылган диалог һәм монолог формасында язылган сәхнә әсәре.

Драма әсәренең башка төрләрдән аермасы бик зур. Еш кына аны әдәбият түгел, мөстәкыйль сәнгать төре дип саныйлар. Төгәлләнмәгән, сәнгать төре түгел, бәлки театр сәнгате өчен «чи» материалның тексты дип исәпләү дә яшәп килә. Бу аңлашыла да. Драма төре бик үзенчәлекле сыйфатларга ия.

Драма әсәренең төп үзенчәлеге шунда: ул сәхнә өчен языла. «Драма сәхнәдә генә яши, аннан башка ул тәннән аерылган җан кебек», – дип язган Н. В. Гоголь. Димәк, әлеге төр, укып кичерү өченнән бигрәк, карап кичерү өчен җайлашкан. Драматург тормыш турында сөйләми, ә бәлки шул тормышны хәрәкәттә күрсәтә. «Драма» сүзе килеп чыгышы ягыннан да грекча «хәрәкәт» мәгънәсенә барып тоташа. Монда проза әсәрләрендәге кебек сөйләп бирү, хикәяләү, ачык күренеп торган автор мөнәсәбәте, портрет, характеристикалар юк. Күп нәрсә укучының фикерләү, күзаллау сәләтенә, хыял куәтенә бәйләнгән. Драматург вакыйгаларны катнашучыларның үз-үзләрен тотышы, кул һәм йөз хәрәкәте, әйткән сүзләре белән «ясый». Шуңа күрә драма әсәрен укыганда, без аны сәхнәдә уйнала торган итеп күз алдына китереп барабыз. Ләкин «хәрәкәтне уйнау» өчен тормышның гадәти агышын күрсәтү генә җитми.

Икенче үзенчәлек итеп драма әсәренең нигезендә каршылык ятуын билгеләргә буладыр. Драма тормышның каршылыклы өзеген алып сурәтли, конфликт бөтен катнашучыларны хәрәкәткә китерә, вакыйгаларны үз янына туплый, холык-фигыльне ача. Кеше драмада киеренкелектә яши, шуңа күрә аның табигате дә бөтен тулылыгында ачыла.

Өченче үзенчәлек итеп драмада хис-кичерешләрнең тирәнлеген атыйбыз. Бу яктан драма лирик төргә якын, ләкин, аннан аермалы буларак, кичерешләр дәвамлы, вакыйгалар эчендә күренә.

Дүртенче үзенчәлек шунда: драма әсәрендә кеше образлары гына хәрәкәт итә. Сөйләмнәре, үзара мөнәсәбәтләре, үз-үзләрен тотышлары, эш-хәрәкәтләре ярдәмендә алар автор әйтергә теләгән фикерне белдерәләр. Субъект (автор) драмада үзе катнашмый, ул әсәр эчендә яши.

Драма әсәре бергәләп иҗат итүне сорый. Автор уйланмасына актёрлар, художник-композитор, режиссёр һ. б. сәнгать әһелләренең дә хезмәте, укучы яки тамашачының күзаллавы кушыла, һәм мәктәптә драма әсәрләрен өйрәнүнең ахыргы максаты – укучыларны әсәр аңларга-анализларга өйрәтү генә түгел, бәлки бу өлкәдә мәгълүматлы, зәвыклы тамашачы тәрбияләү дә.

Драма әсәренең тышкы билгеләре, төзелеше дә башка төрләрдән үзгә. Драматург кара-каршы сөйләшү (диалог) һәм искәрмәдән (ремаркалардан) файдалана, һәр әсәр катнашучылар исемлегеннән һәм вакыйгаларның урыны, вакыты, тәртибе турындагы мәгълүматтан башлана. Пьесаның һәр пәрдәсен һәм катнашучылар сөйләмен искәрмәләр ачыклап бара. Автор алар ярдәмендә күренеш һәм персонажлар, вакыйгалар турында иң кирәкле мәгълүматны хәбәр итә, персонажның хис-кичерешләрен билгели, аның күренүен һәм югалуын күрсәтә.

Диалог – ике кеше сөйләшүе генә түгел, еш кына «автор өчен» сөйләшү дә. Монда хәтта пейзаж, портрет та, әйләнә-тирә, башка персонажларга бәя дә бирелә, үтенү, үгетләү, таләп итү, киңәш бирү, аңлату, сорау, ялыну кебек төсмерләр ачык күренеп тора. Шуңа сөйләшү тәэсирле, әйтелеше ягыннан бай була. Кара-каршы сөйләм драмада ике вазифа үти: вакыйгалар үсешен бирә һәм катнашучыларны сурәтли, бәяли. Бу вазифалар, бербөтен булып, бәйләнештә бирелә.

Драматург сөйләүдән (монологтан) дә файдалана. Аның ярдәмендә сөйләүче үзенең хыялларын, кичерешләрен, теләк-омтылышларын, фикерләрен, уйларын, икеләнүләрен җиткерә. Кайвакыт ул мәгълүмат чыганагына әйләнә. Мәсәлән, герой үзенең чынлыкта кем булуын әйтеп куя.

Драма әсәре вакыт ягыннан чикләнә, сәхнәдә тамаша өч сәгатьтән артып китмәскә тиеш. Шуңа күрә биредә һәр күренеш, һәр вакыйга бәйләнештә, һәр күренеш бер үк вакытта сәбәп тә, нәтиҗә дә булып тора. Мондый бөтенлек сюжет ярдәмендә туа. Драмада сюжетның гадәти үсеше һәрвакыт диярлек саклана, ул җыйнак була. Чөнки геройлар вакыйгаларга тиз кереп, катнашып китәләр, һәрберсенең эш-хәрәкәте мотивлаштырылган. Башлам бик кыска булып, каршылыкта катнашучы якларның кемлеге, каршылыкның нигезе турында сөйли. Драманың сөйләшү һәм сөйләүләргә корылуы вакыйгаларны хәзер бара торган, тамашачы күз алдында башкарылучы хәлләр итеп күрсәтә.

Югарыда каралган әлеге үзенчәлекләр драма әсәрләрен мәктәптә укыту методикасын билгеле, мәктәп анализында исәпкә алына. Драма әсәрләрендә тормышның каршылыклы, конфликтлы өзеге аерып алына, шул каршылык хәрәкәт тудыра, барлык геройларны үз тирәсенә җыя. Драма әсәрләренең конфликты тарихи эчтәлеккә ия: геройлар арасындагы яки эчке кичерешләрендәге, бер герой күңелендәге каршылыкларда чорның иң мөһим, җәмгыятьне борчыган проблемалары чагылыш таба. Конфликтның үсүен тәртипле күзәтү, ярдәмче каршылыклар аркылы төп конфликт хәрәкәте артыннан бару әлеге проблемаларны күреп алырга, аңларга ярдәм итә. Проблема еш кына төп каршылыкның сәбәбе дә булып тора. Геройлар арасындагы каршылыклар аларның холкын бөтен тулылыгында ача, чөнки тормышның тыныч агышында түгел, нәкъ менә каршылыклар, авырлыклар килгән чакта кешенең башкалардан да, үзеннән дә яшереп яшәгән сыйфатлары ачылып китә. Шуңа да драма әсәрен анализлаганда, конфликт үсешен һәм герой характерларын янәшә куеп күзәтү, тикшерү яхшы.

Димәк, драма әсәрен анализлау юлы – автор артыннан бару, ләкин ул юл, образлар бирелешен тикшерү белән кушылып, бергә эшләнергә тиеш. Төп конфликтның тууын һәм үсүен, ярдәмче каршылыкларның асылын өйрәнеп, укучылар бер үк вакытта геройларның эш-гамәлләрен, тормыш позицияләрен, характерын да төшенәләр.

Анализ ясалышын күзәтик. Автор артыннан бару – күренеш арты күренешне, пәрдә арты пәрдәне өйрәнү дигән сүз. Һәр пәрдә һәм күренешләр эчендә ярдәмче каршылыклар табыла. Алар әлеге каршылыкта катнашучы яклар, образлар, аларның эш-гамәлләре, үз-үзләрен тотышлары, характерлары турында сөйләшергә мөмкинлек бирәләр. Мәсәлән, Г. Камалның **«Беренче театр»** комедиясе. Әсәр бер пәрдәдән, өч күренештән тора. Һәр күренеш эчендә ярдәмче каршылыкны һәм характерларны тикшереп карыйк. Беренче күренештә Гафифә белән Вәли арасында каршылык бар. Аның эчтәлеге мондый: Гафифә белән Вәли театрга барырга җыеналар. Вәли инде әзерләнеп беткән, Гафифә исә күлмәк сайлый, һич җыенып чыгып китә алмый. Каршылык

эчендә Вәли образы ачыла башлый. Вәли гади гаиләдән чыккан, укыган егет, Хәмзә бай кызына өйләнеп, аларда тора. Ул – заманча уйлый, барлык хәлләр-вакыйгалардан хәбәрдар, кызу канлы, һәрнәрсәне уйлагач эшләп тә куя, шул ук вакытта ачык күңелле, ипле кеше. Гафифә – иркә генә бай кызы, өйдә утырырга күнеккән, шуңа күрә кеше арасына чыгарга курка, бик озаклап сайлана-бизәнә, кыланчык. Шулай итеп, каршылык – теләкләрдә: Вәлинең театрга ашыгуы һәм Гафифәнең театрга барасы килмәү аркасында, Вәли белән Гафифә арасында туа. Гафифә, театрга бармас өчен, оялуын да сәбәп итә, кеше аз була, димәк, кызык булмас дип тә карый, өстенә күлмәге юклыгына сылтамакчы була. Ләкин каршылык аларның бергәләп театрга китүе белән чишелә, Вәли белән Гафифә арасындагы ярату хисе каршылыкны чишә.

Икенче күренештә ярдәмче каршылык Факиһә белән Хәбибрахман арасында туа. Сәбәбе шул ук – театрга бару. Факиһә – лидер, бик җитез, гайрәтле килен, аның кешедән бер дә калышасы килми, көнчелек тә бар. Хәбибрахман исә – балалыктан чыгып бетмәгән бай улы, бераз томана, буйсынучан, каршы төшеп үзен яклый алмый, ул өйдә утыруны ярата, әкрен холыклы, беркатлы, хәйләкәр, ләкин хәйләсе дә балаларныкы кебек. Бу каршылык та Факиһә белән Хәбибрахманның театрга китүе белән чишелә, ләкин монысын инде Факиһәгә буйсыну хисе чишә.

Өченче күренештә Биби белән Фатих арасында каршылык бара. Фатих Хәмзә байның өйдәме-юкмы икәнен сорый. Биби әйтми. Чөнки Фатих Бибигә ошый, ләкин Биби аңа ышанып җитә алмый. Моны белгән егет Бибине котырта, үчекли.

Шушы ук күренештә Хәмзә бай белән Биби арасында каршылык чыга. Хәмзә бай Бибидән риза түгел, аны аңгыралыкта гаепли. Биби исә Хәмзә байның һәрчак ачуланып, кычкырынып торуын яратмый. Бу каршылык Бибинең өйдәгеләр театрга киткәнне әйтүе белән чишелә.

Еш кына драма әсәрләрендә ярдәмче каршылыкларны төркемләргә, бергә тупларга мөмкин. Бу вакытта әсәр буенча киңрәк гомумиләштерүләр ясарга була, каршылыкларның үзенчәлеге әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрне аңларга да ярдәм итә. Мәсәлән, беренче, икенче, өченче ярдәмче каршылыклар – матур, гадәти, гаиләдә яки егет белән кыз арасында була торган каршылыклар. Дүртенчесе – ямьсез, хуҗа белән хезмәтче арасындагы бер кешене түбәнсетү, җәберләү белән бәйле каршылык.

Драма әсәренең буеннан-буена төп каршылык турында сүз бара, вакыт-вакыт, һәр ярдәмче каршылык эчендә диярлек, әлеге төп каршылык әйтелә. Төп каршылыкны әсәрнең темасын ачыклап билгеләү җиңелрәк. Мәсәлән, шушы ук пьесадан «әсәр ни турында?» дигән сорауга җавап биреп карыйк. Әсәр беренче театр куелу турында. Шунда ук капма-каршы ике лагерь да, төп каршылык та күренә. Аның сәбәбе беренче театр куелу вакыйгасы икән. Бер яктан, Хәмзә бай театрны куйдырмаска йөри. Икенче яктан, аның балалары һәм якыннары театрга китеп бетәләр. Димәк, каршылык Хәмзә бай белән аның балалары һәм якыннары арасында булып чыга.

Төп каршылыкны тикшерү әлеге капма-каршы лагерь – бу очракта Хәмзә бай һәм аның балалары, якыннары хакында – тулырак мәгълүмат бирә, аларның холыкфигылен, кешеләргә, дөньяга мөнәсәбәтен, яшәү рәвешен күрсәтә.

Шунысын да әйтергә кирәк: драма әсәренең исеме һәрвакыт диярлек тема белән бәйле була. Драма әсәренең сәхнә өчен язылуы аның нәрсә турында сөйләвен исемгә чыгара, исем үзенчәлекле реклама ролен дә үти, әсәрнең темасын алдан ук әйтеп куя.

Драма әсәрендә әдип образы катнашмый, автор мөнәсәбәтен, фикерен ачыклау, димәк, идеяне билгеләү катлаулы була. Ләкин язучы карашын әсәрне өйрәнү барышында каршылыкта да, драматургның геройларны сурәтләвендә дә, катнашучыларның теле аша да күрергә мөмкин, пьесаның корылышы, әсәрдә нинди мәсьәләләр күтәрелүе дә шул турыда сөйли. Барыннан да ныграк әсәрнең соңгы пәрдәсе, төп каршылыкның ничек чишелүе язучы фикерен, идеясен күрсәтеп тора. Яңадан үзебез анализлый торган әсәргә әйләнеп кайтыйк. «Беренче театр» Хәмзә бай балаларының һәм якыннарының театрга китүләре белән төгәлләнә, театр куюга каршы көрәшкә чыккан Хәмзә берни эшли алмый, көлкегә кала. Язучы, каршылыкны шулай чишеп, нәрсә әйтергә тели соң? «Беренче театр аңа каршы көрәшүчеләр булса да куелды, бу каршы кешеләр җиңелде, көлкегә калды» диме? Әйе, шулай. Драма әсәрендә мондый шәхси (субъектив) идеядән тыш объектив идея дә бик төгәл билгеләнә. Чөнки әсәрдәге ике лагерь, каршылыкның сәбәбе үк ниндидер гомумиләштерүләргә, зур фикерләргә ишарә ясый.

Безнең әсәрдә Хәмзә бай белән балалары һәм якыннары арасындагы каршылык – яңалык белән искелек арасындагы мәңгелек тартышның бер күренеше ул. Ләкин яңалык, нинди генә киртәләргә очрамасын, барыбер җиңеп чыга, тормыш шулай алга бара. Бу – әсәрнең объектив идеясе.

Әлбәттә, без караган мисал – «Беренче театр» әсәре – кечкенә, кыска пьеса, мәктәптә аны тулысынча өйрәнергә була. Зур, күләмле сәхнә әсәрләрен тикшергәндә исә, анализ өчен төп пәрдә һәм күренешләрне, иң мөһим урыннарны аерып ала белергә кирәк.

Драма әсәренең сәхнә өчен язылуы аның белән эшләүгә нык тәэсир итә. Без, теләсә нинди сәнгать әсәрен шартлы, ягъни гадәти тормышка тәңгәл түгел, дибез. Ә инде театрлаштыруга корылган драма шартлылык алымнарын тагын да киңрәк файдалана.

Бу барыннан да элек катнашучыларны сурәтләүдә күренә. Драма әсәренең герое кайсыдыр ягы белән бүтәннәрдән аерылып тора. Мәсәлән, «Беренче театр»дан Хәбибрахманның, «олы сабый» булса да, диван артына качып утыруы һәм «тычкан бар» дигәч сикереп чыгуы шул күпертүнең, шартлылыкның бер мисалы түгелмени?!

Катнашучыларның холык-фигыле аларның сөйләменә чыга. Мәсәлән, Хәмзә бай, гади сөйләм гыйбарәләре кыстырып кына калмый, бик тупас сөйләшә. «Кая, кил, нәрсә терәлеп торасың», «Һай, бәдбәхет! Күзең чыккан нәрсә! Бар, кит, күземә күренмә», – дип кычкыра ул. Хәмзә бай ике сүзнең берендә кемнедер сүгә, кемгәдер яный. Аның тупас, надан, явыз холыклы булуы сөйләменә үк чыккан. Башка персонажларның да үз сөйләү рәвеше бар. Шуңа күрә мәктәп анализы катнашучылар сөйләменә аерым игътибар бирергә тиеш.

Драмада хәлләр-вакыйгалар да, портретлар, аңлатмалар, вакыт-урын да геройлар сөйләмендә ачыклана. Икенче бер геройның холык-фигыль сыйфатлары да башкалар сөйләшүендә күренә башлый. «Зинһар, тизрәк була күр! Әгәр каенатай кайтып керсә, аннары харап эш. Ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс», – ди Вәли.

«Әти орышмас микән? Без чыгып киткәнче кайтып керсә генә ярар иде. Бармый калыр идек. Хатын ул әтинең гадәте начар икәнен белми. Беркөнне Гали хаҗи Гаптерахманы белән чәйгә кергән өчен дә колагымны шулай итеп борып алды. Күзләремнән утлар күренде», – ди Хәбибрахман.

Катнашучылар еш кына сюжет үсеше таләп иткәнгә түгел, бәлки язучы укучыга яки тамашачыга нидер аңлатырга теләгәнгә сөйләшәләр. Бу максаттан драматург ярдәмче геройлар да кертергә мөмкин. Мәсәлән, без карый торган әсәрдәге Фатих шундыйлардан. Бу образ аша автор Хәмзә байның хезмәтчеләренә дә каты булуын, ләкин аларның да хуҗаны санга сукмавын күрсәтә. «Кеше бәйрәм итә дә итә, мин дә бераз бәйрәм итеп аласы иде. Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк. Бәйрәм булды исә, ишек төбе сакла. Көне буе байга килгән бер кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да кар көрә! Юк инде, булмас болай итеп», – ди ул, ризасызлык белдереп.

Катнашучылар сөйләме драма әсәренең жанр сыйфатларын калкыту ягыннан, көлке яки фаҗигалелек тудыру өчен дә хезмәт итә. Мәсәлән, Хәмзә байның мәдрәсәдә егылуын сөйләгән монологы, Вәли белән Биби арасындагы сөйләшү көлдерү өчен кирәк. Хәмзә байның «җыен аңгыра безгә җыелган» дию анының үзенә бәя булып яңгырый.

Шартлылык алымнары буларак, драма әсәре кабатлаулардан иркен файдалана. Мәсәлән, «Беренче театр»да Гафифә Бибине кислота алырга җибәрүе, ә анының киез каталар күтәреп кайтуы хакында сөйли. Хәмзә бай исә Хәбибрахманны Хисмәткә җибәреп, улының кисмәк күтәреп кайтканлыгын бәян итә. Шул рәвешле автор көлке тудыра, Хәбибрахманны Биби белән тигезләп куя.

Драма төре чамадан тыш арттыру, күпертү (гипербола, гротеск) алымына еш мөрәҗәгать итә. Катнашучылар биредә йә үтә чыккан надан, йә бик батыр, йә бик үзсүзле, гадел сурәтләнә, бу сыйфатлар гадәттән тыш калку бирелә.

* * *

Әдәбият белемендә драма төрен өч жанрга бүлү яшәп килә: трагедия, комедия һәм драма. Мәктәп методикасы да әлеге төшенчәләр белән эш йөртә. Бүленеш әсәрнең каршылыгы, анының асылы, эчтәлегенә бәйле. Без трагедиянең нигезендә – трагик, комедиянең – көлке, драманың нигезендә җитди каршылык ята дип сөйлибез.

Комедия – драма төренең нигезендә иҗтимагый яки шәхси кимчелекләрдән көлү ята торган жанры. Анын үзәгенә көлке каршылык – чынбарлык һәм хыял, хакыйкать һәм күзаллау, матурлык һәм ямьсезлекнең тәңгәл килмәве куела.

Комедиянең чагылдыру өлкәсе булып аерым кешеләр яки тулы бер җәмгыятькә хас кимчелекләр тора. Мәсәлән, Г. Камалның «Бүләк өчен» комедиясендә сәүдәгәр-мещаннар катлавыннан булган аерым кешеләрнең байлыкны бар нәрсәдән, хәтта улының бәхетеннән дә өстен куюы сурәтләнә. Ә инде «Безнең шәһәрнең серләре» әсәре татар җәмгыятендәге наданлык, кирелек, бозыклык, икейөзлелек, яңалыкка дошман булу, усаллык кебек сыйфатларны ача.

Комик каршылык еш кына аңлашылмаучылык, очраклылыкка нигезләнә. Ләкин көлке жанр булуга карамастан, комедия тирән гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә.

Көлкеле каршылык холык-фигыльләр каршылыгын файдалана. Ләкин, драма һәм трагедиядән аермалы буларак, комик каһарманның табигате үзгәрми, үсештә күрсәтелми. Комик геройның мәгънәсезлеген, кимчелекләрен күрсәтү, шуны юмор яки сатира дәрәҗәсендә кире кагу комедиянең төп юнәлешен билгели.

Комедиядә тудырылган көлке дөньяга авторның идеалы каршы куела. Кайвакыт бу идеал уңай геройлар рәвешендә күрсәтелә. Күп кенә комедияләрдә барлык геройлар да тискәре булып (Г. Камалның «Банкрот»ы), комедиядә берләнбер «уңай герой» – авторның көлүе дияргә туры килә.

Холык-фигыльләрнең комиклыгы җәмгыять тормышындагы тискәре күренешләр хакында сөйли. Кешегә хас тискәре сыйфатлардан көлеп, комедия җәмгыятьне әлеге сыйфатлардан арындырырга тели. Шуңа күрә, проблемалар ягыннан караганда, комедия әхлакый мәсьәләләр куя, шуларны чишү юлларын эзли.

Комедия драма төрендә иң калку, иң истә калырлык типлар тудыру сәләте белән дә аерылып тора. Кешеләрдәге көлке якларны күрсәтү өчен, авторлар чиктән тыш арттыру һәм тузга язмаганча күпертү алымнарына мөрәҗәгать итә. Холык-фигыль каршылыгын үзәккә куюю аларны берьяклы, ләкин көлдергеч ясый. Комик герой нинди генә хәлләргә тарыса да, тамашачы аны кызганмый, жәлләми. Чөнки әлеге образның бары тискәре ягы гына тамашачыга күрсәтелә, башка сыйфатлар бөтенләй күләгәдә кала. Комедиядә авыр, трагик чишелеш булмавы да әлеге сыйфаттан үсеп чыга.

Теге яки бу тискәре сыйфатны көлкегә әйләндерер өчен, әлбәттә, аны нык арттырып, күпертеп сурәтләргә кирәк. Комедия шундый, күпертерлек вакыйганы сайлап ала. Мәсәлән, «Банкрот»та акчалар «урлату»ны оештыру һ. б. Байлыгын күбәйтү өчен, юләр булып яшәргә риза Сиражетдин, әлбәттә, «гадәти» тип түгел. Моңа теләсә кем бара алмый.

Комедиядәге көлке тудыручы детальләрне күзәтү дә кызыклы нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә. Мәсәлән, Хәмзә байның, чәч алучы килмәс борын башын сабынлап чыгып, аягын сала алмый интегүе, Хәбибрахманның акча санавы яки Мәскәүгә баручы Сиражетдингә унбиш кеше туярлык ризык хәстәрләү, – көлке дә, геройлар табигатенә бер сызык – дәлил дә. Шулай итеп, комедия жанры, төр үзенчәлекләренә таянып анализланса да, үзенә генә хас алымнардан файдалана. Мәктәп анализы исә шуларны барлый, күзәтә, нәтиҗәләр ясый.

* * *

Драма әсәрләрен өйрәнүгә кереш дәресләр, әсәрнең үзенчәлегенә карап, төрлечә булырга мөмкин. Әдәби, тарихи аңлатмалар бирүче, анализга юл күрсәтүче кереш дәресләр дә һәм шәхси тәҗрибә, биография файдаланып үткәрелгән кереш дәресләр дә уздырыла ала. Ләкин төрнең үзенчәлекләре кереш дәресләргә дә йогынты ясый, аларны үзгәртә. Драма әсәрләре программада бик аз булу сәбәпле, кереш дәресләрдә биографик материаллар, әсәрнең язылу тарихы белән бәйле аңлатмалар һәрвакыт кирәк була. Драматургның әсәрләрен укучыларга тәкъдим итү, китапларыннан күргәзмә оештыру алымы да кереш дәресләрдә нәтиҗәле.

Драма әсәре шул чор, язылу вакыты өчен үткен булган проблемаларга мөрәҗәгать итә, нәкъ көн үзәгендә булган мәсьәләләрне күтәрә. Шуңа да дәвер турында сөйләү киңрәк һәм төгәлрәк, шул заман кешеләрен кызыксындырган, борчыган һәм пьесада чагылыш тапкан проблемалар буенча аңлатмалар бирү кирәк.

Мәсәлән, Г. Камалның «Беренче театр» пьесасын уку алдыннан театр куела башлау, татар театры тарихы, шул чорда театр кую өчен барган көрәш турында кыска, гади, аңлаешлы сөйләү әйбәт булыр.

Драмаларның төзелеш үзенчәлекләре аерым төшенчәләргә аңлатмалар бирүне сорый. Мәсәлән, беренче тапкыр бу төр әсәр белән таныша башлаганчы ук *сәхнә, пәрдә, күренеш, катнашучы* кебек сүзләрне аңлату таләп ителә. Аннары инде, драма әсәрләрен өйрәнү катлауланган саен, анализ өчен *сөйләү* (монолог), *сөйләшү* (диалог), *ярдәмче каршылык, үзәк каршылык, пьеса, спектакль* кебек төшенчәләр алына.

Драма әсәрендә автор аңлатмаларының булмавы катнашучыларны күз алдына китерү эшен авырайта. Шуңа күрә кереш дәрестә катнашучылар исемлеге белән таныштыру аерым игътибарга алына. Чөнки драма әсәрен анализлау геройларны тулы характер буларак аңлауга корыла. Укучы, гадәттә, каршылык чишелгәндә генә геройларны күзаллый башлый. Катнашучылар исемлеге исә катнашучыларның бер-берсе белән нинди мөнәсәбәттә торуын санап бирә, кайбер әсәрләрдә кыскача сыйфатлама, киенү рәвеше дә искәртелә. Катнашучыларны ничек атау, ничек тәкъдим итү аларга язучы мөнәсәбәтен дә белдереп тора. Кайчак исем-фамилияләр герой холык-фигыленә ишарә ясый, аларның кушаматлары бирелә. Әгәр мөмкин булса, теге йә бу рольне уйнаучыларның әлеге рольдә төшкән фотографияләрен күрсәтү яхшы. Бу алым әсәрнең сәхнәгә куелу тарихын күзәтү белән үрелеп барганда, драманы сәхнәдә күзалларга, катнашучыларның тышкы кыяфәтен — портретын — драматург һәм режиссёр тәкъдим иткән рәвештә күрергә ярдәм итә. Кереш дәрестә спектакльдән өзекләр тыңлау — катнашучыларның «тавышын ишетү», аерым мизансцена яки декорацияләрнең рәсемен карау әсәрнең «сулышын», геройлар табигатен укучыга җиткереп, уку һәм анализ эшен җиңеләйтә.

Уку ягыннан драманы тикшерү лирик төрне анализлауга якынрак тора. Әсәр аны өйрәнә башлар алдыннан гына укырга бирелә. Аны бүленмичә, бер утыруда укып чыгу яхшы. Өйдә укырга биреп җибәргәндә, эзләнү төсендәге сораулар-биремнәр тәкъдим итү укучыларны кызыксындыру ягыннан файдалы. Әсәрдә күренеп тормый, ләкин игътибар белән укыганда аңлашыла, табыла торган, әсәр тукымасы белән бәйле өлеш-элементлар эзләү үзенчәлекле эш алымына әйләнә. Мәсәлән, Г. Камалның «Беренче театр»ын укырга бирер алдыннан «Әсәр геройлары барысы да кемнән куркалар?» дигән сорау урынлы.

Драма әсәрен дәрестә уку да аерым кагыйдәләргә буйсына. Әсәр сөйләү-сөйләшүдән, искәрмәләрдән тора, катнашучыларның холкы исә сөйләмендә ачыла. Шуңа күрә драма әсәрен уку персонажның характерын, сөйләү рәвешен күз алдына китереп һәм башкалар да тоярлык итеп башкарылса әйбәт. Ләкин мондый уку күнекмәләр булдыруны сорый. Укытучы укуын, барыннан да бигрәк спектакльдән өземтәләр тыңлауны, рольләргә бүлеп укуны үткәрергә кирәк. Укучылардан тоташ текст итеп кычкырып укыту да рольләргә бүлеп укуның башлангыч төсен ала. Гомумән, методистлар рольләргә бүлеп укуны әсәрнең эчтәлеген ачыклаганнан, аны бер кат укыганнан соң гына оештырырга мөмкин дип саныйлар. Рольләргә бүлгәч, укучыларның үз роле турындагы фикерләрен тыңлау кирәк була: алар геройны ничек итеп күз алдына китерәләр, геройга нинди сыйфатлар хас, ул нинди кеше һ. б. Рольләргә бүлеп уку — геройның халәтен, холкын сөйләмдә күрсәтеп, билгеле бер интонация белән уку. Әсәрне сыйныфта бергәләп уку — кабатлап уку дигән сүз ул. Шуңа да аңлатмалар әсәр эчтәлеген тирәнрәк аңларга, катнашучылар сөйләме аша аларның холкын билгеләргә һәм әсәр телен бәяләргә ярдәм итә. Димәк, текстны игътибар белән уку, аңлатмалар бирү пьесаны анализлауга юл ача.

Әйткәнебезчә, драма әсәрләрен анализлау тәртибе автор артыннан бару юлын кулай күрә. Шуңа күрә тикшерү беренче пәрдә яки андагы берничә күренешне бергәләп күзәтүдән башлана. Гадәттә, драма әсәрендә бу өлеш сюжет сызыгының башлам элементына таңгәл, ул укучыны урын һәм вакыт, катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләр белән таныштыра, туачак каршылыкның җирлеген төзи. Боларны аңлап үтү анализ өчен мөһим. Мәсәлән, Г. Камалның «Беренче театр» комедиясен өйрәнә башлаганда, әсәрнең беренче күренеше укыла-тикшерелә. Бу вакытта укучылар, Вәли һәм Гафифә, аларның холкы белән танышудан тыш, Хәмзә бай һәм аның гаиләсе турында белешмә алалар, Вәлинең Хәмзә бай кайтканчы чыгып китәсе килүгә игътибар итәләр. Төп каршылыкның сәбәбе — шәһәрдә беренче театр куелуы мәгълүм була. Моннан тыш, Гафифә белән Вәли, Биби белән Вәли сөйләшүе Биби образын да шактый тулы яктырта. Шулай итеп, драманы өйрәнә башлаганда ук, алга таба сүз алып барылачак мәсьәләләр ачыкланып, аерылып куела, укучыларда әсәргә карата мөнәсәбәт тудырыла.

Г. Камалның «Беренче театр»ыннан кала, мәктәптә өйрәнелә торган башка драма әсәрләре күләмле, катлаулы сюжетка ия. Аларны тулы килеш сыйныфта укый һәм анализлый бару мөмкин эш түгел. Анализның төп өлеше укучылар мөстәкыйль укып-танышып килгән пәрдә-күренешләрне бергәләп тикшерү төсен ала, кайбер урыннары укучылар тарафыннан өйдә күзәтеп узыла.

Драма әсәрендә автор аңлатмалары булмау анализ эшен шактый авырайта. Укытучыга хәрәкәт үсешен, вакыйгалар эзлеклелеген, геройлар эш-гамәлләренең туры килү-килмәвен укучылар аңлыймы-юкмы, шуны күзәтергә һәм, кирәк икән, аңлатмалар бирергә туры килә. Сөйләшү-сөйләү, искәрмәләрнең эчке мәгънәсенә игътибарны юнәлтү мөһимлеге дә бәхәссез.

Драма әсәрен уку-аңлау укучыдан хыялын эшкә җигүне таләп итә, хәл-вакыйгаларны сәхнәдәгечә күз алдына бастыруны сорый. Бу эш кай ягы беләндер режиссёр хезмәтенә якын, шуңа күрә дәрестә махсус иҗади алымнар файдаланыла. Шуларның берсе — укучылардан мизансценалар төзетү. Мизансцена — актёрларның теге йә бу мизгелдә сәхнәдә урнашу тәртибе. Аны төзү өчен күренешләрне укытучы тәкъдим итә йә укучылар сайлап алалар да ни өчен шушы күренешне сайлаулары турында аңлатма бирәләр. Аңлатманы өйдә язып килергә мөмкин. Мизансценаларны укучы мөстәкыйль төзи. Аннары, бергәләп, укылган мизансценаның уңышлы якларын һәм кимчелекләрен тикшерү, тәкъдимнәр кертү кебек эшләр башкарыла. Алымны катлауландырып, актёрларның кайда урнашуларын гына түгел, торышларын, хәрәкәтләрен, кыланышларын да билгеләүне максат итеп куярга мөмкин. Спектакль карагында, исләрендә калган мизансценалар белән чагыштырырга, бәя бирергә дә була. Бу алым әсәрне күзаллау эшен җиңеләйтә.

«Режиссёр аңлатмасы» алымы — аерым бер күренеш алдыннан сәхнәне күз алдына китерү. Биредә инде декорацияләр, яктыртылыш, геройларның үз-үзен тотышы, сәхнәдәге предметлар һ. б. игътибарга алына. Пьесаның беренче күренешенә «режиссёр аңлатмасы»н укытучы бирә.

Характерларны тикшергәндә, телдән сурәтләү алымы уңышлы. «Сез геройның тышкы кыяфәтен ничек күрәсез? Герой ничек киенгән?» кебек сораулар образны күз алдына китерергә, аңа кагылышлы репликаларны эзләргә мәҗбүр итә.

Шулай ук күрсәтмә материаллардан: декорация эскизларыннан, фотоларыннан файдалану яхшы. Мондый чаралар спектакльне күзалларга булыша.

Югары сыйныфларда укыган пьесага, караган спектакльгә бәяләмә (рецензия) язу, спектакльдәге актёрлар уенын бәяләү, режиссёр варианты белән пьесаны чагыштыру кебек алымнардан файдаланырга мөмкин. Драма әсәрләренең катлаулылыгы алдан ук сораулар төзеп, бу алымнарны билгеле бер калыпка нигезләнеп башкарырга мәҗбүр итә. Түбән сыйныфларда мондый эшнең җиңелрәк варианты — пьеса яки спектакльгә реклама язу, әсәр турында фикер әйтү кебек эш төрләрен башкарырга мөмкин.

Анализ вакытында бер геройның сөйләмен аерып алып күзәтү алымы отышлы. Бер яктан, катнашучы сөйләме геройның эчке дөньясын, холкын, хис-кичерешләр тирәнлеген, мәдәни һәм иҗтимагый дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Икенче яктан, һәр сүз, гыйбарә, җөмлә сюжетны хәрәкәткә китерә, алга этәрә.

Драма әсәрләрен анализлаганда, катнашучыларга сыйфатлама бирү, план төзү, проблемалы сорауларны тикшерү, эзләнү алымнары да киң кулланыла.

Инде әйткәнебезчә, йомгаклау дәресләре еш кына пьесаның соңгы күренешен өйрәнгәндә башланып китә. Монда әсәрнең каршылыгы чишелә, ягъни чишелеш аркылы шушы әсәр хакында нәтиҗәләр чыгарырга урын бар.

Драма әсәрләрен йомгаклау дәресләрендә әсәрне өйрәнү барышында күтәрелгән мәсьәләләр гомумиләштерелә. Әсәр чикләреннән чыгып китеп, әлеге проблемаларны бүгенге көн, тормыш белән бәйләргә мөмкин. Шулай ук бу дәресләрдә әсәрнең төрле тәкъдим ителеше-куелышы, режиссёр аңлатуы белән таныштырырга була. Драма тикшерү эшен спектакль карау белән тәгәлләү бигрәк тә яхшы. Декорация, костюмнар, мимика-хәрәкәтләр, образларның нинди чаралар ярдәмендә ачылуына, вакыйгаларның гәүдәләнү үзенчәлегенә игътибар итеп, ахырдан фикер алышу, пьеса белән спектакльне чагыштырып бәяләү, бәяләмә-рефератлар яздыру, шул рәвешле әсәрне анализлауга нокта кую укучы өчен кызык һәм нәтиҗәле була.

Соңгы дәрестә пьесаның сәхнә тарихына киңрәк тукталып, театр тарихы белән бәйле альбомнар карарга, истәлекләр укырга, драматургның башка әсәрләрен уку өчен тәкъдим итәргә мөмкин, иҗаты турында сөйләшергә вакыт калдыру да еш очрый. Укытучылар йомгаклау баскычында рольләргә бүлеп укуны да файдаланалар. Ул бигрәк тә укучының геройлар характерын никадәр тирән аңлавын тикшерү чарасы хезмәтен үти.

Йомгаклауда укытучы әсәрнең театр тарихы һәм драматургиядә тоткан урыны, роленә туктала. Пьесаның әһәмияте авторның иҗтимагый позициясе белән бәйле. Чөнки драма әсәре чорга, җәмгыять тормышына хас үткен проблемаларны күтәрә, аларга үз мөнәсәбәтен белдерә, дидек. Шуңа күрә әсәр турында сөйләшү әлеге проблемаларга бәйләп автор шәхесе, аның гражданлык позициясе турында фикер алышуга барып тоташырга мөмкин.

Шулай итеп, драма әсәрләрен өйрәнүнең һәр баскычы үзенчәлекле. Ул әсәрнең төр һәм жанр сыйфатларын, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәләрен, әсәрнең үз нечкәлекләрен исәпкә ала.

Дания Заһидуллина,
филология фәннәре докторы, профессор

Драматургиядә гасырлар дәвамында әсәр теленең ике төре формалашкан: 1) драматик текстка турыдан-туры катнашы булмаган автор сөйләме – ремарка; 2) драматик сөйләмнең төп берәмлеге булган диалог. Диалогның состав өлешен һәм нигезен реплика тәшкил итә. Катнашучыларның санына карап, диалог өч төргә бүленә: 1) саф диалог; 2) монолог; 3) полилог. Бу төр диалогларның барысы да, урынына карап, бик кирәкле һәм әһәмиятлеләр. Шулай да драмада иң күп кулланылганы һәм драматик сөйләмнең нигезен тәшкил иткәне – диалог.

Диалог – ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе, бәхәсләшүе, фикер алышуы. Әңгәмәдәшләрнең репликалары һәм каршы репликалары диалог төзиләр. Сәхнәдә вакытның гаять чикләнгәнлеге драматик диалогның тәэсирлелеген, үтемлелеген һәм шул ук вакытта кыскалыгын, гадилеген сорый. Әмма диалоглар, сәхнәдәге вакыйгаларны үстереп кенә калмыйча, персонажларның характерларын, типик һәм индивидуаль сыйфатларын, геройларның эчке кичерешләрен, уйларын, шулай ук һәр персонажга, сәхнәдә барган һәр вакыйгага автор карашын да белдерергә тиешләр. Диалогларның күптөрлелеге һәм аларны төзү сәнгате – драматурглык осталыгының бер сере. Оста драматург, диалогларны алып баруның төрле алымнарын кулланып, әсәрнең идеясен бөтен тулылыгы белән ачуга, персонажларга төрле яктан характеристика бирүгә ирешә.

Г. Камалның иҗат практикасында менә шундый алымнарның берсе – *дигәннән, дигәч* сүзләре ярдәмендә диалог төзү. Мәсәлән, «Банкрот» комедиясендә бу сатирик алым автор тарафыннан гайбәтче хатыннарны фаш итү өчен файдаланыла. Гарифә һәм Мәликәнең бар белгәне – кеше турында начар хәбәр тарату, кешене әшәке сүзләр белән пычрату. Алар, берсен берсе уздырырга теләп һәм берсен берсе бүлдереп, мөмкин кадәр күбрәк гайбәт сатарга ашыгалар, шуңа күрә дә, аерым сүзләргә ябышып, бернинди бәйләнешләре булмаган вакыйгалар, кешеләр турында сөйләп китәләр. Сүз йорт хуҗаларының бламажиларыннан башлана:

«Гарифә. «Бламажи» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Йә бламажилары оемагандыр әле. Йә җилемен аз салганнардыр.

Мәликә. Бламажилары оемаган дигәннән исемә төште, беркөннәрне мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лычкылдап тора.

Гарифә. Андый була ул, әнә беркөнне мин читекче Таҗиларга чәйгә барган идем. Кабарткан паштитлары менә нәкъ такта шикелле булган. Бөтенләй менә үзе такта шикелле, үзе ике куллап сындырып булмаслык каты булган иде»[1].

Бламажи оюу бу репликаларда үрдәк бөккәне пешү белән бәйләнә. Ләкин бөккән, бламажи, паштит – биредә тоташтыргыч сүзләр генә. Репликаларның угы чүпче Әхмәтҗан, читекче Таҗи хатыннарының гайбәтен сату, аларның уңмаганлыкларыннан көлүгә юнәлдерелгән. Шуңа күрә дә дүртенче репликада беренче планга кеше үзе чыга:

«Мәликә. Читекче Таҗи дигәннән исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде. Ончы Шакир улына кияүгә биргәннәр иде, ишеткәнең бармы, чибәр торалар микән?

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 146 б.

Гарифә. Белмим, чибәрдер, сорашканым юк, каенанасының сүзен бер дә тыңламый диләр иде»[1].

Тәгъбирләр арасындагы очраклы бәйләнеш – гайбәтче хатыннар теленең үзенчәлеге. Героинялар үзләренең белгәннәрен әйтергә шулкадәр ашыгалар, хәтта сүзнең элек ни турыда барганлыгын да оныталар.

Г. Камалның сатирик угы Сиражетдиннең кабахәтлеген фаш итүгә генә юнәлмәгән. «Банкрот» комедиясенең уңышы да шунда: автор буржуаз-мещан тормышының бөтен түбәнлеген, җирәнгечлеген төрле яклап ачарга тырыша. Гайбәтче хатыннар диалогы – татар мещанкаларының бөтен уй-фикерләре, интереслары, кунакка йөреп, кеше гайбәтен сату, кием-салым, ашау-эчү турында гына булуын күрсәтер өчен бирелгән бер алым. Персонажларның, кызып-кызып, кеше гайбәте сөйләргә тырышып, бер-беренең сүзен бүлдерүләре, вак детальләргә ябышып, бер объекттан икенчесенә бертөрле дә логик эзлексез күчүләре бу ике мещанканың тормыш түмен гайбәттә, кеше өстенә пычрак атуда табуларын фаш итә.

Диалогта һәрвакыт потенциаль хәлдә сүзне бүлү яши. Сөйләүче үз сүзләрен беткән дип уйламый, киресенчә, ул каршы репликадан соң дәвамлыкны күз алдында тота. Сүз өзелү, яңа хәбәрне, ничек кенә булмасын, әйтергә теләү диалогны үстерә. Әмма сүзнең мәгънә бәйләнешләре буенча бер-береннән ерак торган объектларга күчүе өчен бу гына җитми. Драматик диалог өчен персонаж репликаларының бер-берләре белән тыгыз семантик-грамматик бәйләнештә торулары, һәм мәгънә, һәм грамматик яктан бербөтен тема тәшкил итүләре зарури. Репликалардагы һәр сүзнең мәгънәсе яки грамматик формасы икенче репликадагы сүзләрнең мәгънәсе яки грамматик формасы белән тыгыз бәйләнергә һәм бер-беренә буйсынырга тиеш. Шулай булмый икән, сәхнәдә диалог төрле нәрсә турында сөйләнелгән таркау репликалар кушылмасына әйләнә. Гарифә, Мәликә репликаларының мәгънә ягыннан бербөтен булган диалог тәшкил итүе һәм ул диалогның җанлы, табигый агышының сере – сүзне башта әйтелгән репликага ялгап, икенче темага яки объектка борып җибәргәндә кулланыла торган *дигәннән, дигәч, димәктән* сүзләре кулланылуында. Сөйләү теленә хас бу алым диалогик сөйләмгә җанлылык кертә, шуңа күрә аны драматурглар еш кулланалар.

Диалогның төп төрләреннән берсе – монолог. Драма әсәрендә монолог – персонажның тамашачыларга озак кына сөйләп торуы яки аның кычкырып уйлавы. Персонажның икенче бер персонажга яки персонажлар төркеменә шулай озын итеп сөйләве дә монолог булырга мөмкин.

Монолог – персонажның фикерләвен, теләкләрен, сәхнәдә барган вакыйгага карашын бирер өчен – иң көчле чараларның берсе. Классик драматургларның психологик әсәрләрендә монологлар иң мөһим урыннарда, персонажның эчке кичерешләрен, аның катлаулы характерын тулысынча ачарга кирәк булганда гына кулланылалар.

Монологта фикер эшкәртелеп, төгәлләндереп бирелә, җөмләләр тулы һәм күбесенчә җәенке булалар. Диалогтан, репликадан үзгә буларак, монолог кушма җөмлә, хәтта катлаулы кушма җөмлә, катлаулы синтаксик конструкцияләргә дә бай. Монологларны урынсыз һәм чамадан тыш күп куллану пьесаның сәнгати көчен зәгыйфьләндерә, аның сәхнә әсәре буларак кыйммәтен киметә.

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 147 б.

«Бәхетсез егет»нең беренче редакциясендә Г. Камал да бу кимчелектән котыла алмаган. Нәтиҗәдә беренче редакция, «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз» кебек үк, сәхнә законнарына туры килми. Мәсәлән:

«Гайни. Менә килеп җитәр әле Закирың. Бу кадәр конарсыз нәрсә булыр икән. Күземә чуаш төсле күренә башлады менә, билләһи!.. **Котылырмын дип монда килсәм**, арба артына таккан **дегет лагуны шикелле**, һаман **артымнан һич калмыйча** иярен йөри. Тәмам теңкәмне корытып бетерде инде, казан төбе шикелле каралып, борыннарын, кашларын җыера да килә дә керә, килә дә керә, чисти туеп беттем инде, бер кабар җирем дә калмады»[1].

Монолог ясалма чыккан. Гайни сүзләрендә логика да юк. Ул башта, Закирың килеп җитәр, ди (тартым кушымчасы якынлыкны, иркәләүне аңлата). Шуның артыннан ук аның яманатын сатарга тотына, нәтиҗәдә Закир гайбәтен сөйләү озакка сузыла.

Икенче редакцияне эшләгәндә, Г. Камал моны истә тота һәм әлеге монологны Гайни – Биби диалогы белән алмаштыра, ә монологтан Гайнинең Закирга булган мөнәсәбәтен һәм аннан туюны белдергән чагыштыруны (югарыда бу сүзләр калын хәрефләр белән бирелделәр) бер реплика эчендә калдырып, күп өлешен сыза. Менә ул диалог:

«Биби. Әле ул Закир мондамыни?

Гайни. Монда булмый, кая китсен. Бер тиенгә мохтаҗ булып йөри. Казанда вакытта акчасы беткәч, качып **котылыйм дип, монда килдем**. Алай да котыла алмадым. **Дегет лагуны шикелле, артымнан калмыйча**, тик тагылып **йөри**»[2].

Икенче редакциядә диалогларга күчә бару Г. Камалның монологларны күп куллану чиреннән арынып бетүе дигән сүз түгел. «Г. Камал әсәрләрендә… бер кимчелек бар. Ул – бәгъзеләрендә монологларның артык озын булып китүе»[3], – ди Г. Сәгъди һәм мисалга беренче пәрдәдән Җәмилә монологын китерә. Безнеңчә, монда заман тәэсире, драматургиянең, әдәбиятның үсеш дәрәҗәсе дә берникадәр роль уйный кебек. Монологларның күплеге Г. Камалга гына хас нәрсә түгел. М. Б. Борисованың тикшеренүенчә, М. Горькийның беренче драмаларында да монолог зур урын тоткан[4]. Ләкин аның соңгы драма әсәрләрендә, киң социаль проблемалар күтәрелү сәбәпле, монолог, диалог, полилог белән алмашкан. Мондый үсеш Г. Камал әсәрләрендә дә сизелә. Бу – язучының семья, тәрбия мәсьәләләреннән тормышны киң полотноларда тасвирлауга күчә баруы нәтиҗәсе.

Драматургның индивидуаль стиле диалогларны төзү, характерларны көрәштерү алымнарында ачык күренә. Г. Камалның драматурглык стиленә хас диалог төрләренең берсе – диалог-бәхәс. Аның «Бүләк өчен» комедиясе тулысынча диярлек диалог-бәхәскә нигезләнеп язылган.

Билгеле булганча, сүз, вакыйгаларны сурәтләүдән тыш, объектка мөнәсәбәтне дә белдерә, шуңа күрә сүз өчен көрәш һәм билгеле бер сүзләр куллану шул сүз белдергән төшенчәләргә, күренешләргә персонажлар карашын да чагылдыра. Мещанка Хәмидә кичә генә Хисами хатынын *курнус Әсма* дип мыскыллаган, аның гайбәтен саткан

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 331 б.
[2] Шунда ук. – 45 б.
[3] Татар театры. – Казан, 1926. – 31 б.
[4] Учёные записки. – ЛГУ. – № 198. – Серия филологических наук. – Выпуск 24. – Л.: Изд-во ЛГУ, 1956. – С. 122.

була, чөнки икенче бер хатынның баерак булуы Хәмидәдә гарьлек хисе тудыра, ул аны күралмый. Әмма ситуация үзгәрә. Әсмабикәнең кодагый булу ихтималы, димәк, Хәмидәнең үзеннән баерак хатыннар белән тиң булу, асыл күлмәкләр киеп, «күкрәк киереп мәҗлесләрдә бергә түрдә утыру» перспективасы *курнус Әсманы*, хөрмәтләп, *Әсмабикәгә* үзгәртергә мәҗбүр итә. Хәмидә үзен «черегән» байлар тиңе итеп шулкадәр хис итә ки, үзе дә сизмичә, Әсмабикәне — кодагый, ә Хисамины кода дип атый башлый:

«Хәмидә. Җә, җә, Әсмабикә...

Әхмәтҗан. Кичә генә «курнус Әсма» дип йөриләр иде әле, хәзер инде бүген бикә дә булып җиткән.

Хәмидә. Бикә булмый ни, бикә шул. Әсмабикә кияүгә берлиант кашлы йөзек тә алдырып бирмәкче була, ди»[1].

Биредә Әхмәтҗан әле хатынының «бикә» сүзен куллануыннан мәзәк таба, ироние көлә. Әмма Хәмидә Әсмабикәне «кодагый, ә Хисамины кода дип атый башлагач, Әхмәтҗанның җиңелчә көлүе ачулануга әйләнә, чөнки Әсманы» кодагый, аның ирен кода дию инде буш сүз генә түгел, монда Әхмәтҗанга уйланырлык нәрсәләр бар. Аның өчен бу сүзләр байлар белән кода булу — дүрт-биш мең сум расход чыгу дигән сүз, һәм ул моңа теше-тырнагы белән каршы. Нәтиҗәдә диалог-бәхәс барлыкка килә:

«Хәмидә. Кияүгә дигән сәгатьне Хисами кода үзе...

Әхмәтҗан. Хисами кода түгел.

Хәмидә. Ярар ла инде, Хисами бай үзе Мәскәүгә барып ике йөз тәңкәгә алып кайткан, ди. [...] Әсма кодагый...

Әхмәтҗан. Тфү! Әсма да кодагый түгел бит әле!..

Хәмидә. Син үзең әле Газизәне биргән вакытта гомердә Хисами кода...

Әхмәтҗан. Кода түгел, дим!

Хәмидә. Хисами бай шикелле итеп бирә алмассың»[2].

Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендә диалог-комментарийлар еш очрый. Билгеле булганча, комедиядә автор үз алдына буржуаз җәмгыятьнең барлык якларын фаш итү бурычын куя һәм татар сәүдәгәрләрен, кадимчеләрен төрле шартларда, төрле урыннарда сурәтли. Биредә кадимчеләр өстенлек алган җәмгыяте хәйрия, «тәкъва», «диндар» татар сәүдәгәрләренең ресторандагы бозыклыклары, яңа обстановкада — клубта — тавыш, культурасызлык, татар сәүдәгәрләренең оясы булган көфер почмагы һәм аның әһелләре, ниһаять, театрда җәнҗал чыгарулар һ. б. сәхнәгә чыгарыла. Кыскасы, комедиядә татар буржуа тормышы төрле яклап сурәтләнә. Нәтиҗәдә комедия күз алдына бер-беренә сюжет сызыгы белән җитәрлек бәйләнмәгән берничә мөстәкыйль күренешләр җыелмасы кебек килеп баса. Ләкин сюжет — сәнгать чараларының тик берсе. Язучы әйтәсе килгән фикерен, материалның үзенчәлегенә яки башка сәбәпләргә карап, төрле чаралар белән ачарга һәм шул чараларның бу әсәр шартларында уңышлырагын сайлап алырга хаклы. «Безнең шәһәрнең серләре»ндә буржуазия тормышын төрле яклап сурәтләү һәм бу тормышның һәр ягына үз мөнәсәбәтен белдерү теләге язучыдан башка чара сайлауны таләп итә, һәм Г. Камал материалның үзенчәлегенә туры килгән һәм идеясен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган шундый чараны таба. Ул — диалог-комментарий.

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. — 1 т. — 83 б.
[2] Шунда ук. — 83 б.

Мәсәлән, дүртенче мәнзараның[1] өченче мәҗлесе. Шкафчы Хафиз тыштан суфи, дин юлында армый-талмый эшләүче, саф күңелле, динне хәрефенә кадәр тотучы булып күренергә тырыша. Әмма бу аңа яңарак фикерле кешеләрне мыскыл итәргә һәм үткән-барган кешеләр турында гайбәт сатарга, ягъни шәригатьтә хәрам саналган эшләр эшләргә комачаулык итми, Хафиз күргән-белгән кешеләренә «дару» исеме астында шәригать, хөкүмәт тыйган әфьюн сатудан да чирканмый. Автор, шундый «суфиның» чын йөзен ачу өчен, диалог-комментарий куллана:

«Себер бае. Ул нинди дару сата? [...]

Язучы. Әфиун ул, әфиун. Полиция белмәсен өчен, аны шулай дару дип әйтәләр.

Себер бае *(халыкка карап).* Шәп икән! *(Язучыга.)* Соң ул хәрам түгелмени?

Язучы. Ул ни эшләп хәрам булсын! Ул бит аракы түгел, хәрам булса, аны ишан хәзрәт тыяр иде. Ишан хәзрәт аны бик шифалы нәрсә ди. Әледән-әлегә мулла Әхмәтҗаннан берәр кадаклап алдырта. Бу кеше ишан хәзрәтнең бик якын кешеләреннән»[2].

Нәтиҗәдә диалог-комментарийда дин тоткасы булып күренгән Хафизның динне сүздә генә яклавы, үз файдасы өчен теләсә нинди хәрамлык эшләргә хәзер булуы ачыла. Диалог-комментарий динче карагруһчыларны фаш итүдә зур роль уйный.

Г. Камал әсәрләрендә диалогларның төрләре ситуацияләргә, вакыйгаларга, персонажларның характерларына карап сайланылып алына. Мәсәлән, «Бәхетсез егет» психологик драмасында Җәмилә һәм аның юлдан язган улы Закирның көчле кичерешләр эчендә булуы монологларны еш куллануны сорый. Киресенчә, «Бүләк өчен», «Безнең шәһәрнең серләре» комедияләрендә монологлар бик сирәк, чөнки аларда тасвирлана торган характерлар бөтенләй икенче. Әгәр драматург «Бүләк өчен»дә күбрәк диалог-бәхәс кулланса, «Безнең шәһәрнең серләре»ндә исә ул диалогның күп төрләрен файдаланган. Беренче мәҗлестә сәркәтибнең баштагы сүзләре монолог формасында булса, күп өлешендә диалог өстенлек итә. Җәмгыяте хәйрия утырышы, ресторан күренешләре диалогларга, параллель һәм диалог-комментарийларга нигезләнгәннәр. Ә менә өченче пәрдәдә (Печән базары) массовый күренешләр үзенә яраклы форманы – полилогны таләп итәләр, дүртенче мәҗлеснең күп өлеше полилогтан тора[3].

Полилогның беренче яралгылары «Бәхетсез егет»тә үк күренә. Йортта караклар булган, һәр кеше бу вакыйганы төрлечә каршы ала. Һәркем үзенә якын әйберләр турында уйлый һәм сөйли. Бернинди тәртип юк. Моны бер кешенең эзлекле, төрле якны күз алдында тотып сурәтләүне максат иткән монологы белән бирү кыен. Диалог кына да моны бирә алмый, чөнки һәркем үз күргәнен, үз белгәнен әйтергә ашыга, үз сүзен яклый, икенчесенең сүзен юкка чыгара. Моны бары полилог кына бирә ала. Драманың икенче редакциясендә ул шулай эшләнелә дә. Берничә персонажның бер үк вакытта сөйләшүе булган полилог шундый массовый күренешләрдә кулланыла:

(«Тәрәзәдән халык кычкыра: «Өегезгә карак керде, куа киттеләр».)

---

[1] Хәзерге телдә «пәрдә» сүзе урнашкан булса да, биредә без Г. Камал кулланган атаманы алдык.

[2] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 214 б.

[3] Нәрсә соң ул полилог? Драма әсәрләрендә полилоглар нинди роль уйныйлар? Катнашучыларның саны һәм үтә торган рольләренә карап, диалоглар ике, өч, дүрт һ. б. кеше сөйләвеннән торырга мөмкин. Берьюлы өч-дүрт һәм аннан да күп персонажлар катнашкан диалоглар полилог дип аталалар.

Сәгыйть. Ә?

Әхмәт	(һәммәсе бергә).	Ничә кеше?
Мәрьям		Харап булдык!
Кәрим		Карагыз!
Җәмилә		Ай Алла!
Гайшә		Тоттылармы?

Тыштан 1 нче тавыш. Икәү!
Тыштан 2 нче тавыш. Юк, бер генә.
Тыштан 3 нче тавыш. Ике, ике, үзем күрдем.
Тыштан 4 нче тавыш. Култык астында шкатулкасы бар.
Сәгыйть. Ә? [...] Акча шкатулкасын алганнар.
Мәрьям. Шкафтан минем брушкаларымны да алганнар.
Кәрим. Күпме?

Сәгыйть	(икесе бергә).	Биш йөздән артык.
Мәрьям		Сигез!»[1].

Полилог куллану драматургның осталыгы үсү белән тыгыз бәйләнгән. Тар семья рамкаларыннан чыгып, массовый күренешләр бирү полилог куллануны таләп итә. «Безнең шәһәрнең серләре» — полилоглар иң күп һәм иң уңышлы кулланылган әсәр. Һәм бу табигый. Г. Камал комедиядә бер-ике сәүдәгәр тормышын гына биреп калмый, бәлки барлык Казан сәүдәгәрләрен, аларның тормышларын, үз-үзләрен тотышларын төрле яклап сурәтли. Комедиядә алар төркемнәре белән биреләләр. Аларның барысы да сөйләшә, барысы да үз эшен эшли, алдый, алдана, көлә, мыскыллый, җәнҗал чыгара, хөр күңелле булырга маташа. Әсәрдә бер генә тип та икенчесен кабатламый, бер реплика да икенчесенә комачауламый, алар барысы да ансамбль берлеге — полилог төзиләр.

Комедиядә бөтенләе белән диярлек полилогларга нигезләнгән күренешләр очрый. Мисалга клубта лото-домино уены күренешен алырга мөмкин:

«Бишенчесе. Мәгез, бер башын мин эчтем. Мәгез, өч тә дүрт.

Беренчесе. Маладис ул эшеңә! Минем дүртле дублит китте.

Дүртенчесе *(Икенчегә)*. Нихәл, ни эшләттеләр? Ачасыңмы өчлекне?

Икенчесе. Бер дә ачмый торсын әле! Миндә аннан башкалары да җитәрлек әле! Мәгез, дүрт тә алты.

Дүртенчесе. Чын хәерсез икәнсең! Ябыгыз тизрәк шуның өчлесен.

Өченчесе. Шулай итикмени, мәгез, алайса, алты да биш булсын»[2].

Полилогта җанлы сөйләм бөтен тулылыгы белән файдаланыла. Геройлар, гадәттә, кыска, ләкин эчтәлекле репликалар, ким җөмләләр кулланып сөйләшәләр.

Полифоник диалог төзүнең кыенлыгы — анда берничә персонаж катнашуда. Шушы зур төркем эченнән теге яки бу персонаж берничә генә кыска реплика ташларга өлгерә, бу исә драматургка һәр персонажның характерын, аның йөзен ачарга зур кыенлыклар тудыра, һәрберсенең телен индивидуальләштереп, кабатламыйча бирү драматургтан гаять зур осталык таләп итә:

[1] *Камал Г.* Әсәрләр: 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. — 1 т. — 33–34 б.
[2] Шунда ук. — 197–198 б.

«Серый киемле. Кәрим, ни эшлисең анда?
Кәрим. Теге урын бик бәхетсез икән. Бары икене генә ябып калдым.
Гариф. Анда барып утырганчы, син менә монда өстәл астына кереп утыр!
Кәрим. Утырырмын шул, анда синең эшең булмасын! [...]
Лоточы. 60.
Серый киемле. Әйт шуны!
Гариф. Бая миңа кирәк иде ул. Бая алтмышлы фатирым янды!
Лоточы. 51.
Берәү. Үзеңә булсын.
Лоточы. 17.
Кәрим. Үктәбрис!»[1].

Биредә Кәрим үзенең хорафатларга ышануы, наданлыгы, тупаслыгы, әче теллелеге белән ике-өч репликада ук күз алдына килеп баса.

«Өйләнәм! Ник өйләндем?» комедиясендә Әхмәтнең кредиторлар белән чолганып алынуы полилог белән оста бирелгән. Әхмәткә берничә баласын туйдырырга, киендерергә кирәк. Әмма аның акчасы юк, моңарчы бурычка биреп торган итче, күмерче, сучы, кибетче, утынчы аннан акча даулыйлар:

«Күмерче *(Әхмәткә.)* Бай, бай! [...] Миңа теге ике кап күмернең генә акчасын биреп җибәрегез әле.

Әхмәт *(ни эшләрен дә белмичә).* Аһ! Кабер газабы.

Кибетче. Ие, ие, без менә мөнкәр-нәкирләр.

Итче. Йә, күп телеңә салынма, китер акчаны, минем эшем ашыгыч.

Күмерче *(тәрәзәдән карап).* Тпр-р-р-р-р! Атым китеп бара, кая, тизрәк акчамны биреп җибәр әле...

Сучы *(йөгереп килеп).* Анда минем дә атым бар. [...] Кайда, тизрәк булыгыз әле, көттермәгез әле. [...]

Бала *(йөгереп килеп, Әхмәткә сарылып).* Әти, әти! Миңа арба алып кайт.

Әхмәт *(сикереп торып).* Чәнчелегез, кадалыгыз! Бетте баш! *(Чыга башлый.)*

Һәммәсе бергә. Тукта, тукта, качма, кайда барасың? Җибәрмә! Кача алмассың!»[2].

Кыскасы, татар драматургиясе тарихында Г. Камал сүз остасы, персонажлар телен индивидуальләштерүнең беренче үрнәкләрен бирүче итеп кенә каралырга тиеш түгел. Аның драматурглык осталыгы, драматургия тарихындагы роле диалогик сөйләмне үстерүдә, диалогик сөйләмнең күп төрләрен беренче буларак куллануның гүзәл үрнәкләрен бирүдә күренә.

Искәндәр Абдуллин,
филология фәннәре кандидаты

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 202 б.
[2] Шунда ук. – 311–312 б.

«Көлү – бөек эш! Кеше көлүдән курыккан кебек бернәрсәдән дә шулай курыкмый. Көлү гаепленең җанын да, малын да алмый, ләкин ул аның көчен бәйли, һәм кеше, көлүдән куркып, башка бернинди дә көч туктата алмаган эштән тукталып кала»[1], – дип яза Н. В. Гоголь. Көлүнең мондый көчкә ия була алу сере – аның матур формаларга корылырга маташкан әшәкелекнең бушлыгын гади һәм үткен итеп ачып бирә белүендә. «Мәгънәлелеккә һәм реаль әһәмияткә ия булуга дәгъва иткән, матуррак тышкы кыяфәткә төренгән эчке бушлык һәм түбәнлек көлке тудыра... Әшәке нәрсә, матур булып күренергә маташканда, көлкегә әйләнә»[2]. Чын көлү тормыш күренешләрен тирәнрәк күрергә ярдәм итә, дөреслекне ялганнан аеру өчен арадашчы да була. Әмма көлүнең шундый тәэсирлелеге өчен үткен тел чаралары булу да мәҗбүри.

Тормыштагы барлык артта калган, тискәре күренешләрне, яңалыкка тешетырнагы белән каршы торган реакцион элементларны фаш итүдә, җәмгыятьнең аерым төркемнәрендәге начар сыйфатларны ачуда, мәгънәсезлекне, һәртөрле ваклыкны, кешелексезлекне, гомумән, барлык искелекне, консервативлыкны җимерүдә гади сөйләм элементлары, тиргәү лексикасы үзләре генә тиешле нәтиҗәне бирмиләр. Ә бу төр лексиканы еш куллану аның үтемлелеген, тәэсирлелеген югалтуга китерә. Өстәвенә гади сөйләм элементлары, тиргәү сүзләре күбрәк надан, тискәре персонажлар теленә хас кабахәтлек, алдау, бозыклык белән кискен көрәш үткенрәк, үтемлерәк тел-сурәтләү чараларын куллануны сорый.

Г. Камалның тел-сурәтләү чаралары арсеналында актив һәм яратып, оста файдаланылганы – халык теленең иң нечкә, иң бай күренешләреннән берсе булган күпмәгънәлелеккә, омонимия, омофония, омография, фразеология таркалуына һ. б. лексик-семантик, фонетик күренешләргә, чараларга нигезләнгән каламбур һәм сүз уйнату. Менә шуңа күрә дә Г. Камалның тел-сурәтләү чаралары куллану осталыгын тикшергәндә, каламбур һәм сүз уйнату турында дәшми үтү аның сатира һәм юмор осталыгы турында бернәрсә дә сөйләмәү булыр иде. Г. Камал татар драматургиясе тарихында, диалог төзү остасы буларак кына түгел, каламбур һәм сүз уйнатуны уңышлы һәм төгәл файдалануы белән дә атаклы.

Г. Камалны күргән-белгән, аның белән бергә эшләгән кешеләр беренче чиратта аның үткен, җор телле, тапкыр сүзгә аптырап калмаучан кеше булуына басым ясыйлар. «Галиәсгар абзыйда җавапны озак уйлап бирү гадәте юк иде. Ачы һәм тапкыр җавапка оста булганга күрә, аптырап калмый, [...] шунда ук, шул ук минутта ук җавап кайтара торган иде»[3], – дип яза «Эш» газетасында Г. Камал белән бергә эшләгән К. Әмири. Үткен, ачы теллелектә, шул ук минутта дошманының йөрәгенә җитәрлек итеп җавап бирә белүдә Г. Камал тел-сурәтләү чаралары арасыннан аеруча каламбур һәм сүз уйнатуга таянган.

Шул ук К. Әмири үзенең истәлекләрендә: «Галиәсгар абзый Тукай урамы буйлап миңа каршы килә. Мин барып җитмәс борын, кыяфәтеннән үк сәүдәгәр икәнлеге

---

[1] *Гоголь Н. В.* О литературе. – М.: Гослитиздат, 1952. – С. 81.
[2] *Чернышевский Н. Г.* Полное собрание сочинений. – М.: Гослитиздат, 1949. – Т. 2. – С. 185–186.
[3] СССР ФА ИЯЛИ архивы. – 13 ф. – 2 оп. – 21 сакл. бер. – 22–23 б.

күренеп торган бер Печән базары татары, артыннан килеп: «Галиәсгар *ага*!» – дип кычкырды. Әкрен генә атлап килә торган Галиәсгар абзый, туктап, аңарга таба борылды да: «*Акмый* әле», – дип куйды. Алар янына барып туктаганда, ике арада шундый сүз бара иде:

– Нәрсә *акмый*?

– Галиәсгар *ага*, дисең ич, Галиәсгар ничек *аксын* инде.

– *Картаюны* белмисең, ахры, һаман да шаян син.

– Ник *карт аюны* белмәскә, *карт аю* урманда була ул.

– Һәй, куйсана әле, мин сиңа ул турыда әйтмим бит! Синең әзрәк динең бармы соң, Алладан *оялмыйсыңмы*?

– Нигә, Алла *өй сатамыни*?

– Әстәгъфирулла тәүбә, большевикларда эшли башлагач, бөтенләй *юлдан чыккансың* икән.

– Менә син, большевикларда эшләмәсәң дә, *юлдан чыккансың* ич.

– Ничек *юлдан чыккан*?

– *Юлдан килмисең* ич, тротуардан киләсең.

– Агай-энеңең алтын-көмеш яшергәннәрен язмасаң, большевиклар акча бирми торганнардыр шул.

– Ә, сиңа да барып төртелдемени, күпме яшергән идең соң?

Бу сүздән соң теге кеше эндәшмәде, кулын селтәде дә үз юлына китте», – дип яза[1].

Үз ана теленең бай хәзинәсеннән, бу очракта исә аның омоформия, омофония, фразеология таркалу күренешләреннән оста файдаланган[2] Г. Камал тапкыр сүзгә аптырамый, халыкның гасырлар буена җыйган бай тел-сурәтләү тәҗрибәсенә таянып, татар сәүдәгәрләреннән ачы көлә. Ниһаять, бу – аның Көнчыгыш халыкларының, бигрәк тә төрки халыкларның каламбур, сүз уйнату, мәзәк буенча зур тәҗрибәсенә таянуы да. Әскияләрне, Хуҗа Насретдиннең меңнәрчә мәзәкләрен иҗат иткән төрки халыкларда сүз уйнату, каламбур гасырлар буенча традиция булып килә.

Каламбур телнең милли үзенчәлеге белән органик бәйләнгән. «Юморда һәм үткен сүзлелектә милли момент әһәмиятле роль уйный, чөнки биредә комиклык эффекты, көлдергеч нәрсәләрне зиһенгә алу характерның милли психик складны, милли культура традицияләренә бәйләнә»[3]. Әгәр характерларның, вакыйгаларның, ситуацияләрнең көлкелеге төрле милләт вәкилләре өчен бердәй аңлашылса (мәсәлән, кигән киемнең, эшләгән эшнең көлке тудыруы), тел чаралары белән барлыкка килгән комиклыкка тик шул телнең стилистик, лексик-фразеологик һәм грамматик үзенчәлекләрен тулысынча һәм бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән тәкъдирдә генә ирешергә мөмкин. Моның сәбәбе гади: тел чараларына нигезләнгән комик эффект гомумкулланыш формасын, сөйләү

---

[1] СССР ФА ИЯЛИ архивы. – 13 ф. – 2 оп. – 21 сакл. бер. – 8–9 б.

[2] Автор «ага» исемен «агу» фигыленең хәзерге заман берлек сан өченче зат формасы белән бәрелештерә. «Картаю» – «карт аю» сүзләре тирәсендә сүз уйнату исемне сыйфат һәм исемнән торган сүз тезмәсе белән бәрелештерүгә корылган. «Оялу» фигылен омофоник «өй алу» сүз тезмәсе белән очраштыру да сәүдәгәр белән ироник тонда сөйләшүгә, аны мыскыллауга юнәлдерелгән. «Бозылу, әхлаксызлану» мәгънәсендәге «юлдан чыгу» фразеологик әйтелмәсе Г. Камал тарафыннан туры мәгънәсендә («юлны ташлап, кырыйга чыгу») алына.

[3] *Борев Ю.* О комическом. – М., 1957. – С. 39–40.

формасын юри бозуга нигезләнә. Ә моны сизмәгән кеше каламбур һәм сүз уйнатуның тозы нидә икәнлеген дә сизми. Каламбурда, сүз уйнатуда комиклык үзенчәлекләре милли тел формасы аша аеруча ачык, үткен рәвештә килеп басалар һәм чит телләр тарафыннан бирелә алмый торган үзенә бертөрле гүзәллек, нәфислек саклыйлар. Үткен каламбур, милли телнең каймакларыннан гына төзелеп, үзенә бер эстетик ләззәт тудыра.

«Каламбур – авыр эш, ул барлык кешеләрнең дә көченнән килми»[1], аның өчен сүз остасы булу зарури. Ә бу үз чиратында үткен сүзлелекне, телнең иң нечкә чараларын белүне сорый.

Әйтик, алты мәгънәле «көрәшү» сүзенең нейтраль стильдәге туры мәгънәсе – «бер-береңне куллар белән тотып алып егарга, җиңәргә тырышу». Ә Г. Камалның бер герое Аҗак аны «нәрсәне дә булса юкка чыгарырга, бетерергә тырышу, шул юлда эш алып бару» мәгънәсендә куллана. Менә шул мәгънәләрне әңгәмәдә очраштыру комик эффект, каламбур тудыра:

«Аҗак. Мин яңалифчә наданлык белән көрәшү җәмгыятенә член булып язылдым.

Кужак. Кит аннан! *(Курка.)*

Аҗак. Ник гаҗәпләндең?

Кужак *(куркып, кире чигенә башлап)*. Ярый, хуш, сау бул, алайса!

Аҗак. Тукта әле, кайда качасың?

Кужак. Ныклап тамак туйдырып ашап килергә.

Аҗак. Соңыннан да өлгерерсең.

Кужак. Көрәшәм дисең ич, ашамаган, көчсез көенчә мин ничек көрәшим?» («Аҗак белән Кужак»)[2].

Телдә бертөрле әйтелеп тә, төрле мәгънәдә йөргән һәм үзара эчке семантик бәйләнештә тормаган сүзләр – омонимнар да бар (мәсәлән, ат – хайван, ат – исем, ат – ату). Омонимнар – каламбур өчен иң кулай материал, чөнки контекстта мәгънәләрнең көтелмәгәндәге бәрелеше каламбурга үзенә бертөрле үткенлек бирә.

Менә «Беренче театр»дан бер мисал:

«Гафифә. Нинди күлмәгемне киим икән, *асылмы*, җонмы?

Вәли *(үз-үзенә)*. *Асыласың килсә, асыл* инде»[3].

Өлешчә омонимиягә нигезләнгән бу каламбур геройның билгеле моменттагы хәлен, персонажлар арасындагы мөнәсәбәтне ачыграк күрсәтә. Шуның белән бергә бу омонимик сүзләр бәрелеше комик эффект та тудыра.

Шушы ук каламбурны Г. Камал «Чегән бәете»ндә дә куллана:

Күлмәкләрем *асыл* иде,
Бар мorатлар хасил иде...
Дөньяда рәхәт калмады,
Инде тот та *асыл* инде,
Һи Аллам ла,
Инде тот та *асыл* инде[4].

---

[1] *Некрасов Н.А.* Полное собрание сочинений. – М.: Гослитиздат, 1953. – Том XI. – С. 553.
[2] СССР ФА ИЯЛИ архивы. – 13 ф. – 2 оп. – 2 сакл. бер. – 3 б.
[3] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 66 б.
[4] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1979. – 2 т. – 354 б.

Шулай итеп, контекстта бер үк сүзнең төрле мәгънәләрен яки төрле мәгънәләргә ия булып та, бердәй әйтелешле сүзләрне (омонимнарны) очраштыруга нигезләнгән комик эффект тудыра торган тел-сурәтләү чарасы каламбур дип атала. Каламбурның асылы – бер үк аваз комплексы эчендә мәгънәләр бәрелешеннән комик эффект тууда. Икенче сүз белән әйткәндә, каламбурның нигезе – семантика. Бу – аны сүз уйнатудан аера торган төп билге.

Халык телендә, комик эффект тудыру өчен, алынма сүзләрне теге яки бу максатларда юри, аңлы рәвештә бозу алымы еш кулланыла. Мәсәлән, Г. Камалның һәрвакыт нәрсәгә булса да бәйләнергә яратучы Нәфисә исемле персонажы *гараж, трактор* сүзләрен хәтта *кара җәяү, трактир* сүзләренә әйләндерә. «Алланың мәчет астын шайтан арбасы, әллә нинди җен машинасы абзары ясаганны кем күргән дә, кем ишеткән?» «Гаражия» дип йөргән булалар. Әстәгъфирулла тәүбә!.. Тфү! Тфү! *Гаражия! Кара җәяү* калганыгызны сизми дә калырсыз әле! [...] *Трах-тыр! Трактирлар* борынгы заманда калада да базарлы авылларда гына буладыр иде. Кайчан чыгардылар?!» («Могҗиза»)[1].

Телдә якын әйтелешле, ләкин төрле мәгънәдәге сүзләрне якынайту, бәрелештерүгә (парономазиягә) нигезләп комик эффект тудыру очраклары да бар. Мәсәлән:

«Хәмзә. Бар әле, [...] Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. «Абзый *чәч* алырга чакыра» дисеннәр.

Биби. Нинди *мәче* алырга?

Хәмзә. Һәй, аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа мәче алырга дидеммени! *Чәч* алырга, дим! Чәч! *(Үз чәчен тарткалап.)* Менә, менә, шушыны алырга, дим»(«Беренче театр»)[2].

Хәмзә бай сүзләрен аңламаганга салышкан Биби чәч алу әйтелмәсендәге *чәч* сүзен *мәче* дип ишеткән була. *Чәч* һәм *мәче* сүзләре аваздаш түгелләр, ләкин автор комик эффект өчен бу ике сүзне *ә, ч* авазлары уртаклыгына нигезләп якынайта.

Сүз яки сүз тезмәсенә төрле фонетик-морфологик үзгәрешләр кертеп, ике яки берничә аваздаш сүз барлыкка китерүгә, сүзнең составын үзгәртүгә, фразеологик әйтелмәләрдә лексик элементларны алмаштыруга, парономазиягә, контаминациягә, гомумән, сүзнең формасын үзгәртүгә корылган комик эффект тудырудан гыйбарәт тел-сурәтләү чарасы сүз уйнату дип атала. Сүз уйнату, каламбурдан үзгә буларак, сүз яки сүз тезмәсенең формасын үзгәртү белән бәйләнгән. Мәсәлән, К. Тинчуринның «Алар өчәү иде» комедиясеннән алынган түбәндәге өзектә *метеор, матур* сүзләренең беркадәр аваздашлыклары сүз уйнатуга нигез булган:

«З а р җ а н. Гөлшат *метеор* ул.

М ә х м ү д ә. Бик *матур* шул, Аллага шөкер».

Яки:

«Бигрәк явыз булды бу «Йолдыз»ның җәяүле хәбәрчесе! Гласныйларның йоклауларын, казанлыларның һичбер нәрсә укымауларын карап йөрүләре генә җитмәгән, аның өстенә һәрбер мәхәлләләрне карап йөреп, кайда ни эшлиләр дә кайда нәрсәне ишмиләр, кайда кемне күтәрәләр, кайда нинди мулланы *түнтәрәләр* – һәммәсеннән идарәгә хәбәр биреп кенә тора» (Г. Камал, «Ишмиләр – түнтәрәләр»).

---

[1] СССР ФА ИЯЛИ архивы. – 13 ф. – 2 оп. – 36 сакл. бер. – 2 б.
[2] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 75 б.

Байларның кәефләренә карап, Казан мәчетләрендә муллалар алмашынудан көлү булып яңгыраган бу сүз уйнату атаклы реакционер Ишмөхәммәт Түнтәринең (Ишми ишанның) исемен «әйләндереп төшерү, әйләндереп ыргыту» мәгънәсендәге *түнтәрәләр* һәм «бауны бөтерү» мәгънәсендәге *ишү* фигыле белән бәрелештерүгә нигезләнгән.

Телнең мондый үзлеген халыклар бик күптән файдаланганнар. Без аларны XI йөз әсәре «Котадгу белек»тә, халыкларның меңнәрчә еллар буенча сөйләнеп, җыелып киленгән мәзәкләрендә табабыз. Язучылар гасырлар буенча образларга характеристика бирүдә, фикерне үткенәйтүдә каламбур һәм сүз уйнатудан оста файдаланып киләләр. Мәсәлән:

Әя, җаным, кызыл *алмам*,
Ки сәндин һич күңелне *алмам*,
Барырса, гайрене *алмам*,
Идүп синңа мөлакати.

(Г. Кандалый, «Шәфгый»)

Сөйгәненә мәхәббәт хисләрен көчлерәк белдерү өчен, Г. Кандалый мондый тип каламбур рифмаларны еш куллана.

Каламбур һәм сүз уйнату сатирик-юмористик максатларда К. Насыйри әсәрләрендә дә очрый: «Бер ярлы кеше үлем сырхавы белән ятканда, мулла-мунтагай аңа әйткән: «Фәлән абзый, синең хәлең бик начар, *иманыңны* әйт», — дигән. Авыру кешенең моңа бик ачуы килгән: «һай, исән вакытта йөдәтүләре җитмәгән, инде үлем түшәгендә дә имана сорап үзәгемә үтәләр ләбаса!» — дигән» («Фәвакиһел-җөләса»). *Имана* һәм *иман* сүзләренең аваздашлыгына нигезләнгән бу сүз уйнату патша власте вакытында крестьяннарның авыр хәлен тагын да ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итә.

Бу гүзәл традиция татар әдәбиятында Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин әсәрләрендә дәвам итә.

Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Г. Камал эшчеләр арасында эшли, драмтүгәрәкләр оештыра. Аның үзе эшләгән фабрика-заводлар тормышыннан конкрет фактларга нигезләп, «көннең кадагына сугып» язган һәм шул фабрика-завод клубларында куелган интермедияләре, скетчлары кимчелекләрне, тискәре күренешләрне фаш итүдә көчле корал булып файдаланылганнар. Мәсәлән:

«Эшче. Профессор Бизи Төньяк боз диңгезендә яңа бер атау эзләп тапкан — *утрау ачкан*.

Галия. Исең киткән икән. *Утрау ачкан*, имеш! Менә ул, әгәр дә ул бик шәп кенә булса, безнең комбинатка яки фабкомга килеп, бер генә тапкыр булса да вакытында *җыелыш ачып* карасын иде» («Контроль будкасы»)[1].

Эшче бу сүзне *утрау ачкан* әйтелмәсендә «аңа кадәр мәгълүм булмаган бер җирне табу» мәгънәсендә ала. Галия бәхәскә керергә ярата. Бу юлы да ул хәбәргә исе китми, *җыелыш ачу* әйтелмәсендәге *ачу* сүзен «башлау» мәгънәсендә алып, фабрикаларында оештыру эшләренең начар куелганлыгыннан көлә:

«Галия. Бераз гына булса да *мариновать ителгән* нәрсәләр булса да зарар итмәс иде.

---

[1] СССР ФА ИЯЛИ архивы. — 13 ф. — 2 оп. — 29 сакл. бер. — 7 б.

Э ш ч е. *Мариновать ителгән* нәрсәләр кирәк булса, аларның байтагын безнең фабкомнан табып булыр. Әгәр дә ул гына җитмәсә, производство киңәшмәсеннән сорап карарсың. [...] Анда эшчеләрнең шактый гына кыйммәтле тәкъдимнәре *мариновать ителәләр*» («Контроль будкасы»)[1]. Полемик рухтагы каламбур диалогның сатирик көчен үстерә.

Ә менә Г. Камалның *ия* сүзен *Сербия, Германия* ялгызлык исемнәрендәге ия кушымчасы белән бәрелештереп, сүз уйнатуга нигезләнгән «ъ һәм і яне бетерү» исемле политик шигыре ак эмигрантларның Совет хөкүмәте кирәксез дип тапкан ъ (ять) хәрефен һәм *ія* кушымчасында *і* хәрефен яклап чыгуларын фаш итүгә багышланган:

Совет хөкүмәте бетерсә дә ять (ъ) не,
Аның урынына бирде зур хөрриятне,
Әмма союзниклар бетерергә телиләр «ия»не (ія).
Телиләр кол итәргә һәрбер *ияне*.
Бетерә алар Сербіяне (Серб*ияне*),
Сербы калса да, китә аның яме.
Калса да немец милләте дөньяда,
Бетерергә телиләр алар Германіяне (Герман*ияне*).

Каламбур һәм суз уйнатуның матур әдәбиятта икенче төп роле — образларны ачуга, аларга характеристика бирүгә булышу. Оста кулланылган каламбур һәм сүз уйнату персонажның чын йөзен тулысынча ачарга мөмкинлек бирә.

М. Горький, Г. Камал, Ф. Бурнаш диалогларының характерлы үзенчәлеге аларның сүзне төрле мәгънәләрдә куллана алуга нигезләнгән драматик киеренке бәхәс, капма-каршы характерлар, фикерләр бәрелешенә корылуында. Тел нинди генә гомуми чара булмасын, төрле социаль катламнар сүзләрне үзләренчә аңларга һәм аңлатырга, үзләренә файдалы мәгънәдә кулланырга тырышалар. Мәсәлән:

«К о м и с с а р. Хафиз белән *арагыз* ничек?

Ә х м ә д и. Ничек дип әйтергә кирәк, бер җир буе кадәр бар. Ул югары очныкы, без түбән очныкы.

К о м и с с а р. Мин анысын сорамыйм, аның белән дуслыгыгыз яки дошманлылыгыз ничек, дим.

Ә х м ә д и. Ничек дип, дус вакыт та, бозылышкан вакытлар да була» (Г. Камал, «Хафизәләм иркәм»)[2].

Алдау юлы белән җирле органнарга оялаган кулаклар һәм аларның иярченнәре үзләренә ошамаган ярлы халыкны төрлечә изәргә, мыскыл итәргә, буйсынырга теләмәгәннәрен төрмәләрдә черетергә маташалар. Ләкин власть эшче-крестьяннар кулында. Хезмәт ияләре кулак махинацияләрен фаш итәләр. Кулакларның башбаштаклыкларына чик куела. Бернинди гаебе булмаган ярлы егет Хафиз өстеннән оештырылган суд кулакларның үзләренә каршы борыла. Кара эшләре өчен җавап бирәсен аңлаган кулак иярчене Әхмәди ничек кенә булса да судан коры чыгарга, судны саташтырырга һәм сорау алуда Комиссарның «мөнәсәбәт» мәгънәсендә алынган *ара* сүзен «ераклык» дип аңлаганга салышып, йомгакның очын яшерергә маташа. Әмма бу инде котылгысыз җиңелүгә дучар ителгән дошманның соңгы талпынуы гына. Ул фаш ителә, тиешле җәзасын ала.

---

[1] СССР ФА ИЯЛИ архивы. — 13 ф. — 2 оп. — 29 сакл. бер. — 16 б.
[2] СССР ФА ИЯЛИ архивы. — 13 ф. — 2 оп. — 14 сакл. бер. — 10 б.

Г. Камал сатирасының пафосы үлемгә дучар ителгән искелек калдыкларыннан үткен итеп көлә белүдә, аларның җиңелүенә тирән ышануында. Шундый искелек калдыкларының берсе — Государственная Думага депутат итеп сайланган татар мулласы. Аның өчен эсерлар интересы да, социал-демократлар интересы да, «Мөселман иттифакы» интересы да барыбер. Тәүлегенә ун сум акча өчен ул теләсә кемгә сатылудан һәм теләсә кемне сатудан чирканмый. Мулла Государственная Думада депутат булуны да табышлы урын дип кенә карый. Шушындый «депутат»ның чын йөзен ачар өчен, Г. Камал үзенең «Депутат озату» фельетонында сүз уйнатудан файдалана:

«Монда бер дә хәйләсез мөмкин түгел. Әмма үзләрен кызык иттем соң. Сайлау вакытында яныма бер урыс килде дә, колагыма гына: «Сез *әсирме?*» — ди. «Мин нишләп *әсир* булыйм, мин — азат кеше, һичбер кешегә кол булганым юк. Нишләмәк кирәк, аздан гына эшне калдырырга ярамый. Башымны селкеп: «Ун, ун», — дидем. «Алай булса, сезгә шар салам», — диде. Аның артыннан икенче бер урыс килде дә: «Князь, сез эздикме?» — ди. *Измәдек* түгел инде, дөнья булгач, төрле вакытлар була. *Изгән* чаклар да юк түгел иде. Кайвакытларда куерта да торган идек. Шулай булса да, серне биреп бетерергә ярамый, кешенең кәефе китүе ихтимал. Аңар да: «Ун, ун», — дидем».

Хәзрәт *эсер* (социалист-революционерлар партиясе члены), *эсдек* (социал-демократ) сүзләрен, ялган этимология буенча, *әсир* (тоткын) һәм «каты нәрсәне чылатып болгату, йомшак хәлгә китерү» мәгънәсендәге *изү* сүзенең издек (үткән заманның беренче зат күплек) формасы белән бутаганга салышып, үзенең капма-каршы партия тарафдарларыннан алдап тавыш алуын акларга маташа.

Эш моның белән генә бетми. Хәзрәт янына «үз кеше» — «Мөселман иттифакы партиясе» члены килә. «Хәзрәт, сез Мөселман иттифакы партиясеннәнме?» — диде. Аңар ялгышлык белән: *«Ун, ун»*, — дип ычкындырып җибәрдем. Әле ярый мәгънәсен аңламады. «Хәзрәт, сез русча гына сөйләшәсез икән», — ди. [...] *«Ун»* дип әйтмәенчә, ничек дип әйтим? *Ун* булгач, аны *унбер* дип әйтиммени? *Унбер* сум булган булса, дәхи дә яхшырак булган булыр иде дә бит, ни хәл итмәк кирәк, артыгын бирмиләр».

Оятсыз хәзрәт монда да аптырап калмый, бирелә дә ансат котыла. *Он* («ул») һәм *ун* (сан исеме) сүзләренең аваздашлыгына нигезләнгән бу сүз уйнату мулланың чын йөзен ачып сала. Хәзрәтнең сайлаучылар интересында эше юк, аның бар теләге — депутатка көн саен бирелә торган *ун сум* акча исәбенә баю.

Мондый тип сүз уйнату һәм каламбур Г. Камалның политик сатирасын үткенәйтә торган тел чараларының әһәмиятлесе буларак еш кулланыла. Нәкъ менә шундый әсәрләр турында Ф. Хөсни: «Яндырып керү һәм турыдан-туры дошманны сугып егу — сатираның тозы әнә шунда. Сатира ул кытыклап кына калдырмый, сатира үтерә. Сатира ул, батыр кулындагы кылыч шикелле, дошманны урталай яра һәм аның эчендәге бөтен әшәкелекләрен, бөтен шакшылыгын кояш яктысына чыгарып күрсәтә»[1], — дип яза.

М. Горькийның реалистик традицияләрен дәвам иткән Г. Камал фельетоннарында, драма әсәрләрендә бу алым коры сүз уйнату, тамашачыларны җиңелчә көлдерү өчен генә алынмый, бәлки персонажлар көрәшен, вакыйгалар үсешен кыска, ләкин тулы эчтәлекле итеп бирү өчен файдаланыла.

Бу уңайдан тагын бер моментка — каламбур һәм сүз уйнатуның кем тарафыннан ясалуына да игътибар итәргә кирәк. Кайбер каламбур һәм сүз уйнату ясалу персонажның билгеле бер максат тотуы һәм аңлы эшчәнлегенә бәйләнгән. Образны

[1] Совет әдәбияты. — 1938. — № 4. — 49 б.

ачуда кулланылган бу төр каламбур һәм сүз уйнату күбесенчә персонажның җаваптан качарга тырышуын сурәтләгән очракларда кулланыла.

Байлар тирәсендә куштанланып йөрүче Әптери бай хатыннарын күзләргә («кош тотарга») килгән Әнвәрдән акча алмакчы була, ялагайлана:

«Әптери. Ә-һә-һә, рәт була! Әнвәр абый килә. Эш пеште. Ахутага чыккан. Ул бер дә кызганмый инде. Никадәр теләсәң, шулкадәр яудыра. Только җаен гына белергә кирәк. Әнвәр абый, нихәл? *Исән генә* йөрисеңме?

Әнвәр *(илтифатсыз гына). Исән* булмасам, доктор булмакчы идеңме?» («Уйнаш»)[1].

Исәнләшүне белдергән *исән генәме* әйтелмәсен таркатып, туры мәгънәсендә аңлауга корылган бу каламбур Әптеридән котылу өчен корал итеп кулланыла:

«Себер бае. Соң ул (әфьюн. – *И. А.*) *исертмиме*?

Язучы. Юк, аның һич тә *исе* сизелми, аны борчак кадәрдә генә кабып, аның артыннан чәй эчеп җибәрсәң, бөтенләй күз аллары яктырып китә» («Безнең шәһәрнең серләре»)[2].

Кайчандыр бер семантик берлектә булып та, омонимнарга әйләнгән бу сүзләр кадимче язучы тарафыннан яңадан беренчел мәгънәләренә кайтарылалар. Тәкъва булып кыланган Шкафчының әфьюн сатуын күргәч, җәдитче Себер бае аның исерткеч (хәрам) нәрсә икәненә ишарә итә. Кадимче Язучы исә Шкафчыны якларга тырыша, *исертүне ис сизелүгә* кайтарып, ялгыш аңлаганга салыша.

Каламбур һәм сүз уйнату матур әдәбиятта еш кына персонажларның бер-берләрен аңлый алмавына, аңлашылмаучылыкка корылган комик ситуация тудыру өчен дә файдаланыла:

«Биби. Абзый, Миңлебай абзыйга әйткән идем, *«Коръән укый торган шәкертне алып чык»* дип. «Нинди шәкерт ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда Әфтияк укучы юк», – ди.

Хәмзә *(аяк тибеп)*. Һай, ахмаклар! Әрәмтамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, *мәчеттә Коръән укый торган шәкертне, Гайфулланы* чакырып чыксын!

Биби. Икесен дә чакырсынмы?

Хәмзә. Нинди икесен дә?!

Биби. *Коръән укучыны да, Гайфулланы да.*

Хәмзә. Үләм инде, мин сезнең белән җәфаланып үләм! Аңгыра. Соң шул *Коръән укучы шәкерт* белән *Гайфулла* икесе дә бер ләбаса инде!» («Беренче театр»)[3].

Яхшы укыганы өчен, Гайфуллага мәчеттә Коръән уку эше йөкләнгән. Шуңа күрә аңа исеме белән эндәшү урынына *Коръән укучы шәкерт* кенә диләр. Бу әйтелмә исә, үзенең конкрет мәгънәсен («китап уку») югалтып, кушаматка әйләнгән. Миңлебай исә, аны төп мәгънәсендә аңлаганга салышып, фразеологик әйтелмәне тарката. Моның нәтиҗәсе буларак, комик эффект туу Хәмзә байны әйтелмәне *мәчед* сүзе белән конкретлаштырырга мәҗбүр итә. Ләкин ул моның урынына икенче бер төгәлсезлек ясавын сизми. Ул Гайфулла исемен аерымланган тәмамлык ролендә ала. Бибинең моны тиңдәш тәмамлыклар дип аңлап, кайтарып соравы комик эффектны тагын да көчәйтә:

«Факиһә. Кая киттеләр җизниләр?

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 100 б.
[2] Шунда ук. – 214 б.
[3] Шунда ук. – 76 б.

Б и б и. Алар син сорасаң, ничек дип әйтергә икәнен миңа әйтмәделәр. [...] Абзый сораса, кодаларга киттеләр, дип әйтерсең, диделәр.

Ф ә к и һ ә. Ә *башка кеше* сораса?

Б и б и. *Башка кеше* кем сорасын? Фатыйх абый сораган иде дә, мин аңар әйтмәдем.

Ф ә к и һ ә. Миңа мин сорыйм.

Б и б и. Син *башка кешемени?*»[1].

Диалогта *башка* сүзенең ике мәгънәсе очраша. Факиһә *башка* сүзен «бүтән», «үзгә» мәгънәсендә кулланса, Биби аны «ят кеше» мәгънәсендә аңлый. *Башка кеше* — Хәмзә бай семьясына карамаган кеше. Шуңа күрә дә Биби «ят» мәгънәсендәге башка кеше исәбенә Фатыйхны гына кертә, Факиһәнең үзен башкалар (бүтәннәр) рәтенә кертүенә беркатлы Биби чын күңеленнән исе китә.

«В ә л и. Без хәзер *театрга* китәбез...

Б и б и. Кая?

В ә л и. *Театрга!*

Б и б и. Нәрсә *төятергә*?

В ә л и. Баш *төятергә*.

Б и б и. Нинди баш?!

В ә л и. Атаң башы! Мин сиңа *төятергә* димим, *театрга*, дим, аңладыңмы, *театрга*, дим!

Б и б и. Йә, аңладым инде, тиятергә, ул нинди җир соң?»[2]

Биби *театр* сүзен беренче мәртәбә ишетә һәм аны, татар теле чаралары аша аңларга тырышып, ялган этимология нигезендә, *төятергә* сүзе белән бутый. Гафифәнең озак юануына ачуы килгән Вәлине Бибинең бу соравы чыгырыннан чыгара, ул Биби соравына тупас җавап бирә. Ә бу Биби өчен кирәк тә! Һәм ул *баш төятергә* әйтелмәсен туры мәгънәдә ала. Вәли исә Бибинең аңгыралыгына гаҗиз. Шуңа күрә дә С. Волжская-Гыйззәтуллина Бибине «авылдан килгән татар кызы итеп, ни акыллы, ни юләр, аңгыра һәм кире кеше итеп уйный»[3]. Бибидә аңгыралык галәмәте юк түгел. Әмма, дөреслектә, *театр* сүзе — бөтен татар халкы өчен яңа нәрсә, аны күпчелек беренче тапкыр ишетә, моңа карап кына гади халыкны аңгыралар рәтенә кертү ялгыш булыр иде.

Биби Хәбибрахман, Гафифә кебек берни эшләми атасы акчасын ашап яткан бай балаларыннан өстен. Ул аны үзе дә сизә һәм урыны туры килгән саен сиздерә дә белә:

«Г а ф и ф ә. Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем. «Абыстай «Гарифәнең алдырган *кислатас*ы юк микән. Бик күңелләрем болганып тора. Үзебездә судысы барбарын да, ирләр өйдә вакытта *кислата* алдырырга онытылган» дип әйтте, дип сора», — дигән идем, барган да: «Абыстай киез каталарын биреп торсыннар ла», — дип сорап, миңа *кислата* урынына *киез ката* күтәреп кайткан. Гарифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә керерлек булдым»[4].

Биби, никадәр генә аңгыра булмасын, байлар өендә кислота булмаса да, киез катаның табылганын, әлбәттә, белә. Кислота урынына киез ката алып кайту (Биби *кис-*

---

[1] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. — 1 т. — 69 б.
[2] Шунда ук. — 63 б.
[3] *Кашшаф Г.* Беренче артистка. — Казан, 1958. — 35 б.
[4] *Камал Г.* Күрсәтелгән хезмәт. — 65 б.

лота сүзен ялган этимология нигезендә татар сүзе *киез ката*га алмаштыра) – Гафифә өстеннән чираттагы көлү генә. Шуңа күрә Г. Болгарская Бибине «башын юри юләргә салып, үзен җәберләүчеләрдән үч алучы, үткен акыллы асрау»[1] итеп дөрес башкара да.

Хәмзә бай өендә чын аңгыра – бай малае Хәбибрахман. Моны хәтта Хәбибрахманның атасы да инкяр итә алмый:

«Х ә м з ә. Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга: «Бар, агач базарына *Хисмәткә* бар да, аны тизрәк монда алып кайт», – дип җибәргән идем, барган да бер зур *кисмәк* алып кайткан. Менә бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде»[2].

Үткен каламбурда иң төп нәрсә – бөтенләйгә якын килә алмый дип уйланылган төшенчәләр, күренешләр арасында эчке бәйләнеш таба алган фикернең үткен булуы. «Үткен фикерлелек – моңарчы бертөрле дә мөнәсәбәттә булмаган фикерләрнең кинәттән очрашуы»[3], – ди М. Твен. Үткен уй телнең үткен формасын таләп итә. Бу шарт үтәлмәгәндә, фикер үткенлеге югала.

«Без әдәби осталык турында күп сөйлибез. Ләкин әдәби осталыкны беренче чиратта тел осталыгы, телгә байлык, телне дөрес куллана белү дип аңларга кирәк. Язучы кешедә телгә аеруча бер сизгерлек булырга тиеш: ул һәр сүзнең тулы мәгънәсен аңлау гына түгел, аның эчке аһәңен, кай урында ничек яңгыравын, ниһаять, сүзләрнең үзара бәйләнешен тоя белергә тиеш. Әйтәсе дә юк, бу осталыкка ирешү ансат түгел, әмма шунсыз чын язучы булу мөмкинме соң?»[4] – ди Ә. Еники үзенең «Хикәя турында» исемле бер мәкаләсендә.

Г. Камалның сатира-юмор арсеналында иң көчле тел-сурәтләү чараларыннан берсе булган каламбур һәм сүз уйнату – авторның үз туган телен бөтен нечкәлекләренә кадәр белүен һәм ул нечкәлекләрне, телнең эчке мөмкинлекләрен оста файдалануын күрсәтүче мисал.

Искәндәр Абдуллин,
филология фәннәре кандидаты

---

[1] Шәрәфиев Ф. Г. Болгарская. – Казан, 1957. – 14–15 б.
[2] *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 т. – 75 б.
[3] *Твен М.* Рассказы и шутки. – «Библиотека Крокодила», 1947. – № 15. – 18 б.
[4] Язучылык хезмәте турында. – Казан, 1958. – 175 б.

ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНӘ ҺӘМ ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ. КОМЕДИЯ ЖАНРЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

(10 нчы сыйныф)

I. Дәреснең максатлары:

1. Фәнни максатлар:

1) Г. Камалның татар драматургиясендә тоткан урыны хакында тирән мәгълүмат бирү;

2) Г. Камал әсәрләре мисалында комедия жанры үзенчәлекләрен ачыклау.

2. Коммуникатив максат: комедия жанрын анализлау, мәгълүматны гомумиләштерү күнекмәләрен булдыру.

3. Тәрбияви максат: Г. Камалның тормыш юлы һәм иҗаты мисалында шәхес булып җитлегү үзенчәлекләрен барлау.

II. Дәреснең бурычлары:

1. Г. Камалның тормыш юлын, иҗатын искә төшерү.
2. Комедия жанры, конфликт, көлү алымнары турында аңлатма бирү.
3. Г. Камал комедияләренә хас сыйфатларны аерып чыгару.
4. Анализдан соң синтез ясау, комедия жанрына караган әсәрләрне тикшерү тәртибен үзләштерү.

III. Принциплар:

1. Фәннилек принцибы.
2. Оптимальлек принцибы.
3. Белем һәм тәрбия берлеге принцибы.
4. Әдәбиятны сүз сәнгате буларак укыту принцибы.
5. Әсәрне шәхсән кабул итү принцибы.
6. Гуманлылык принцибы.

IV. Укыту ысулы: эвристик.

V. Укыту алымнары: слайд-шоу күрсәтү; текстның аерым элементларына игътибар итү; план төзү; язучы стилен күзәтү; әңгәмә; билгеләмә төзү.

VI. Дәреснең төре: катнаш дәрес.

VII. Материал:

1. Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар) : татар телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек / М. Х. Хәсәнов, А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин, И. З. Нуруллин; А. Г. Әхмәдуллин редакциясендә. — 3 нче басма. — Казан : Мәгариф, 2005. — 399 б.

2. Әдәбияттан хрестоматия : татар телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен / төз. А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин. — 3 нче басма. — Казан : Мәгариф, 2005. — 511 б.

VIII. Җиһазлау: слайд-шоу (презентация), дәреслек, комедия жанрын анализлау схемасы, Г. Камал мирасына багышланган таблица, модульләр.

IX. Файдаланылган әдәбият:

1. Әдәбият белеме : терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Д. Ф. Заһидуллина, В. Р. Әминева, М. И. Ибраһимов һ. б. — Казан : Мәгариф, 2007. — 231 б.

2. *Гыйлаҗев Т. Ш.* Татар әдәбияты. XX гасыр башы : лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар : югары уку йортлары өчен уку әсбабы / Т. Ш. Гыйлаҗев. — Казан : Мәгариф, 2007. — 239 б.

3. *Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә : әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә. Закирҗанов. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2004. — 175 б.

4. *Заһидуллина Д. Ф.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы / Д. Ф. Заһидуллина. — Яңарт. һәм тулыл. 2 нче басма. — Казан : Мәгариф, 2004. — 367 б.

5. *Камал Г.* Әсәрләр : 3 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. — 3 т. : хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр (1900—1933). — 415 б.

6. *Камал Г.* Сайланма әсәрләр / төз. Р. Корбан. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2004. — 302 б.

7. Татар әдәбияты тарихы : 6 томда. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1986. — 3 т. : XX гасыр башы. — 600 б.

Дәрес планы

I. Башлам (1 мин.):

1. Исәнләшү.
2. Дәрес планы белән таныштыру: тема, максатны әйтү.

II. Актуальләштерү этабы (18 мин.):

1. Г. Камалның тормыш юлын, иҗтимагый эшчәнлеген искә төшерү:
   1) презентация карау;
   2) нәтиҗә чыгару (таблица тутыру).

III. Яңа материалны аңлату этабы (16 мин.):

1. Комедия жанрының үзенчәлекләрен билгеләү.
2. Комедия жанрын анализлау тәртибе белән танышу.

IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту этабы (4 мин.):

1. Г. Камал мирасы үзенчәлекләрен таблицага кертеп бетерү.

V. Өйгә эш бирү (1 мин.):

1. Дәрестә язылган схемаларны кабатлау.
2. Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясен уку.

VI. Йомгаклау (5 мин.):

1. Тест язу.

Дәрес барышы

I. Башлам:

1. Укытучы: Исәнмесез, укучылар!

Укучылар: Исәнмесез!

2. Укытучы: Бүгенге дәреснең темасы – Г. Камалның татар драматургиясенә һәм театр сәнгатенә керткән өлеше. Комедия жанрының үзенчәлекләре. Дәреснең төп максаты – Г. Камалның мирасын ачыклау.

II. Актуальләштерү этабы:

1. Укытучы: Кеше туа, яши һәм үлә. Безнең һәрберебез бу өч дәверне үтә. Г. Камал бу дәверләрне бик мәгънәле үткәргән, үзеннән соң бай мирас калдырган. Әлеге мирасның асылын, әһәмиятен аңлау өчен безгә нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

Укучы: Шул мирасны калдырган шәхеснең тормыш юлын белергә кирәк.

Укытучы: Бик дөрес. Кешенең мирасын аңлау өчен башта ул шәхес белән танышырга кирәк. Хәзер без Г. Камалның тормыш юлын һәм иҗатын искә төшерербез. Язучының тәрҗемәи хәле турында сез өйдә укып килдегез инде. Презентация күрсәтелгәндә, сораулар бирелеп барачак. Сорауларга җавап бирергә әзер булыгыз. Һәр дөрес җавапка балл бирелә. Үзегезгә кызык булган мәгълүматны дәфтәрегезгә теркәп барырга онытмагыз. Башладык! Экранга игътибар итик. Сезнең алда Г. Камалның портреты (слайд). Укучылар, Г. Камал ничәнче елларда яшәгән?

Укучы: 1879–1933 елларда.

Укытучы: Дөрес (җавап слайдта күрсәтелә). Шәхеснең формалашуына нык тәэсир иткән шартлар: аның туган җире һәм яшәгән чоры. Укучылар, Г. Камал кайчан һәм кайда туган?

Укучы: 1879 елның 6 гыйнварында Казанда туган.

Укытучы: Истәлекләрдә әйтелгәнчә, 1879 елның 6 гыйнвары дүшәмбе көн булган. Г. Камал таң вакытында дөньяга килгән. Бу слайдта сез аның туган йортын күрә аласыз. Бу йорт элеккеге Фукс урамында урнашкан була. Укучылар, хәзер бу урам кемнең исемен йөртә икән?

Укучы: Бу – Г. Камал урамы.

Укытучы: Яхшы. Булачак драматургның әти-әниләре кемнәр була (слайд)?

Укучы: Әтисе – Галиәкбар агай. Ул оста мехчы, тире эшкәртүче була. Әнисе – Мәүгыйзә апа.

Укытучы: Галиәсгарнең әти-әнисе бик күп эшли. Галиәсгар җәйләрен авылда туганнары янында үткәрә, кышларын шәһәрдә яши. Ул җырларга ярата. Күршеләр аңа, җырлаган өчен, хәтта бер-ике тиен акча да бирә торган булалар. Җырлап йөргән җырларының берсе мондый:

Алты кыек тәрәзә,
Куйдырмыйсың бер ишек.
Бетәр микән, бетмәс микән
Сиңа төшкән бу гыйшык.

Укучылар, искә төшерик әле: Г. Камал кайсы мәдрәсәләрдә белем ала?

Укучы: «Госмания», «Халидия», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә, русчага өйрәнү сыйныфларында укый.

Укытучы: Дөрес. 1886 елда кечкенә Галиәсгар сабакка йөри башлый. Башта әнисенең туган авылы Түбән Масрада (хәзерге Арча районы) бер кыш укый, аннары, Казанга кайтып, «Госмания», «Халидия» кебек кадими мәдрәсәләрдә укуын дәвам итә. 1893 елдан үз заманында татарның алдынгы уку йортларыннан саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчә. Бер үк вакытта мәдрәсә янындагы өч класслы русча мәктәптә дә укый (слайд). Укучылар, Г. Камал шәкертлек елларында яз һәм җәйләрне ничек уздыра?

Укучы: Яз һәм җәй көннәрендә, Мөхәммәтгали Кадыйров дигән кешегә яллanып, Әстерхан, Түбән Новгород, Буа ярминкәләрендә эшли, кышын шул хезмәт хакын мәдрәсәдә уку өчен тота.

Укытучы: Дөрес. Укучылар, Г. Камалның үсмер чагын күз алдына китерик. Бу чорда ул театр сәнгате белән кызыксына башлый. Моңа нинди вакыйгалар сәбәп була?

Укучы: Беренчедән, ул, базарларда кәмит карап, үзе дә шуларны оештырып йөри. Икенчедән, «Рисаләи Газизә», «Белек» җыентыкларын, К. Насыйри китапларын, Г. Ильяси, Ф. Халиди пьесаларын укый. Өченчедән, рус спектакльләрен карый.

Укытучы: Бик дөрес. Г. Камал рус операларын да карый. Мәсәлән, Николай Андреевич Римский-Корсаковның «Садко»сына бара. Гётеның «Фауст» әсәрен берничә мәртәбә укый һәм шундый ук яхшы әсәр язарга хыяллана (слайд). Укучылар, бу елларда Г. Камал нинди әсәр иҗат итә?

Укучы: 1898 елда беренче сәхнә әсәрен — «Бәхетсез егет» драмасын (1 нче вариантын) яза.

Укытучы: И. Әхмәтҗанов исемле яшь приказчик Төркиядән китаплар алып кайта. Шулар арасында Нәмыйк Кемалның бер әсәре була. Ул Г. Камалга нык йогынты ясый, һәм яшь язучы аны тәрҗемә дә итә. Укучылар монда Нәмыйк Кемалның кайсы әсәре турында сүз бара дип уйлыйсыз?

Укучы: «Зәваллы чуҗык». Бу әсәр 1873 елда басылып чыга.

Укытучы: Г. Камал 1900 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. Әтисе аңа өйләнергә һәм мулла булырга тәкъдим итә. Г. Камал мулла булудан баш тарта. Язучы һөнәрен якын күрә. Тормыш иптәше итеп Бибигайшәне сайлый (слайд). Шулай итеп, Г. Камал, асылына хыянәт итмичә, үз тормыш сукмагын таба. Укучылар, әгәр Г. Камал мулла булса, нәрсә булыр иде икән?

Укучы: Татар драматургиясе олуг драматургсыз калыр иде. Бәлки, ул алдынгы фикерле мулла яки җәмәгать эшлеклесе булыр иде.

Укытучы: Шулай, иң мөһиме: һәр шәхес, үз юлын табып, аннан тайпылмыйча барыр өчен, үзендә көч булдырсын иде.

Укытучы: Г. Камал, өйләнгәч, тормышына, иҗатына тагын да җитдирәк карый башлый. Ныклап эшкә керешә. Укучылар, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Г. Камал нәрсә белән шөгыльләнә?

Укучы: Ул газеталар тарату һәм китап бастыру буенча Казанда «Мәгариф көтепханәсе» дигән сәүдә ширкәте оештыра. Мәдрәсә шәкертләре арасында «Дөнья күренеше» («Манзаратель-галәм»), «Телескоп» исемле кульязма газеталар күбәйтеп тарата.

Укытучы: 1902 елда ул, яңа китаплар алдыру нияте белән, Төркиягә бара. Укучылар, Г. Камал кайсы газеталарда эшли?

Укучы: 1905 елда – «Казан мөхбире» газетасында, 1905–1906 елларда – «Азат», «Азат халык» газеталарында эшли. Аннары «Йолдыз»га күчә.

Укытучы: Г. Камал кайсы газетаның баш мөхәррире була?

Укучы: «Азат халык».

Укытучы: 1906 ел – татар театры тарихында һәм Г. Камал тормышында да олы бер дата. Бу елда нинди вакыйгалар була?

Укучы: 1906 елның 21 апрелендә Уфада беренче рәсми спектакль – Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш»ы куела. 5 майда Казанда беренче тапкыр рәсми рәвештә «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе» спектакльләре уйнала. 1906 елның 22 декабрендә «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе» спектакльләрен Яңа клубта профессиональ артистлар уйный.

Укытучы: 1907 елда «Бәхетсез егет»нең икенче варианты языла. Укучылар, ни өчен Г. Камал әсәрне яңадан яза?

Укучы: Ул әсәрнең проблематикасын киңәйтә: шәхес хатасы, ата-ана тәрбиясе кебек мәсьәләләрне күтәрә.

Укытучы: Укучылар, Г. Тукай белән Г. Камал кайсы журналларда бергә эшлиләр?

Укучы: 1908 елның августыннан 1909 елның июненә кадәр Г. Камал белән Г. Тукай революцион-демократик эчтәлектәге рәсемле сатирик «Яшен» журналы чыгаралар (барлыгы – 10 сан). Соңыннан «Ялт-йолт» журналын әзерлиләр. Г. Камал, журналның рәсми редакторы булу белән бергә, анда күп санлы мәкаләләре, шигырь һәм карикатуралары белән дә актив катнаша.

Укытучы: Дөрес. 1908–1911 еллар арасында Г. Камалның нинди танылган комедияләре иҗат ителә?

Укучы: 1908 елда – «Беренче театр», 1909 елда – «Бүләк өчен», 1911 елда – «Безнең шәһәрнең серләре», «Банкрот» әсәрләре языла.

Укытучы: Яхшы. Ә ни өчен драматург бу елларда актив иҗат итә икән?

Укучы: Бу чорда татар драматургиясен аякка бастырырга кирәк була.

Укытучы: 1910 елның 5 ноябрендә әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенә 10 ел тулу уңае белән Казанда Яңа клуб залында Г. Камалның юбилей кичәсе уздырыла. Кичәдә «Бәхетсез егет» драмасы һәм «Бүләк өчен» комедиясе күрсәтелә. Г. Тукай бу юбилейга бәйле язылган бер мәкаләсендә аны танылган рус драматургы белән чагыштыра. Ул драматург кем?

Укучы: Г. Тукай Г. Камалны «татар Островские» дип атый.

Укытучы: Г. Камал әсәрләр язу белән бергә журналистлык эшен дә калдырмый. 1912 елның көзендә, Балкан сугышы вакытында, ул, «Йолдыз» газетасының махсус хәбәрчесе булып, Төркиягә барып кайта. «Йолдыз»ның 1912 елгы декабрь һәм 1913 елгы гыйнвар саннарында бу сәфәргә бәйле егермеләп мәкаләсе дөнья күрә. 1914–1917 елларда Г. Камал башлыча тәрҗемә өлкәсендә эшли, шулай ук «Йолдыз» газетасындагы хезмәтен дә дәвам итә. Ул тәрҗемә иткән кайбер әсәрләр: А. Н. Островскийның «Яшенле яңгыр» (1914); Мольерның «Саран» (1915), «Ирексездән табиб» (1916); Н. В. Гогольнең «Ревизор» (1916) һ. б. 1917 ел революция җәмгыятькә азатлык алып килә. Г. Камал тагын да дәртләнеп эшкә керешә. Укучылар, сез аның бу чоры турында нәрсә әйтә аласыз?

Укучы: Г. Камал бу чорда «Эш», «Кызыл Армия» газеталарында эшли. Күп сатирик шигырьләр яза.

Укытучы: Яхшы. Язучының тормышында булган вакыйгаларны алга таба таблицада карыйк.

1917 ел. Февральдән соң	Мөселман социалистлар комитеты органы булган «Кызыл байрак» газетасына (редакторы – М. Вахитов) мәкаләләр яза.
1919 ел	Казанда Татар запасной батальон карамагындагы театр труппасында артист булып эшли.
1920–1931 еллар	«Татарстан», «Татарстан хәбәрләре» һәм «Кызыл Татарстан» газеталары редакцияләрендә хезмәт итә.
1923 ел	Иҗат эшчәнлегенә 25 ел тулу уңаеннан Татарстан хөкүмәте драматургка «Хезмәт батыры» дигән исем бирә.
1926 ел	Татар театрының 20 еллык бәйрәме уңае белән Г. Камалга «Татарстанның халык драматургы» дигән исем бирелә.
1929–1930 еллар	Әсәрләренең икетомлыгы басылып чыга.
1931–1932 еллар	Казанда Наркомсобес клубы каршындагы сукырлар драмтүгәрәге белән җитәкчелек итә.
1933 ел, 16 июнь	Г. Камал йөрәк өянәгеннән вафат була.

Укытучы: Укучылар, Г. Камал исеме бүген киң җәмәгатьчелеккә танышмы?

Укучы: Әйе. Татар дәүләт академия театры аның исемен йөртә. Казанның бер урамы шулай ук Г. Камал исеме белән аталган.

Укытучы: Дөрес. Г. Камал мирасын күз алдына китерү өчен, таблица ясарга кирәк. Без аны башта тактада эшләрбез, соңыннан дәфтәргә күчерербез. «Мирас» дип аталган бу таблицада ике багана бар. Беренче баганада Г. Камалның әдәбиятка караган эшчәнлеге, ә икенчесендә башка өлкәләргә караган эше турында язылачак. Беренче баганага нәрсә яза алабыз?

Укучы: Драматург, тәрҗемәче, шагыйрь, прозаик, тәнкыйтьче.

Укытучы: Дөрес. Икенче баганага нәрсә язарбыз?

Укучы: Журналист, мөхәррир, карикатурачы, артист, режиссёр, декоратор.

Укытучы: Дөрес. Аның иҗаты башлыча драматургия өлкәсенә карый, шуңа күрә аны тәфсилләп язачакбыз. Драматургиядә ул нинди төп ике жанрда эшли?

Укучы: Драма һәм комедия жанрларында.

Укытучы: Монысын да беренче баганага теркәп куябыз.

III. Яңа материалны аңлату этабы:

1. Укытучы: Яхшы. Укучылар, таблица белән эшне без дәвам итәрбез. Дүртбиш юл калдырыгыз. Бүгенге дәреснең тагын бер темасы – комедия жанры. Бу жанрның үзенчәлекләрен ачыклыйк. Комедия жанрына сез нинди билгеләмә бирер идегез?

Укучы: ....

Укытучы: Комедия ул – драма төренең бер жанры. Комедиянең асылын билгелик. Без комедия караганда нишлибез?

Укучы: Көләбез.

Укытучы: Әйе, комедиянең асылы – көлү. Без нәрсәдән көләбез? Көлү объекты булып нәрсә санала ала?

Укучы: Күңелле вакыйгалар, кимчелекләр.

Укытучы: Кемнең яки нәрсәнең кимчелекләре була?

Укучы: Кешенең, җәмгыятьнең.

Укытучы: Шулай итеп, комедиягә без нинди билгеләмә бирә алабыз?

Укучы: Комедия – драма төренең нигезендә иҗтимагый яки шәхси кимчелекләрдән көлү ята торган жанр.

Укытучы: Билгеләмәне язып куегыз. Һәрбер әдәби әсәрнең үзәгендә каршылык ята. Комедиядә – көлкеле каршылык. Ул нинди сәбәпләр аркасында туа ала? Әйтик, «Беренче театр»да Биби белән Вәли арасындагы көлкеле каршылык нәрсә аркасында туа?

Укучы: Аңлашылмаучылык нәтиҗәсендә.

Укытучы: «Бүләк өчен» комедиясендә төп каршылык нинди сәбәп аркасында барлыкка килә?

Укучы: Хәмидәнең хыялы чынбарлык белән туры килмәү нәтиҗәсендә.

Укытучы: Бик дөрес. Көлкеле каршылык тууның икенче сәбәбе – хыял белән чынбарлыкның туры килмәве. Язып куегыз: «Көлкеле каршылыкның сәбәпләре: 1) аңлашылмаучылык; 2) хыял белән чынбарлыкның туры килмәве». Комедиядә нинди геройлар күбрәк катнаша?

Укучы: Тискәре геройлар.

Укытучы: Аларга нинди сыйфатлар хас?

Укучы: Икейөзлелек, ялагайлык, алдау, наданлык һ. б.

Укытучы: «Бәхетсез егет» әсәрендә Закир – тискәре герой. Закир белән «Беренче театр»ның Хәмзә баен чагыштырсак, алар арасында аерма бармы?

Укучы: Бар. Закир үзенең кылган гамәлләренә үкенә, Хәмзә бай бу хакта уйлап та карамый.

Укытучы: Укучылар, ә хәзер комедия жанрына бәйле геройларның әлеге үзенчәлекләрен гомумиләштереп әйтик.

Укучы: Комедиядә тискәре геройлар үзгәрми, ә драмада үсештә бирелә.

Укытучы: «Беренче театр», «Бүләк өчен» әсәрләрен чагыштырсак, алардагы төп геройлар нинди?

Укучы: Тискәре. Типик геройлар.

Укытучы: Г. Камал иҗатына типик геройлар тудыру хас. Шул геройларга бәйле рәвештә автор нинди проблемалар күтәрә?

Укучы: Иҗтимагый, әхлакый проблемалар.

Укытучы: Тискәре геройларга каршы автор үз идеалын тәкъдим итәме?

Укучы: Әйе. «Беренче театр»да, мәсәлән, Вәли белән Факиһә образларын.

Укытучы: «Банкрот» әсәрендә автор идеалы булып көлү тора. Димәк, комедиядә автор идеалы ике юл белән бирелә: 1) уңай герой образы; 2) көлү образы. Хәзер комедия геройларының үзенчәлекләрен саныйк һәм язып куйыйк:

1. Төп геройлар – тискәре геройлар.
2. Тискәре геройлар үсеш-үзгәреш кичерми.
3. Геройлар типиклаштырыла.
4. Автор идеалы ике юл ярдәмендә бирелә: 1) уңай герой образы; 2) көлү образы.

Укучылар, саналган үзенчәлекләргә игътибар итегез әле. Г. Камалның барлык комедияләренә хас төп үзенчәлек нәрсә?

Укучы: Типик геройлар.

Укытучы: Бу үзенчәлекне дә без «Мирас» исемле таблицага теркәп куйыйк. Укучылар, көлүнең ике төре була: 1) сатира; 2) юмор. Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

Укучы: Сатира – усал көлү, юмор – яратып көлү.

Укытучы: Г. Камал комедияләрендә көлүнең нинди төре өстенлек ала?

Укучы: Сатира.

Укытучы: Бу – шулай ук Г. Камал иҗатына хас бер үзенчәлек. Көлү төрләрен язып куябыз. Хәзер көлке тудыру алымнарын карыйк. Мәсәлән, «Беренче театр», «Бүләк өчен» әсәрләрендә нинди алымнар файдаланыла?

Укучы: Читкә әйтү репликасы, санап чыгу, аңлашылмаучылык, сөйләм телендә кызык сүзләр куллану.

Укытучы: Саналган алымнарны дәфтәргә язып куйыйк: «Көлке тудыру алымнары:

1. Читкә әйтү репликасы.
2. Гадәти булмаган исем, фамилия, кушамат.
3. Арттыру, күпертү.
4. Детальләрне санау.
5. Экспрессив лексика».

Г. Камал бу алымнарны оста файдалана. Укучылар, Г. Камал, нинди максатны күздә тотып, комедияләр яза? Алар ярдәмендә аның нәрсә әйтәсе килә?

Укучы: Комедияләре аша Г. Камал җәмгыятьнең кимчелекләрен фаш итә.

Укытучы: Бик дөрес. Комедиянең әһәмияте дә нәкъ шунда чагыла. Кимчелекләрне фаш итү башлыча кайсы иҗат юнәлешенә хас сыйфат?

Укучы: Реализмга, тәнкыйди реализмга.

Укытучы: Бу үзенчәлек тә Г. Камал мирасына карый, аны таблицага язабыз.

2. Укытучы: Комедиянең үзенчәлекләрен язып чыктык. Укучылар, алдагы әдәбият дәресләрендә сез бу схеманы ничек итеп куллана аласыз?

Укучы: Теләсә нинди комедияне анализларга мөмкин.

Укытучы: Анализлау тәртибен тергезик. Язып куегыз: «Комедия жанрындагы әсәрләрне анализлау тәртибе» (түбәндәге анализлау тәртибе төзелә):

1. Жанр.
2. Каршылык.
3. Каршылык проблема тудыра.
4. Тема – каршылыкның сәбәбе.
5. Идея – каршылыкның чишелеше.
6. Геройлар: 1) төп; 2) ярдәмче; 3) эпизодик; 4) аталучы.
7. Сюжет.
8. Композиция.
9. Сәнгатьчә эшләнеше: 1) көлү төрләрен ачыклау; 2) көлү алымнарын барлау.

Укучылар, күчереп языгыз.

IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту этабы:

1. Укытучы: «Г. Камал мирасы дигән» таблицага әйләнеп кайтабыз. Биредә язылганнарны күздән кичерик һәм дәфтәргә күчерик.

«Мирас»	
Әдәбият	Башка өлкәләргә караган эшчәнлек
Драматург, тәрҗемәче, шагыйрь, прозаик, тәнкыйтьче. *Иҗат үзенчәлекләре:* 1) драма, комедия жанрлары; 2) типик геройлар; 3) сатира; 4) тәнкыйди реализм.	Журналист, мөхәррир, карикатурачы, артист, режиссёр, декоратор.

V. Өйгә эш бирү:

1. Укытучы: Укучылар, көндәлекләргә өй эшен языйк:
1) дәрестә язылган схемаларны кабатлау;
2) «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясен уку.

VI. Йомгаклау:

1. Укытучы: Укучылар, без бүген Г. Камалның иҗатын да, тормыш юлын да тикшердек, комедия жанрының үзенчәлекләрен ачыкладык. Хәзер тест эшлик. Бер дәфтәр битенә исем-фамилиягезне языгыз. Экранда сораулар күрсәтеләчәк. Җавапларның бер генә варианты дөрес. Тест сораулары экранда күрсәтелә:

1. Г. Камал ничәнче елда туган?
А. 1859.
Ә. 1878.
Б. 1880.
В. 1879.

2. Г. Камал кайсы мәдрәсәдә укымаган?
А. Күл буе мәдрәсәсе.
Ә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе.
Б. «Халидия» мәдрәсәсе.
В. «Госмания» мәдрәсәсе.
3. Г. Камалның иҗади һәм шәхси якын дусты кем?
А. Ш. Мөхәммәдьяров.
Ә. Ш. Бабич.
Б. Х. Туфан.
В. Г. Тукай.
4. Г. Камал кайсы сатирик журналда эшләгән?
А. «Карчыга».
Ә. «Ялт-йолт».
Б. «Туп».
В. «Әлгасрелҗәдит».
5. Г. Камалның кайсы пьесасы Казанда беренче тапкыр рәсми төстә уйналган?
А. «Бәхетсез егет».
Ә. «Беренче театр».
Б. «Банкрот».
В. «Уйнаш».
6. «Бәхетсез егет» драмасында нинди мәсьәлә күтәрелгән?
А. Хатын-кыз азатлыгы.
Ә. Милләт язмышы.
Б. Тәрбия, әхлак.
В. Сыйнфый көрәш.
7. «Бүләк өчен» комедиясенең каһарманы кем?
А. Гафифә.
Ә. Гарифә.
Б. Җәмилә.
В. Хәмидә.
8. Г. Камалны кайсы әдип «татар Островские» дип атаган?
А. Ф. Әмирхан.
Ә. Г. Тукай.
Б. Г. Ибраһимов.
В. С. Рәмиев.
9. «Беренче театр» комедиясендә каршылыкның нинди төре чагылыш тапкан?
А. Трагик.
Ә. Драматик.
Б. Комик.

Укучылар, тест нәтиҗәләре икенче дәрескә билгеле булачак. Сау булыгыз!

Гөлнара Мансурова,
Казан (Идел буе) федераль университеты студенты

Г. КАМАЛНЫҢ «БАНКРОТ» КОМЕДИЯСЕН МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

(10 нчы сыйныф)

«Банкрот» комедиясе ике дәрестә өйрәнелә, шуңа күрә укучыларга өйдә әсәрне укырга һәм түбәндәге сораулар буенча сөйләшергә әзерләнеп килергә кушыла:

1. Ни өчен автор пьесаны комедия дип атый?
2. Комедиядә күтәрелгән төп тема һәм проблемалар.
3. Сиражетдин образы сездә нинди фикерләр уятты?

Программага нигезләнеп, «Банкрот» комедиясен тулырак һәм тирәнрәк анализлауның, ягъни төп темасын, идеясен, персонажларның характерларын, әдәби үзенчәлеген ачуның мөмкинлекләрен һәм нәтиҗәле форма, метод, алымнарны куллану юлларын карап үтик. Комедия ике дәрестә өйрәнелә, беренче дәрескә түбәндәге максат-бурычлар куела:

— комедия жанрының төп сыйфатларын искә төшерү; сатира һәм сатирик конфликт үзенчәлекләрен ачыклау;
— пьесаның сюжет-композициясен күзәтү;
— Сиражетдин образы, аның әхлакый йөзе, тормыштагы максат һәм идеаллары турында фикер алышу.

Дәрес башында әдәбият теориясенә караган мәсьәләләр ачыклана. Укучылар комедия жанры белән түбән һәм урта сыйныфларда танышалар, шуңа күрә аның үзенчәлекләрен искә төшерү, шулай ук «Банкрот»ның ни өчен комедия дип аталуын ачыклау зур кыенлык тудырмый. Укытучы исә, дәреслектән һәм «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән файдаланып, *сатира, сатирик конфликт* үзенчәлекләре турында яңа мәгълүмат бирә.

«Банкрот»ның язылу һәм сәхнә тарихы турында алдан хәзерләнгән укучы сөйли ала, ә укытучы докладны тулыландыра. Башка әсәрләрендәге кебек үк, комедиягә нигез итеп, Г. Камал тормыш материалын ала. Татар сәүдәгәрләренең, наданлыклары аркасында бөлеп, банкротлыкка чыгуы ул вакытларда шактый киң таралган була. Мисал өчен, Ш. Мөхәммәдевнең «Яфрак асты, яки Мәкәрҗә ярминкәсе» әсәрендә шундый герой сурәтләнә. Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, Сиражетдиннең прототибы булып Казан сәүдәгәре М. Апакаев тора. Бурычларын түләмәс өчен, ул юләргә сабыша һәм психик авырулар йортына эләгә. Озак та үтми, врачларга зур ришвәт биреп, шифаханәдән чыга.

«Банкрот» комедиясе 1911 елда языла. Г. Камалның башка әсәрләре арасында аның сәхнә тарихы иң бай санала. Татар буржуазиясе вәкилләренең әхлагын, яшәү рәвешен, мещанлык тормышын кискен тәнкыйтьләве белән әсәр, язылганнан башлап, һәрвакыт киң җәмәгатьчелек, театр труппалары игътибар үзәгендә була. Комедия «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1911 елны беренче тапкыр сәхнәгә куела һәм 1918 елга кадәр, ягъни әлеге труппа таркалганчы, аның репертуарыннан бер дә төшми. Төп герой Сиражетдин образында Г. Кариев һәм А. Кулалаев уйныйлар. Х. Гобәйдуллин истәлекләреннән күренгәнчә, Г. Кариев уенында җиңеллек, юмор күбрәк булса, А. Кулалаев үзенең героен юләр итеп кенә түгел, максатына ирешүдә шактый нык һәм хәйләкәр итеп күрсәтә.

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Банкрот» инкыйлабтан соң беренче тапкыр 1925 елны куела (реж.-куючы Ш. Шамильский, Сиражетдин — Б. Тарханов),

ә аннан соңгы елларда спектакль берничә тапкыр яңартып уйнала: 1933 (реж.-куючы К. Тинчурин, Сираҗетдин – Х. Әбҗәлилов), 1944 (реж.-куючы Х. Уразиков, Сираҗетдин – Х. Әбҗәлилов), 1962 (реж.-куючы Х. Уразиков, Сираҗетдин – Х. Әбҗәлилов, Р. Бикчәнтәев), 1978, 1989 (реж.-куючы Н. Исәнбәт, Сираҗетдин – Р. Шәрәфиев) һ. б. Театр белгечләре фикеренчә, әсәрнең төп темасын һәм идеясен иң уңышлы күрсәтү Х. Уразиков куелышында була, ә Сираҗетдин ролен әлеге спектакльдә Х. Әбҗәлилов уйный.

Әнә шул рәвешле әсәрнең язылу һәм сәхнә тарихы белән таныштыру, күптөрле истәлекләрне файдалану, альбомнар буенча спектакльләрдән күренешләр карау, төп рольләрне башкаручы артистлар белән танышу һ. б. укучыларда матур хисләр уята, кызыксынуларын үстерә һәм комедияне бөтен тирәнлегендә аңларга теләк тудыра.

Әсәрне анализларга керешеп, аның төп эпизодлары искә төшерелә. Комедиянең үзәгендә сәүдәгәр Сираҗетдиннең ялган банкротлыкка төшеп, хәйлә юлы белән зур табыш алу вакыйгасы ята. Байлык үзләштерү максатында ул шактый кыен һәм куркыныч адым ясый – Мәскәүдәге товар биреп торучы сәүдәгәрләргә зур күләмдә акча алып барганда, үзен поездда талау күренешен оештыра. Нәтиҗәдә Сираҗетдин «җүләрләнә» һәм, шуңа нигезләнеп, бурычлары өчен ташлама ясарлар дип өмет итә. Үзенең «ролен» бик яхшы башкарып, ул ялганына якыннарын гына түгел, Мәскәү сәүдәгәрләрен дә ышандыра.

Методикада драма әсәрләрен анализлауның түбәндәге юллары билгеле: а) «автор артыннан бару», ягъни сюжет буенча анализ ясау; ә) образлар системасы аша; б) тематик-проблемалы. Аерым хезмәтләрдә тагын әсәрнең төзелеше, тел-сурәтләү үзенчәлекләре аша анализлауны да күрсәтәләр. «Кайсы юлны сайларга?» дигән сорау һәр укытучы алдында тора. Белгәнебезчә, әдәби әсәрнең һәр элементы автор әйтергә теләгән төп идеяне ачуга хезмәт итә. Шунлыктан анализ башлангычы булып сюжеты да, образлары да, тел характеристикалары да, хәтта аерым бер деталь дә тора ала.

«Банкрот» комедиясенең үзенчәлекләре, хәрәкәтнең үстерелеше, төп конфликтның бирелеше, гомуми тематика һ. б. пьесаны анализлауның төп юлын билгелиләр – «авторга ияреп», ягъни сюжет үстерелеше буенча. Шул ук вакытта комедияне тирән эмоциональ, образлы кабул итүгә, әдәби-эстетик үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итәрдәй мәсьәләләргә – төп конфликтның сюжет-композициядә чагылышы, авторның вакыйгаларга, геройларга мөнәсәбәте, әсәрнең Г. Камал иҗатындагы урыны һ. б. – җитди игътибар бирү сорала.

Драма әсәрләрен анализлаганда, аерым күренеш, эпизодларны сәнгатьле уку һәм аларга аңлатма бирү кебек эш төре куллану уңышлы. Рольләргә бүлеп уку, сыйныфның үзенчәлекләреннән һәм мөмкинлекләреннән чыгып, видео һәм аудио язмалар тыңлау белән алмаштырылырга мөмкин. Комедиянең укылган яки тыңланган эпизодларын аңлатып бирү әлеге өлешнең гомуми сюжет үстерелешендәге урынын һәм ролен, персонажларның аерым сыйфатларын, аларның сөйләм телен, башкаларга мөнәсәбәтен, драматургның әдәби осталыгын аңларга, ачыкларга ярдәм итә һәм укучыларны китап белән игътибарлы эшләргә, геройларның эш-хәрәкәтләре, сүзләре артында яткан тирән мәгънәне күрергә өйрәтә.

Әсәр текстын өйрәнү, югарыда әйтелгәнчә, хәрәкәт үстерелеше буенча, рольләргә бүлеп уку, аерым эпизодларны анализлау һәм аңлатып уку, әдәби сурәтләү чараларын ачыклау кебек эш төрләре белән бәйләп алып барыла.

Г. Камал катнашучылар исемлегендә бары тик төп герой Сиражетдингә генә характеристика бирә: «Заһир дә бик суфи (тыштан бик изге) күренә торган сәүдәгәр». Чынлыкта кем ул, нинди кеше ул? Пьесаның беренче пәрдәсендә Сиражетдиннең Мәскәүгә, үзенә товар биреп торучыларга акча илтергә хәзерләнүе һәм китүе күрсәтелә.

Ул сәхнәгә газета тотып килеп керә һәм тамашачыларны ниндидер яшерен эш белән кызыксындыра: «Сез (газеталар. – *Ә.З.*) минем өчен бик кадерле нәрсәләр. Сез миңа никадәр зур гакыл бирдегез. Сез биргән гакылны шайтан үзе дә эзләп таба алмас. Коры көе генә, турыдан-туры гына, зарар иттем, кеше өстендә алачакларым бик күп китте – фәлән дип кенә шартлап булмый. Алай итеп кенә мәскәүләргә сумына ун-унбиш тиен генә биреп булмый. Аның мудасы да беткән, ышанмыйлар да. Ә болай булганда үзләренең дә күзләре алакаер». Нәрсә эшләргә уйлый соң ул? Сүз бит ниндидер кырык тугыз мең турында бара. Алдагы вакыйгалар шуны күрсәтә, Сиражетдин суд практикасын да, кешеләр психологиясен дә яхшы белеп эш итә. Банкта акча алганда, ул «очраклы рәвештә» генә аларны Мәскәүгә алып баруын әйтә. Өендә исә әлеге «акчаларны» (чынында гади кәгазьләр) хатыны алдында аягына урый, ягъни алдан үзенә шаһитлар әзерләп куя. Драматург тамашачыларны кызыксындыру белән Сиражетдиннең планнарын ачарга ашыкмый. Вакыйгаларның тормышчанлыгын күрсәтү өчен, авторга төп геройның яшәү рәвешен, аның белән бәйләнештә булган төрле кешеләрнең фикер-карашларын, теләк-омтылышларын сурәтләү кирәк.

Буржуаз-мещан тормышының бөтен яклары икенче пәрдәдә чагылыш таба. Уңышлы эшләнгән эпизод-күренешләрдә һәртөрле сәүдәгәр һәм сатучы хатыннарының мәгънәсезлекләре, әхлаксызлыклары, комсызлыклары, көнчелекләре бөтен тулылыгында ачыла. Бу уңайдан әлеге катлауның карашларын, кунакка гына йөрүгә, гайбәт сөйләшүгә, киенеп-ясануга гына кайтып калган яшәү рәвешләрен бик ачык күрсәтүче ике хатын арасындагы диалог кызыклы. Укучыларны алдан хәзерләп, бу эпизодның инсценировкасын сыйныф бүлмәсендә күрсәтергә мөмкин. Диалог бу хатыннарның рухи дөньяларының никадәр сай, ярлы икәнлеген күрсәтә. Тар карашларыннан читкә чыга торган һәрнәрсәне алар начар, ярамый дип кабул итәләр.

Икенче пәрдәдә шактый тулы итеп Сиражетдиннең хатыны Гөлҗиһан сурәтләнә. Күптөрле күренешләрдә күрсәтелеп, эпизодтан эпизодка аның характер сыйфатлары, аерым алганда, түбәнлеге, эчкерлеге ачыла бара. Иренең каты авырып китүен ишеткәч тә, (Сиражетдин үзенең планнарын беркемгә дә әйтми), аның турында кайгыртасы урында Гөлҗиһанны башка нәрсә борчый: «Аһ, харап булдык! Читек балтыры! Кырык тугыз мең сум! Туганым! Туганым! Ни эшлик? Кырык тугыз мең сум! Бөлдек, беттек! Инде ни эшлим? Мәҗлес! Бламажи! Кунаклар!..»

Бу мещанканың чын йөзе, иренә мөнәсәбәте тулысынча өченче пәрдәдә ачыла. «Инде Мәскәү бүләкләре кайта дип көтеп торганда гына, ирең шулай җүләрләнеп кайткач, ничек итеп хафаланмассың! Ичмасам, акчасын алдырмый гына кайткан булса, тагын да бер хәл иде, – ди Гөлҗиһан, үзен ире түгел, ә акчалар күбрәк борчыганын яшермичә, һәм илтифатсыз гына дәвам итә: – Сиражине башларына чәйнәп яксыннар, җүләр белән тормасам, миңа ир бетмәгән! Ачуымны китерсәләр, иртәгә үк аерылып китәрмен. Тәмам туеп беттем инде». Тар карашлы, мәгънәсез, шуның өстенә «баласы булмый» торган бу хатын үзен алыштыргысыз дип саный. Хәленең комедиячеллеге соңгы эпизодта иң югары ноктасына җитә:

«С и р а ж е т д и н. ...Эш пеште! Бер минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында! *(Чыгып китә.)*

Г ө л җ и һ а н *(ишектән сөйләнеп керә).* ...Үзе дә тереллде! Байлыгыбыз да үзебезгә калды. Кунакка барам, кунак чакырам, мәҗлес уздырам! Янсын дошманнарның йөрәге!»

Бу сүзләрне әйткәндә, Гөлҗиһан әле үзен ни көткәнен белми. Тамашачы, аның теләкләре белән мөмкинлекләре арасында җир белән күк аермасы барлыгын күреп, тагы да күбрәк көлә.

Өченче пәрдәдә хәрәкәт үстерелеше тизләнә һәм Мәскәү доверенныйларының, үзләре белән доктор алып, Сиражетдиннең җүләрлеген ачыклау өчен килүләрендә югары ноктасына җитә. Сиражетдин үзенең артистлык осталыгын тагын бер кат күрсәтә. Ул бик җиңел генә биш йөз сумга докторны сатып ала һәм тагын биш йөз сумга «акылын кайтара».

Драматург үзенең героен оста, тапкыр, хәйләкәр итеп сурәтли. Үзенең максатына ирешү өчен, Сиражетдин шактый зур тырышлык һәм ихтыяр көче, түземлелек күрсәтә. Ул алдан бик яхшылап үзенең афёрасын башкару юлларын уйлый һәм, шаһитлар әзерләп, «киләчәк тикшерүчеләр өчен юлны сызып куя. Алары чыннан да шул юл буенча киләләр һәм «кенәзгә» йөз сигез мең калдыралар»[1].

Сиражетдин әхлаксыз, кешелек сыйфатларын җуйган адәм заты булып күзаллана. Үзенең байлыгын арттыру, зур табыш алу өчен, ул әллә нинди түбәнлекләргә төшүдән, сау-сәламәт була торып җүләргә сабышудан да чирканмый.

Дәрес әнә шул рәвешчә Сиражетдин образына характеристика бирү белән тәмамлана.

Алдагы дәрестә «Банкрот» комедиясен өйрәнү дәвам итела. Фикер алышырга әзерләнү максатыннан укучыларга өйгә түбәндәге сораулар, биремнәр бирелә: 1. Комедиядә уңай герой бармы? Булса, кем ул? 2. Пьесаның финалын сез ничек аңлатырсыз? 3. Рус драматургы А. Н. Островскийның «Үз кешеләр — килешербез» комедиясен искә төшереп килергә.

Дәресне түбәндәге план буенча оештырырга мөмкин:

1. Пьесаның төп идеясен ачуда эпизодик образларның роле.
2. Әсәрдә уңай герой проблемасының чишелеше. Автор позициясе.
3. «Банкрот»ны А. Н. Островскийның «Үз кешеләр — килешербез» комедиясе белән чагыштырып карау.
4. Комедиянең Г. Камал иҗатында тоткан урыны.

Пьесаның идея эчтәлеген тирәнәйтүдә ярдәмче персонажларның әһәмияте бик зур. Алар, бер яктан, төп геройның аерым сыйфатларын күрсәтеп, аны тулыландырсалар, икенче яктан, әлеге образлар шул чорның социаль һәм иҗтимагый тормышын киң планда күрсәтеп, төрле катлау кешеләрендәге әхлаксызлык, комсызлык, мещанлык сыйфатларын ачуга хезмәт итәләр. Ярдәмче персонажлар арасында бигрәк тә Доктор образы аерылып тора. Ул сурәтләнгән эпизод аның кем икәнлеген тулысынча ача. Бу күренеш сәнгатьле итеп кычкырып укыла, аннары укучыларның фикерләре тыңлана.

---

[1] *Нуруллин И.* XX йөз башы татар әдәбияты. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. — 79 б.

«Доктор. ...Менә инде хәзер тамырларын карап карыйк. *(Сираҗетдиннең асылынып торган кулын кулына ала.)*

Шул арада Сираҗетдин бик кечкенә итеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра.

(Ул, биш йөзлеккә күзен төшереп, үзалдына.) Һа, алай икән, эш сизелде, бик шәп акылдан шашкан икән. Ярый, миңа барыбер. *(Кесәсеннән сәгать алган булып, биш йөзлекне кесәсенә тыга. Тамырын тотып караганнан соң.)* Эш бу яктан бик өметле түгел, тамыр бик еш тибә...»

Доктор биш йөз сумга бик җиңел генә, гадәти күренеш кебек, Сираҗетдинны «җүләр» итә, күрәсең, мондый эш белән ул беренче тапкыр гына шөгыльләнми. Бу моментта әлеге ике герой бер-берсен бик яхшы тулыландыралар. Алар өчен акчага бөтен нәрсә сатыла: намус та, сәламәтлек тә. Ул инде бу аферистларның хәтта яшәү законына әйләнгән.

Башка ярдәмче образлар – имче карчык Нәгыймә, Сираҗетдиннең туганнары Җамали белән Камали да үз чорының «җимешләре» итеп сурәтләнәләр. Әгәр беренчесе кешенең бәхетсезлегеннән акча эшләү өчен файдаланса, икенчеләре исә, сәүдә эшенә алынып та, укырга-язарга өйрәнмәгәннәр. Телеграмма уку өчен дә ниндидер бер Вәлигә йөгерәләр.

Эпизодик персонажлардан, әдәбият галиме И. Нуруллин билгеләп үткәнчә, «доверенный образлары гына канәгатьләндереп бетерми. Артык беркатлы кешеләр. Әгәр алар «князь»нең алдашуын сизеп алып, файданы бүлешү чарасына керешсәләр, нур өстенә нур, комедиянең идея эчтәлеге тагын да баерак булыр иде»[1]. Тәнкыйтьченең бу фикере белән килешми мөмкин түгел.

Шулай итеп, Сираҗетдин үзенең алдауга корылган планын уңышлы тормышка ашыра. Шул ук вакытта шактый уңай сурәтләнгән Мәскәү доверенныйлары алданып, җиңелеп калалар. Комедиядә уңай герой бармы соң? Авторның позициясе ничек? Мондый сорауларны ачыклау, гадәттә, дәрестә бәхәс тудыра. Укытучыдан исә, укучыларның активлыкларын, кызыксынуларын киметмичә, бәхәсне тиешле юнәлештә алып бару сорала. Бәхәс вакытында төрле карашларны чагыштыру әсәрнең төп идея эчтәлеген ачыкларга һәм күтәрелгән мәсьәләләргә автор мөнәсәбәтен билгеләргә ярдәм итә. Бу сөйләшүнең нәтиҗәсе буларак түбәндәге фикерләр ассызыкланса, яхшы булыр иде:

– драматург кешегә матур итеп яшәргә, кеше булып калырга комачаулаучы күренеш-сыйфатларны бөтен тулылыгы белән фаш итә;

– буржуаз-мещан тирәлегендә автор уңай герой тапмый, шуңа күрә аның позициясе катып калган феодаль-мещан әхлагыннан, бөтен яшәү мәгънәсе акчага, капиталга кайтып калган аерым сәүдәгәрләрнең яшәү рәвешеннән, намуссызлыкларыннан ачы итеп көлүдә чагыла. Ягъни уңай герой ролен әлеге көлү башкара;

– Г. Камал, Сираҗетдиннең «җиңүен» күрсәтеп, аңарда һәм аның кебекләрдәге икейөзлелек, комсызлык, әхлаксызлык кебек сыйфатларны кискен тәнкыйть итүе белән, алар өстеннән мораль җиңү яулый.

Өйрәнелә торган әсәрнең үзенчәлекләрен тирәнрәк ачыклау, рус әдәбиятының, аерым алганда, драматургиясенең татар әдәбиятына тәэсире турында укучыларның

---

[1] *Нуруллин И.* XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. – 79 б.

белемнәрен киңәйтү максатында, «Банкрот»ны А. Н. Островскийның «Үз кешеләр – килешербез» комедиясе белән чагыштыру – нәтиҗәле эш төрләреннән берсе. Г. Камал рус язучысын кабатламый, ә мөстәкыйль сюжетка нигезләнгән үзенчәлекле әсәр тудыра. Бу әлеге ике пьесада китерелгән проблемаларны һәм аларның чишелешен якыннан караганда күренә. Ике комедиядә дә сүз банкротлыкка чыгу турында бара. А. Н. Островскийның төп герое Большов үзен банкрот дип, билгеле инде, баю максатында белдерә. Шул ук вакытта көчсезләрне, ярлыларны төрлечә мыскылларга, изәргә гадәтләнгән бу сәүдәгәр акча биреп торучыларга бурычын кайтаруны үзенә хурлык дип саный, шуңа үзенең товарын теләсә ничек таратырга, хәтта юкка чыгарырга әзер. Нәтиҗә буларак Большовның байлыгы приказчигы Подхолюзин кулына керә, ә үзе бурычын түләмәүчеләр «чокырына» эләгә. Сәбәбе нәрсәдә соң? Төп сәбәп Большовның томаналыгында, кирелегендә, мәгънәсезлегендә, ягъни ул инде кичәге көн сәүдәгәре. Г. Камалның герое Большовка караганда хәйләкәррәк, үткенрәк. Ул, заман үзгәрешләрен тиз аңлап алып, үзенең планнарын тормышка ашыруда газета-журнал мәгълүматына таяна һәм, Мәскәү фабрикантларын алдап, отышта кала.

Дәрес материалына нәтиҗә ясап, укытучы «Банкрот» комедиясенең сюжет-композиция төзелеше, тормышчан характерлары, көчле фаш итүче юнәлеше, әдәби-эстетик эшләнеше белән Г. Камал иҗатында иң яхшы әсәрләрнең берсе булуын ассызыклап күрсәтә.

Әлфәт Закирҗанов,
филология фәннәре докторы, доцент

Г. КАМАЛНЫҢ «БАНКРОТ» КОМЕДИЯСЕНДӘ ГАИЛӘ МӘСЬӘЛӘСЕ

(10 нчы сыйныф)

Максатлар:

1. Г. Камалның «Банкрот» әсәрен үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү.
2. «Бәхетле гаилә» төшенчәсен аңлау өчен җирлек тудыру, иҗади фикерләү, дәлилләп бирү осталыгын үстерү.
3. Укучыларда тормышка дөрес караш тәрбияләү, әхлакый мәсьәләләрне аерып чыгару.

Җиһазлау: «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», дәреслек, язучының портреты, интерактив такта, презентация.

Метод һәм алымнар: өлешчә тикшеренүгә корылган әңгәмә, проблемалы сорау кую.

Дәрес барышы

I. Оештыру. Эшкә юнәлеш бирү.

Укытучы: Укучылар, сез бүген өч төркемгә бүленеп эшләрсез. Бер-берегезне тыңлап, үзара киңәшләшеп, фикерләрегезне дәлилләргә тырышырсыз. Кабат исегезгә төшерәм: нинди генә булуына карамастан, фикерләр укытучы тарафыннан тәнкыйтьләнми. Соңыннан бергәләп нәтиҗә ясарбыз. Уңышлар сезгә!

II. Актуальләштерү.

Укытучы: Укучылар, сезнеңчә, гаилә нинди булырга тиеш? (Укучылар төркемнәрдә эшлиләр, һәр төркемнән бер укучы җавап бирә.)

Көтелгән җавап: *I төркем.* Гаилә дус, тату, бердәм булырга тиеш. *II төркем.* Гаиләдә әти-әни һәм бала булырга тиеш дип уйлыйбыз. Безнеңчә, гаилә әгъзаларының берсен-берсе тыңлый белүе, хөрмәт итүе бик күңелле күренеш. *III төркем.* Гаиләдә җаваплылык һәм ярату хөкем сөрергә тиеш, сабырлык та комачауламас.

Укытучы: Рәхмәт, укучылар, фикерләрегез бик матур. Әйдәгез, «гаилә» төшенчәсенә билгеләмәне сүзлекләрдән эзләп карыйк. («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» белән эш.)

Укытучы: Укучылар, исегезгә төшерегез әле, алдагы дәрестә без нинди әсәр укыдык, кайсы язучы иҗаты белән таныштык?

Көтелгән җавап: Драматург Г. Камалның (портреты күрсәтелә) «Банкрот» комедиясе белән таныштык.

Укытучы: Әйтегез әле, әлеге комедиядә гаилә бармы?

Көтелгән җавап: Бар, Сираҗетдин Туктагаев гаиләсе. Ул хәләл җефете Гөлҗиһан белән яши. Сираҗетдиннең ике ир туганы бар.

Укытучы: Укучылар, әлеге гаилә турында ниләр әйтә аласыз? (Һәр төркемнән бер укучы җавап бирә.)

Көтелгән җавап: Гаилә тулы түгел, чөнки балалары юк. Әлеге гаиләдә бер-берсенә ышаныч, хөрмәт, мәхәббәт булмавы күзгә ташлана.

Укытучы: Рәхмәт, балалар, ә хәзер, әйдәгез, фикерләрегезне мисаллар белән дәлиллик.

Көтелгән җавап: *I төркем.* Сираҗетдин хатыны Гөлҗиһанга җикеренеп кенә тора, дорфа итеп сөйләшә, аның фикерен тыңлап та тормый. *II төркем.* Гөлҗиһан ире сүзеннән уза алмый, ни әйтсә, шуңа риза була, аңа ярарга тырыша, әмма аның

таланып, юләрләнгәнен белгәч, ире кирәкмәс кешегә әйләнә. «Гомеремдә мин аннан ни рәхәт күрдем?» – дип зарлана. *III төркем.* Сиражетдин хатынына гына түгел, туганнарына да ышанмый, аларның берсе белән дә киңәшләшми, үзе уйлаганча гына яши.

Укытучы: Рәхмәт, укучылар! Ә хәзер, әйдәгез, бергәләп уйлыйк әле. Бәхетле гаилә кору өчен, Сиражетдин белән Гөлҗиһанга нәрсә комачаулый? Ни өчен алар матур гаилә төзи алмаганнар? Әлеге сорауларга җавап эзләр алдыннан, спектакльдән өзек карап китик. (Өзекне табып булмаган очракта, рольләргә бүлеп, дәреслектән укытырга мөмкин.)

Көтелгән җавап: *I төркем.* Безнең уйлавыбызча, бәхетле булу өчен, аларга комсызлык, акчага, байлыкка табыну комачаулый. *II төркем.* Гаиләдәге мөнәсәбәтләрне җылыту өчен, сабый җитмидер, бәлки. Әлбәттә, балалары булган гаиләләр дә таркала, әмма Гөлҗиһан «кысыр хатын» сүзен бик авыр кичерә. *III төркем.* Гаилә тоткасы – хатын-кыз, Гөлҗиһанның наданлыгы, кешедән көнләшү, бай булырга теләве Сиражетдингә берничек тә уңай тәэсир итә алмый. Үзара мөнәсәбәтләренең начар булуына Гөлҗиһан үзе дә гаепле.

Укытучы: Әйдәгез, балалар, игътибарны слайдка юнәлтик. «Комсызлык белән бәхетнең очрашканы юк. Алар бер-берсен белмиләр *(Бенджамин Франклин)*». Әлеге гыйбарәне сез ничек аңлатыр идегез? (Фикерләр тыңлана.)

Укытучы: Бу фикер без бүген сөйләгәннәргә туры киләме?

Көтелгән җавап: Әйе, туры килә. Сиражетдин белән Гөлҗиһанга үзара тату, матур гаилә корырга комсызлыклары комачаулый. Алар беркайчан да булган белән канәгатьләнә алмыйлар. Әсәрдән күренгәнчә, әлеге гаиләгә таркалу яный, чөнки Сиражетдин яшь хатын алу турында хыяллана. Гөлҗиһан да аны чын күңелдән яратмый, ул иренең акчаларына гына гашыйк.

Укытучы: Укучылар, әйдәгез, автор фикерен ачыклап карыйк әле.

Көтелгән җавап: Автор акча бәрабәренә намусларын саткан кешеләрдән көлә. Г. Камал кешенең акчага, байлыкка омтылуын, акча алдында кол булуын күрсәтә, байлык өчен хәтта җинаять кылырга да әзер булуын ача.

III. Гомумиләштерү.

Укытучы: Укучылар, әлеге әсәрдә күтәрелгән проблемалар бүген дә актуальме?

Көтелгән җавап: Әйе, безнең заманда да җиңел юл белән акча үзләштерергә теләүчеләр, ялган юл белән банкротлыкка чыгучылар шактый. Акчаның, байлыкның гына бәхет китермәвен тормыш мисалында күреп торабыз. Шулай булмаса, «хан сараенда» яшәүче гаиләләр таркалып, балалары ятим үсмәс иде. Кызганыч, матди яктан гына түгел, күңел байлыгы ягыннан «банкрот» булган адәмнәр торган саен ешая бара, ә бу – тагын да аянычрак күренеш.

Укытучы: Әйтегез әле, бай, мул тормышта яшәү начармыни?

Көтелгән җавап: Юк, әлбәттә, кеше үзенең гомерен хәерчелектә уздырырга тиеш түгел. Әмма аның байлыгы намуслы хезмәт нәтиҗәсендә тупланырга тиеш.

IV. Өй эше:

1. «Минем булачак гаиләм» темасына инша язарга.
2. Байлык бәхет чыганагымы? Шул хакта уйлануларыгызны әдәбият дәфтәренә язып килегез.
3. Әсәрнең сәхнә тарихын өйрәнеп килергә.

Гөлгенә Нурмиева,
Казан шәһәренең 27 нче номерлы гимназия укытучысы

##ҺӘР ЧОРНЫҢ ҮЗ «БАНКРОТ»Ы
(«БАНКРОТ» СПЕКТАКЛЕНЕҢ ЯҢА КУЕЛЫШЫ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ)

2014 елның 28 августында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары һәм бер төркем кунаклар арасында эшлекле иҗади очрашу узды.

Очрашу Татарстан китап нәшриятының «Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты» редакциясе мөдире *Талия Шакирова* һәм редакция мөхәррире *Гөлнара Мансурова* тарафыннан оештырылды.

Түгәрәк өстәл сөйләшүендә, бер яктан, Г. Камалның «Банкрот» спектаклендә катнашучы артистлар, икенче яктан, филология фәннәре докторы, профессор *Дания Заһидуллина*, 96 нчы номерлы гимназия укытучысы *Гузәлия Тарханова*, 27 нче номерлы гимназия укытучысы *Гөлгенә Нурмиева* һәм аның укучылары катнашты[1].

Максат: артистлар һәм тамашачы диалогы аша укучыларга «Банкрот» комедиясенең актуальлеген һәм әһәмиятен, заманча куелышта чагылыш тапкан үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итү.

«Түгәрәк өстәл» сөйләшүе

Талия Шакирова: Театр җәмгыятьне, бигрәк тә аның яшь буынын тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйный. Тормышыбызны театрдан башка күз алдына китерү дә кыен. Хөрмәтле артистларыбыз, сезнең фидакяр хезмәтегез алдында баш иябез. Бүгенге очрашу укучыларыбыз теләген исәпкә алып оештырылды. Мәктәп баласы күңеле белән театрны якын итә икән, димәк, ул артистларыбызны, аларның уенын ярата. Укучылар өчен мондый очрашулар бик кирәк, чөнки кайбер сорауларга җавапларны артистларның үзләреннән ишетү күпкә яхшырак. Сүзне укытучыларга һәм укучыларга бирәбез.

Гөлгенә Нурмиева: Балалар, сезгә спектакль ошадымы? Ул сезне кайсы ягы белән җәлеп итте?

1 нче укучы: Спектакль бик ошады. Беренче минуттан ук сәхнәдә бара торган тормыш эчендә калган кебек буласың.

2 нче укучы: Без Г. Камалның «Банкрот» комедиясен укыган идек. Бу тамашаның нигезендә шул ук әсәр ятса да, сәхнәгә куелышында бераз гына үзгәреш сизелә. Артистларга соравым бар: сез моны ничек аңлатасыз?

Наил Дунаев («Василий Дмитриевич»): «Банкрот» комедиясе беркайчан да актуальлеген югалтмаган. Аны күп тапкырлар куйганнар һәм хәзер дә куялар. Беренче тапкыр «Банкрот»ны Г. Кариев куйган. Режиссёрлар Х. Уразиков та, П. Исәнбәт тә аны үзләренчә куйганнар. Алар җәмгыятьтә яшәп килгән социаль гаделсезлекләрдән, җитешсезлекләрдән ачы итеп көлгәннәр.

Г. Камал театрының бүгенге режиссёры Ф. Бикчәнтәев сәхнәләштергән вариантны да тамашачы яратты, чөнки «Банкрот»тагы тормыш безнең заман яшәеше белән бик охшаш. Без үзебезнең тамашачыбыз белән уртак тел таптык дип уйлыйм.

---

[1] «Банкрот» әсәре турында сөйләшү мәктәптә дә дәвам итте. Бу язмада чагылыш тапкан кайбер сораулар һәм җаваплар мәктәптә оештырылган сөйләшүдән дә алынды.

«Банкрот» спектакленнән күренешләр. 2014

Искәндәр Хәйруллин («Гарәфи»): Һәр заманның үзенә хас үзенчәлеге бар. Режиссёрлар төрле булган кебек, тамашачылар да төрле. Хәзерге яшьләргә бүгенге тамаша аңлаешлырак та әле. Тормышны гел бизәкләргә төреп кенә күрсәтеп булмый. Ул ничек бар, шулай кабул ителергә тиеш. Без аны шулай күрсәттек тә һәм, минемчә, тамашачы аны җылы кабул итте. Артистлар да бик шәп уйнадылар.

3 нче укучы: Комедиядә хәзерге заманга хас «суши», «Бәхетле» кибете h. б. яңа сүзләр очрый. Бу сүзләрне куллану арттырып җибәрү булмыймы?

Рушания Юкачёва («Мәликә»): Бу комедия хәзерге заманга яраклаштырып куелды. Ул шулай булырга тиеш тә. Яңа сүзләрне кулланып сөйләшү комедияне бүгенге заманга тагын да якынайта төшә. Яшьләргә дә, өлкәннәргә дә аңлашыла алар. Эчтәлеккә бер зыян да килми, әсәрне кабул итәргә әзер тамашачы өчен бу гадәти әйбер.

Гүзәлия Тарханова: Г. Камал да «бламажи» сүзен кулланган. Бу да французның «бламанже» дигән сүзеннән үзгәртеп ясалган. Чыннан да, безнең чор тамашачысы үз вакытында бу сүзне кабул итте бит. Димәк, бүген дә тамашачы яңа сүзләрне шулай ук кабул итәчәк.

Дания Заһидуллина: Сәхнә бизәлеше шартлылыкка корылган. Шартлылыкны бар тамашачы да кабул итәме? Яшьләргә моны ничек аңлатыр идегез?

Әзһәр Шакиров («Доктор»): Бик тә урынлы сорау. Сәхнә бизәлеше, чыннан да, үзенчәлекле. Дивардагы тәгәрмәчләр төрле юнәлештә әйләнеп торалар. Алар

тормышның үзен сурәтләү өчен кирәк. Тарихи вакыйгалар да кабат әйләнеп кайтучан, шуңа күрә тәгәрмәчләрнең кайберләре кирегә әйләнә. Аларның күпчелеге алга таба әйләнә, бу тормышның дәвам итүен, гел алга баруын чагылдыра. Түшәмгә элеп куелган вазалар, сәгать, зур сейф та үз урыннарында. Беренчедән, тамашачы аларны шартлы рәвештә бик җиңел кабул итә. Икенчедән, артистка иҗат итү мөмкинлеге дә зурая. Трамвай да төрле юнәлештә йөреп кенә калмый, революциягә кадәр булган документаль сәхифәләрне чагылдыра торган экран ролен дә башкара. Зур түгәрәк өстәлнең дә мәгънәсе үзенчәлекле. Кешеләр бар нәрсәне дә уртага салып эш итәргә һәм уртак фикергә килергә тиеш. Тормыш үзе түгәрәк сыман гел әйләнеп-кабатланып тора. Гомумән, игътибарлы тамашачы моны тиз аңлый.

Гөлгенә Нурмиева: Комедия геройлары турында сездә нинди фикерләр туды?

4 нче укучы: «Банкрот» әсәрен укыганнан соң, без геройларны башкачарак күз алдына китергән идек. Сиражетдин дә, Гөлҗиһан да олырак яшьтәге кешеләр булып тоелган иде. Бүген без аларны башкачарак күрәбез. Миңа Ләйсән Рәхимованың Гөлҗиһаны бик ошады. Ул гади дә, самими дә, тамашачыны ышандыра ала. Аның тыныч кына әйтеп куйган репликаларын ишеткәч, Гөлҗиһанны тыйнак һәм ипле, кайгыртучан хатын итеп күрәсең.

5 нче укучы: Ул шундый шаян. Ире киткәч, асраулары һәм кибетчеләре белән чын оркестр оештырып, җыр уйнаулары бар тамашачыга да ошады. Мин Ләйсән Рәхимованың мондый таланты барлыгын белми идем әле.

1 нче укучы: Радик Бариев төп рольне башкарды. Минем аңа соравым бар. Сезгә кадәр бу рольне Р. Шәрәфиев уйнаган. Сез аннан үзегезгә ни дә булса алдыгызмы?

Радик Бариев («Сиражетдин»): Равил абый – үз чорының иң шәп герое. Минем героем бөтенләй башка. Мин Сиражетдинне үземчә уйнарга һәм ачарга тырыштым.

2 нче укучы: Миңа Радик Бариевның турыдан-туры тамашачы белән уйнавы бик ошады. Ул тамашачылар белән бик тиз дустанә мөнәсәбәтләр урнаштырды һәм тамашачы мондый уенны кабул итте. Бигрәк тә, сейфка акча яшергәннән соң, аны югарыга күтәртеп кую һәм акчаны «сакларга» дип тамашачыга тапшыру күренеше бик оста уйналды. Әгәр дә таныш булмаган тамашачы белән шулай уйный алган икән, димәк, Радик Бариев кешеләрне аңлый торган чын психолог та булып чыга, минемчә.

3 нче укучы: Миндә Искәндәр Хәйруллин катнашкан эпизод ике төрле фикер уятты. Ул, һичшиксез, талантлы артист. Искәндәр абый аны бу уенында да раслады, шуңа күрә аның эпизодик роле дә нык истә калды, «телсез» Гарәфине без дә аңладык. Һәр хәрәкәте, мимикасы белән ул тулы бер вакыйганы «сөйләп» бирде. Тик болай эшләгәндә, уен сузыла төште сыман.

Искәндәр Хәйруллин: Режиссёр белән берлектә бу образ турында озак уйландык. Вакыйганы сөйләп кенә аңлату артык кыска булып тоелды. Миңа бу образны үзем теләгәнчә ачу мөмкинлеге бирелгәч, мин шушы икенче вариантны сайладым. Минемчә, ул уңышлы чыкты.

Гөлгенә Нурмиева: Укучылар, ярдәмче образлар һәм аларны башкаручылар турында сез ни диярсез?

4 нче укучы: Миңа Фәридә Сафина башкарган Хәдичә образы бик ошады. Ул Сиражи байга кирәк-ярак алып кайтырга кушып кына калмый, бер метр чамасы озынлыктагы исемлекне Гөлҗиһан кулына тоттыра. Җитмәсә, расписка яздыртып, муенына

аскан печать белән тамгалагач, бу нәкъ безнең көннәрдәге кешеләрне сурәтләгән кебек килеп чыкты. Димәк, режиссёр да, артист та иҗат итәләр.

5 нче укучы: Нәгыймә абыстайны башкаручы Рузия Мотыйгуллинаның бар хәрәкәте дә соклану тудыра. Ул һәр ситуациядә үзгәреп тора. Бер карыйсың, ягымлы һәм хәйләкәр, икенче караганда, ул усал һәм икейөзлегә әйләнә.

1 нче укучы: Башка комедияләрдә уңай геройны күрергә мөмкин. Монда бер уңай герой да юкмыни?

Әзһәр Шакиров: Комедиядә уңай герой булмаса да, монда тамашачы көлүе уңай герой булып тора.

Дания Заһидуллина: Театр артистларының уены искиткеч. Арттырып сурәтләү һәм башка көлке тудыру алымнары һәм детальләре уңышлы файдаланылган. Тамашачыларның, бигрәк тә яшь буынның бу комедияне кабул итүе шул турыда сөйли. Рәхмәт сезгә, хөрмәтле артистлар!

Гөлнара Мансурова: Укучылар, сез матур тамаша карадыгыз, үз фикерләрегезне дә җиткерә алдыгыз. Сезгә һәм хөрмәтле артистларыбызга зур рәхмәт.

Гүзәлия Тарханова,
Казан шәһәренең 96 нчы номерлы
гимназия укытучысы

АФӘРИН, СИРАҖЕТДИН![1]

Пьеса 1 пәрдәдә

КАТНАШАЛАР:

Сираҗетдин – «Банкрот» комедиясе герое.

Гөлсылу – Сираҗетдиннең яшь хатыны.

Сираҗи-2 – Сираҗетдиннең икенче «Мин»е, эчке дөньясы, уйлары.

Нәгыймә – им-том итеп йөри торган карчык.

Гайникамал – асрау кыз.

Беренче күренеш

20 нче гасыр башы. Сираҗетдин Туктагаевның фатиры. Гөлсылу көзге каршында бизәнә.

Гөлсылу. Гайникамал, Гайникамал, дим.

Гайникамал. Мин монда, абыстай.

Гөлсылу *(кабынып)*. Нинди абыстай ул тагын? Хуҗабикә, диген, юньсез. Бар, бай абзыеңны бирегә чакыр.

Гайникамал. Хәзер чакырам, абыс... хуҗабикә. *(Чыга.)*

Сираҗи керә.

Сираҗи. Нәрсә бар, Сылуым? Мәкәрҗә ярминкәсенә ашыгуымны беләсең бит. Әйт сүзеңне тизрәк.

Гөлсылу *(иркә тавыш белән)*. Беләм, җаным! Сәлим бай хатыны Гөлҗамалны да алып бара икән. Минем дә барасым килә.

Сираҗи. Юкны сөйләмә. Мин анда уйнарга бармыйм. *(Зур кесә сәгате чыгарып карый.)* Кара, синең белән сөйләшеп торып, банкка соңга калам икән ич.

Гөлсылу. Парахутың кайчан китә?

Сираҗи. Кич белән. Минем күлмәк-ыштаннарны тыктыңмы?

Гөлсылу *(үпкәләвен сиздереп)*. Гайникамал тыккандыр.

Сираҗи *(йомшарып)*. Җә, ярый, үпкәләмә, үпкә ашатырлар үзеңә. Сиңа нәрсә алып кайтыйм?

Гөлсылу *(борылып)*. Миңа ефәк күлмәклек, алтын беләзек алып кайт. Кешелеккә кия торган туфлием дә аякны кыра. Теге зәңгәр күлмәгемә көмеш брошка бик килешер иде. Тагы-ы-ын...

Сираҗи *(бүлдереп)*. Җә, җитәр, вакыт калса, барын да алырмын. Банкка соңга калам. *(Чыга.)*

Нәгыймә керә.

Нәгыймә *(җилпәзә белән җилләнеп)*. Уф, көчкә килеп җиттем. Сираҗетдин Мәкәрҗәгә китә, дигәнннәр иде. И череп тә баеды инде. Банкрутка чыккач, зур таш пулат салдырды. Гөлҗиһанны дөбердәтеп куып чыгарды да япь-яшь кызга өйләнде. Машинада гына җилдерәләр.Түлке Гөлсылу Гөлҗиһан түгел инде. Бик саран. Тамыр

[1] Г. Камалның «Банкрот» әсәренә ияреп язылды.

кайнатырга да кушмый. Ярар, Ходайдан вакыт җиткәч, барыбер миңа ялынычы төшми калмас. Тамыр төнәтмәсенә бер ияләшкәч, атна саен ясатыр, Алла теләсә. Мине« имче Нәгыймә», диләр. Бәй, кайда соң болар? Элегрәк, Мәскәүгә барган саен, илле тиеннән дә ким таммый иде сәдака. Моңарчы бик ипле булды Сираҗетдин. Берәү дә күренми, әллә соңга калдыммы соң, Ходаем?

Саквояж тоткан Сиражи керә.

Сиражи. Исән-саумы, Нәгыймә абыстай!

Нәгыймә. Саулык шәптән түгел әле, Сираҗетдин. Сиңа юл догасы укырга дип, көчкә килеп җиттем.

Сиражи. Укы, Нәгыймә абыстай, укы.

Тегесе укый, дога кылалар.

Сиңа хәерем бар иде, ал әле. *(Хәер бирә.)* Гөлсылуга күз-колак булырсың, Нәгыймә абыстай. Үзе генә Бакыр бабай бакчасына да, базарга да йөрмәсен. Кара аны, Нәгыймә абыстай, җавабын синнән сорармын.

Нәгыймә. Ярар соң, Сираҗетдин.

Сиражи чыга.

Бер сум көмеш биргән бит. *(Тешләп карый.)* Гөлсылуга күз-колак булырга кушты, шуңа юмартланган инде. Менә бит, бирәм дигән колына...

Гөлсылу керә.

Гөлсылу. Син дә килеп җиткәнсең икән. Сәдака дигәндә, Себергә китәргә дә риза син, Нәгыймә абыстай.

Нәгыймә. Алай каты кыланма син, килен. Миннән зыян күрмәссең әле. Мин ясаган тамыр төнәтмәләрен эчеп, гел көлеп кенә йөрерсең. Мә, эчеп кара әле. *(Кечкенә шешә бирә.)*

Гөлсылу *(эчеп карап)*. Кара, шәп нәрсә күренә бу, оетып та җибәрде. Иртәгә алып килерсең.

Нәгыймә. Аны ясау өчен бераз акча кирәк, килен. Сырасы-мазары, дигәндәй.

Гөлсылу. Мә, ал. Калганын иртәгә бирермен. Кара әле, Нәгыймә абыстай, минем белән Бакыр бабай бакчасына барасың киләме? Озатучым булып.

Нәгыймә. Барам, ник бармаска, күңел ачып та кайтырмын бераз.

Гөлсылу. Тик Сиражи белмәсен. Мин сине буш итмәм. *(Чыга.)*

Нәгыймә. Белмәс, белмәс. Серне тишәргә мин җүләрме әллә?! Ике яклап та тамып торса, эчне төртеп тишмәс әле. Ярый, аш өенә төшим. Килгән-килгән, чәй эчеп китим. Гөлҗиһан барында рәхәтләнеп кунак була торган идем дә. Бу саранрак шул. Әйдә, чәй эчеп кит, дисә, кимерелмәс иде әле. *(Чыга.)*

Икенче күренеш

Сиражи керә.

Сиражи. Банкта эшне бетердем. Ярминкәдән кызыл мал төяп кайтсам, тагын бер кибет ачып җибәрермен. Тимерне кызуында сугарга кирәк. Байлык арта артуын, тик күңел башканы тели. Элегрәк ун сум керем керсә дә, шатлык була иде. Хәзер анысына да артык ис китми. Башкача яшисе иде, тик ничек? Үзебезнең бистәдә бер мәчет төзергә уйлап торам да...

Янына С и р а ж и-2 килеп баса.

С и р а ж и-2. Дөрес уйлыйсың, югыйсә башка татар байларыннан оят. Аларның кайберләре мәктәпләр ачтырды, гәҗит-журнал чыгарырга ярдәм итүчеләре дә бар.

С и р а ж и. Тагын кайдан килеп чыктың инде? Син әйтмәсәң дә, шулайрак уйлый башлаган идем.

С и р а ж и-2. Мәкәрҗәгә барам, дисең, ә?

С и р а ж и. Берәр нәрсә уйлый башласам, киләсең дә җитәсең. Ник минем эшкә тыгыласың, кем соң син ул кадәр?

С и р а ж и-2. Оныттыңмыни? Мин ул – син. Мин – синең икенче яртың. Мине син үзең барлыкка китердең. Банкрутлыкка чыкканнан бирле, башыңда ике төрле уй синең. Син бер төрле уйласаң, мин – синең икенче төрле уең.

С и р а ж и. Үзем дә аптырыйм. Элек башымда байлык туплау уе гына иде.

С и р а ж и-2. Кеше үзгәрми тормый. Синең дә уйларың үзгәрде.

С и р а ж и. Соңгы вакытларда башка әллә нинди уйлар килә шул.

С и р а ж и-2. Мәчет салырга телисең, шул турыда уйлыйсың. Уйлыйсы да юк, тот та эшлә. Алдап-йолдап, банкрут булдың, йөз дә сигез мең акчаң янга калды. Баедың. Урыс баеса чиркәү сала, татар баеса хатын ала, диләр. Син дә сал үзебезнең бистәдә шәп мәчет. Халык рәхмәт әйтер үзеңә.

С и р а ж и. Гөнаһларың кимер, савабың артыр, дисеңме?

С и р а ж и-2. Дөрес. Син, шуны белә торып, хатының бар өстенә икенчене алдың. Нәрсәсе ярамый иде Гөлҗиһанның?

С и р а ж и. Акча югалтуны белгәч, мине кайгыртасы урында, югалган акчалар өчен кайгырды. Ул мине түгел, акчаларымны гына яратты. Аңа плюш пәрдәләр, матур киемнәр генә кирәк иде.

С и р а ж и-2. Хәзер ни үзгәрде соң? Гөлсылуга да син кирәк түгел. Аңа да байлык кына кирәк. Гөлҗиһаның күзеңә генә карап тора иде, бусы үзен генә кайгырта. *(Саквояжга күрсәтеп.)* Бер саквояж тотып чыгып китәсең ич. Гөлҗиһаның бер атналык ризык төяп җибәрә иде. Ә бусы нәрсә әзерләде?

С и р а ж и. Син дә каныма тоз салма әле. Ашарга-мазар алмыйм, парахутта ресторан бар, шунда капкалармын.

С и р а ж и-2. Бик алыр идең дә, сиңа аны әзерләп бирүче юк. Аңладыңмы инде?

С и р а ж и. Гөлсылу мине ярата. Минем өчен үлеп тора.

С и р а ж и-2 *(көлеп)*. Ярата? Син китүгә үк, акчаңны туздырып, күңел ачып яши башлаячак.

С и р а ж и. Мин мәҗлес җыярга үзем рөхсәт иттем.

С и р а ж и-2. Җыймый ул мәҗлес. Саран синең бу хатының. Акчаңны башкача башка урында туздырыр. Гомереңне алданып үткәрмә. Аерып җибәр син аны.

С и р а ж и. Мин хатынсыз ничек яшәрмен?

С и р а ж и-2. Бала табарга да теләмәгән хатын ник кирәк сиңа? Синең үз байлыгыңны калдырырлык улың да, кызың да юк ич.

С и р а ж и. Әйе, анысын дөрес әйтәсең. Гөлҗиһан да кысыр булды. Күпме яшәп, Гөлсылу да бала турында авыз ачмый. Сүз кушсаң, чыга да китә.

С и р а ж и-2. Син үзең дә гаепле. Шулкадәр байлыгың була торып, берәр ятим асрый алмыйсыңмы әллә?

С и р а ж и. Ятим бала асрасаң, авызың-борының кан булыр, ди халык.

Сиражи-2. Син дә ятим идең. Мин хәтерлим әле, юка бишмәт киеп, калтыранып йөри идең. Ерак туганың ачка үләргә ирек бирмәде: кибетенә эшкә алды. Приказчикларның йомышчысы итеп куйды.

Сиражи. Мин үзем дә аякка басарга тырыштым. Көнне төнгә ялгап эшләдем, ну теләгемә ирештем.

Сиражи-2. Баедым, димәкче буласыңмы? Приказчиклар күрмәгәндә күпме акча чәлдерә идең? Кибетче ярдәмчесе итеп куйдылар үзеңне. Шул чакта бай абзаңның малын итәк астыннан шудырып та шактый акча эшләдең. Тора-бара үзең дә кибет тота башладың. Әнә хәзер ничек баеп киттең! Тик барын да оныттың, ятимнәргә ярдәм итеп яшәсәң, әҗере кайтыр иде.

Тавышлар ишетелә.

Әнә хатының керә. Парахутта сөйләшеп бетерербез. *(Чыга.)*

Гөлсылу. Сиңа әйтәм, Мәкәрҗәдә озак торырсың микән?

Сиражи. Эшне бетермичә кайтып булмас. Ник сорыйсың?

Гөлсылу. Болай гына. Синсез күңелсез булыр инде.

Сиражи. Булмас. Әнә Гөлҗамал абыстай янына барып, гарәпчәңне ныгыта тор. Аскы катта бер бүлмә буш тора, шунда бала-чага укытырсың.

Гөлсылу. Кит әле, ни сөйлисең син? Мин, абыстай булып, кеше балалары укытыр өчен кияүгә чыкмадым.

Сиражи. Үзебезнекеләр дә булыр әле, соңыннан шуларны укытырсың. Абыстай сине күп нәрсәгә өйрәтер.

Гөлсылу *(читкә)*. Синнән бала табып, аны карап интегергә җүләрмени мин?!

Сиражи *(сәгатен карап)*. «Меркурий» парахуты китәргә күп калмаган икән. Ярый, җаным, мин китәм инде, хуш. Тәртипле генә торыгыз. *(Чыга.)*

Гөлсылу. Хуш, Сиражетдин. *(Ишеккә кадәр озата.)* Тәртипле генә тор, дигән була картлач. Яшь гомеремне заяга үткәрәм ди, көт. *(Асраугa.)* Гайникамал, син кайда?

Гайникамал. Монда абыс... әй лә, хуҗабикә.

Гөлсылу. Мин туган апаларга барам, бәлки, кунып та калырмын. Өйне кара.

Гайникамал. Бәй, абзый Мәкәрҗәгә китте ич. Туган-тумача җыеп, табын уздырмыйбызмыни?

Гөлсылу. Син нәрсә, Гөлҗиһан кебек җүләр дип белдеңме әллә мине? Аларны ашатып-эчертеп ятарга башыма тай типмәгән әле.

Гайникамал. Абзый күп итеп акча калдырды ич.

Гөлсылу. Күп белмә. Ул акчага урын табармын мин. Бар, эшеңдә бул. *(Чыга.)*

Өченче күренеш

Газета тотып, Сиражи каютага керә. Аңа Сиражи-2 ияргән.

Сиражи. «Вакыт» гәҗите. Элегрәк мондый гәҗитләрне уку түгел, кулга да тотмый идем. Бар укыганым сәүдәгәрләр турында иде.

Сиражи-2. Шәп ич, ә. Ырынбур бае Гани Хөсәеновны күрербез дип кем уйлаган?! Менә кемнән үрнәк алырга кирәк безгә!

Сиражи. Ул Аурупа илләре белән дә эш йөртә икән ич.

Сиражи-2. Татар милләте бай да, укымышлы да булырга тиеш, ди. Кара син аны, ә.

Сиражи. Безнең янда утыручы кара фикерле юан бай бер дә яратмады аның сүзләрен. Бар кеше дә укымышлы булса, безгә кем эшләр, ди.

Сиражи-2. Гани байның энесе бик тиз томалады аның авызын. Укымышлы милләтнең генә киләчәге була, акча саный белү генә җитми, дигәч тынды теге.

Сиражи. Юан байның күршесе ни диде әле?

Сиражи-2. Халык турында дәүләт кайгыртсын. Ник әле мин хәләл акчама мажик баласын укытырга тиеш, диде.

Сиражи. Аллага шөкер, Гани бай парахуттагыларга барын да төшендереп бирде. Миңа Хөсәеновның сүзләре бик тә ошады.

Сиражи-2. Гани бай шәп әйтте. Безгә патша дәүләте мәктәпләр, мәдрәсәләр салырга беркайчан да булышмады һәм булышырга уйламый да. Сез йөри торган мәчет-мәдрәсәләрне алдынгы карашлы байлар салдырган. Татар милләтенең киләчәге турында уйлаган һәр бай аз-маз гына өлеш кертсә дә, безнең халык бик тиз күтәрелеп китәчәк, дигәч, тегеләр чыгып ук киттеләр.

Сиражи. Элек мин үзем дә кара фикерле идем. Бүген күзем ачыла башлады сыман. Мә, Гани бай биргән бу гәҗиттә ниләр язганнар икән? Укы әле.

Сиражи-2 *(укып)*. Алтын приискасы хуҗалары Закир һәм Шакир Рәмиевләр мәдрәсәсен бетергән яшьләр Истанбулда укуларын дәвам итәчәкләр. Аларның барлык чыгымнарын Рәмиевләр үз өсләренә алды.

Сиражи. Минем ул байлар турында ишеткәнем бар иде. Алар үзләре яшәгән һәр җирдә мәктәпләр төзиләр икән, хатыннары да кызлар өчен мәктәпләр салдыралар, ди. Дөресме?

Сиражи-2. Дөрес, дөрес. «Вакыт» гәҗите белән «Шура» журналы да алар акчасына чыга. Бар эшләгәннәре милләт өчен.

Сиражи. Үзебезнең Казанда да бар инде андый байлар. Без алар кебек үк булдыра алмабыз шул.

Сиражи-2. Син курыкма, әздән башла. Иң элек мәчет салдыр, авылдан килгән ярлы балаларын укытырга булыш.

Сиражи. Гөлсылу каршы төшәчәк. Минем яшь хатын белән яшәвемне онытма. Берәр нәрсә аныңча булмаса, китү белән куркыта башлый.

Сиражи-2. Китсен. Ул надан хатын сиңа барыбер рәхәт күрсәтмәячәк. Бар тапканыңны җилгә очырырга гына тора. Ичмасам, халыкка файдалы эшкә тотарсың артык акчаңны. Исемеңне менә шундый гәҗитләргә язарлар. Сине бар татар дөньясы белер.

Сиражи. Шулай дисеңме?

Сиражи-2. Мин сиңа гади генә бистә кызын табып бирермен. Чиста күңеллене, сине хөрмәт итә торганны. Уйла.

Дүртенче күренеш

Сиражи өе. Гайникамал өй җыештырып йөри.

Гайникамал. Бүген бай абзый Мәкәрҗәдән кайта. Гөлсылу абыстай иртәдән бирле турсаеп йөри. Бигрәк тиз кайтты, рәхәтләнеп ял да итә алмадым, ди. Нинди ял инде аңа? Болай да көн туды исә, машинага утыра да чыгып чаба. Бай абзыйның

шуферы да туеп бетте инде. Кайтмыйча да калыштырды әле. Туган апаларда кундым, дигән була. Белмиләр ди аның кайда йөргәнен. Сиражи бай кызганыч.

Гөлсылу керә.

Гөлсылу. Җыештырып бетер дә аш әзерләүчегә булышырсың.

Гайникамал. Ярый, хуҗабикә!

Гөлсылу. Кара әле, Сираҗи сораштыра башласа, артыгын сөйләп ташлама. Авызыңны үлчәп ач, югыйсә эштән куармын. Барыр җиреңюклыгын онытма.

Гайникамал. Хуҗабикә, син Нәгыймә карчыкка да әйт. Аның теле бер дә тик тормый. Беркөнне син югында килде дә икенче асраудан сораштырып торды. Мин тыңлап тормадым, вакытым юк иде. Әнә үзе дә килеп җитте бугай. *(Чыга.)*

Гөлсылу. Җен карчыгы, тыгылмаган җире юк. Аның авызын акча белән томаласам гына инде. Сираҗи тикшереп торырга кушкандыр әле. Шул, шул. Ну, байлыгын кулыма төшерсәм, бер генә көн дә тормас идем. Япь-яшь көемә әниләр кушканга гына чыктым шул. Таш пулатта яшәрсең, машинада гына йөрерсең, имеш. Шуңа кызыктым.

Нәгыймә керә.

Нәгыймә. Исәннәрмесез! Бу араларда күренмәдең, авырмагансыңдыр бит?

Гөлсылу. Юк, туган апаларда кунакта булдым.

Нәгыймә. Алайса, минем күршем сине Бакыр бабай бакчасында ялгыш күргәндер инде.

Гөлсылу. Миңа анда ни калган? Икенче юлы күзен ачып карасын. *(Сандыгын ача.)* Нәгыймә абыстай, сиңа бүләк әзерләп куйган идем. Мә, бу күлмәклекне алып куй әле. Беркөнне бу йөзегемә дә кызыгып караган идең. Аны да сиңа бүләк итәм. *(Салып, карчыкка бирә.)* Кара, таман гына булды үзе. *(Читкә.)* Иң яраткан йөзегем иде.

Нәгыймә. И-и, бигрәкләр дә зурладың инде. Алланың рәхмәте яусын үзеңә.

Саквояж тоткан Сиражи керә. Гөлсылу, йөгереп барып, ирен кочаклый.

Сиражи. Чү-чү, аяктан егасың ич. Исән-сау тордыгызмы?

Гөлсылу. Сагынып беттем, җаным!

Нәгыймә. *(читкә).* Саргаеплар калдың шул инде.

Сиражи. Синең хәлләрең ничек, Нәгыймә абыстай? Нинди яңалыклар алып килдең? Мә, сиңа бераз күчтәнәчем дә бар иде. *(Төргәк тоттыра.)*

Нәгыймә. Рәхмәт, Сиражи улым! Бай бул! Хәлләр әйбәт, бар да син дигәнчә булды. Ярый, сезгә комачауламыйм. Китим әле, яңадан килермен. *(Чыга.)*

Сиражи. Гөлсылу, абыстайдан гарәп сабаклары алдыңмы?

Гөлсылу. Юк. Минем бала-чага укытып йөрисем юк.

Сиражи. Кызлар мәктәбе салдырам. Мин сиңа ышанып торган идем, җаным.

Гөлсылу. Әллә бар акчаңны шул әтрәк-әләм өчен тотмакчы буласыңмы?

Сиражи. Алай әйтмә. Бистәбездә мәчет белән мәдрәсә дә салдырам әле.

Гөлсылу. Акчабыз бетсә, ничек яшәрбез?

Сиражи. Акчабыз, димә, акчаң, диген. Син акча тапмыйсың ич. Сәүдәләр шәп бара, Гөлсылу. Акча бар. Мәкәрҗәдән дә шактый табыш керде. Алып кайткан товарны да яхшы бәягә алучылар җитәрлек. Булган табышның бер өлешен моннан соң мәктәп-мәдрәсәләр салуга тотармын, дип торам.

Гөлсылу *(үртәләп).* Яраткан хатыныңа бүләгең дә юкмы?

Сиражи. Бар, менә бу шкатулка сиңа.

Гөлсылу *(кәгазь чыгарып).* Бу нинди кәгазь? *(Укый.)* Аерылышу кәгазе ич бу.

Сиражи. Дөрес. Кайчан да булса гөнаһларың өчен җавап бирү кирәктер ич. Мин аларны исеңә төшереп тормыйм. Барын да җиткереп торалар иде миңа, тик моңарчы берәүгә дә ышанмадым. Бу юлы арттырып та җибәргәнсең икән. Мин синең хыянәтеңне кичерә алмыйм. Син ирекле. Бүген үк чыгып кит.

Гөлсылу. Китәм, мине акчалы кияү таба алмас дисеңме? Табам. Байлыгын читкә тараткан кеше кирәкми миңа. Яшә шунда бай хәерче булып. *(Чыга.)*

Сиражи-2 керә.

Сиражи-2. Афәрин, Сиражи! Әллә кайчан шулай кирәк иде. Күңелең тынычландымы? Син дөрес юлда. Яңа тормыш башлыйсың. Мәктәпләр, басмаханәләр төзетерсең. Татар халкы сине бик тиз таныр. Алдынгы фикерле Казан байлары белән аралаша башлагач, өр-яңадан туган кебек булырсың әле. Мин сиңа ялгышырга ирек бирмәм. Янныңа килгәләп йөрермен. Ярый, мин китим инде. *(Чыга.)*

Эпилог

Сиражи өендә исәп-хисап эше белән шөгыльләнеп утыра.

Сиражи. Тәк, тәк, унбиш меңен хәйрия фондына бирәм, калганына тауар алып кайтам, биш меңен шифаханәгә тапшырырга булыр. *(Сәгатен алып карый.)* Театрга барыр вакыт җитеп килә икән. Бүген анда Галимә мөгаллимә белән очрашам. Бик яхшылап сөйләшергә булыр. Өйләнешергә ул каршы түгел шикелле. Гайникамал, бирегә кереп чык әле?!

Гайникамал. Нәрсә, бай абзый, өстәл әзерлимме?

Сиражи. Рәхмәт, кирәк түгел. Минем өс киемнәремне әзерләдеңме?

Гайникамал. Әзерләдем. Театр билетын кесәгезгә тыгып куйдым.

Сиражи. Яхшы. Башка эш юк. Мин биргән китапны укып бетерергә тырыш.

Гайникамал. Ярый. *(Чыга.)*

Сиздермәстән Сиражи-2 килеп керә. Кулында газета.

Сиражи-2. Күрәм, эшләрең шәп бара. Бүгенге гәҗитне алдыңмы әле?

Сиражи. Күптән күренгәнең юк иде. Нинди хәбәр китердең?

Сиражи-2. Мә, укы.

Сиражи *(укып).* Казан бае Сираҗетдин Туктагаев, бистә мәдрәсәсен төзетеп бетерүгә, шәкертләр өчен тулай торак салдыра башлады.

Сиражи-2. Әйттем ич мин сиңа. Күр менә: исемеңне гәҗитләргә язалар. Казан халкы сине яхшы белә. Син хәзер бәлеш ашап, кунактан кунакка йөрүче Сиражи түгел инде, ә Казанның хөрмәтле кешесе. Әйдә, театрга киттек. Тамаша башланырга вакыт күп калмады.

Сиражи. Әйдә.

Чыгалар.

Пәрдә.

Гүзәлия Тарханова,
Казан шәһәренең 96 нчы номерлы гимназия укытучысы

ТЕАТР

Халыкка дәрсе гыйбрәттер[1] театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.

Театр яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.

Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

Күрерсең анда үз хәлең: көләрсең —
Көләрлек булса; булмаса — җыларсың.

Күрерсең: тормышың нинди, җитешме?
Җитеш булмаса, кай җире җитешми?

Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең[2], —
Шулай шактый белем тәхсил итәрсең[3].

Үсәр яхшылыгың, син яхшы булсаң;
Җылы канлы итәр ул, вәхши булсаң.

Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә — император.

Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул,
Тәмам хөр ул вә бик киң ул, азат ул.

Вә ул дарел-голүм[4], дарел-әдәптер[5],
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер.

Вәләкин шарты бар: яхшы төзелсә,
Әгәр һиммәт[6] агачыннан өзелсә,

Ул — алма, мөддәте тулганда[7] пешкәч,
Кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч.

---

[1] *Дәрсе гыйбрәт* — гыйбрәт дәресе.
[2] *Тәкмил итү* — камилләштерү.
[3] *Тәхсил итү* — белем алу.
[4] *Дарел-голүм* — белем йорты.
[5] *Дарел-әдәп* — әдәп йорты.
[6] *Һиммәт* — игелек.
[7] *Мөддәте тулу* — вакыты җиту.

ЭЧТӘЛЕК

Тәрҗемәи хәле 4

Шәҗәрә агачы 21

Галиәсгар Камал һәм аның варислары 24

Истәлекләр 26

Әсәрләр

Беренче театр 48
Бүләк өчен 62
Банкрот 72
Безнең шәһәрнең серләре 104
«Кызыл алма» китабы 142
«Бәдәвам» китабы 143
Татарга 145
Яңа «башмак» көе 146

Рецензияләр

Яңа әсәрләр («Мирза кызы») 147
«Помада мәсьәләсе» 148
«Хәкыйкатьме, хыялмы?» 149
«Үги балалар» 150
«Яшь гомер» 151
«Ачлык кушты» 152
Яңа әсәрләр («Яшьләр», «Кыямәт») 154
Мәрхүм Әхмәд Мидхәд әфәнде 155

Карикатуралар 157

Анализ үрнәкләре

Галиәсгар Камал иҗатына гомуми күзәтү. *Д. Заһидуллина* 158
Мәктәптә драма әсәрләрен өйрәнү (Г. Камал комедияләре мисалында). *Д. Заһидуллина* . 167
Галиәсгар Камал — диалог төзү остасы. *И. Абдуллин* 176
Галиәсгар Камалның юмор һәм сатира осталыгы. *И. Абдуллин* 183

Дәрес эшкәртмәләре

Галиәсгар Камалның татар драматургиясенә һәм театр сәнгатенә керткән өлеше. Комедия жанры үзенчәлекләре. *Г. Мансурова* 193
Г. Камалның «Банкрот» комедиясен мәктәптә өйрәнү өчен методик күрсәтмәләр. *Ә. Закирҗанов* 203
Г. Камалның «Банкрот» комедиясендә гаилә мәсьәләсе. *Г. Нурмиева* 209
Һәр чорның үз «Банкрот»ы («Банкрот» спектакленең яңа куелышы турында фикер алышу). *Г. Тарханова* 211
Афәрин, Сиражетдин! *Г. Тарханова* 215

Театр. *Г. Тукай* 222

Учебное издание

Серия «Ученик и учитель»

ГАЛИАСГАР КАМАЛ

Биография
Воспоминания
Произведения
Анализы
Поурочные разработки

Составитель
Шакирова Талия Ривовна

Казань. Татарское книжное издательство. 2014
На татарском языке

Уку-укыту басмасы

«Укучы һәм укытучы» сериясе

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ

Тәрҗемәи хәле
Истәлекләр
Әсәрләр
Анализ үрнәкләре
Дәрес эшкәртмәләре

Төзүчесе
Шакирова Талия Риво кызы

Мөхәррире *Г. К. Мансурова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Корректорлары *Г. Г. Габдуллаҗанова, Г. М. Хәбибуллина, С. Н. Галимуллина, Г. Г. Зиннәтуллина, Л. Р. Галимова*
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.11.2014.
Форматы 84×100 1/16. Шартлы басма табагы 21,84.
Тиражы 2000 д. Заказ А-3051.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете. Тел.: (843) 519-45-13.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

УКУЧЫ ҺӘМ УКЫТУЧЫ

Татарстан китап нәшрияты балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятына аеруча зур игътибар бирә. Ел саен нәниләр һәм мәктәп укучылары өчен төрле характердагы, төрле жанрларны, төрле максатларны күз уңында тотып әзерләнгән һәм серияләргә берләштерелгән китаплар нәшер итә. Моңа классик язучыларыбызның, бүгенге көн әдипләренең, яңа гына әдәбият мәйданына килгән яшь каләм ияләренең китаплары; «Нәниләргә бүләк», «Син мәктәпкә әзерме?», «Исәнме, мәктәп!», «Шәхесләр», «Рәсем ясарга өйрәнәбез», «Балачак энциклопедиясе», «Спорт», «Туган якны өйрәнү», «Кызлар энциклопедиясе» һ. б. дистәләгән яңа проектлар керә.

«Укучы һәм укытучы» сериясе — яңа һәм үзенчәлекле проект. Аның яңалыгы һәм үзенчәлеге шунда: әлеге сериягә кергән китапларда татар әдәбиятының классик язучылары турында мәгълүмат (тәрҗемәи хәле, шәҗәрә агачы, фоторәсемнәр, истәлекләр), аларның мәктәп программаларында урын алган әсәрләре, шул әсәрләргә анализ үрнәкләре һәм дәрес эшкәртмәләре бер җыентыкка туплап бирелә. Китаплар әдип яшәгән чорның рухын чагылдыру ягыннан да әһәмиятле.

Бу җыентыклар киләчәктә укучылар, укытучылар һәм татар әдәбияты белән кызыксынучы һәркемнең өстәл китабына әйләнер дип өметләнәбез.

9 785298 028059